# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1998





**Шамил Усманов**
*1898—1937*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

**12**

(914)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әхсән БАЯН. Салават күпере астында. *Шигырьләр* .......... 5
Мансур ШАҺИМӘРДӘН. Татлы агу. *Роман* .......... 11
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шәфәкъ аша таң ата. *Шигырьләр* .......... 47
Госман ГОМӘР. Шаһмиран. *Мажаралы повесть* .......... 55
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Тамгалы таллар. *Шигырьләр* .......... 95

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Мөхмүт ГАЛӘҮ. Яшәсен ипи белән суган .......... 99

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Тукайлар, Бабичлар юлыннан .......... 105
Равил БИКБАЕВ. Җыр башы. *Шигырьләр* .......... 106

ПУБЛИЦИСТИКА

Флүс ЛАТЫЙФИ. Чистаенда чистарындык, Туапседа тупландык. *Эссе* .......... 111

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Кече Кирмәннең олы Ринаты .......... 134

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Алсу КӘРИМОВА. А.М. Горький музее һәм татар әдәбияты .......... 142

ШАМИЛ УСМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Илдус ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Язучы - каһарман .......... 158

ТАРИХ

Рәис САФАРОВ. Төрки халыклар .......... 164

КАЙТАВАЗ

Тәэминә БИКТИМЕРОВА. Хәнифәме, Мәстүрәме? .......... 175

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ЖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕНӘ 60 ЕЛ

Лима КУСТАБАЕВА. Милли учак яктысы .......... 178

Безнең календарь .......... 180

Елмаеп-көлеп кенә .......... 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": окончание романа М. ШАГИМАРДАНА "Сладкий яд", повесть Г. ГУМЕРОВА "Шагмиран"; стихи А. БАЯНА, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ.
"Из сокровищницы татарской прозы": рассказ М. ГАЛЯУ "Даздравствует хлеб и лук". Предисловие Р. ФАЙЗУЛЛИНА к стихам Р. БИКБАЕВА.
"Публицистика": эссе Ф. ЛАТИФИ "Очистились в Чистополе, сплотились в Туапсе".
"Литературная критика": статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА к 50 - летию Р. Мухамадеева.
"К истории культуры": статья А. КАРИМОВОЙ "Музей А.М. Горького и татарская литература"; к 100 летию писателя Ш. Усманова статья И. ГИЗЗАТУЛЛИНА "Писатель - герой".
"История": статья Р.САФАРОВА "Тюркские народы", статья Т.БИКТИМИРОВОЙ "Кто такая Ханифа?"
Статья и фотоиллюстрации к 60-летиюГосударственного ансамбля песни и пляски республики Татарстан.
Наш календарь.
Юмор и сатира.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: древний тюрко-татарский календарь; литературовед Ф. Галимуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": the finishing of M. SHAGIMARDAN'S novel "The sweet poison"; story of G.GUMEROV "Shagmiran", verses of A. BAYAN, R. FAIZULLIN,F. GIZZATULLINA;
"From the tatar prose treasury": tale of M. GALYU "Long live to bread and onion."
A prefase of R. FAIZULLIN to verses R. BIKBAEV.
"Publicism": essay of F. LATIFY "Having cleaned in Chistopol and having united in Tuapse".
" Literary criticism ": the article of F. GALIMULLIN for 50 years anniversary of R. Muhamadeev.
"To the history of culture": the article of A. KARIMOVA "Museum of M. A. Gorky and tatar literature"; for 100 years anniversary of writer Sh. Usmanov, the article of I. GIZZATULLIN "Writer - is a Hero".
"History": the article of T. BICTIMIROVA "Who is she Hanifa".
The article and fotoillustration of State ensemble of song and danse of Tatarstan.
Our calendar.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the ancient turki-tatar calendar; writer F. Galimullin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.11.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 11338 Заказ Я-565
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Әхсән Баян

### САЛАВАТ КҮПЕРЕ АСТЫНДА

**Күзнең тын сурәте**

Китмәгезче, диеп ялварсам да,
Тезелешеп чылбыр шикелле,
Җәй артыннан калмый, юлга чыга—
Ерак юлга—казлар төркеме.

Язгы сөенеч, җәйге ямьнәр белән
Кай арада бер ел яшәлгән!
Күзгә күннәр сөенә алсын өчен
Инде кирәк сабыр аһәңнәр.

Илдән, җирдән китеп барган чакта,
Кирәк буламыни күп сүзләр!
Кошлар юлы олы максат тулы—
Исән кайтып, кабат күрешүләр.

Юлда, кошлар, афәт очрамаса,
Чылбырны сез үзегез өзмәссез!..
Өметләрнең, күзнең тын сурәте
Канат җилпи—сүзсез, күз яшьсез.

*1966 /97/*

* * *

Яманга юл саба кояш,
Яхшыга да шул кояш.
Күтик, килер акылга, дим,
Гел битараф булалмас.

Тик илләр бозык чагында
Юллар төзек калалмас.
Көтикме юл салышырга
Килер дип безгә алмаш?

Төзәтә башлыйкмы юллар,
Заманны төзәтмичә?
Ничек юллар салыйк, кая
Илтәчәген белмичә?

Кая китте кыйбла? Ул бит
Бар кебек иде кичә?
Ә иртәгә? Узар, ахры,
Ул да нәкъ бүгенгечә.

*1993*

## Сәмруг кош

Мин Сәмруг кош бугай...
Бирде Ходай,
Игелеген күр дип, мул ризык.
Бирде Ходай, амбар тутырып, бодай—
Йөз ел, мең ел яшәп булырлык.

Бөртекләрне саный белмәдем тик,
Җилгә чәчтем гүя яртысын.
Ризык кадерен, вакыт кадерен белү
Аңга җитте килеп артык соң.

Инде күрәм: бодай бөртекләре
Көшел-көшел түгел амбарда.
Биниһая төсле ризыкны да
Кирәк икән уйлап кабарга.

Һәм кабарсың көнгә син өч бөртек.
Һәм бер бөртек таман тоелыр.
Һәм соңгысын йотмый сакларсың син.
Һәм шул килеш күзең йомылыр.

Еллар, еллар күпме калдыгыз сез
Гомер дигән серле амбарда?
Тиеш бугай бодай бөртекләрен
Син берәмләп инде санарга.

*1997*

## Байлыгың

“Елларым—байлыгым!”—диеп,
Җырлаганнар хаклыдыр.
Яшәлгән елларны җыйсаң,
Хәзинәләр чаклыдыр.

Кайсын алтын, кайсын көмеш,
Кайсындыр бакыр дидем.
Бик ялынып сорасалар,
Бәхәссез сатыр идем.

Сатыр идем. Акчасызга
Бушлай өләшер идем.
Бәлки шулай юмарт диган
Данга өлгәшер идем.

Йә, кем ала?! Әллә бәя
Төшерик тагын дамы?
Кыйбатка түгел, бушлай да
Алучы табылмады...

Нишлик? Шулай җуябызмы
Елларның без барлыгын?
Булсын, калсын хак байлыгың—
Эшең, исемең, саулыгың.

*1997*

## Бозлар аккан чакта

Казансуда бозлар аккан чакта,
Кыйгак-кыйгак казлар кайткан чакта,
Тарих катламнарын вата-вата,
Су төбеннән риваятьләр калка.

Дәрья төсле еллар агып ята,
Карашларны гасырларга тарта.
Табан белән карап өске якка,—
Каткан бозга,—ага иске ката.

Ә янында төссез бүрек ята,
"Башлар кайда?"—диган уй кузгата.
Башлар әллә калка, әллә бата...
Әрәмәдә кемдер мылтык ата.

Һәйкәл булып, баһадирлар кайта,
Аларга тиң ирләр, кызлар арта.
Су төбеннән риваятьләр калка,
Каңгылдашып казлар кайткан чакта.

Бозлар аккан чакта.

*1994*

## Көч билгесе

"Чор—безнеке!"—диеп күкрәк кагу
Синең көчкә дөрес билгеме?
Диңгез кыслалары океаннарда
Тусалар да йөзә белми бит.

Тау куышы хөрлек була алган,
Хәнҗәр тоту ирлек булалган.
Инде яман кулдан хәнҗәр тартып
Алганнарны көтә бу заман.

Җай чыкканда кысу, чәнчү, тырнау
Кыслалардан сиңа күчкәндер.
Үз намусын чор шәһрәте иткән
Көч билгесе ләкин бүтәндер...

*1975 /98/*

## Өч дәһшәт

Ут. Су. Хатын-кыз.
Көн саен
Янап торган өч дәһшәт.
Тап шулардан гүзәлрәкне,
Кадерлерәк, кирәгрәкне—
Кара шуларсыз
Яшәп!

*1994*

## Бәет

Мәхәббәт мине күккә очырды.
Мәхәббәт мине атып төшерде.

Туялмыйм тиргәп күзең-кашыңны,
Шулар ашады газиз башымны.

"И ялгыз башым, и тыныч ашым!"—
Шулай дип, тыныч түгелә яшем.

Сау бул, хуш, сиңа бәхетләр телим,
Үз бәхетемне уйлый ук белмим.

Күргәч көлсәм дә, син бел, инде мин
Мәхәббәт өчен тере түгелмен.

Үпкән-кочканга йомгаклар ясыйм,
Мәхәббәтемә чыгамын ясин.

Көям тик шуңа: табынып сиңа,
Кемдер бит тагын булачак фида!

Дуслар, сөегез, һич итмәм гаеп.
Ә мин гыйшкыма чыгардым бәет.

*1997*

## Мин—җил түгел

Тәрәзәмне ник кагасың,
Бармы, җил, әйтер сүзең?
— Мин—җил түгел, яшьлегеңне
Алырга килгән көзең.

Син тагын, тагын килгәнсең,
Тәрәзәмне кагасың.
— Мин—кышың, килдем алырга
Чәчләреңнең карасын.

Нишләп әле бик ешладың,
Ник ашыгасың артык?
— Мин—уең синең, мин—Вакыт.
Кара—мине туктатып!..

*1998*

* * *

Бергәлеккә артык күнеккәнгә,
Җуйды бугай төсен мәхәббәт.
Яңарышлар әллә кирәк булды,
Ялгышлармы булды бик хаҗәт...

Аерылганда очы селкенмәде
Күкрәгеңә төшкән яулыкның.
Нишлик, нишлик, тик югалгач кына
Белгәбез бит кадерен саулыкның.

Тыныч агыш, уртак сагыш белән
Вакытлыча диеп хушлашкач:
"Коткар!"—диеп беребез салыр аваз,
Кире кайтыр юлны югалткач.

*1985 /95/*

* * *

Яшел чагын юксыныптыр,
Уйчанланды урман-кыр.
Моңланды болыт, яшенле
Күкрәүләрен уйлаптыр.

Җитезлекне алгандырмы
Җор куян баласыннан.

Узып китте яшь чибәр кыз
Куаклар арасыннан.

Елмаеп кул болгавыннан
Хушлашканы сизелде.
Сөюме китте ашыгып,
Әллә гомер үземе?

*1998*

* * *

Йөрәккәем, басыл инде,
Ашкыну тиеш түгел.
Күршеләрдә пешкән җиләк—
Ул синең җимеш түгел.

Тынычлан, болай ымсынма
Ят бакча җимешенә.
Булды, җитте, җитте, кермә
Яшь көннәр өлешенә.

Тыңла, зиһен киңәш бирә—
Киңәшнең иң дөресен.
Аның сүзен тыңлый белсәң,
Тигезләнер тибешең.

Тыңла, һич тә ялгышмыйча
Йөри сәгать, келт-келт дип.
Үзеңә дигән вакыттан
Булмый узып китеп дип.

Ияр минем йөрешемә,
Бу иң дөрес йөреш дип.
Дөрес, дөрес! Тик безгә шул
Кирәк түгел дөреслек.

Кирәк түгел.

*1998*

## Салават күпере астында

Кояшны болытлар каплагач,
Күк йөзе, яшеннән чатнагач,
Коелып төшкәндәй тоелды.
Ә дөнья шатлыкка коенды.

Шатлыклар күкләргә ашты да,
Кояшлы уй туды башымда:
Әйдәгез, туганнар, җыйналыйк
Салават күпере,
Салават күпере астында.

Ул күпер—офыктан-офыкка,
Офыклар тоташкан дуслыкка.
Бер якта кыялы таулардыр,
Бер якта киң сулы ярлардыр.

Ярларны, тауларны бәйләгән
Киңлектә без җәйләр җәйләгән.
Бергәләп сайрашкан сабанда.
Бәйрәмнәр гел бергә һаман да.

Салават күпере төсләре
Күкләргә ирешкән хисләрдер.
Чирәмдә сабыйлар йөгрешә.
Бәйрәмдә безгә дә килешә.

Шатлыклар күкләргә ашты да,
Кояшлы уй туды башымда:
Җыйналыйк Тәңребез каршында,
Салават күпере,
Салават күпере астында!

*1998*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Мансур
Шаһимәрдән

# ТАТЛЫ АГУ

РОМАН

## Бишенче башлам

Август азакларында Рәсимә белән Сөләйманның эшләре мөшкелләнә башлады. Аларның эзләренә төштеләр дә әйбәтләп тикшерергә керештеләр. Шуннан... кулга да алдылар. Чөнки Сөләйман белән Рәсимә базардагы кара кешеләр контрабанда юлы белән китергән товарларны аткарып, Казан халкын юлдан яздырырга маташуда гаепләнәләр иде. Әлбәттә, тикшерү барышында Кадрияне дә читләтеп үтмәделәр. Кем? Кайдан килгән? Ни өчен килгән?—барысын да төпченеп, жентекләп, кат-кат сораштырдылар. Шул вакытларда Кадриянең "мине дә кулга алалар, утырталар ахыры" дип коты очты, яшисе килми башлады. Әмма тикшерүчеләр Сөләйман белән Рәсимәне биек, калын тимер капка артына яшереп куйсалар да, Кадриягә орынмадылар. Гаеп тагарга дәлилләре житенкерәмәде булса кирәк. Шулай да Кадриянең тынычлыгы качты.

Бервакыт базарга барган иде, шунда һичкөтмәгәндә аны курку алды. Тиктомалдан гына, сәбәбен үзе дә белми шүрләргә керешге. Аннары ул җилкә чокырында нәрсәдер тоеп, борылып караган иде, эшләпә кигән ике таза кешенең аңа төбәлеп торуларын искәрде. "Димәк... күзәтәләр", дип уйлады ул һәм базардан тиз-тиз генә китеп барды. Шуннан элеге базарга бүтән бармады Кадрия. Әмма... күңеленә, йөрәгенә сеңеп калган курку барыбер бетмәде, кимемәде дә; аны иртән-кич, хәтта төнлә дә эзәрлекли бирде.

Аптырагач, йөдәгәч хатын чәчләрен карага буятты. Өйгә кайткач, көзге каршына килеп баскан иде, имәнеп китте: көзгедән аңа әллә нинди ят бер яшь ханым карап тора. Ай, әрәм булды алтын-сары чәчләрем, дип чак-чак кына елап җибәрмәде Кадрия. Аннары, күзәтү астында яшәгәнлеге исенә төшкәч, уйларыннан кире кайтты, кабат көзге каршына килде. Әйе шул, миңа кара чәч тә килешә, хәтта бик-бик килешә икән, дип сөйләнде. Ләкин бераздан... сул бите ай, уңы кояш ханымның йөзе кинәт кара болыт каплаган сыман булды. Чөнки алтын-сары чәчкә яраштырып сатып алган кием-салымның күбесе хәзер шомырт-кара чәчкә тәңгәл түгел иде. Димәк, өскә янә кием-салым мәсьәләсе калкып чыга! Димәк... элеккечә яши башларга, яңадан-яңа бәйләнешләргә керүдән дә тайчанмаска кирәк. Чөнки, элеккеге мул бүләк бирүчеләрнең күбесе белән инде ара бөтенләйгә өзелгән, алардан нәрсә дә булса өмет итү— күктәге торнага адарынып яшәүгә бәрабәр ул! Мөбарәк? Ай, ул бигрәк

---

Ахыры. Башы журналның 11 санында

тә кәмит кеше булып чыкты әле. Бер авылдан үзе. Күрше житмәсә. Мәхәббәтемне кабул итте, миңа өйләнде. Хәер, миңа өйләнеп яшәве дә шундый әкәмәт булды инде аның. Өйләнгән башы белән ялгыз— әтиләрендә, мин—әни янында, балалар—детдомда: тормыш диген инде шуны?! Аннары, калага яшәргә килгәч тә... Әй, яшәдемени ул монда, андый яшәү буламыни?! Менә мин ичмасам! Дөрес, бу корсакны белендерми яшәп булмый инде хәзер. Чөнки ул бар! Һәм... матур яшәргә комачаулый да! Әй, теге вакытта абортка керәсе калган аны... һаман шул Мөбарәк инде: тап, бусы кыз булыр сыман, диде. Ә үзе... Ну, болай буласын белгән булсам-м...

Кадрия һәркөнне диярлек, эшкә барганда яки кайткач, көзге каршына килеп баскан чакларда әнә шулай үз-үзенә сөйләнә: Мөбарәкне битәрли. Әмма... Мөбарәк каршында үзенең тау чаклы гаебе барлыгын аңларга теләми. Аңласа, ул ирен эзләп табып, аның алдына тезләнеп гафу сорар, ярлыкавын үтенер, бәлки, Мөбарәк хатынын кичергән дә булыр иде. Ләкин, юк шул, Кадриядә мин-минлек куәтле, тәкәбберлек көчле. Ул әле һаман да үзен Казанның беренче чибәре итеп саный...

Мәгәр көзгедән үз-үзенә карап күпме генә сокланма, хатын-кызлар арасында булганда алардан үзеңне зифарак та, чибәррәк тә, сөйкемлерәк тә итеп күпме генә хисаплама—әгәр дә шул өстенлекләреңне танып, тирә-юньдә сиңа чын күңелдән игътибар юнәлтүче һәм мәдхия укучы табылмаса, синең бу "өстенлекләрең" кемгә хажәт?!

... Мөбарәксез яши торгач, Кадрия, ниһаять, бер нәрсәгә төшенде: чит-ятларга Кадрия үзе түгел, аның тәне генә кирәк икән! Алар бүләкфәләнне дә аның сылулыгына, гүзәллегенә мөкиббән китүдән түгел, бары тик... тәнен татыган өчен генә бирәләр икән! Болайга киткәч, Кадрия кем булып чыга инде?! Тән сатып бүләкләргә тиенү—фәхишәләргә генә хас шөгыль бит ул! Ә Кадрия?! Ә Кадрия үзен һич кенә дә фәхишәгә санамый иде. Мөбарәк янәшәсендә булганда шулай иде. Ул әшәке сүзне хәтта уена да китереп карамый иде. Аннары, ул чакта Кадриягә карата бүтән ирләр дә ягымлы, илтифатлы һәм кешелекле мөнәсәбәттә иде бит! Соңыннан, Мөбарәк юкка чыккач, шул ук кавалер-ирләр Кадриягә фәхишәгә караган кебек кенә карый башлаганнар икән ич! Аһ...

Менә шул фикерләр күңеленә килеп, нәфис тәненә тигәнәк шикелле сырышкан майлы карашлы ирләрнең битлегән салдыру мәртәбәсенә ирешкәч, Кадриянең бу икейөзле, хәйләкәр, алдакчы дөньяда бер генә көн дә яшисе килми башлады.

Башта ул суга ташланып үләргә карар итте. Шул ният белән байтак вакыт Болак тирәсендә уралды. Мондагы суның әшәке һәм сай икәненә тәмам инангач, Кабан күле буенда болганып-тулганып йөрде. Инде хәзер сикерәм, бусында, әлбәттә, ташланам, дип, тәвәккәлләргә генә торганда, исенә йә авылда калган әнисе, йә детдомдагы малайлары төшә дә, юк әле, башта әни янына кайтып килим, аннары малайларым янына барыйм, дип, әнисе янына кайтып китә, аннары, билгеле инде, малайлары янына юл тота!

Ә берсендә... малайларын күрергә барса, коточкыч хәбәр аны аяктан ук егып салды. Малайларның берсе вафат булган, аны Архангель зиратына күмеп үк куйганнар икән инде. Нидән? Ни сәбәпле?! Бусына төгәл генә җавап бирүче булмады. Мәгәр малайның ашап утырганда кинәт катып китүе, егылуы һәм... ясалма сулышның да, уколларның да ярдәм итмәүе хак иде!

Кадрия исенә килеп, торып йөри башлагач һәм... малаеның үлеме белән килешкән сыман булгач, аңа детдом врачы бик мөһим хәбәр ирештерде. Игезәкнең сыңарын, ягъни исән калганын тәрбиягә алып үстерергә теләүче парлар бар икән. Бик әйбәт, бик ачык, кешелекле кешеләр, ди. Үзләренең балалары юк икән.

— Ул кешеләр кайдан?—дип сорады Кадрия.

Врач ханым кирәкле кәгазьләрне алып килеп күрсәтте.

Кадриянең башка чарасы юк иде, килешкәнен белгертеп, ым какты.

— Алайса менә монда кул куегыз!—диде врач ханым.

Кадрия авыр итеп сулады да күрсәтелгә[illegible]ынга кулын куеп җибәрде.

Менә шулай... Игезәкнең сыңары гаилә җылысын тоеп үсәчәк хәзер. Үсәчәк! Моның шулай икәнлегенә Кадриянең иманы камил!

Әмма Кадриянең үз язмышы билгесез кала әле. Киләчәккә юлы өзелгән, өмете киселгән. Мескенлектән арынырга, җитешсезлекләрне төзәтергә, биеккә күтәрелергә ул үзендә көч тә, теләк тә таба алмый инде.

Учакны бер сүрелсә тиз генә кабызырмын димә. Кеше дә бер бетә икән.

Кадрия күңеленә ныклап кереп утырган теләген тормышка ашырыр өчен Казансу яннарында да болганып алды. Әмма ни ярдан ташланырга, ни дамба күпереннән сикерергә йөрәге җитеп бетмәде. Сикерсә дә, ташланса да суны колач җәеп йөзеп чыгар иде әле ул. Бата башлагач үләсе килмәс иде. Хәер, кем белә... Менә шул соңгысы, билгесезлеге өркетә дә инде Кадрияне. Әле бит аның эчендә озакламый бу кабих дөньяга аваз салачак нарасые бар! Аның гомерен алай уптым-илаһым гына ничек өзмәк кирәк, йә? Аннары, Кадриянең әнисе ялгыз калачак. Тагын... бу йомры күкрәкләргә, зифа буйга, нәфис аякларга ымсынучы... әй, юк ла, миңа инде андый ир-затларының поты бер тиен! Мин аңладым инде хәзер... Мине бары тик авылдашым, күршем Мөбарәк кенә чынлап сөйгән, чынлап яраткан икән! Шулай булмаса, ул миңа атап җыр иҗат итәр идемени? Ә җыры... җыры нинди бит әле аның:

Үтеп барган чакта
Төп-төз генә атлап...

Кадрия шулай җырлый-җырлый, елый-елый тәвәккәлләп агу эчте...

Аннары аның белән ни булган? Егылып яткан төштә аны кем башлап күргән һәм... Юк, Кадрия инде боларын белми. Ул уянып күзләрен ачканда, ягъни кабат бу дөньяга әйләнеп кайтканда—хастаханәнең реанимация бүлегендә, нинди апаратлар янәшәсендә ята иде.

Шуннан соң да Кадриянең тормышы өчен көрәш тукталмады әле. Хәер, монда Кадриянең гомере өчен генә түгел, аның корсагындагы баланы исән-имин саклап калу өчен дә врачлар кулларыннан килгәннең барысын да эшлиләр иде.

Кадриянең нигәдер аларга ачуы чыкты. Ул иң беренче күзенә чалынган ак халатлы чибәр туташка:

— Мине исән калдыру нигә кирәк булды сезгә?—диде.

Туташ аппаратка карый-карый журналга нәрсәләрдер язып торган җиреннән башын күтәрде:

— Үләргә беркайчан да соң түгел, яши алганча яшәгез әле, дөнья әнә нинди матур, нурлы бит!—диде.

Кадрия мөләем йөзле туташ белән килешеп:

— Әйе шул, дөнья нурлы, дөнья матур,—дип, як-ягына карана-карана уйланды. Аннары, янә мөшкел хәле исенә төшеп, күңелсез хисләргә бирелде. Ярый, аны исән калдырдылар, ди. Көннәрнең берендә ул моннан терелеп чыкты ди. Шуннан?!

Юк, ул инде хәзер элеккеге тормышына әйләнеп тә карамаячак! Ә яңа тормышы нинди булыр, кайсы эздән, нинди сукмактан башланыр—шайтан белә! Ләкин шулай да Кадрия бер нәрсәне ачык аңлый: ул инде ирләргә моннан соң сылу, нәфис тәненең ләззәтле мизгелләрен татытыр өчен генә табынмаячак! Юк! Ир-егетләр аның тирәсендә моннан соң назга сусап, ләззәт теләнеп, бөтерелеп, ялынып-ялварып, хәтта үрмәләп йөриячәкләр әле! Кадрия хыялы белән артыграк мавыгып китеп, элекке сөяркәләренә нәфрәтләнеп, телен күрсәтте: "Менә сезгә!" Моннан соң җир йөзендә Кадрия дигән кеше булмас инде, аның исен дә, эзен дә таба алмассыз! Ул, кайчандыр ки, бу кабих дөнья белән араны мәңгегә

өзәргә карар иткән икән, ошбу карар әле үз көчендә кала: Кадрия аның белән араны барыбер өзәчәк! Ләкин башка ысул кулланып!

Кадрия уйларыннан арынып, каршыдагы ятакка төбәлгән иде, кинәт сискәнеп китте, аннан аңа соры күзле, коңгырт бөдрә чәчле бер ир-егет карап ята иде.

Кем ул? Монда ни өчен ята, нинди сәбәп белән?!

Бу сорауларга җавапны Кадрия шәфкать туташыннан сорашып тапты. Әлеге егет чуаш милләтеннән икән! Финанс-икътисад институтының соңгы курсында укый, ди. Әтисе—андый-мондый гына кеше түгел—райком секретаре, имеш. Ә егетнең бирегә килеп эләгүе—юлда, үз машинасында авариягә очрау аркасында икән...

Шулай да Кадриянең эченә жылы кереп китте. Ул бит бу реанимация дигән сәер исемле бүлмәдә әллә кем белән түгел, ә райком секретареның студент улы белән кара-каршы ята...

Әгәр дә Кадрия агу эчеп,—тьфү-тьфү,—бирегә килеп эләкмәгән булса, кайда күрер иде әле бу реанимация дигән нәрсәне һәм кайда очратыр иде—муены, куллары, күкрәге марляга чорналып беткән райком секретаре малаен?!

Язмышына рәхмәт инде: исән дә калды, аннары әнә... соры күзле, коңгырт бөдрә чәчле кардәш чуаш егете көннәр буе аны күзәтеп ята. Хәле җиңел түгел, билгеле. Әмма шулай да ул, Кадриядән сокланулы күзләрен ала алмый, гел карый да карый. Димәк, ул егет Кадриядә нидер тапкан! Әйе, әйе...

Көннәрнең берендә—бүлмәдә беркем дә юк чакта—егет Кадриягә дәште:

— Исемең ничек синең?

Кадрия әйтте.

— Ә минеке Василий,—диде егет.

— Әтиең райком секретаре, иеме?!

— Кайдан беләсең?

— Мангаеңа язылган!

Егет, "Минем турыда мәгълүматлы икән инде бу" дип уйлап булса кирәк, һич көтмәгәндә:

— Бездә—Николаев! Ә сездә кем бар!—дип көлемсерәде.

— Ну... Муса Җәлил,—диде Кадрия.

— Муса Җәлил касманаут түгел ул. Николаев касманаут! Чуаш касманаутлы милләт!..

— И-и... әйтәм аны... үзең дә чак-чак кына кусмыска очмый калгансың, шуңа икән!—дип елмайды Кадрия.

Василий эндәшмәде, иреннәрен тешләде; аның карашы моңсуланып киткән иде: күрәсең, ул үзе турында исенә төшергәнне яратмый иде. Әлбәттә, нечкә сиземләве белән, Кадрия моны колагына киртләп куйды һәм... сүзне шунда өзде. Аннары ул Василийга игътибар итмәскә тырышты. Кайчакта карашлары очрашса да, күзләрен тиз генә икенче урынга юнәлтергә ашыкты. Бу исә Василийны ярсыта, ачуын чыгара иде. Әйе, әллә кайдан сизелеп тора шул, Василийга Кадрия бик-бик ошый! Анын бу гаҗәеп чибәр, сөйкемле хатын-кызны... үзенеке итәсе килә!

Кадрия исә, гадәттәгечә, егеткә игътибар итмәскә тырышып үз уйларына чумды:

"Һич юк! Чәчең белән аякларымдагы тузанны сөртсәң дә... Минем бит сылу, нәфис тәнем генә түгел, моңлы йөрәгем, нечкә күңелем, газизләрдән газиз җаным да бар! Шулай егетем, синең дуамал теләгеңне канәгатьләндереп кенә миңа бу тормышта җиңеллек килмәячәк!"

Василий:

"Инде... нишләргә тиеш мин?!"

Кадрия:

"Машинаны идарә итәр өчен, йөртүче таныклыгына ия булу гына җитми, машинаның үзенә дә ия булырга кирәк!.."

Василий:

"Һм-м-м... Каты чикләвеккә охшагансың охшавын да, ләкин безнең тешләр нык, әллә нинди каты чикләвекләрне дә ваткан бар, алай бик масайма әле!.."

Шулчакны бүлмәгә ак халат кигән юан гына, зур гына гәүдәле, ыспай кыяфәтле бер ир килеп керде. Култык астына кавын, карбыз кыстырган, кулына тәм-том тутырылган капрон букча тоткан. Ул Кадриягә сәер итеп кенә карады да, врач урындыгын алып, улы янәшәсенә килеп утырды.

Аларның сөйләшкәннәрен тыңламас өчен Кадрия читкә борылды. Шуннан йоклап та киткән...

Уянып күзләрен ачканда ул янындагы урындыкка куелган кавын, карбыз телемнәрен һәм... тәм-том күрде. Шундук каршындагы ятакка төбәлде. Василий аны күзәтеп ята иде. Сылукайның үзенә тутырып каравын искәреп, егет телгә килде:

— Синең өлеш алар. Аша!—диде.

Кадрия баш тартырга мәҗбүр булды.

— Татлы әйберләр күрсәтеп мине азаплама, зинһар, барыбер сатып ала алмассың!—диде.

Василий гаҗәпләнгән сыман кыланды:

— Ба-а, нинди тәкәббер кыз! Кем әле сине сатып алырга җыена? Мин бары тик сиңа күчтәнәчләрдән өлеш чыгарырга гына теләгән идем.

— Әйе, беләм мин күчтәнәчтән ничек авыз иттерәләр икәнлеген. Башта сыйлаган булалар, аннары...

Василий елмайды:

—Авызың пешкән икән инде бер, димәк. Ләкин миннән юкка шикләнәсең, ефәгем. Мин андый бәндәләрдән түгел: аша, аша!

— Мин... ашармын да... Әмма соңыннан боларның әҗерен сиңа ничек кайтарырмын соң?!

— Мин әҗер сорамыйм бит әле синнән. Бары тик ашарга гына тәкъдим итәм!

— Ярый алайса,—дип Кадрия кавын телеменә үрелде,—күчтәнәчләреңне ашыйм ашавын, ләкин бел, үземне сиңа ашатмыйм...

Василийның колакларына тикле кып-кызыл булды.

— Мин анысын ук сорамадым бит әле синнән,—дип ул карашын, ниһаять, читкә юнәлтте. Әмма озакка түгел...

Менә шулай башланды аларның танышып, бер-берсе белән кызыксынып китүләре. Аннары Василий белән Кадрия реанимациядән төрле палаталарга күчерелгәч тә, ашханәдә очрашканда яки дәвалау бүлмәләрендә врачка күренергә чират торган вакытларда гел бергә булырга тырыштылар. Әлбәттә, сүзләре һаман төртмәле, чәнечкеле булып, болай сөйләшү аларга бик ошый иде. Бер кичне Василий Кадрияне палатадан чакырып чыгарып аулак урынга алып китмәкче булды.

Кадрия олы корсагына ымлап:

— Шушы килешме?—диде.

Василий елмаерга тырышып:

— Ә безгә бу... комачауламаячак!—дип җавап кайтарды.

Кадрия кинәт дөрләп кабынып:

— Мин бит... кавыннарыңны ашаганда әйттем: "Боларның әҗерен кайтара алмыйм, и... үземне дә ашатмыйм!"—дидем. Әйттем бит?!

— Ну, әйттең инде, әйттең,—диде Василий гадәттәгечә куе кызыл төскә кереп.—Сине ашарга җыенган кеше юк ич әле!

— Алайса ник мине анда кодалыйсың, монда гына сөйләшеп торырга ярамыймы?!

Василий ык-мык итте:

— Монда бит... әнә... аяк асты... уңайсыз...

— Ояласыңмы? Шулай... Мин бала анасы булачак кеше, кияүдәге хатын, ә син өйләнмәгән егет! Оялырсың шул атаң җиткерсәләр?!

— Причем монда әти? Гомумән, мин үземә баш, үземә аяк! Ә ашау мәсьәләсенә килгәндә, мин бик талымлы егет, ефәгем. Аннары, синең турында байтак нәрсәләрдән хәбәрдар инде. Монда ни сәбәпле әләгүеңне дә...

— Җитте, кирәкми бүтән!—дип кычкырып куйды Кадрия. Минем ирем бар!—һәм кереп китмәкче булды.

Мәгәр Василий көмәнле килеш тә күз явын алырдай чибәр ханымның шулай эшлисен сизеп, нәфис кулларыннан тотып алды:

— Юк синең ирең! Юк!

— Бар дим, бар! Җибәр кулларны!

— Кем ул? Әйтсәң...

— Аның исеме Мөбарәк!

— Мө-ба-рә-әк?

— Әйе.

Василий нигәдер диварга сөялде:

— Таныш исем! Шундый берәүне беләм мин.

— Әй, Мөбарәк исемле кеше беткәнмени дөньяда! Төсе-кыяфәте нинди иде соң аның?

— Анысын син әйбәт беләсең инде, ефәгем! Аның икенче исеме дә бар бугай әле. Мөшәрәф!

Кадрия Василийның муеныннан кочаклап алганын тоймый да калды:

— Син аны кайдан беләсең, җаным?! Кайда күрдең? Кайда очраттың?

Василий шушы илаһи мөмкинлектән файдаланып, әкрен генә Кадриягә елышты, билләренә кулларын салды:

— Элек үбешик!

Кадрия Василийны этеп җибәрде:

— Менә анысы булмас инде! Сез шул хатын-кызның йомшак чагыннан файдаланып калырга гына торасыз. Барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән нәрсәләр сез!—дип кереп китмәкче иде, Василий озын буе белән аның каршына килеп басты, юлын бүлде:

— Ефәгем! Мин шаяртып кына бит. Ә Мөбарәк-Мөшәрәф бүгенге көндә төрмәдә утыра!

Кадрия үзе дә сизмәстән Василийга таба борылды:

— Ни-чек?!

— Ярый, тыңла...—Василий бер чирле хатынны җитәкләп үтеп киткәннәрен көтеп торды да, кулларын артка куеп диварга сөялгән килеш, ашыкмый гына сөйләргә керешге:

— Минем әтинең кем икәнлеген яхшы беләсең инде, ефәгем— татар-урыс районының хуҗасы, ягъни падишаһы ул! Менә шулай, ефәгем... Синең туксан тугызлы Мөбарәгең Казаннан табан ялтыраткач, минем әтигә тезләнүче районның Муки дигән урман хуҗалыгына килеп, шундагы бер куе урманга каравылчы булып урнаша. Бу тилене алалар, әлбәттә. Шул көннәрдә генә райүзәктән яшертен хәбәр алына: "Фәлән-фәлән көнне, фәлән урманыгызга падишаһ үзенең әшнәләре белән ау сәфәренә кузгалачак. Көтегез!" дип.

Көтәләр, билгеле. Әле ничек кенә көтәләр биредәге әтрәк-әләмнәр. Падишаһның ау сәфәре уңышлы чыксын өчен, кулларыннан килгәннең барысын да эшлиләр. Якын-тирә урманнардан өстәмә пошилар, кыргый кабаннарны куып китерәләр! Аннары—алтын әйберләргә биһуш, акчага мөкиббән озын торыклы, кара, сары чәчле, коңгырт, зәңгәр күзле кызларны...

Менә шулай, ефәгем... ошбу сәфәр күңелле генә башланып китә дә, азагы күңелсез генә бетеп куя! Барысына да районның ач күз прокуроры белән профсоюз комитетының гуж тамак рәисе гаепле! Икесенә бер маржа кызын бүлешә алмаганнар бит, тинтәкләр, беткәнмени инде шунда чибәр-чибәр татар кызлары!

Шуннан менә шул, профсоюз рәисе—ике, ә районның прокуроры өч тешеннән колак кага! Шуннан эш зурая-бүселә, судка ук барып житә, ефәгем!

Ә судта гаепләүче—прокурор үзе! Хәер, хөкем җәтмәсен бик оста, бик хәйләкәр үрә алар. Закон үз кулларында бит, нигә файдаланып калмаска! Шуннан... җәтмәгә профсоюз комитеты рәисе килеп капты дип уйлыйсыңмы, ефәгем? Ялгышасың алай уйласаң. Һичкайчан карга карганың күзен чукымый. Бу—аксиома! Ә менә җәтмәгә бер гаепсез кеше килеп эләгә. Ул—ахмак Мөбарәк. Ни өченме? Чөнки, Мөбарәк урман каравылчысы буларак үз вазифасын тиешенчә башкармаган имеш. Ягъни, әлеге дә баягы урманда кабан дуңгызларының нормадан артык үрчүләренә юл куйган; бу хәлне белә торып та тиешле органнарга вакытында хәбәр итмәгән: нәтиҗәдә, азган-тузган кабан дуңгызлары прокурор белән профсоюз комитеты рәисе утырган машинага һөҗүм итәләр... Иң соңыннан, судья чыгарган карар буенча, Мөбәрәгең, ефәгем, дүрт елга ирегеннән мәхрүм ителә!

— Менә шулай...—дип сүзен очлады Василий,—Мөшәрәф-Мөбәрәгең тү-тү...

Райком секретаре улының әлеге сүзләреннән соң Кадриягә нигәдер җиңел булып китте. Әйе, күптән, бик күптән билгеле иде инде Мөбарәк белән нәрсә дә булса булачагы! Менә булган инде, Мөбарәк теләгенә ирешкән—элмәккә барып үзе башын тыккан, Вася әйткәндәй, тиле!

Шушындый уйлардан соң Кадриягә тагын да җиңелрәк булып китте. Ул йөрәгенең сулкылдаудан туктавын, күңеленең бушануын, җанына тынычлык инә баруын сизде.

Василий да сылу, гүзәл көмәнле ханымдагы үзгәрешнең нәкъ үзенә кирәк яктан салулап китүен аңлады. Инде бу җиңү иде. Һәм бу "җиңү"не ничек кенә булса да кулдан ычкындырмаска кирәк!

Василий, мин хәзер киләм, ефәгем, дип, палатасына юнәлде. Чыннан да озак тормады, кызыктыргыч ялтыр тышлы китап тотып, килеп тә житте, китапның урта бер төшен ачып, "Тыңла", диде, укырга керешге:

— ... "Бәхетләренә, яшенле-яңгырлы төн иде. Шуннан файдаланып, яшь, чибәр, дәртле хатын сөяркәсе белән сөешеп туя алмады. Тышта тәҗрибәсез солдатларның нидер сорап эндәшүләре, офицерларның тупас рәвештә кычкырган авазлары ишетелә, әмма. Күк күкрәве чатыр эчендәге сәгадәтле ыңгырашуларны күмеп китә иде"...

— Йә... ничек?!

Кадрия иң элек китапның тышына төбәлде. Авторы бөтенләй ят һәм әсәрнең исеме дә сәер аталышлы иде.

— Моның ише "особый" китапларны укыганың бармы соң әле?—Василий, кәпрәеп, Кадриягә сораулы карашын юнәлтте.

— И-и, кая инде ул безгә-ә...—дигән булды көмәнле сылукай.—Китапханәләрдә юк та юк инде болар! Китап кибетләренә кайтсалар да, безнең ише түбән катлау вәкилләренә эләкмиләр!

— Во! Дөрес әйтәсең,—диде Василий, кабынып.—Мондый затлы китаплар районыбыздагы үзәк китап кибетенә Мәскәүдән почта аша гына кайтарыла! Аннары туп-туры безнең өйгә килеп керәләр. Бары тик безнең өйгә генә!.. Бездә шушындый китаплар, беләсең килсә, ефәгем, биш йөз мең тәңкәлек булды инде!

Кадрия исе китеп:

— Би-ш йө-з ме-ң?!—дип куйды.

— Әйе... биш йөз мең!—диде Василий исе китмичә генә.

— Бу бит... бу бит... колхоз фермасындагы һәммә сыерлар бәясе чак-лы-ы!!!

— Әйе шул,—диде Василий.—Ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда, әти ул китапларны түләп алмый! Безгә ул китаплар бушка килә!

— Ничек?! Нинди юл белән?!

— Бер нинди юл белән дә түгел. Әти шалтырата, алар китерәләр, вәссәләм!

— Ә китапларга акчаны кем түли?

— Мин кайдан белим!

— Көннәрдән бер көнне атаңны җавапка тарттырып куйсалар?!

Василий башын тагын да текәрәк тотып:

— Патшанымы?—диде.—Бездә коммунист патшаларны кемнең җавапка тарттырырга җөрьәт иткәне бар әле, ефәгем?! Хәер, өйдә бу мәсьәлә турында да сүз чыккалый чыккалавын. Әтием андый чакларда: “Әгәр дә тикшерергә керешсәләр, минем түрәләр арасында шөһрәтем артачак кына һәм мине Обком секретаре итәчәкләр!”—ди. Менә шулай, ефәгем, шулай яшәргә кирәк дөньяда!

Василий тагын әллә нинди әкәмәт, кызыклы хәлләр һәм Кадриянең төшенә дә кереп карамаган, башына да килергә мөмкин булмаган мавыктыргыч, сәер рәхәтлекләр турында сөйләде. Ниһаять, Кадриянең шушы Василий әле генә сөйләгән мохит эчендә кайныйсы, яшисе килә башлады! Әмма бу әлегә матур, татлы хыял гына шул. Бу хыялны чынбарлыкка әверелдерер өчен, әлбәттә, иң элек Василийны кулга төшерергә кирәк. Ә нигә... Бу—булмастай эшме?!

Кадрия, чытлыкланып, Василийга ябышты:

— Ай, үләм... Әллә нигә башым әйләнеп китте!—диде.

Сылукайның тыныч, елмаюдан балкыган йөзе Василийның күңелендә дәрт уятты. Егет үзе дә елмаеп, ай, минем дә башым әйләнә ич, диде дә, Кадриянең муеныннан кочаклап, җиләктәй иреннәренә йотылды. Мәгәр сихри байлык иясе тиз айныды. Көч тә бар икән үзендә! Икенче мизгелдә инде Василий яңагын тотып басып тора, ә Кадрия палатасына таба китеп бара иде.

— Ух, ашыктым!—дип уйлады Василий.—Бераз сабыр итәргә кирәк булган да бит!

Мәгәр иртән ашханәдә алар тагын очраштылар. Василий манный боткасы, егерме биш грамм май, пешкән ике йомырка һәм кисәл салынган йомрыны күтәреп, Кадрия янәшәсенә килеп утырды. Сылукай инде үзенекеләрен җайлап кына ашарга тотынган иде.

— Төнозын йоклап булмады,—дип сүзгә кереште падишаһ улы.

Кадрия эндәшмәде.

— Яңак сызлады,—дип өстәде Василий.

— Миннән әҗерен көтәсеңме?!—Кадрия егеткә яндырып карады.

“Һай-йәй... Ачуланганда да нинди матур, күркәм йөзле булып кала белә бу, каһәр!”—дип уйлады Василий һәм пижама кесәсеннән нәрсәдер алып, тиз генә сылукайның уң кулын эләктерде дә, учы төбенә салып, бармакларын йомдырды. Аннары авызын гүзәллек иясенең нәфис колагына якынайтып, серле рәвештә:

— Миннән сиңа бүләк бу, ефәгем!—диде.

Кадрия башта: мә, кирәкми миңа синең бүләгең дип, уч төбендәге нәрсәләрне иясенә кире кайтармакчы иде, мәгәр... үзенең инде тирәсендә ике-өч егетне биетеп йөртә торган яшь кыз кәмәше түгел икәнлеге исенә төшеп, ул ниятеннән ваз кичте һәм уң кулының бармакларын тирә-юньдәге кешеләрдән качырып кына ачып, уч төбендәге нәрсәләрнең ахак кашлы алтын алкалар икәнлеген белде. Шундук аның бер бите ай, икенче бите кояш йөзенә соклану галәмәте чыкты һәм ул Василийга үтә җылы караш ташлап, “Рәхмәт”, диде дә, аннары кинәт уйчанланып өстәде:

— Менә мин сиңа тагын әҗерле булып калдым инде!

Василий бусында инде чыннан да өстенлеккә ирешә баруын тоеп, әмма шаяртып:

— Әҗереңне ни-нәрсә белән түләрсең икән, ефәгем?—диде.

Сылукай күзләрен зур ачып, хәйләкәр төстә:

— Хәзер үк түләр идем дә, күрәсең ич... кассам йо-заклы-ы!—диде.

Василий кызарып, мәгәр сер бирмәскә тырышып җавап кайтарды:

— Йозакнымы?! Һәй, йозакны гына ачарга була аны!..

— Йә, ачып кара соң алайса?!—Кадрия горур гына кыяфәт белән, урыныннан торып китте.

Берничә көннән, хастаханә подвалында, яшелчә саклагыч янәшәсендәге каравылчы бүлмәсендә Василий Кадрия алдына тезләнгән килеш тора иде.

— Юк!—дип кырт кисте сылукай.—Соңгы тапкыр әйтәм: кассам йозаклы, йозак ишеге мөһерле, ә мөһергә орынырга намусым кушмый!

— Намус, намус, имеш...—дип, эчке киеренкелектән шартларга җитешеп, кабатлады падиша улы.—Йә, нинди гөнаһларым өчен шулай рәнҗетәсең син мине? Алайса әйт: әҗерләреңне ничек итеп түләмәкче буласың син миңа, ә?!

Кадрия билләренә таянып, тешләрен кысты:

— Ирен төрмәгә яптыргач, хатыны белән ни кылансаң да була дип уйладыңмы? Юк инде, мине алай җиңел генә төп башына утыртып калдыра алмассыз! Мин фәхишә түгел! Мин... намуслы хатын! Белмәсәң бел...

Василий озын бармаклы куллары белән коңгырт бөдрә чәчле башына ябышты:

— Һаман бер сүз: ирем дә ирем, имеш! Синдә генә булган ди ир. Соң, төрмәгә мин яптырмадым ич! Аннары, аннан кайчан чыга әле ул? Ә синең гомерең үтә! Минем бит әле сиңа "фәхишә" дигәнем юк! Минем болай синең җәберләүләреңә түзүем дә бары тик сине яратканнан гына, ефәгем! Әйдә, килешик инде. Вакытны заяга үткәрмик! Йә...

Кадрия нәфис аякларына Василийның куллары тиеп китүдән, ток бәргәндәй, чирканып, артка чикте:

— Кит, кит, кагылма миңа, хакың юк!

Василий хәтта тешләрен шыкырдата-шыкырдата, үкереп куйды:

— Ну-у... Ну-у... Ай, нигә син шундый чибәр булдың икән? Яратам бит мин сине! Ә мин... яраткан кешемне... бары тик үземнеке генә итәргә тиешмен! Ефәгем, алайса... чык миңа кияүгә!

— Ки-яү-гә-ә?!

— Әйе, әйе... Кияү-гә-ә!

Сылукай корсагына ымлады:

— Шушы килешме?!

— Ә, юк, аны тудыруханәдә калдырып чыгасың...

— Ярый, мин... уйлап карармын!—Кадрия башын текә тотып, бүлмәдән чыгып китте.

... Ниһаять, алар килештеләр.

Менә инде Кадрия кызын тудыруханәдә калдырып, Василий иярләгән ак "Волга"да Жданов урамына таба җилдерә. Фатирдан киемнәрен алырга! Ләкин Рәсимәнең төрмәдән чыккан салмыш ире фатирны сакларга овчарка алып кайтып куйган икән. Эт сылукайны ишеккә якын да китермәде, эчтән гел ырылдап өреп торды!

Шуннан соң Василий кулын селтәде:

— Киттек, ефәгем! Мин сине районыбыздагы иң шәп кибеткә алып кереп, өр-яңадан киендерермен,—диде.

Кадрия тәрәзәләрдәге көнчел һәм усал, хыянәтчел карашларны искәреп, әмма нигәдер әле ишегалдыннан аерыласы килмичә, тагын бер мәртәбә бәдрәф турысына карап, Мөбарәк белән булган күңелсез, кызганыч хәлне исенә төшереп, авыр сулап куйды:

— Киттек, Василий!

Менә инде Кадрия—авылдан күптән түгел генә кузгалып, зур өметләр, ак хыяллар эчендә бөтерелеп, калага яшәргә килгән яшь хатын—кабат каладан кузгалып, райүзәккә таба китеп бара.

Ул авылдан алтын-сары чәчле булып, Кадрия исеме белән килгән иде. Ә хәзер кара чәчле булып, бүтән исем астына сыенып кайтып бара!

Ни көтә аны анда?!

Ә Василий, әнә, арттан килүче машиналарны күзәтергә куелган көзгедән һаман-һаман Кадриягә карый, елмая. Елмаерлыгы да бар шул, Казан хәтле Казанның беренче гүзәлен янәшәсенә утыртып алып кайтып

бара бит! Көннәрнең берендә банкет-фәләндә, Василийның кочагына кереп сыенган шушы илаһи җан иясен шәйләп өлгергәч, район прокуроры белән профсоюз комитеты рәисенең чепи күзләре маңгаена менәчәк әле! Менәчәк... Шуларны уйлагач, Василийга иллә дә рәхәт булып китте...

Кадриянең уйлары исә—дөньяда иң-иң якын кешесе—әнисе тирәсендә бөтерелә иде. Аны авылдан кузгатырга һәм райүзәк тирәсенә урнаштырырга туры килер инде!

Гүя сылукайның күңелен күтәрергә, кәефен шәбәйтергә теләп, февраль кояшы дәррәү кыздырып җибәрде. Дамбада кар эри башлады. Юл читендәге агачлар да ап-ак күлмәкләрен салып ташладылар...

## II

Беренче башлам

“Адәм баласы тугач ук дөньяга елап аваз сала. Шундый каты, чәрелдәп, үпкәләп елый ки, тәннәр чемердәп, йөрәкләр тетрәнеп китә. Бу—әллә нәрсә дә түгел инде үзе—сабыйның тәкәбберлеге генә. Ул:

— Тизрәк кулыгызга алыгыз мине, күтәреп йөрегез, сөегез, иркәләгез һәм минем күңелемне күрер өчен сыер булып мөгерәгез, маймылдай мәтәлчек атыгыз, тагын әллә ниләр, әллә ниләр эшләгез, мәгәр мине генә елатмагыз!—дип кисәтә төсле.

Һәм хөрмәтле ата-ана “бердәнберем”нең, “күз нурым”ның күңелен күрер өчен, кем әйткәндәй, тәмугка кереп чыгарга да ризалар инде.

Әнә шулай тәрбияләнеп үскән бала, бер көнне, һич көтмәгәндә, дөньяны шаккатырып куя—җинаять юлына кереп китә!”..

— Фәхишәләк җинаять була икән алайса!—дип Василий китабын читкә куеп, урыныннан торды. Гәрчә, биш урында биш сөяркә асраса да, ул үзен һич кенә дә фәхешкә санамый иде. Шулай да китаптан укыган нәрсәләр тәэсир итте булса кирәк: “Шәфкать белән араны ныклап өзәргә кирәк, миннән бала да бар ич, аннары... ул яңа бәйләнешләргә дә кергән бугай”,—дип уйлады. Бу турыда шул ук көнне Шәфкатькә дә җиткерде.

Василий янынннан өстеннән тау төшкәндәй, җиңеләеп, чыгып киткәч, Шәфкать:

“Ярар, ахыры хәерле булсын!—дип уйлады.—Бүре баласын бүреккә салгач та урманга карый, диләр бит... Үз ишемне табармын әле. Эшем бик әйбәт ич! Йомышлары төшеп, яныма кемнәр генә килми дә, кемнәр генә китми. Арада әйбәт кенә бер сатучы егет тә бар әле. Кармакны менә шуңа салып карарга кирәк! Булды, тәвәккәллим!..”

Шәфкать бизәнеп-ясанып эшкә китте.

... Урам буйлап килгән матай тавышы ишетелде. Кешеләр борылып, йә башларын күтәреп карадылар. Матай кибетче Тимергали капкасы буена кайтып туктады.

Кибетченең хатыны тәрәзәгә капланды:

— Корычнур икән!

Егет үзе өйгә керергә ашыкмады, матаеннан төшми генә тәмәке кабызды: “шулай итеп, бер бите ай, бер бите кояш кызны күреп кайттым райүзәктән”, дип, күңелләләнеп уйлады ул.

— Корыч-чнур-р!

Ишегалдыннан яңгыраган әлеге аваз егетне сискәндереп җибәрде. Ул тәмәкесен җиргә ташлап, үкчәсе белән басып сүндерде дә, матаеннан төшеп, капка keләсенә үрелде. Тимергә тимер бәрелеп чылтыраганы ишетелде...

Сызылып киткән кара мыеклы, уртача буйлы, әмма төптән нык,

алсу йөзле егет, болдырга барган жиреннән туктады һәм зур, озынча башын янга борып, кысыграк күзләрен этисенә төбәде. Сарай диварына терәп өелгән утыннар турысында юан гына бер ир карама бүкәнгә утырган көе, телен чыгарган да тырышып-тырышып ике тезе арасына кыстырган пычкыны кайрый. Әмма шул ук вакытта астыртын рәвештә, малаена карап алырга да өлгерә иде.

Малае үзенә сынап карап торгач, гайрәтле ир эшеннән бүленгәндәй, мәгънәле генә итеп елмайды.

— Нәрсә, эти?—диде егет этисенең төпченүчән күзләренә туры карамаска тырышып һәм урманга барырга жыенуына төшенеп эченнән генә: “Әзерләнгән утыннарыбыз әнә ничаклы, тагын нәрсәгә инде?!”—дип, күңелсезләнә калды.

Чыннан да, урманга барасылар икән, мәгәр бусында утынга түгел, эшләнәчәк яңа капка өчен, имән кисәргә. Инде урман хужалыгыннан алынган рөхсәт язуы да бар, кайдан, нинди агачларны егарга кирәклекне урманчы да күрсәткән, ди, имеш.

Ир кеше шуларны әйткәч, янә, малаена төбәлде.

Егет тагын кызарды. Әле өченче көн генә этисе бер авыл агаена: “Корычнурның печәндә дә, утында да кайгысы юк... Корычнурның кайгысы быел хатын-кызда!”—дип сөйләп тора иде ич. Әнисе дә кичә бер авыл апаена: “Менә, Ходай кушып, яңа капка эшләткәч, көзгә Корычнурны өйләндерербез инде аннары”,—диде.

“Түбән оч Саниягә өйләндерми торыгыз әле, яме,”—дип күңелсезләнеп уйлады Корычнур һәм Шәфкатьне күз алдына китереп хыялга бирелде.

— Жә...—диде ир кеше, ике тезе арасына кыстырган пычкыны әйләндерде дә, күзләренә якын китереп карады, аннары өч почмаклы игәү тоткан кулының баш бармагы белән тешләренең үткенлеген тикшерә башлады. Егет исә ни өчендер аксыл-зәңгәр күккә карап тора иде. Әнә кояш... әнә болытлар... әнә түбәннән генә жиде карга очып үтеп бара.

— Сөйлә, юлларың ундымы?—дип төпченүен дәвам итте ир кеше, пычкының икенче як тешләрен кайрый биреп.

“Ничек итеп жавап бирергә инде бу этигә?..” Егет караңгы чырай белән ак этәчкә карап уйланып торгач, сулъяк кесәсенә тыккан кулын нервланып уйнатып алды.

— Жә, ник дәшмисең?—диде ата кеше, ниһаять, эшеннән бүленеп, соры күзләрен чак кына кыса төшеп, малаена карады.—Мин синнән “юлларың ундымы” дип сорадым, ә син һаман дәшмисең...

— Дәшмәгәч, билгеле инде,—диде егет, теләр-теләмәс кенә, караңгы чырай белән.

— Юлларың уң булмаган, шуңа шулай дисең инде син.

— Билгеле, шуңа шулай дим.

— Ярый... Ә хәзер минем төп соравыма жавап бир: ялгышмасам, син товар кирәклек өчен генә бармагансың ул сәүдә берләшмәсенә?!..—Ир кеше тотлыкты, тамагын кырып куйды һәм сүзен дәвам итте.—Теге хатынны күрү өчен...—Ләкин ул ни өчендер сүзен әйтеп бетермәде, тәмәке кабыза башлады. Шырпысын сүндереп аяк астына атты, төтенне тәмле итеп суырып эчкә алды да, берәздән өреп чыгарды:

— Матай... сүнеп аптыратмадымы соң?

— Юк, эти... матай әле һаман бер басуда кабына!

Ир кеше тирәсендә чүпләнеп йөргән тавыкларга тешләре арасыннан гына чиртгереп жибәрде.—Шулай да, улым, бигүк акыллыга ошамаган син...

“Ник алай әйтә соң бу эти?”—дип уйлады егет.

— Балалы хатынга кызыкканга күрә әйтүем.

“Бары тик баласы булган өчен генәме?!.”

— Хатын—хатын инде ул, баласы булса булмаса да—кыз түгел!

“Эти дөрес әйтә шикелле,—дип уйлады егет.—Нигә мин балалы

хатынга кызыктым соң? Юк, гаеп миндә түгел, әлбәттә, түгел, чөнки башлап ул үзе миңа... складына товар алырга барган көнне үк, минем егет икәнлегемне белеп, минем белән бик ачылып сөйләшә башлады. Дөрес, минем үземә дә ошады, бик ошады ул. Шуннан соң мин аны бер генә көн дә күрми тора алмый идем инде. Ә танышуыбызга бер ай вакыт үткәч, Шәфкать (исеме генә дә ни тора бит!) минем янга мотоциклга утырып, безнең авылга, туганнарына кайтырга чыкты. Бу сәфәрнең сәбәпчесе, әлбәттә, мин идем бугай...

— Күккә кара! Болытлар кабара бит, яңгыр явачак ахрЫ,—диде кыз.

— Яуса... әллә яңгырдан куркасыңмы, шикәр кебек эреп төшәрмен дип.

— Яңгыр—фәләннән курыкмыйм ла анысы, яшеннән генә шүрлим мин,—диде кыз нәүмизләнеп.

— Яшенле яңгырдан...—дип төзәтте аны егет.

— Әйе, яшенле яңгырдан. Беләсеңме, мин бәләкәй чакта безнең өйнең морҗасыннан яшен ташы килеп керде... бәхетебезгә дер, әни түр тәрәзәне япмыйча калдырган булган икән. Яшен ташы шуннан чыгып юк булды. И, курыктык!

— Бүген менә курыкмаска тырыш инде,—диде егет.—Курыкканга куш күренә ул.

— Курка, ди... Алай куркырлык булсам, сиңа утырып юлга чыкмаган да булыр идем әле,—диде кыз кыю гына итеп. Ул ике кулы белән дә егетнең биленнән кочып алды, аннары аның җилкәсенә башын куйды.

Егетнең гүя аңы томаланды, йөрәге гөрселдәп-гөрселдәп тибә башлады һәм ул чак-чак кына борчак кырына кереп китүдән үзен тыеп кала алды. Аннары бераздан: "Ир түгел шул мин, кызның бу тәвәккәл адымын бәяли белмим, әгәр ир булган булсам бу халәтен аңлап аңа берәр... сүз әйтер идем",—дип уйлады егет.

"Юк, ярамый,—дип куйды егет, ниһаять,—чөнки егет-җиләнгә хатын кеше алдында әдәплелек сакларга кирәк ләбаса! Ә бәлки, киресенчә, хатын кешегә егет-җилән алдында әдәплелек саклау фарыздыр! Шәфкать үзе ни уйлый икән бу турыда, беләсе иде..."

Шулвакыт, көтмәгәндә генә, җил өермәсе купты. Уңъяк арыш басуының буеннан-буена тирән-тирән дулкыннар хасил булды. Юл читендәге нәзек каеннар, матур йөзләрен хәтәр давылдан яшерергә телəгәндәй, һәммәсе дә бер тарафка таба авыштылар. Көн кинәт сүрәнләнеп, караңгыланып китте, баш өстендәге күк йөзен тоташ соры, кара болытлар каплап алган иде инде.

— Озакламый коеп, орып яңгыр ява башлаячак,—диде егет, томан сарган сыман булып тоелган якка күзләрен талдырганчы текәлеп карап.

— Мин яңгырны болай бик тиз ява башлар дип уйламаган идем. Болай булгач, нишлибез инде?!—диде кыз хафага калып.—Яңгыр яугач, юллар пычраныр бит, матайның көпчәкләре таер, егылып, имгәнеп бетәрбез. Төнгә каршы, җитмәсә, якын тирәдә авыллар да юк.

— Урманда кунарбыз...—диде егет төксе итеп .

— Ки-и-ит... курыкмыйчамы? Анда кайда кунмак кирәк? Яңгыр яугач, урманның барча төше юеш булачак бит.

— Коры урын да табарга була. Учак кабызып җибәрергә мөмкин хәтта,—диде егет. Кызның кайнар тән җылысы аның йөрәген соң чиккәчә алгысытып, тегендә, урманда әллә нинди күңелле тамашалар буласына ымсындырып тора сыман иде.

— Умарталыкта бик шәп бер шалаш бар, шунда тукталып...—егет сүзен әйтеп бетерә алмый калды, кинәт җирне-күкне дер селкетеп күк күкрәп узды, чытырдатып яшен яшьнәде, якында гына нәрсәнедер сукты да инде әллә!

Кыз "ай" дип кычкырып җибәрде һәм егеткә тагын да ныграк ельшa төште.

Корычнур кызны тынычландырырга теләп, кулларыннан сыйпап

куйды. Шәфкать исә бу сыйпауга каршы, шулай ук, тойдырмастан гына егетнең муенынннан үбү белән җавап кайтарды. Юк, бу гына канәгатьләндермәде әле кызны, ул тагын эченнән генә егеткә иркә, матур сүзләр әйтте... Корычнур, аның күнелен аңлагандай, башын чак кына борып:

— Шәфкать! Мина утырып китүенә үкенмисенме?—дип сорап куйды.

— Юк, бәгырем, үкенмим! Син үкенмисенме соң?

Шәфкатьнең соңгы сүзләрен егет әллә ишетте, әллә юк: урман каршында юл икегә аерыла, шул урынга җиткәч, коточкыч күк күкрәве һәм яшен яшьнәве аралаш, җиргә чиләкләп-чиләкләп яңгыр коя башлаган иде. Баярак кына, каршыдан искән куәтле җил, ачык изүе аша кереп, егетнең күлмәген салдырып алырга теләгәндәй кабартса, хәзер инде яңгыр чылаткан шул ук күлмәк, егетнең тәненә сыланып ябышкан сыман булып калган иде. Хәер, Шәфкатьнең үзенең дә хәлләре шәптән түгел иде. Аның да күлмәге сап-салкын булып тәненә сыланган: тундырыпмы тундыра, калтыратыпмы калтырата. Озакламый кызның тешләре, кем әйткәндәй, шык-шык итеп әргән уйнап җибәрде.

Чу! Әнә, матай урман авызын яктырткан да, нәрсәдәндер өркеп капкадан керергә кыймый торган сыер кебек, арт көпчәгән бер урында зырылдатып тик тора. Вакыты-вакыты белән ян-якка салулый һәм көтмәгәндә генә килгән якка таба борылып куя.

— Ныграк тотынып утыр, Шәфкать,—дип кычкырды егет, һәм киреләнеп маташкан "айгыр"ны урманга таба борып, әкрен-әкрен генә урынынннан кузгалып китте. Бу юлы матай чыгымлап азапламады: киреләнүенең файда итмәячәгенә төшенде, ахрысы.

— Юк, Шәфкать, мин сине утыртып алып китүемә үкенмим!—дип күкрәгеннән чыккан горур тавыш белән кычкырды Корычнур.

Матай уты юлны шәп яктырта... Ләкин кичке урман кичке урман инде... шомлы, куркыныч. Агачлар, гүя, нниндидер серле көчләр тарафыннан тораташка әверелгән җанияләре. Менә шулар кинәт хәрәкәткә килерләр дә, озын кулларын сузып, арттан эләктереп алырлар шикелле. Шәфкать Корычнурга чытырдап ябышып утырса да, үзе моны сизми, уйлары белән әллә кайларда йөри: әнә коточкыч озын буйлы, кәкре борынлы, тәлинкәдәй бер күзле диюнең, яшен яктысында, иләмсез ыржайган авызы һәм кара тешләре күренеп кала... әнә икенче бер дию, кайдадыр имән агачлар тезеп ясалган юлдан җигүле атка ләгәннәр төяп, даңгыр-доңгыр, шаңгыршоңгыр китеп бара...

Менә берзаман яңгыр урман эчендәге юлны да пычратып ташлады. Җитмәсә юл тигез түгел, кәкре-бөкре тыкырык кебек йә уңга, йә сулга борыла, ул да түгел, кинәт түбән төшеп китә, аннары югары менә, урыны-урыны белән чоңгыллы-чоңгыллыдыр әле үзе!

"Әйе, Корычнур... сиңа ышанырга була!"—дип уйлады Шәфкать егетнең матай йөртү осталыгына таң калып. Аннан да битәр егетнең үзенә зыян салмаячагына эчке бер сиземләү белән инана иде ул. Кызның тизрәк-тизрәк шалашка барып җитәсе килде...

— ... Әйдә, жыена башлыйк, улым,—диде ир кеше.

— Нәрсәләр алабыз соң, әти?—диде егет күзләрен читкә төбәп.

— Билгеле инде: балта, пычкы, кайрак,—ул авызын чак кына кыегайтып, күккә карап куйды. Егет кулын кесәсенә тыгып, нервланып, кибет ачкычларын чылтырата башлады.

— Юк, ашарга дим мин, нәрсәләр алабыз дим...

— Чәй генә алып торсак та ярый, чатнаганда эчәр өчен...

Егет чәй алырга дип, өйгә кереп китте.

— Кайттың да мыни, улым?—дип каршы алды аны мич янында коймак майлап торган әнисе. Өстәл янында түбән оч Саниянең анасы утыра иде.

— Күрәсең ич...—диде егет әнисенең төпченә башлавыннан шикләнеп. Ул кунак карчык белән исәнләште дә, термоска чәй агыза башлады.

— Тагын юлларың уңмадымы әллә?—дип, сәер генә итеп, сорап куйды әни кеше. Һәрхәлдә ул Корычнурга шулай тоелды.

Егет, склад мөдирен очратып булмады, дип әйтмәкче иде, ләкин кире уйлады, "склад ачык булмады",—диде дә, аралыкка кереп, эш киемнәре кия башлады. Карчыклар чөкердәшә-чөкердәшә чәй эчәргә керештеләр. Чәй тәмле, бал юкәнеке, ә коймактан майлар тамып тора иде шул. Озакламый сүз янә Корычнур тирәсенә әйләнеп кайтты. Саниянең әнисе егетнең кая баруы белән кызыксына иде, ахры. Әни кеше тотырып җавап биргәч, малае ягына таба борылып:

— Кайда йөри икән соң ул хатын? Кичә дә ачык булмаган склады, бүген дә... Бигрәкләр типтерергә ярата торган нәрсә икән ул, әкәмәт!—диде.

"Юк, сез аны белмисез, бик әйбәт кыз ул, алтын кыз ул!"—диде егет, эченнән генә Шәфкатьне мактап. Ул термосны сумкага салды да ишеккә таба кузгалды.

... Ул төнне яңгыр яуды да яуды. Егет шалаш авызын әйбәтләп печән белән томалап куйганга, салкын һәм аҗаган яктысы эчкә үтеп керә алмый иде инде. Бая кечерәк кенә учак ягып тәннәрен киптергәч, аларның кәефләре дә күтәрелә башлады. Күлмәк-фәләннәрен өрлек ботагына элеп куйдылар.

Эчтә дөм караңгы, күзләр берни аермый. Корычнур кулын әкрен генә йөртеп, Шәфкатьне эзләргә керește:

— Кайда соң син?

— Янында утырам ич!

Егет кулы, ниһаять, Шәфкатьнең анадан тума диярлек шәрә тәненә орынып китте:

— Ә, менә икән!..

— И, кем уйлаган...—диде кыз,—яңгырлы төндә, урманда, шалашта бер егет белән кунып калырмын дип...

— Мондарак килеп утыр, Шәфкать!

— Җилкәгә җилкәне терәп утырыйк әле,—диде кыз. Аннары, урманны шаулатып яуган яңгырга колак салып.—Сибәләп тә карый соң, ә!—дип өстәде.

— Кая, тышта нинди тамашалар бар икән, бер күз салып алыйммы.

— Кирәкми...—диде кыз егетнең беләгеннән эләктереп.—Анда яшен яшьни... мин яшеннән куркам ич...

Егет дәшми-тынмый гына сузылып ятты һәм Шәфкатьне биленнән эләктереп, үз янына аударды.

— Ай-яй, бая шәп чытырдатты да соң! Шушы тирәдә генә берәр имәнне сукты булса кирәк.

— Сөйләмә... әле һаман йөрәгем үз урынында түгел.

— Без икебез дә романтиклар, әйеме?

Кыз эндәшмәде. Бары тик тирән сулап көрсенеп кенә куйды. Аннары:

— Печән эченә кереп, синең белән янәшә җылынып ятасым килә минем,—диде пышылдап кына.

— Әйдә алайса!..

— Менә хәзер туңмыйм,—диде кыз егеткә елыша төшеп.

— Минем уң аягым бераз туңа әле.

— Ә син аны болай ит... Кыз егетнең аягын үз аяклары эченә яшерде.

— Менә хәзер туңмый!

— Ә син туну турында бөтенләй уйламаска тырыш.

Егет иреннәрен, кызның колагына якын ук китерде:

— Мин сине сөям, Шәфкать!!

— Корычнур! Кирәкми!—диде кыз егетнең кинәт каударланып үбәргә маташуына каршылык күрсәтеп, һәм аның шашкын дәртен салкын канлылык саклап сүрелдерәчәгенә өмет итеп.

— Бер генә, тик бер генә мәртәбә...—дип ялынуында булды егет,

кайнар сулышы белән кызның йөзен, муенын көйдереп ала-ала.

— Юк... ярамый...—дип үз сүзендә нык торды Шәфкать, авылда, әнисе янында калган ике яшьлек малаен күз алдына китереп.

— Үлеп яратам бит...

— Кит Корычнур, тыңларга да теләмим. Яраткач, башкачарак итеп яратырга кирәк аны!

— Ничек итеп? Әйт, аңлат, Шәфкать жаным...

— Иртәгә әйтермен, яме, Корычнур... ә хәзер теге ягына борылып ят та, йөзгә чаклы сана...

Әтисе юлдан читкә чыгып бераз баргач, матайны сүндерде. Егет үзләре туктаган урынны күздән кичерә башлады. Кайчандыр буш алан булган бу. Урман хужалыгы эшчеләре килеп аңа нарат үсентеләре утыртып киткән. Наратлар кечкенә әле, шуңа күрә алан эче кояшның бөтен нурларын үзенә жыйгандай яп-якты булып тора. Ә тирә-юньдә кара урман: серле дә, шулай ук, үзенә чакырып кызыктыра да шикелле. Кошларның чутылдап сайрашулары ишетелә...

— Башлап кайсын кисәрбез икән?

— Менә бусына ымсынып куйдым инде мин,—диде ир кеше янәшә үскән өч имәннең уртадагысына күрсәтеп,—бу төзрәк тә, калынрак та. Моннан ким дигәндә ике баганалык чыгачак.

— Ә очы өрлек-фәләнгә ярап куяр,—диде егет.

— Өрлек? Юк, кирәкми әле безгә. Бакчаның берничә баганасы черегән, шуларны...

— Әйдә, кисә башлыйк инде!

Ир кеше тезләнде һәм имәннең яшелләнеп торган бер урынын балта белән киртләп куйды. Аннары пычкыга үрелде. Кисәргә керештеләр.

— Пычкыны үзеңә табарак каер әле,—диде әтисе.—Менә шулай. Тагын азрак каерсаң да ярый әле. Һоп, булды, булды... Баһадир имән шытырдаган аваз чыгарып әкрен-әкрен генә ава башлады һәм дәһшәтле ботаклары белән мәһабәт юкаларне дуамалланып кыйный-кыйный, ниһаять, жиргә сузылып ятты да, тынычланып калды.

Ир кеше тирләгән маңгаен, йөзен, муенын әрекмән яфрагы белән сөртте һәм канәгать төстә елмаеп:

— Шөкер, булды бусы,—диде.

Аннары тәмләп ботакларын чабып ташлады. Инде хәзер дүртәр пычкы буе үлчәп кисәсе генә калды.

Ир кеше термостан чәй агызып эчкән арада, егет чишмә тарафына карады һәм... теге шалашны күреп алды.

— Корычнур?!

Егет иренеп кенә күзләрен ачты. Тавышның кайдан килгәненә төшенеп житмичә, бер мәл аңгыраеп торгач, ниһять, кичәге тамашаларны хәтерләп, ялт кына печән эченнән чыгып басты. Һәм үзенең трусиктан гына икәнен күреп, уңайсызланып, чалбар-күлмәген эзләп як-ягына каранды, чөнки шалаш алдында аңа елмаеп Шәфкать басып тора иде.

— Синең чалбар-күлмәгеңне дә киптердем,—диде кыз һәм каяндыр алып егеткә киемнәрен сузды. Корычнур ашыкмый гына киенә башлады:

— Әйе шул, чынлап та кипкән! Кай арада өлгердең?

Шәфкать сул күзен кысып кояшка карап алды, аннары чишмә тарафына төбәлде һәм уйлап куйды: "Мин иртүк уяндым инде! Юеш печәнне аралап шалаштан чыкканда—кошлар сайрый, үләннәрдә, яфракларда чык бөртекләре жемелдәшә, аксыл-зәңгәр күктә кояш көлә иде!"

— Юллар сиркемәгәнме икән әле?—диде егет, Шәфкатьнең юеш күлмәк итәгенә төбәлеп.

— Сиркегән!—диде кыз Корычнурның кабарып торган мускулларыннан күзен ала алмыйча. Үзе уйлап куйды: "Шулай да урман эче юеш әле. Агач ботагына орынып китсәң, шыбырдап өскә су коела башлый...

Ә суының салкынлыгы, мин сиңа әйтим!..”

— У-у, рәхәт икән монда... кем әйткәндәй, полный консерватория!— Егет як-ягына комсызланып карана-карана тышка чыгып басты. Ерак түгел генә бер урында нәни поши шалаш тарафына төбәлеп, иснәнеп тора иде. Аңалашыла. Нәни пошины ят ис, бензин исе әсәрендергән булса кирәк. Әнә ул, егет пәйда булгач, шүрләптер инде, чытырманлыкка кереп сызды... Әйе, чынлап та кояш ярыйсы ук кыздыра башлаган икән. Инде чебен-черки, кигәвен бөгәлҗән, бал кортлары, төклетуралар һәм шөпшәләр дә, күбәләкләр һәм энә караклары да эшем ияләре булып киткәннәр, имеш. Һәр тарафтан баллы үлән исе, сихәтле җир мае исе, черегән агач, яфраклар исе аңкып тора иде. Их, һавасы ла һавасы!.. Егет көчен кая куярга белмәгәндәй, рәхәтләнеп, тартыла-тартыла киерелде дә, артыннан юеш эзләр калдырып түбән таба төшә башлады.

— Корычнур!.. Син кая?..

Егет әллә ишетте, әллә юк—эндәшмәде. Шәфкать исә, авырттырырлык итеп, иреннәрен тешләде, мәгәр егетне күздән ычкындырмады: “Олы юлны карарга бара!”—дип уйлады ул.

Чынлап та Корычнур юкәләрне, элмәләрне аралап бара-бара, олы юлга килеп чыкты. Юлның калку урыннары инде кипшенә башлаган, сөзәк төшләре исә юеш һәм пычрак иде әле. Мәгәр Корычнур юлда төрлечә йөреп карады һәм, матайда үтәргә була, дигән нәтиҗәгә килде. Аннары, борылып китәм дигәндә генә, аның очлы күзләренә, имән ботагында эленеп калган кызыл косынка чалынды. Ул аны тиз генә барып алды. Гаҗәп! Мондый нәфис косынканы Корычнур Саниянең башында бик еш күргәли иде ләбаса!.. Мондый охшаш косынкалар азмыни дөньяда дияр идең дә, ләкин Саниянең әтисе урман каравылчысы бит! Шул абзый Корычнурның әтисенә капка баганалары өчен имәнне биредән кисәргә рөхсәт иткән ич!..

Егет кулын селтәде дә косынканы кесәсенә салып куйды.

... Ул әйләнеп килгәндә Шәфкать шалаштан ерак түгел генә тал төбенә утырып, кура җиләге ашый иде. Кыз егеткә сынап карап куйды, аннары йомшак кына итеп эндәште:

— Ашыйсыңмы, Корычнур?!

— Рәхмәт,—дип, егет кыз янәшәсенә утырды һәм, кәгазь савыттагы кура җиләген башта учына салды, аннары авызына озатты. Аһ, нинди сусыл, нинди тәмле!..

Кыз бәләкәй сәгатенә карады:

— Корычнур... Мине районга илтеп куярсың инде, яме!

— Булмый,—диде егет кырт кисеп. — Озакламый Олы юл аша машиналар үтә башлаячак. Берәрсенә утырып кайтырсың әле!

Шәфкать зәңгәр кофтасын иңенә салды да, кара, куе чәчле башын түбән иеп, дәшми-тынмый гына китеп барды.

“Ул чынлап та мине ярата бугай!—дип уйлады егет.—Ә мин үзем ятаммы соң аны? Белмим... Яраткан булсам, мин аны туктатыр идем. Ярар, китә бирсен. Төнлә ул минем теләгемә аркылы төште... Китүе әйбәтерәктер дә әле... Әгәр дә төнлә ул минем теләгемне үтәсәме... мин аны, һичшиксез райүзәккә үк илтеп куйган булыр идем. Кит, Шәфкать, кит: шәфкатьле бул!”

Ике көн үткәч, Корычнур райүзәккә барды. Шәфкать эшли торган складның ишегендә ике йозак эленеп тора иде.

— Кемне көтәсең? Шәфкатьнеме? Көтмә син аны, авырый ул,— диделәр егеткә.

— Күтәрмә, дурак!..

Егет иләмсез авыр чи имәнне иңбашына алып, җирдән аерырга азаплана иде.

— Эченне төшерәсең киләмени? Хәзер үк җиргә ташла!..

Алар имәнне икәү күтәреп, аннары алып килеп, әрдәнәгә салдылар.
— Ярар, бүгенгә житеп торыр,—диде әти кеше, авыр сулап.
— Мин чишмәгә барып, су эчеп киләм әле,—диде егет.
— Хәзер кайтабыз ич. Өйдә тәмләп чәй эчәрсең.
— Мин, әти, бик сусадым шул...
— Ну, бар алайса, озак торма!

Кибетче егет ашыга-ашыга туп-туры шалаш янына юл тотты. Килеп житеп эчкә керде, икәү янәшә яткан урынга тәбәлеп, тәмәкесен тарта-тарта, чак кына уйланып торды. Аннары чалбар балакларын бераз гына өскә күтәреп чүгәләп утырды:

— Менә монда куйган иде инде ул башын!—диде һәм шул төшне учы белән йомшак кына итеп сыйпый башлады. Кинәт бармаклары ниндидер каты әйбергә тиеп киткәндәй булды. Печәнне жентекләбрәк капшап караса... тарак! Әмма ул урталай сынган иде. “Соң... бу аның тарагы ич инде... алыйм әле мин аны”. Егет эре тешле яшел тарак сыныкларын әйләндереп-әйләндереп карады да, кесәсенә төшереп жибәрде...

Капка төбенә килеп туктаган машина тавышы ишетелүгә, ана белән кыз урыннарыннан торып, чыгарга кузгалдылар. Әмма Шәфкать ишек токтасына үрелгән жиреннән, кире борылып, баласының караваты янына килде. Чебен-черки бимазалап, йөдәтеп бетермәсенгә каплап куелган пәрдәнең читен күтәреп, улы Болгарга йотылып-йотылып карады. Ике яшьлек сабый таза кулларын як-якка ташлап, әнисенең китеп барачагын белмичә, чайрап йоклый иде. Вакыт-вакыт ул күз кабакларын кыймылдатып куя, көлгәндәй итә, әллә төш күрәме?!

Шәфкать әнисенә сиздерми генә күзендәге яшьләрен сөртте. Болгарның сары бөдрә чәчләреннән сыйпап алды да, кабалана-кабалана, маңгаеннан, чигәсеннән, йөзеннән үбә башлады. Ләкин машинаның “пип”елдәве, жаннарны сискәндереп янә өй эченә үтеп керде, бала белән озак юанырга ирек бирмәде. Әй, бу Гыйлемханның ашыкмаган сәгате бармы икән, валлаһи! Аналы-кызлы капкадан атылып диярлек килеп чыктылар. Шәфкать кабинага кереп утырды.

— Тәрәзәнне яп, кызым, жил бит! Әле әнә терелеп тә бетмәгәнсең бугай!—диде ана кеше, борчылуын ачыктан-ачык сиздереп.

— Ничава апа... Шәфкатьне мин районга күз ачып йомганчы илтеп житкерәм,—диде шофер. Ул үрелеп, каты итеп, ишекне япты.

Дөрестән дә, машина тиз килеп житте.
— Кайда төшәсең, Шәфкать?
— Туктат... шушында. Тулай торакка кагылып чыгасым бар әле минем.

Көләч йөзле ир машинасын туктатты:
— Саулык-сәламәтлек кенә юлдаш булсын сиңа, Шәфкать!
— Рәхмәт утыртып алып килгәнең өчен, тагын бер мәртәбә рәхмәт изге теләкләрең өчен, Гыйлемхан абый!—Шәфкать каршыдагы урамга аяк басты. Асты таш, өске каты агач йорт яныннан үткәндә, кыз, култык астына портфель кыстырып ак “Волга”дан чыгып баскан мәһабәт иргә дикъкать итте. Элеккеге кайнатай! Аның янәшәсендә шулай ук култык астына портфель кыстырган тәбәнәк, юан, ләкин үтә ыспай киенгән тагын бер ир басып тора. Анысы кайнатайның яңа кодасы була инде... Шәфкать башын горур тотып, тәкәббер кешеләр яныннан ашыкмый гына үтеп китте. Урам бетеп, сулга борылгач, Камага карата салынган ун тәрәзәле йорт буена килеп басты. Кызлар яши торган тулай торак иде бу...

Шәфкать барып кергәндә, иптәш кызы Нурия коридорда идән юып маташа иде:
— А-а-а, малай... сине күрер көннәребез дә бар икән...
— Юбилейга әзерләнеп йөрисеңме әллә?—дип сорады Шәфкать житди генә.

Нурия кычкырып көлеп жибәрде:

— Каян сездән? Ие шул, малай, юбилейга әзерләнеп йөрибез. Пурия Сандровнаның юбилеена...

Бу тулай торакта торучы карт кызлар туган көн үткәрүне "юбилей" дип мөһерлиләр иде. Пуриянең чыннан да юбилее—аңа утыз яшь тула икән һәм аны бик зурдан кубып үткәрергә уйлаганнар, имеш.

— Карале, Шәфкать,—диде Нурия кинәт җитдиләнеп,—син юк чакта бирегә бер егет килгәләп йөрде бит әле. Тәмам җөдәтеп бетерде, малай...

Шәфкать дерт итеп куйды:

— Нинди егет?

— Көмеш Елга авылы кибетчесенең малае ул.

Шәфкатьнең йөзе кып-кызыл булды:

— Шуннан?..

— Сине сорый инде гел: кая ул? Ник килми? Ник күренми?—ди... Кинәт кенә авырып китте дә, авылларына озатып куйдылар, мин әйтәм. Аннары менә бу таракны калдырды. Шәфкатьнеке иде, килгәч үзенә тапшырырсың, яме, ди. Өр-яңа, иеме...

Нурия халат кесәсеннән алып Шәфкатькә биргән тарак чынлап та өр-яңа иде!

— Әйе, бу—минеке,—дигән булды Шәфкать.—Гаҗәп! Кайда югалткан идем икән соң мин моны? Һич башыма сыйдара алмыйм...

— Китми тор әле, малай!—Нурия янәшәдәге бүлмәнең ишеген шакылдатты.—Корычнур нинди дер язу да калдырган иде. Анысы Пуриядә булырга тиеш. Бар, кереп сора үзеннән.

Рузанова йокысыннан уянган, ләкин тормыйча ята иде әле. Ишек ачылган тавышка башын борып карады:

— Ә-ә-ә, Шәфкать, сәламәтләнеп җиттеңме инде, акыллым?

— Ие, Пурия Сандровна!

— Яхшы... кияүгә чыгарга ниятләмисеңме соң әле?

— Бер авыз пешкәч инде...

— Өреп кабарсың икенче юлы, матурым. — Пурия дәртләнеп көлеп куйды.—Монда бер егет килеп сиңа записка калдырган иде. Рузанова чалкан яткан килеш кенә мендәре астыннан урталай бөкләнгән конверт чыгарып Шәфкатькә сузды.—Укып җиффә-әр кычкырып. Үземә укырга вакыт тимәде. Кичә күрше бүлмә кызлары янында банкетта булдым лабаса.

— Күңелле булдымы соң?

— Һи, булмаган кая!.. Йә, укы! Укы!.. Минем дә күзләремнән яшь чишмәсе агып карасын әле бер.

Шәфкать конвертны ертып, эчтән кош теледәй кәгазьне алып шыпырт кына укый башлады.

"... Әти белән әни мине өйләндермәкче булалар. Кәләш тә табып куйдылар инде. Ләкин мин синнән башка берәүгә дә өйләнмәячәкмен. Ә әти белән әни минем сиңа өйләнергә ниятләвемне тыңларга да теләмиләр. Шуңа күрә мин авылдан китәргә мәҗбүр булдым.

Син мине көт Шәфкать. Озакламый яныңа кайтырмын..."

Соңгы җөмләне укый башлаганда, Шәфкатьнең кайнар күз яшьләре хат өстенә тамып-тамып киткәләде. Кыз шыпырт кына елый иде. "Син мине көт... Озакламый кайтырмын",—дигән бит.

Шулчак ишек шакыган тавыш ишетелде.

— Керегез,—диде Пурия.

— Атасы... атасы дим...

Ир кеше күзләрен ачып җибәрде һәм мендәреннән башын калкытты. Тулы түгәрәк ай, урамны, кырларны гына түгел, өй эчен дә ярыйсы ук яктырткан иде.

— Ни булды? Ник уяттың мине, анасы?

— Китмә... китмә, дип, елыйсың ич, ир башың белән, мышык-мышык.

— Саташып елаганмын инде. Ә син ник йокламыйча калҗаеп утырасың әле?

— Гаҗәеп сәер төш күрдем мин, атасы. Имеш, безнең өйгә Сания белән ике яшьлек малай күтәргән бер хатын килеп керә. Ә мин мичтәге күмерләрне чуенга тутырам икән. Бер күзем күмерләрдә, бер күзем тегеләрдә: ни уйларга да белмим. Шунда ят хатынның баласы ачыргаланып елый башлады. Сания, теге матур бала елавыннан туктасын дип, анарга конфет бирде. Бала конфетны алды да, идәнгә ташлады, тагын да катырак итеп еларга керешге "Бу сихерче хатын,—диде Сания.—Ул Корычнурны бозган..." "Мин Корычнурны үлеп яратам",—диде балалы хатын. "Юк, юк, Корычнурны мин яратам!"—диде Сания. Шул вакыт өйгә ап-ак сакаллы бер бабай килеп керде: "Нигә бәхәсләшәсез, балакайларым? Нәрсә бүлешә алмыйсыз?"—дип сорады ул Сания белән балалы хатыннан. Тегеләр Корычнурны ничек итеп ратуларын сөйләп бирделәр. Аларның һәркайсы Корычнурга кияүгә чыгарга тик үзен генә хаклы санады. "Аңлашылды,—диде бабай.—Сез безгә Корычнурны ничек итеп яратуыгызны сөйләп бирдегез, ышанырга була. Инде хәзер безгә менә шушында Корычнурны ничек итеп яратуыгызны күрсәтеп тә бирегез"... "Яратуны күрсәтеп буламыни аны?"—дип кычкырып җибәрде Сания. Балалы хатын дәшмәде. "Була!"—Бабай мичтән кыскыч белән утлы күмер алып, Саниянең учына салды. Аннары шундый ук күмерне балалы хатынның учына төшерде. "Инде хәзер кулыгызны йодрыклагыз"... Бабай соңгы сүзен әйтеп тә бетермәде, Сания учындагы утлы күмерне сулы чиләккә ыргытып та бәрде. Ә балалы хатын... кулын йодрыклады: башта елмайды, аннары көлемсерәде,—ни гаҗәп, малае да елавыннан шып туктады... Бабай миңа таба борылып: "Менә бу балалы хатын гына сезнең улыгызга мәңге тугрылыклы булып яшәячәк!"—диде. Шуннан мин уянып киттем...

— Ала-а-ай,—дип сузды ир кеше уйчан гына.

— Атасы, әллә мин әйтәм, икесен дә кайтартыйкмы икән үзебезнең янга, йөрмәсеннәр читтә интегеп...

— Элек күрим әле мин ул хатынны,—диде ир һәм урыныннан торып, ишегалдына чыкты. Баш турысында, күктә балкып торган айга карап алгач, тәмәке кабызды да, баскыч төбенә утырды. Тиз-тиз генә тартып бетерде һәм төпчеген ботинка үкчәсе белән таптап-изеп сүндерде. Барып капканы ачты. Матайны урамга житәкләп чыгарды. Бераздан инде ул кара урманга таба җилдереп китеп бара иде.

Керүче кеше Корычнурның әтисе иде.

Шәфкатьнең йөрәге кинәт нидер сизеп, тынычсызланып, дөпелдәп тибә башлады. "Минем янга килүе микәнни?—дип уйлады ул.—Юк, эш буенча—йомышы төшеп түгел, ә Корычнур хакында сораштырырга! Сораштырса, сораштырыр инде... мин Корычнурга кияүгә чыкмадым бит әле! Дөресен генә әйткәндә, минем бу абзый каршында йөзем ак, күңелем пакъ!"—Шәфкать эчтән үзен шулай дәртләндерсә дә, тыштан исә кыяркыймас кына ир кешегә карады. Ир кеше дә яшькелт соры күзләрен кыса төшеп, эчтән зәһәр елмаеп, анар текәлеп карады. "Бер түгел, мең нәләт... сиңа явыз хатын!"—ди иде кебек абзыйның бу утлы карашлары.

— Шәфкать!—дип эндәште Пурия тавышын күтәрә төшеп.

— Нәрсә?

— Тимергали абыйга урындык тәкъдим ит: басып тормасын инде, олы кеше ич ул!

— Рәхмәт!—диде ир кеше.—Мин бирегә утырмага килмәдем. Миңа... завсклад хатын кирәк иде.

— Мин булам ул завсклад хатын!—диде Шәфкать.

— Биш минутка гына чыгып кер әле, сеңелем, миңа синең белән... сөйләшергә кирәк...

— Килен, балакай—дип әйт, Тимергали абый,—диде Пурия елмаеп.

— Күпне беләсең Сандровна, тиз картаерсың,—диде ир кеше

ачуланмый гына һәм ишектән чыкты.—Мондарак кил, сенелем. Исемеңне ничек дидең әле?

— Шәфкать дидем ич!

Ир кеше стенага сөйләде:

— Исемең җисемеңә муафыйкмы соң синең? Шәфкатьлеме соң син, кызым?

"Нәкъ Корычнурга охшаган бу абый... Корычнурның әтисе бит инде ул... Олыгайгач Корычнур да әтисе шикелле юан булырмы икән?" Шәфкать елмайды. Ир кеше дә көлемсерәде. Әлеге балалы хатынның уч төбендә утлы күмердән калган җәрәхәт эзен күреп алган иде ул. Аның күңелен шул мизгелдә кызыксыну биләп алды:

— Уч төбендә нинди җәрәхәт эзе ул, сеңелем?!.

— Минем кыйблам билгесе бу!—диде Шәфкать.—Мин Корычнурга мәңге тугрылыклы булырга дип шулай үземчә ант иткән идем!

— Урманга барыпмы?!

Шәфкать оялып башын түбән иде.

Ир кеше кесәләрен актара башлады. Шырпы белән тәмәке чыгарды. Кабызып җибәрде.

— Кызганычка каршы, чәчәк гомере бик кыска шул!—диде абзый, ниһаять. Ул саубуллашмый—нитми генә тулай торактан чыгып китте.

Шәфкать үз бүлмәсенә керде, ишекне эчтән бикләде дә мендәренә капланды. Озак итеп, сулыгып-сулыгып елады ул. Тәнне пычак белән кисеп, ярасына тоз сипсәң дә болай ук телгәләмәс иде кебек бәгырьне. Хәер, пычак ярасы кайчан да бер төзәлә ул, ә тел ярасы? Тел ярасы—юк!..

Уйланып, газапланып ята торгач, авыр нәрсә күтәреп барган кешедәй кинәт хәлсезләнеп, йоклап китүен дә сизми калды Шәфкать. Ул төш күрде. Урман эчендәге бер өйдә Корычнур белән икәү кара-каршы чәй эчеп утыралар, имеш. Улы Болгар идәндә мүкәләп уйнап йөри. Малай шундый шат, шундый көләч: бит урталарын чокырайта да, Корычнурга: "Әти!" ди "Хәзер, улым!"—ди Корычнур. Эчә башлаган чынаягын өстәлгә кире куеп урыныннан тора да, малайны күтәреп түшәмгә чөя. Тотып ала. Тагын чөя. Болгар рәхәтлектән кыты-кыты итеп көлепме көлә, имеш. Бу күңелле шау-шуга Шәфкать тә катышып китмәкче була. Әмма өлгерә алмый кала, ишектә (йә, Хода!) Корычнурның әтисе пәйда була. Абзыйның гүя йөзендә кан әсәре калмаган, күзләренең нуры юк. Менә ул Корычнурның каршына ук басып: "Нишләп әле синең улың булсын... кеше баласы бит бу!"—дип кычкырып җибәрә. Корычнур дерт итеп китә һәм кулында малай барлыгын да онытып, башына тотына. Болгар, җан ачысы белән кычкырып, идәнгә мәтәлә.

— Ай, улым... бәгырем...

Шәфкать иңрәп, ыңгырашып уянды. Бу коточкыч хәлнең төштә генә булуын белгәч, шатлыгыннан елап җибәрә язды.

Шәфкать эчке киемнәрен алыштырып кигәч, көзгегә караган иде— егылып китә язды: йөзе тәмам акшарланган моржа кебек булган ләбаса! Райпода, аның турында, тагын әллә ниләр уйларлар инде!

И, уйласалар уйларлар! Авырды ич ул. Авырган кешенең хәле билгеле инде аның..

Шәфкать өстенә гади вә очсызлы тукымадан тегелгән кыска җиңле күлмәген киде, ишекне бикләде һәм ачкычын Нуриягә кертеп бирде.

* * *

— Исәнмесез, Кәрим Фәсихыч.

— Исәнме, сеңлем, эшкә килүеңме инде бу?

— Әйе, Кәрим Фәсихыч.

Директор сәгатенә карап куйды:

— Алайса болай эшлибез, сенелем. Чистайдан төнлә баржа китерделәр. Хәзер Гыйлемханга утырып Алан авылы янындагы тугайга төшәрсең дә безнең берләшмәгә тиешле товарларны складына ташый башларсың.

— Ярар, Кәрим Фәсихыч!

— Туктале сеңлем,—диде директор.—Менә бу язуны Пуриягә тапшыр әле. Ул анда минем өстән каманда бирә бугай...

Шәфкать, Гыйлемханга утырып Кама буена килеп тә житте. Алан авылы янәшәсендәге үзәнлектә гүя сабантуе... Биредә тик озын ак колга һәм колга очына бәйләп куелган сөлге генә юк иде. Әнә, калын тимер трап буенча ЗИЛ-130 арты белән баржага якын ук килеп туктаган. Ана, тәннәре кояшта янган һәм тозлы тир белән пешеп кап-кара төскә кергән, сары, коңгырт вә кара чәчле ирләр шешәле әржәләр төииләр. Ә түбәндә, баржа идәнендә исәпсез-хисапсыз буш аракы, сыра һәм “шифалы су” шешәләре төрлесе-төрле кыяфәттә аунап ята. Эчеп тә күрсәтәләр соң бу женнәр, әй-йәй!... Әнә тагын бер ЗИЛ-130, су буенда, тегесенең төялеп бетеп китеп баруын көтеп тора. Бу 1973нең августы иде. Бу чорда зур-зур КамАЗлар юк иде шул. Чиратта торучы машиналарның күпчелеге ГАЗ-51ләр иде. Сирәк-сирәк кенә булса да ГАЗ-52ләр һәм ГАЗ-53ләр дә күзгә чалынгалый. Бер читтә, вәкарь белән генә килеп туктаган берничә ак “Волга”, кызыл “Жигули” һәм яшел “Москвич”ның хужалары, әлбәттә, “зур кешеләр”—райком заказының бөртеге дә читкә шумавын, тулысынча райком складына кайтып урнашырга тиеш икәнлеген, нәфис ак куллары белән хәтәр элмәкләр ясап күрсәтә-күрсәтә, Пурия Рузановага сеңдереп маташалар. Пурия, утызны яңа гына тутырган кыз кеше, райком кебек дәрәжәле исемне ишетсә, дә, әлләни сыгылып төшми. “Тегесеннән берничәне генә үземә алам әле”,—дип, кабатлапмы кабатлый. “Юк, алмыйсың”...—диешәләр райком вәкилләре нәзек бармакларын селки-селки янап. Һәм... “карагыз аны!!..” дигәндәй, як-якларына ялт-йолт каранып, үтә эшем кешеләредәй, машиналарына утырып, тиз-тиз генә китеп баралар. Берничә минуттан чират көтеп ятучы халык райком заказының тулы исемлеген белеп ала. Менә алар: югары сортлы бодай аракысы—фәлән йөз шешә; рислинг, бальзам, кыйммәтле коньяклар—берничә йөз шешә; ак вино—берничә йөз шешә... Ләкин халыкның моңа әлләни исе китми. Чөнки ул заманда аракы-винонын очсызракларын да, һәр ашамлык кибетендә, жаның теләгән чаклы сатып алырга була иде...

Шәфкать баржа янына килде. Райпоның өлкән товароведы янында басып торган Пурия Рузанова амбар кенәгәсенә ниләрдер язып маташа иде. Шәфкать аңа Кәрим Фәсихычның запискасын суздьл. Сандровна язуны күз йөгертеп укып чыкты да:

— Алай бик оста булгач, Кәрим Фәсихыч килеп житәкчелек итсен монда, ә мин конторада үз эшләрем белән шөгыльләнәм,—диде.

— Чакырмагыз аны, кирәкми, бәйләнчек ул...

Шәфкать, каян килә икән бу тавыш, таныш та кебек үзе дигәндәй, як-ягына каранып куйды, ләкин якын тирәдә бер кемне дә күрмәде. Пурия түбәнгә таба карап елмайды. Баксаң, үзәк складның мөдире Захар Иваныч трап астына, күләгәгә төшеп яткан да, кечкенә генә тишек аша дәрман гына биреп тора, имеш. Зур кызыл борыны өстенә пластмасс кысалы күзлеген атландырып кигән. Бил тиңентен чишенгән. Симез йонлач күкрәген салкын су белән чылаткан. Сулъяк беләгендә шәрә хатын татуировкасы... Түбәндәрәк: “Вот она, любовь моя!” дип язылган. Захар Иваныч тагын бер мәртәбә:

— Кирәкми, килмәсен,—дип кабатлады да трап өстендә, ГАЗ-52 әржәсендә тирләп-пешеп товарларны жайлап урнаштырып маташкан шадра йөзле шоферга эндәште:

— Машинаның номеры?..

— 09-54.

— Тәк... путевка!..

Шофер тишек эченә, Захар Иванычка путевкасын сузды. Мөдир

склад кәгазенә ниләрдер сызгалап куйды да, йөк төяүчеләргә кычкырды.

— Бөркетләр, тыңлагыз... Кондитер әйберләре, фәлән хәтле, дөресме?

— Так-точно!

— Макарон?..

Аннары Захар Иваныч тишек аша шоферга биш нөсхәдән торган транспорт-товар накладнойлары сузды:

— Кулыңны куй!—Шуннан соң мөдир трап астыннан чыгып, машина әрҗәсендәге товарларны тагын бер мәртәбә үзе тикшереп ала да янә түбәнгә, кояш күрми торган урынга төшеп ята. Кайвакыт гырлап йокыга да китеп куя. Мондый чакта тиз генә уятам димә инде аны!

— Министрларның да иң баш министры кебек бу Захар Иваныч,— диләр хатын-кызлар уенын-чынын бергә кушып. Ул үзе ата үшән булса да ялкауларны сөйми—гади халыктан: трактористлардан, пешекчеләрдән, дуңгыз карауччылардан көләргә—алар турында әллә нинди әкәмәт мәзәкләр чыгарып сөйләргә ярата. Захар Иваныч, бигрәк тә, кияүдән аерылган яшь, чибәр хатынның... хыянәтен авыр кичерә иде. Менә әле дә ул, чираты җитеп, Гыйлемханны трапка керткән Шәфкатькә яшелле-күкле тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Әй! Кая чиратсыз?!. Шоферыңа әйт: машинасын читкә чыгарып куйсын!!.

— Захар Иваныч, мин бит...—дип гаҗиз калып эндәште Шәфкать.

— Тыңлыйсызмы—юкмы, ә?!.

Бәхәстә, әлбәттә, үзәк склад мөдиренең өстен чыгачагы билгеле иде инде. Шәфкать үзенең көчсезлегеннән гарьләнеп, елар дәрәҗәгә җитеп, читкә китеп барды. Аның урынына трапка Көмеш Елга авылы кибетчесе (Корычнурның әтисе) килеп керде.

Тимергали абзый артыннан чиратта торучылар Шәфкатькә кызганыч итеп карап куйдылар.

“Карагыз, әйдә, карагыз,—дип уйлады Шәфкать яшь аралаш елмаерга тырышып.—Менә мин инде ул кияүдән кайткан яшь балалы хатын... Йә, карап туйдыгызмы? Тагын карыйсыгыз киләме?”

Шәфкать яр читенә килеп, үлән өстенә чүгәләде дә, баржадан бушатылган өемнән түгәрәк, яссы чуерташлар алып, салмак кына Кама суына ыргыта башлады. Юк, тын буадагы яки күлдәге кебек, чуерташларны сикертә-сикертә, гаҗәеп боҗралар ясап булмый иде биредә... Дулкыннар бер-бер артлы, әллә каян, әчтән, ерактан, ярга таба ябырылалар да ябырылалар... Тәннәргә дымлы һава килеп сылана, борынны тере балык исе ерып керә... Аннары дулкыннар хәлсезләнеп кире чигенәләр; су чите тагаракта сабынлап кер юган шикелле күбекләнеп кала.

Чуерташлар, дулкыннарга бәрелеп, чулт итәләр дә төпкә чумалар... Кама үзе ерактан ак кебек, ә якынрак килеп карасаң, аның суы яшькелт сары төстә. Зур елга суы бервакытта да саф, үтә күренмәле булмый шул, дип нәтиҗә ясап куйды Шәфкать. Ә диңгез суы нинди төстә була икән? Шәфкатьнең әле чын диңгезне үз күзләре белән күргәне юк иде. Хәер, диңгез күрү генә бәхетле итәме икән соң әле ул адәм баласын!

Шәфкатьнең күзалдына яшенле, яңгырлы төн, урман эчендәге шалаш һәм ярым шәрә Корычнур килеп басты. Корычнурның тыгыз мускуллы беләге Шәфкатьнең йомры күкрәкләренә тиеп-тиеп ала.

... Корычнур кулларын сузып кочакларга итәм дигәндә генә, Шәфкать сискәнеп китте, уйларыннан арынды һәм, ялт кына баржа ягына карады. Тимергали абзыйның ГАЗ-52се инде, әрҗәсенә түбәләмә товар төяп, траптан чыгып бара иде.

— Гыйлемхан абый!—дип эндәште Шәфкать, машинасы астына, кояштан качып, ял итәргә кереп яткан шоферга.

Гыйлемхан, астан, иренеп кенә килеп чыкты. Иснәнеп, сузылып киерелә-киерелә:

— Ай-яй, машиналар күп тә соң! Саескан кичүендә паром көтәләрмени!—дип куйды.

— Чират безнеке хәзер. Машинаңны трапка керт тизрәк.
— Барыбер куып төшерәләр ич...
Өрлектәй ирнең мәлҗеп, югалып калуы Шәфкатьнең ачуын күпертә генә төште. “Их, ир исемен күтәреп йөрисең, ичмасам, син дә”... диде ул эченнән генә. Һәм җәһәт кенә ишекне ачты да, менеп руль артына утырды. Кайчандыр, машина йөртү һөнәренә иреннән өйрәнеп калган иде ул. Белем менә кайда кирәк булып чыкты! Шәфкать машинаны, күз ачып йомган арада, трапка кертеп тә куйды.
Чират житкәнен көтеп торучы ирләр, хатын-кызлар, нидер сизенеп, сагая калдылар. Ләкин түбәннән... боерулы аваз ишетелмәде.
...—Уф!—диде Шәфкать, баш авыртуын басарга теләп, бармаклары белән чигәләрен кысты. Көнозын Кама буенда, көйдергән кояш астында баржага чират торулар, товарны алып кайтып складка бушатулар, кибетчеләр килми калган авылларга товар озатып җибәрүләр—һәммәсе дә Шәфкатьне эт итеп арыткан иде. Ул складын бикләп тулай торакка кайтырга чыкты. Үзәк складлар янәшәсеннән узып барганда, кызыл “Жигули”ның кузовына сөялеп басып торган, кияү егетедәй итеп киенгән Захар Иваныч Шәфкатькә эндәште:
— Шурочка! Туктале, күгәрченем...
“Кемгә әйтә соң бу!” Шәфкать як-ягына каранып куйды, ләкин беркемне дә күрмәде.
— Нәрсә кирәк соң сезгә миннән?—дип сорады ул.
Захар Иваныч “Жигулие”нең уңъяк ишеген ачты:
— Кереп утыруыгызны үтенәм!
— Рәхмәт! Җәяү дә кайтырмын әле, аякларым юлны саташтырмаслар!
— Әйбәт машина дип мактыйлар моны, Шурочка! Баш тартмагыз, утырыгыз, мәңге үкенмәссез! Утырыгыз инде...
Захар Иваныч—чыгышы белән Воронеж ягыннан—үзеннән егерме яшькә олы хатынга йортка кергән кеше. Аның хатыны район банкының управляющие—бик шәп киенеп, ясанып йөрергә ярата торган мөлаем йөзле, чәчләрен буяткан, зифа буйлы ханым, таныш-белешләречә шикелле итеп әйткәндә, Надежда Игнатьевна—бик тә сәер кеше. Хезмәт урынында ул тырыш, булдыклы, кем әйткәндәй, таш астыннан чыккан ханым инде менә. Ә өендә ялкауның да ялкавы... Захар Иваныч та шундый: киенеп, ясанып йөрергә ярата, хәтта бизәнә дә әле, хезмәт урынында ут та ут, ул да ут, ә өенә—хөрмәтле Надеждасы янына кайткач—дуңгызга әверелә дә куя. Монда икәүдән икәү генә калгач, аларның яшь аермасы сизелми дә диярлек. Әйтик, ярым шәрә Надежда Игнатьевна (аны кияүдәге ике кызның анасы димәссең дә), гәүдәсен шәм кебек итеп, зал аша йокы бүлмәсенә таба китеп барганда, Захар Иваныч ботинкаларын да салмаган аякларын өстәлгә куйган килеш, күн креслосында киерелеп, авызын чәпелдәтеп иснәнә дә, теләр-теләмәс кенә торып чишенә башлый. Ул киемнәрен теләсә кая ташлый, ботинкаларын кайчакта хәтта сервант шүрлегенә, алтын йөгертелгән фарфор чәшкәләр һәм бәллүр савытлар янына да куеп калдыргалый... Аннары ул, ат сыман, пошкыра-пошкыра, Надежда Игнатьевна янына, яшел атлас тышлы, йон юрган астына, җылыга кереп ята. Ә Надежда Игнатьевна исә, гадәттәгечә, тавык кебек кытаклый-кытаклый, Захар Иванычның гайрәтен уятырга керешә. Шулай төн үтә, таң туа. Затлы җиһаз белән аяк басар урын чак-чак кына калган өй эченә ачык ишектән (ә аны мәче чыгып ачык калдырган була) чебешләр кереп тула... Башта Захар Иваныч уяна, аннары Надежда Игнатьевна күзләрен ачып җибәрә. Кайдадыр әтәчләр кычкыра, кәҗәләр микелдәп куя. Юрган эчендә җылы, рәхәт. Һич кенә дә торып, чебешләрне өйдән куып чыгарасы килми. Менә бер чебеш, кыюланып китеп, Захар Иванычның башына менә дә, чәченә кәкәйләп куя. Надежда Игнатьевна тетелеп көлеп җибәрә. Ул да булмый, ниндидер ак сыеклык Надежда Игнатьевнаның борынына да чәпелдәп килеп төшә. Инде бусында Захар Иваныч ыржая: ха-ха-ха...
Менә шундый әкәмәт кешеләр алар.

Шәфкать саран гына елмаеп куйды. Әгәр дә Надежда Игнатьевна, Захар Иваныч машинасына яшь, чибәр хатын утыртып, билгесез тарафка китеп югалды дигән хәбәр ишетсәме... бетте инде: биштәреңне җилкәңә ас та, Воронежыңа кире кайтып кит. Ләкин Захар Иваныч үтерсәләр дә Воронежга кире кайтмаячак инде. Анда аны кем көтеп тора? Ул бит кечкенәдән балалар йортында тәрбияләнеп үскән. Аңа кая барса да, кайда яшәсә дә барыбер. Әйе, ул армиягә алынып, Казанда хезмәт итә башлагач, Даша исемле кыз белән танышты. Даша аны, көннәрнең берендә, әнисе белән таныштырырга дип, Балык Бистәсенә алып кайтты. Ә иртәгесен сержант Захар Иваныч үзенең Дашаның әнисе, Надежда Игнатьевнаның җылы, йомшак кочагында иркәләнеп ятуын күрде... Шулай итеп, киләчәккә сукмак салынды, Захар Иваныч Надежда Игнатьевнаның ике катлы агач йортында хуҗа булып яшәп калды...

— Аннары ул армия хезмәтен тәгәлләп, Балык Бистәсенә—Надежда Игнатьевна янына кайткач, башта милициядә эшләде. Аннары ул, үзәк складка—промтовар бүлегенә, Надежда Игнатьевнаның бер туган энесе янына, кладовщик булып урнашты. Ә хәзер, ашамлык әйберләре үзәк складының мөдире!

— Йә, утырыгыз дим бит инде... нигә ялындырып торган буласыз?

Захар Иванычның соры-яшькелт болганчык күзләре, майга юлыккан мәченеке шикелле, ялт-йолт итеп торалар иде.

— Инде нишләргә миңа хәзер?!—дип уйлады, бер бите ай, бер бите кояш хатын, көтмәгәндә генә кыен хәлгә таруын аңлап. Чөнки моңарчы Захар Иванычның нәфесе төшкән матур хатыннарның берсенең дә судан коры чыга алганы юк иде!

Мәгәр, Аллаһы Тәгалә бар бит ул: әнә, бирегә таба кемдер килә!

Чыннан да, ерактан ук рәхмәт фәрештәсе булып күренгән кеше якынлаша-якынлаша Корычнурга әверелде.

... Тулай торакның акка буялган тәрәзәсеннән, ай балкып күренә. Ай тирәсендә, мәгәр шактый гына еракта вак-вак йолдызлар җемелдәшәләр.

Болар—Корычнурга гына күренәләр. Ә Шәфкатькә бары тик, тәрәзәдән үтеп кергән ай яктысында, бүлмәнең бер өлеше һәм түшәм генә шәйләнә.

Шәфкать үзен поездда барган сыман хис итә: әкрен генә тирбәлә, чайкала һәм аның белән гүя бүлмә дә тирбәлә, түшәм дә чайкала...

Корычнурга исә, ай тирбәлә һәм йолдызлар чайкала кебек тоела. Шуннан егетнең эчендәге "мин"е тернәкләнеп китә: Молодец! Айны син тирбәлдерәсең, йолдызларны син чайкалдырасың бит, янәсе.

Шәфкатьнең уйлары башкачарак иде: "Җитәр!—диде ул. —Артык майлыланып китәр, җә... Ардым дигән булырмын. Ялынсын, ялварсын әле. Менә шул вакытта мин аңа бөтен булган гөнаһларымны да сөйләп бирермен. Гафу итәрме-юкмы, белмим. Аның каравы, мин тынычланып калырмын!..."

Ниһаять, Корычнур торып, кабалана-кабалана су эчте, аннары тышка чыгып тартып керде. Шәфкать, һаман да булса аннан наз көткәндәй, таралып бетеп ята иде әле. Корычнур уйлап куйды: хатыныңны канәгатьләндерә алмасаң, азакта бу турыда исеңә төшерә-төшерә ул сине гомере буена газаплап яшәячәк, дип. Шул хәл булмасын дисәң...

Шәфкать тә гүя Корычнурның уйларын укып ята. Ул: ну, дәрт тә соң үзендә... тәмам тирләтеп бетердең, дигән булып, уң аягын юрган өстенә бөкләп куйды һәм:

— Кил инде, кил! Мин бит сине бик-бик сагынып көттем, Корычнур, бәгырем, минем сиңа сөйлисе сүзләрем дә бар әле,—диде.

Ул кыйссасын салкын канлылык саклап түгел, киресенчә, Корычнурны үбә-назлый сөйләргә кереште. Ә керешкәч инде... Әйтәләр бит: керешкән эш, беткән эш, дип... Керешкәч, хәтта сөяркәләренең сөяркәләре турында да белгәннәрен сөйләп бирде. Һәм Корычнур читкә чыгып киткәч кенә танышкан иң соңгы сөяркәсенең район эчке эшләр бүлеге

тикшерүчесе икәнлеген дә чишеп ташлады.

Корычнур сикереп торганын да тоймый калды:

— Син... нәрсә?! Шаяртасыңмы әллә?!

— Ю-ук, Корычнур... шаяртмыйм,—диде Шәфкать, тыныч кына,— мин сиңа бары тик дөресен генә сөйләдем! Мин бит, кайчандыр ки, алтын-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле Кадрия исемле кыз идем. Әйе-әйе... Һәй, нигә алай сәерсенеп карыйсың, жаным? Чәчләрне... буяттым менә! Тырыша торгач, күзләрне каралтырга да өлгердем, бер врачны сөяркәм итеп! Ә исем алыштыру бездә проблема түгел ич!..

Корычнур ни әйтергә дә белмичә, бер мәл "кыз"га текәлеп, карап торды. Аннары әкрен генә:

— Ай, Шәфкать, әллә нинди сәер, ят булып киттең әле син! Без бит... алай килешмәгән идек!.. Болай килеп чыгарлык булгач, нигә алдап йөрдең син мине?!—дип куйды.

Шәфкать торып киенә башлады:

— Нишләп алдыйм ди! Тәти күрсәтеп алдарга баламыни син?!

Корычнур болдырга чыгып басты. Көнчыгыш тарафта сизелер-сизелмәс кенә булып таң атып килә иде. Егет тәмәке кабызып җибәрде: "Менә сиңа әйбәт, чибәр "кыз", булачак яхшы ана!!!—дип уйлады исе китеп.—Баксаң, Шәфкать барып чыккан фәхишә икән!"..

Корычнур тулай торак өйалдыннан матаен урам чатына алып чыгып утырды да, күзе күргән якка китеп барды. Озакламый юл аны Балык Бистәсенең уң ягына—Каманың иң биек яры буена китереп чыгарды. Моннан хәтта, еракта, бик еракта, Көмеш Елга колхозы биләмәләренә керүче ак ярлар да, уч төбендәгедәй күренәләр иде.

Егет комсызлана-комсызлана тәтен суырды. Инде хәзер аның күз алдына әти-әнисе килеп баскан иде.

— Сиңа, улым, Сания таман гына инде!—ди, имеш, әтисе.

— Саниягә өйләнсәң бетеп уңарсың инде, улым!—ди икән әнисе. Көтмәгәндә генә пәйда булган Саниянең әнисе дә:

— Мунчагыз салынып бетте. Өегез яңа, шәп. Әти-әниең дә синең өчен үлеп тора. Тот та өйлән кызыма!—ди.

Ә Сания... түбән урамда яши, сыер савучы булып эшли. Сары чәчле, күе коңгырт күзле ул. Үзенең болай килмәгән җире дә юк шикелле инде. Әле мин аны, кайчандыр ки, җаен-чарасын табып, өч мәртәбә озатып, бер тапкыр әйбәт кенә итеп суырып үпкән дә идем! Шуннан соң авылда: "Корычнур Бакир Саниясенә өйләнә икән!"—дип тә сөйләделәр. Ләкин тора-бара эшләрнең көе китте. Арага һич көтмәгәндә чем кара күзле, шомырттай кара, куе чәчле Шәфкать килеп керде дә...

Егет, тәтен суырырга дип, тәмәкесен авызына китергән иде, шул мәлне ниндидер тупас, кыргый көч аны, матае белән бергә чөеп түбәнгә ташлады!

Егет соңгы мизгелдә шәйләргә өлгерде: тау өстендә өр-яңа зәңгәр "Жигули" тора иде.

Шуннан... барысы да юкка чыкты.

## Икенче башлам

Борис Сергеевич командировка йомышлары белән зәңгәр "Жигули"енда килеп чыкмаган булса, Екатерина Павловна әле һаман Балык Бистәсендә "ысланып" яткан булыр иде.

Шулай... алар һич көтмәгәндә очраштылар да, аннары парлашып, Казакъстан якларына юл тоттылар—аэродром төзелешенә. Баксаң, Борис Сергеевич бу өлкәдә зур белгеч икән!

Шулай итеп, Екатерина Павловна—язмышына бәхет елмайган бер

көндә—начальник хатыны булып китте. Дөрес, алар языльшммый-нитми генә яшәделәр. Әмма бергә яшәделәр! Борис Сергеевичның элеккеге никахлы хатыны исә, балалары белән Пермьдә, әнисе янында торып калган иде. Борис Сергеевич ай саен гаиләсенә шактый күләмдә акча җибәрде. Күрәсең, шул акча-фәләнгә Пермьдәге гаилә канәгать иде.

Казакъстанда Борис Сергеевич яшь хатынын, дөресрәге, сөяркәсен бухгалтерлар курсында укытып, аннары үзе җитәкләгән оешмага бухгалтер-ревизор итеп урнаштырып куйды. Шулай эшләре җайлы гына бара иде дә бит... Ләкин, аэродром тулысынча төзелеп беткәч, үзәк Борис Сергеевичны тагын урыныннан кузгатты—Өфегә күчерде, шулай ук яңа аэродром төзелешенә!

Аннан соң—Куйбышев, Тольятти, Чаллы...

Һәм, ниһаять, алар—Казанда!..

* * *

Таң беленеп килгәндә Айгөл тәрәзә шакып Актимерне эчкә чакырып алды. "Хәлем начарланып китте. Бүген эшкә бара алмам ахры. Үләм!"—Айгөл бер төн эчендә сулып калган ак йөзе белән түшәмгә таба борылып яткан һәм еш-еш сулый иде. Аның эчкә баткан ачык соры күзләре куркынып һәм ялварып карый. Яшь хатынның мондый хәлдә беренче мәртәбә генә калуы иде әле. Актимер ни кылырга да белмәде. Ул бер тәрәзәгә каранып, бер күмер тузаны каралткан кулларына төбәлеп чак кына уйланып торгач, үзе эшли торган поселокка атна элек кенә хатынын алып баруын хәтеренә төшерде. Юллар тигезле-тигезсез һәм кайбер урыннарда хәтәр генә сикәлтәләр дә бар иде. Ә Айгөл бит көмәнле! Әмма корсаклы яшь хатынга шул сәфәрдән кайткач та берни булмады кебек. Ул элеккечә мебель фабрикасына вакытында барып, вакытында кайтып йөри бирде. Анда сыйфат тикшерүчесе булып эшли һәм аның алай күңелне төшерерлек итеп зарланганы да юк иде. Ә бүген менә һич көтмәгәндә...

— Ни булды сиңа, Айгөл? Әллә цехта ялгышып кына берәр нәрсә күтәреп җибәрдеңме?

— Юк, бер нәрсә дә күтәрмәдем, Актимер. Миңа күтәрергә ярамый бит. Эчем менә... борып-борып...—Айгөл йөзен чытты, күзләрен йомды. Ул стенага таба борылып ятты да, кинәт йомгак кебек йомарланып, ыңгырашырга кереште.

— Сукыр эчәк-фәлән түгелме икән, Айгөл?

— Белмим... ай, әни, бәгырем!

— Дару биримме әллә? Авыруың басылып китәр иде, бәлки?

— Бу хәлдә миңа дару эчәргә ярамый лабаса, Актимер... Ай, әни...—Яшь хатын икенче ягына борылып ятты. Калын толымнарының берсе уңъяк беләге астында, икенчесе исә мендәр өстендә елан сыман бorгаланып калды. Аның юрганы аякларына тикле ачылып китте дә, Актимер күз алдында гаҗәеп сәер күренеш пәйда булды. Айгөл яткан урын яртылаш юеш иде. "Бәрәч! Нинди юеш бу?.."—Айгөл чак кына калкына төшеп, бая яткан урынына карады: "Эчтән су чыга ахры".. Ул хәлсезләнеп янә мендәре өстенә сыгылып төште. Бизгәк тоткан кебек калтырана башлады.

— Айгөл?—Яшь хатын күзләрен ачты, керфекләрен сирпеп иренә карады:

— Нәрсә?!

— Ашыгыч ярдәм машинасы чакырыйммы әллә?

— Кирәкми, Актимер, мәшәкатьләнмә... үтәр әле.

Әйе, Айгөл, Актимер кебек үк, калада туып авылда үскән кыз шул. Аның әти-әнисе дә олы инде, бик диндар кешеләр, авырып киткән чакларда, тәнгә энә кадатып терелүгә караганда, Ходайга ялварып сихәтләнүне мәгъкульрәк күрәләр. Шул нәрсә кызларының канына да тирән сеңгән булса кирәк!

Айгөл газапланып йөзен чытты, ике куллап эченә ябышты. Яшь хатынның кулларында кан тамырлары аермачык булып беленеп, зәңгәрләнеп тора иде. Гаҗәп тамаша! Бер ел элек кенә туйлап йөргәндә Актимернең кәләше нинди таза, йөзе нинди алсу, кочагы нинди кайнар иде бит! Аның бу кызулыгы хәтта Актимер шикелле таза-таза өч егеткә дә житәр сыман иде! Әмма чынлыкта исә алай булып чыкмады: өйләнешеп бергә яши башлауларына бер ел да үтмәде, Айгөл тәмам ябыкты, йөзеннән алсулык качты, битләренә куе булып сипкелләр сибелде, күзләре, элеккеге көләчлекләрен җуеп, ниндидер серле бер моңсулык белән карый башлады. Иң хәтәре—кочагының рәте-чираты сүрелде!

— Актимер, бәгърем?!

— Нәрсә, карчык?!

— Күрше әбине чакырып керәсеңме әллә?! Өшкереп караса дим, терелеп китәр идем, бәлки...

Чынлап та Айгөл шул юл белән терeләсенә ышана икән, нигә аның бу теләгенә каршы килергә? Актимер үзе дә бәләкәй вакытта бик каты гына чирләп китеп, исеме гади халык арасында гына түгел, олыолы түрәләргә дә билгеле булган авылдагы мәшһүр "табиб" карчыкны чакыртып өшкерткәч терелеп аякка баскан иде бит!

Яшь ир ишегалдына чыкты. Янгыннан соң калгандай, кап-кара күмер урынын кар явып агарткан инде. Бәдрәфкә илтүче сукмак та күмелеп өлгергән. Сарай почмагында җил өермәсе бөтерелә... Актимер морҗага төбәлде. Төтен чыгамы? Беленер-беленмәслек кенә булып чыга бугай! Әйе шул, Донбасс күмере диләр аны! Ул, әнә, мичтә, кызган тимер кебек, агарып янып ята...

Күрше әби өендә юк иде ахры, тәрәзә каккач та, ишекне дөбердәткәч тә эчтән аваз бирмәде. Җитмәсә, Актимернең үги апасы да өйдә түгел, кызы белән инвалид җизнәләрендә рәхәтләнеп яшәп ята булса кирәк. Әйе шул, анда су ташып чиләнәсе, мичкә брикет тузаны ягып мәшәкатьләнәсе юк. Ул әле үги энесенең бик әйбәт күмер алып кайтуын да белми торгандыр...

Узган ел Актимер Айгөлне ияртеп калага яшәргә килгәч, Таһирә аларны кочак җәеп каршы алган иде. "Ирем ир түгел, айлар, еллар буе командировкадан кайтып керми, кызым белән икебезгә генә күңелсез, бергә-бергә яшәүләре җиңел булыр",—дигән иде. Ләкин бергә яши башлагач, тормыш, Таһирә әйткәнчә, алай җиңел генә булып чыкмады. Йорт хуҗасы кирәгеннән артык вакчылланып китте, юкка-барга да бәйләнә башлады. Айгөл белән Актимергә бәләкәй бүлмәләренә кереп, бердәнбер караватка утырып, башларына ябышудан бүтән чара калмый бу вакытта. Әлеге тамаша исә Таһирәне икеләтә ярсыта. "Нәрсә, авызларыгызга су каптыгыз? Нигә минем сорауларыма җавап бирмисез? Бу сезгә авыл түгел! Кала бу! Кала! Монда, җыен җулик арасында һаман башыгызны түбән иеп кенә йөрсәгез башсыз калырсыз әле!"

Айгөл белән Актимер мәгънәле генә итеп бер-берсенә карашалар. Әнә ничек кыздыра-кыздыра яшәргә өйрәтә аларны үги апалары! Шул арада өч яшьлек Энҗе чәрелдәп җибәрә. "Нишләдең?!" "Кистем" "Ник орындың соң пычакка? Ахмак!" "Бәйлә!" "Ах-х..." Чалт иткән тавышка Айгөл белән Актимер сискәнеп китә. Таһирә бар көченә кызының яңагына менеп төшкәннән соң, ниһаять, гайре табигый хәленә кайта: ни үле, ни тере кызын тиз генә киендерә дә, күтәреп, җизнәләренә сыза.

Ике-өч көннән ишектә ялгызы гына пәйда була ул. Дүрт йә биш көн сөйләшми йөргәннән соң, алтынчы яки җиденче көнне берәр сәбәп табып, ызгыш-талаш чыгара. "Ник үзегезгә урындык алмадыгыз? Ник минем бүлмәмә кереп йөрисез? Минем утынны, минем брикетны ягасыз, оятсызлар!"

Айгөл белән Актимернең үз кайгылары кайгы әле. Менә ни гомер яшь хатынны ире янына пропискага кертмичә азаплыйлар. Әле сәүдә техникумында укып йөргән чагында ук Актимер үги апасы янына пропис-

кага теркәлгән иде. Аларга бу йортны, уртак итеп, әтиләре сатып алып биргән иде. Шуңа күрә Актимер авылга вакытлыча эшкә киткәндә дә биредәге пропискадан төшмәде. Хәзер, әнә, аларның кулында район советы рәисенең үтергеч җавабы. Имеш, бу йортка Таһирә генә хуҗа. Чөнки Актимер үги апасы янына пропискага бары тик фатирчы булып кына теркәлгән, шунлыктан ул әлеге өйгә берничек тә дәгъва кыла алмый икән! Менә ничек кыек атып туры тидерә белә ул безнең заман түрәсе. Апа белән йортны бүлешергә кирәк дигән фикер Актимернең башына да килеп караганы юк лабаса! Һәм аны нигә бүләргә? Болай да кемнең кем, нәрсәнең нәрсә икәнлеге бик яхшы аңлашылып тора ич.

Аңа бары хатынын үз янына пропискага гына кертергә кирәк. Алты ел инде әнә Актимернең паспортында кала пропискасы мөһере сугылып куелганга! Шулай булгач, яшь хатын ире янына пропискага кертелергә тиешме? Әлбәттә тиеш!

Таһирә һаман мыр-мыр килеп йөри. Айгөл бүлмәсендә мендәргә капланып, елап ята. Актимер исә, мич каршында, тәмәке өстенә тәмәке пошкыртып, уйланып утыра. "Әйе, апаның гаилә тормышы барып чыкмады. Ире читтә зур акча артыннан куып йөри бирә, типтерә. Шуңа күрә апа безнең тату яшәвебездән көнли, безне күрә алмый. Ә Айгөлнең хәле мөшкел. Пропискасы булмагач, аны бер җирдә дә эшкә алмыйлар. Ахыр килеп, мин аны үз яныма кибеткә алдырмакчы идем, вакытлыча гына эшләп торырга. Ләкин ОРСта Айгөлнең көмәнле икәнен белеп алдылар да, баш тарттылар: безгә корсаклы хатын кирәкми, диделәр. И Айгөл! Нишләргә инде синең белән, нишләргә???"

Ә тышта кар ява да ява. Мичтә, сасы ис чыгарып, брикет тузаны яна. Брикетның көле генә түгел, корымы да бик күп. Ул корым төтен юллыгыннан кызган һава белән өскә суырылып чыга-чыга да, түбәгә, күрше-күләннең элгән керләренә һәм ишегалдына төшеп куна, кар өстен кап-кара итә. Үткән-сүткәннәрнең аякларына ябышып урамга чыга яки өйгә керә, идәннәрне "матурлый". Шул брикетны яндыру аркасында күршеләрдән күпме әр, каргыш һәм янау ишетте Актимер. Ләкин нишләмәк кирәк, эт өрер, бүре йөрер дигәндәй, дөньясына кул селтәп, яга бирәсең инде. Өйне салкын тотып, радиаторларны шартлатып, күрәләтә катып үлеп булмый ич! Моны күршеләр дә аңлый, кер эләселәре булса кереп хәбәр итәләр, мичкә якмый торуларын үтенәләр. Ләкин каты салкыннарда өй тиз суына, мичкә өзлексез ягып торырга кирәк була иде. Андый вакытларда күршеләр керләрен кая чыгарып эләләрдер, шайтан белсен! Таһирә исә үз керләрен җизнәләренә алып китеп юа. Шуңа да ул чиләк-көянтә асып, урамдагы колонкага барып, катып-өшеп суга чират тормый. "Су миңа түгел, сезгә кирәк, сез барыгыз",—ди. Һәм бара Айгөл, икегә, өчкә бара, Актимер рөхсәт итмәсә дә бара. Аның зифа буена карап күршеләр шаккатып баш чайкап калалар. Ләкин алар Айгөлнең Актимергә карата көннән-көн суына баруын белмиләр иде шул...

Беркөнне кич, Актимер эштән кайтканда, Айгөл инде су ташып барча савыт-сабаларны мөлдерәтеп тутырган, мичне ягып өйне җылыткан: кабызлыкка утын таба алмагач, алты газет, узган айда чыккан "Казан утлары" белән "Азат хатын"ны ягып бетергән иде.

Актимер исәнгәндәй итте:

— Һай, тәмле ис чыгаргансың, карчык! Нәрсә пешердең?

— Пешерергә вакыт юк әле, карт, син алып кайткан тушонканы ачып, табада җылыттым инде.

— Ярый-ярый, тушонканы да көйдермичә генә җылыта белергә кирәк бит әле!—дигән булды Актимер, куе кара кашлары астыннан гына елмаеп. Айгөл бу юлы ачуланмый, иренең төртмәле сүзләренә кара коелмый, киресенчә авызын колакларына таба ерып җибәреп, чокырларга хуш исле чәй агыза башлады. Анысы да Актимер алып кайткан Һинд чәе. Гомумән, Актимер үтә юмарт ир булып чыкты. Ул эшли торган ОРСта җаның ни тели—барчасы да бар. Шуларның һәммәсен дә диярек,

аз-азлап кына булса да, Актимер өйгә алып кайтып тора иде. Болар өчен зур рәхмәт ана! Аннары тагын бер олы шатлыгы бар әле Айгөлнең.

— Мин бүген эшкә урнаштым!—диде яшь хатын сипкелле йөзендәге елмаюын тамчы да киметмичә.

— Ә? Пропискасызмы?

Айгөл көлеп куйды:

— Әйе, пропискасыз!

— Ничек алай?..

— Шулай инде, бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына... сыманрак килеп чыкты ул.

— Сөйлә әле...

— Ризыгың суына...

— Ашказанына барып төшкәч жылыныр әле, карчык, сөйлә!

— Тынла алайса... Бүген көндез эшкә урнаштыру бинасының коридорында, бер сөйкемле генә апа минем каршыма басты да, күзләремә туры карап сорау бирде. "Син авылныкымы, сеңелем?" "Әйе",—мин әйтәм. "Урта мәктәпне тәмамладыңмы?" "Әйе". "Эшкә урнашырга исәплисеңме?" "Әйе". "Пропискаң бармы соң?" "Юк шул". "Анысы начар икән менә!"—Сөйкемле апа мине култыклап бер читкә алып китте.— "Кияүдәме?" "Әйе", мин әйтәм. "Кияверң кайда эшли?" Мин аңа барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Сөйкемле апа шатлыгыннан хәтта минем иңбашыма төртеп алды. "Һи, болай булгач, эш эзләп мәшәкатьләнәсе юк икән сиңа, сеңелем, киттек әйдә, мебель фабрикасында әллә ничә төрле эш табам мин сиңа!"

Шулай итеп, әлеге апага ияреп киттем. Бу апа мебель фабрикасында кадрлар буенча инспектор булып эшли икән... Бара торгач, сөйкемле апа ничектер минем корсагыма игътибар итте. "Әллә, йөкleme син сеңлем?" "Йөкле шул, апа",—дидем мин. "Ничә айлык?" "Врач белешмәсе буенча, биш тулып, алтынчы айга китте инде". "Күп икән шул инде". "Болай булгач, мине эшкә алмыйсызмы инде?" "Белмим инде, сеңелем, ни әйтергә дә белмим... пропискага да кермәгәнсең ичмасам!"—Һәм инспектор апа текәлеп, ләкин ягымлы итеп миңа карап куйды. Мин түзмәдем, елап жибәрдем. "И, хәлең, чынлап та, мөшкел икән шул, бик кызганам мин сине... ярар, сеңелем, саулыгыңа шөкерана кыл, алам мин сине эшкә!".. Менә шулай итеп, мебель фабрикасына сыйфат тикшерүче булып, эшкә урнашып кайттым!..

Актимер, "булдыргансың, молодец" дип, хатынын кочаклап үпмәкче иде, Айгөл читкә тайпылып өлгерде.

— И, кыргый да инде син, карчык!

— Бушка гына кочаклап үпмәкче була, хитрый...

...— Өшкерүче әби өйдә юк,—диде Актимер хатынына. Айгөлнең күзләре кызарган. Елый инде әллә.

— Кайда соң ул?

— Белмим.

— И, ходаем... эчем... күңелем болгана...

— Ай, кан!!—дип кычкырып жибәрде Актимер коты очып. Ул ялан-баш, күлмәкчән генә өйдән чыгып, телефон-автоматка йөгерде.

— Алло!!

Врач ханым Айгөлгә сөзеп кенә карады.

— Все ясно, жыеныгыз, киттек!

Актимер хатынын житәкләп алып чыкты.

— Хәлең ничек?—Айгөл башын иренең иңенә куйды, газаплы төстә йөзен чытты. Аннары күзләрен йомды да, хәлсез тавыш белән:

— Әллә нигә үләрмен кебек тоела!—диде.

— Андый сүз әйтмә карчык. Иртә әле бу дөньяны ташлап китәргә. Яшәргә дә яшәргә әле безгә!

— Һи, яшәттең инде, бик... бер японский кремплин күлмәк тә

алып кайтып кигергәнең булмады...

— Гафу ит карчык! Әгәр дә малай таба калсаң берне түгел, икене алып кайтып куям мин сиңа!..

Актимер, Островский урамына таба борылганда гына, кемдер аңа эндәште:

— Әй, ир кеше, туктагыз әле!

— Караса—баягы сестра!

— Китмәгез, хәзер хатыныгыз бәбиләячәк!

Актимер, йөрәге каккан хәлдә, еларга да, көләргә дә белмичә, тукталып калды.

— Шулаймыни?! —дип кенә әйтә алды ул.

Шулай шул, хөрмәтле ир кеше!

Актимер, кире борылып, сестрага ияреп китте. Сестра арт ягына борылып яшь иргә карый, ни өчендер көлемсери һәм ашыга-ашыга атлый... Актимер хатынының сапожкиларын култык астына кыстырып, тәмәке кабызмакчы иде, шырпысы сүнде. Болак тарафыннан көчле җил исә иде... Актимергә каршы килүче берәү кинәт, киселгән агачтай, авып китте. Сумкасы кулыннан ычкынып, машина юлына барып төште. Баярак кына, иртән яуган карны куырып, яңгыр сибәләп үткән, шул сәбәпле, һәммә төш тайгак иде. Егылган кеше үрмәләп барып сумкасына тотынды. Сумкадан, муенына кызыл чүпрәк бәйләнгән кара мәче баласының башы күренә иде. “Жив, мой миленький?!”—дип сорады егылган кеше мәче малаеннан. Тегесе исә: “Мияу-у!” дип аваз биреп куйды. “Ну и хорошо. Пошли дальше”.—Һәм абзый торып, чатанлый-чатанлый ары китте.

Актимернең борынына яңа пешкән итле бөккән исе килеп бәрелде. Каян чыга соң бу ис? Нәкъ шундый ук тәмле ис күрше түтинең морҗасыннан чыгып, ишегалдына еш тарала торган иде ләбаса!

Актимер иртән ашамаганлыгын исенә төшерде, карынының өзелеп-өзелеп ачыгуын тойды.

— Э-һе-й! Ир кеше!

Актимер тавыш тарафына борылып карады. Сестра икән! Ишекне ачкан да, башын гына күрсәтеп кычкыра:

— Сөен, ата кеше, кызың бар!

— Малай түгелмени?!

— Кыз дим бит, Хода бәндәсе! Кара син аны, малай кирәк булган аңа! Юк, кыз бу! Кыз! Буе—илле ике сантиметр, авырлыгы—өч кило йөз илле грамм! Ишек ябылгач та Актимернең күз алдында сестраның көләч йөзе, берничә минут балкып торды.

“Димәк ки, кыз алайса!”—Актимер юл буе шул турыда уйланды. Трамвайдан төшкәч, өйгә кайтып керәсе килмәде. Чөнки анда кеше юк, күңелсез, ә сөенечне кем беләндер уртаклашырга кирәк! Ул бераз уйланып торгач, эшенә—Аэропорт төзелешендәге кибетенә барырга булды.

Павлюхин урамында, Киров клубына каршы чатта оясын туздырып ташлаган кырмыскалар шикелле, кешеләр кайнаша иде. Куптән басып торалар, автобуслары килми дә килми икән. Әнә, ак түбәле, зәңгәр билле яңа “Паз”ик ишеген ачты.

— Әй, сатучы...—дип кычкырдылар эчтән.—Утыр, әйдә...

— Аэропортка барасызмы әллә?

— Аэропортка!

Актимер кереп басуга, шофер автобусның ишекләрен япты. Яшь ир артыннан ябырылган халык, автобусның ябылып өлгергән ишегенә килеп бәрелде.

Йомшак урыннарда рәхәтләнеп, җәелеп утырган хатыннар да Актимер белән баш кагып исәнләшкәндәй иттеләр. Ә аэропорттагы төзелеш идарәсе начальнигының гүзәл хатыны исә Актимергә, миңа син бүген бик тә кирәк идең дигәндәй, аеруча якын итеп елмайды:

— Озын гомерле булырсың ахры, әле генә сине сөйләшеп тора идек!

— Мин бүген хатынымны тудыруханәгә илттем: кызым бар инде!— диде яшь ир, начальник хатынының нурлы йөзеннән күзләрен ала алмыйча, тәмам сихерләнгәндәй, ымсынып карап.

— Шулаймыни?—диде чибәр хатын. Аның алсу йөзе, гүя, кояш кебек балкып китте.

— Ата кеше булгансың ләбаса!—диештеләр начальник хатынының хезмәттәшләре, шулай ук елмаеп яки елмаерга тырышып.

Начальник хатыны иң алдагы ялгыз урындыкка утырып бара иде. Актимер ишек янындагы буш урындыкка чумәште. Начальник хатынының уймак авызы бер дә йомылып тормый. Ул йә берсе, йә икенчесе белән сөйләшә. Үзе исә һәр сүзе саен елмая, йә көлә иде. "Начальникка бик тә күнелледер инде һәр яктан килгән бу нәфис хатын белән яшәве,—дип дулкынланып уйлады Актимер.—Әйе шул, бар дөньяда бәхеткә башаяк күмелгән кешеләр!"

Чибәр хатын, яшь ирнең уйларын сизгәндәй, ялт борылып, ягымлы карашы белән, жанны эретерлек итеп, елмаеп сорады:

— Син тартасыңмы?!

— Тартам!

Начальник хатыны кечкенә ак кулын затлы перчатка эченнән чыгарып, сак кына ридикюль төймәсенә басты... һәм аннан ниндидер ялтыравык кап алып, Актимергә суздызы:

— Күчтәнәч бу! Ирем кичә генә Америкадан сәяхәттән кайткан иде.

Актимер, оялчан кызлар кебек, башын түбән иде. Алыргамы, юкмы? Алсам килешерме? Алмасам тагын ничек?

Начальник хатыны яшь атаның икеләнеп торуын күреп, елмая-көлә аны үзенә чакырып китерде һәм кулына теге ялтыравык капны тоттырды да, колагына таба сузылып: "Мин сиңа тагын бер нәрсә бирәм әле!"—дип кайнарланып пышылдады.

Актимернең колакларына чаклы кызарды, оялудан, дулкынланудан башына шаулап кан йөгерде. Ул, автобустагы хатын-кыз халкына күтәрелеп карарга кыймыйча, күзләрен түбән текәгән көе, шыпырт кына урынына барып утырды. Чибәр хатынны инде ул хәзер фәрештәгә тиңли, хыялында аның белән атлый-атлый каядыр китеп бара иде.

— Әй, кибетче?!

Актимер дерт итеп сискәнде. Хыялы, ак карга кайнар су сипкәндәй, эреп юкка чыкты. Ул гайре табигый хәленә кайтырга мәжбүр булды. Тупас йөзле бер хатын аңа эндәшә икән:

— Ишетмисеңме әллә? "Начальниха" сиңа әйтә бит!

Актимер фәрештәгә төбәлде. Чибәр хатын елмая һәм озын керфекләрен сирпеп-сирпеп яшь иргә карый иде:

— Кызыңның буе күпме булган? Авырлыгы?

Актимер әйтте.

— О-о-о, ярыйсы гына икән! Әйбәт!

"Нәрсәсе әйбәт?" Актимер аңламады. Бәлки, начальник хатыны яшь иргә ярарга тырышып кына, аның күңелен төшермәс өчен генә шулай дип әйтәдер...

Кичке якта кибетендә Актимер ялгызы гына иде. Ишектән берничә ир-ат эшче килеп керде.

— Салямгалайкум!,—диештеләр алар Актимергә ярарга тырышып.

— Сәлам!—дип җавап кайтарды кибетче теләр-теләмәс кенә.

— Ягулык бармы әле? Аларның "ягулык" дигәннәре тройной одеколон инде!

— Бетте шул!

— Нәрсә бар соң?

— Бер нәрсә дә юк!

— Черки-фәләннәргә каршы куллана торган сыеклык та юкмы?

— Ул да бетте!

— И, эштән туктатма инде син безне, бир инде берәр нәрсә!

— Каян алып бирим соң?! Бернәрсә дә калмады дим бит, бетте!

— Аэропорт чаклы аэропорт төзибез ләбаса, тап инде!

Менә сөйләш син алар белән: тап та тап диләр! Булмаганны каян табасың инде, күктән төшми ич ул! Актимер кырт кисеп:

— Юк!—диде. Ул тегеләргә кин җилкәсен күрсәтеп басты да тәрәзәдән карап тора башлады. Әмма боларның китәр исәпләре сизелми. Торалар да торалар. Хәзер начальник хатыны килергә тиеш! Ләкин юлда берәү дә күренми... нишләп тоткарлана соң әле ул, "көт, киләм!" дигән иде бит.

— Кибетче, ә, кибетче... үтермә инде, үзеннең дә йомышың төшәр әле безгә... дөнья бу!—Шалабайларның соңгы сүзләре, ниһаять, Актимерне уйга калдырды. Күптән түгел генә әле аңа хатыны: "Күгәрми торган тимердән кухня пычагы ясатып кайт, яме!"—дигән иде. Шул турыда әлеге эшчеләргә әйтте Актимер. Әйтүгә, эшчеләрнең берсе шактый ук таушалган сумкасыннан ялт-йолт итеп торган пычак алып, кибетчегә тоттырды:

— Үземә дип ясаган идем... мә, ал, рәхәтен күр!

Актимергә пычак бик ошады. Ул аның бәясен сорады:

— Алты тәңкә. Ләкин акча алмыйм... син безгә ягулык бир...

Кибетче начальник хатынына ике тартма "огуречный лосьон" дигән нәрсә калдырган иде. Бу нәрсәне аэропорт төзүдә катнашучы эшчеләрнең шактые бик яратып эчә икән!

Бер тартмада алты савыт. Актимер тартманы алып, эшчеләр каршына, прилавка өстенә куйды. Шундук кырыс йөзләргә нур инде, күзләр елтырый башлады. Авызлар колакларга таба ерылып китте.

— Рәхмәт кибетче, мең яшә!—диеште эшчеләр "кыяр лосьон"ын кесәләренә тутыра-тутыра. Болай булгач, буржуйларга социализмны юк итәргә ирек бирмибез инде без... алга иптәшләр, коммунизмга! Ур-ра-а!

Нәкъ шул мәлдә кибеткә начальник хатыны килеп керде. Актимернең битләренә гүя ут капты, күзләре очкынланды. Ул үзе дә сизмәстән, елмаеп:

— У-у, Екатерина Павловна! Әйдәгез, рәхим итегез,—диде.

Начальник хатыны сабыр, күндәм рәвештә, мәгәр бер бите ай, икенче бите кояш йөзендәге серле елмаюны тамчы да киметмичә Актимер каршына килеп басты да, ялтыравык ридикюлен лавка өстенә куйды:

— Мин... сиңа... тегене... Әйткәнием ич!—һәм көмеш тиеннәр челтерәвен хәтерләтеп, көлеп куйды.—Мин бүген бер зур түрәнең туена барам! Син... миңа бер көнне обещать иткәннәрне, теге...

— Ә-ә, ие,—диде Актимер, исенә килеп. Ул лавка астыннан олы гына төргәк чыгарды. Екатерина Павловна җәһәт кенә үрелеп, төргәкне алды да, авырлыгын чамаларга теләгәндәй, нәфис ак пирчәткәле куллары белән әйләндереп-әйләндереп карады:

— Миннән күпме тиешле?

Актимер әйтте. Начальник хатыны күңелле генә елмаеп, акча түләгәч, кара ридикюленнән чытыр кәгазьгә төргән чит ил маркалы шешә алып Актимергә сузды:

— Бу—миннән күчтәнәч! Ләкин моны... тегенең хисабына кертмә, яме! Ханым бер бите ай, бер бите кояш йөзен тагын да балкытыбрак елмайды, мәгәр кибеттән чыгып китәргә ашыкмады, нидер көтеп Актимергә карады.

Сатучы ир сизде: аңа хәзер һич тә сынатырга, җебеп, мәлҗерәп төшәргә ярамый. Бу очракта бер генә саксыз хәрәкәт тә, килешсез ым да, ятышсыз сүз дә бөтен эшне харап итеп, ватып-җимереп, туздырып ташларга мөмкин. Актимер, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды. Гаҗәп! Кибет эчендә алардан гайре кем дә юк. Сатучы ирнең уйларын белгән шикелле, начальник хатыны да ялт кына ишек ягына карады, аннары барып, ишекне эчтән бикләде. Бу—Екатерина Павловнаның яратып башкара торган шөгыльләренең иң кәттәсе иде. Ул шулай кибет эчендә кеше-кара булмаганда, ишекне эчтән бикли дә, зәвыгына тиндәш күлмәк-фәлән эләктереп, аны киеп һәм көзгедән үз тәнендә күреп вә тукымасының да исен-ушын тоеп карар өчен, кибетнең бәләкәй генә складына кереп югала

иде. Озакламый аннан: “Актимер, кереп кара әле, миңа бу күлмәк килешәме икән?!” кебегрәк аваз ишетелә...

Менә бу юлы да...

Чү! Нигә әле Екатерина Павловна эндәшми? Үзе дә чыкмый... Ни булды икән аның белән?!

Актимер, кинәт шебһәләнеп, тәшвишләнеп, әкрен генә складка таба бара башлады. Складның ишеге ачык, эчтә дә ут яна, ләкин Екатерина Павловна шәйләнми иде.

“Нинди хәл соң бу?”—Актимер курку катыш кызыксынып тыңлап-тыңлап торды да, кыштырдау гына да ишетелмәгәч, борылып китмәкче иде, шул мизгелдә арттан аның муенын йомшак, нәфис куллар кочаклап алды. Бу... шул, үзе! Екатерина Павловна... Аһ-һ!..

Актимернең хәле китте, аяклары тотмас булды һәм башы әйләнеп, йөрәге сикереп-сикереп тибәргә тотынды. Нишләргә? Нинди карар кабул итәргә?.. Бит Актимернең тормышында мондый сәер, әкияти вакыйганың булганы юк иде әле! Хәлбуки, жиргә табарак төшеп уйласаң, патшалар, корольләр, ханнар, солтаннар тормышында моннан да кәттәрәк мәхәббәт мажаралары булган лабаса! Ә нигә... Актимергә ярамыймы кемнедер сөяргә һәм аның тарафыннан сөелергә?! Ә хатын?.. Нинди хатын?! Айгөлме? Ул нәрсә белә бу турыда?! Аннары, Айгөл дип, шушындый илаһи мөмкинлекне кулдан ычкындырып, гомер буе үкенеп яшәргәме?! А-а, юк инде, анысы булмас, Актимер кулга кергән бәхеттән баш тартырга ул чаклы ук тиле түгел әле, шөкер!

Сатучы ир, тәвәккәлләп, муенын кочаклап алган гүзәллек иясенең кулларын сыйпый-сыйпый үбәргә керешге. Бу, әлбәттә, Екатерина Павловнага тәэсир итми калмады. Ул, ниһаять, бөтен көчен туплап, кыюланып, батыраеп, тәненең бөтен байлыгы, кайнарлыгы белән Актимергә сарылды! Яшь ир-егет, як-якка каранып, башта сиздерми генә сөндергечкә орынды, склад эчен караңгылатты, аннары өстәге киштәдә өелеп яткан йоп-йомшак мамык мендәрләрне селкетеп жибәрде. Мендәрләр идәнгә ишелеп төштеләр. Шуннан соң Екатерина Павловна белән Актимер, атналар буе ач йөреп интегеп беткән һәм кинәт өстәл тулы сый-нигъмәткә юлыккан кешеләрдәй, бер-берсенә ябырылдылар...

Борыннар борынны капшады, иреннәр иренне! Ә күзләр, гәрчә инде складта караңгы булса да, рәхәтлектән йомылдылар... Куллар төймәләрне чишеп, күлмәкне салдыра-салдыра һәм тәнне сыйпый-назлый түбән төштеләр дә...

Бераздан инде алар әкрен генә чинаша-чинаша мендәрләр өстендә аунныйлар иде.

Актимернең әле мондый гаҗәеп урын-жир ярышын—дәрт белән дәртнең, дәрман белән дәрманнан соң чиккә житеп чәкәләшкән вакытын гомерендә тәү мәртәбә күрүе, кичерүе иде! Шунлыктанмы, әллә башка бер сәбәптәнме, яшь ир, ниһаять, югалып калды, үзе дә сизмәстән, хатынның сул колак йомшагын алкасы-ние белән тешләде...

Бу өлкәдә зур тәжрибәгә ия булган Екатерина Павловна, әлбәттә, Актимернең хәлен аңлады... ханым эченнән генә канәгатьләнү хисе кичерә иде. Ул, рәхмәт йөзеннән, Актимерне назлап сыйпамаган, үпмәгән төшен калдырмады бугай!

Екатерина Павловна, назлап сыйпаганда, куллары Актимернең муены турысына житкәч бер әйбергә игътибар итте: күлмәк якасы астында кала торган урында зур-зур ике миң бар иде...

— Улым-м!!!—дигәнен сизми дә калды ханым.—Игезәкләремнең сыңары! Бәгырем!

Актимер коелып инде:

“Бу нәрсә була инде?! Моны ничек аңларга?! Әлегә чаклы һаман урысча гына сөйләшкән бер бите ай, бер бите кояш ханым кинәт татарчага күчеп: “Улым!”—дисен әле”...

Әлбәттә, сатучы ир үзенең бәләкәй вакытыннан ук каладан, детдом-

нан алып кайтып, тәрбияләп үстерелгән булуын белә иде. Әмма, көннәрнең берендә, кайчандыр ки, үзен шәфкатьсез язмыш кочагына ташлап качкан чын әнисе белән, кабахәтлек кылганнан соң очрашуы—башына һичничек сыймады! Ул янә эченнән генә: "Бу ничек була инде?! Моны ничек аңларга?!"—дип кабатлады, Җитмәсә, хатыны Айгөл дә бәләкәй чагыннан ук каладан, детдомнан алып кайтып, тәрбияләп үстерелгән! Аның да муенында ике миңе бар! Шулай булгач, монысын тагын ничек аңларга?!

Яшь сатучы ир, йөрәгенең сыкравын басарга тырышып, әкрен генә, сабыр гына итеп:

— Айгөлнең дә муенында ике миң бар,—диде.

— Кем ул Айгөл?!

— Минем хатыным.

— Кайда ул хәзер?!

— Больницада. Бәбиләде.

— Син, Актимер, чын әниеңнең исемен белә идеңме?

— Кадрияме?

— Мин шул "Кадрия" булам инде!...—Хатын өстәп нидер әйтергә теләде. Мәгәр, теге кабахәт эштән соң нәрсә әйтә ала инде ул?! Бигрәк әллә ничек, җайсыз килеп чыкты лабаса, оятыннан кая кереп качар урын тапмассың, валлаһи!

Актимер нинди уйлар кичерә иде бу минутта? Хатын моны чамалый алмады. Хәер, каян чамаласын—ул бит, кайчандыр ки, Кадриядән—Шәфкатькә, аннары Екатерина Павловнага әверелгән бер фәхишә кисәге, сөйрәлчек калдыгы, бактерия, микроб! Ул бит... очсыз рәхәтләр, түбән ләззәтләргә алданып, җанын сатып көн күргән, теләсә кайда, теләсә кем куенына кереп, газиз гомерен суга салып агызган шакшы, пычрак, иң әшәке хатын!.. Шулар гына да җитмәгән, инде, әнә, малае белән... Ә бусы инде моның бер киртәгә дә сыймый! Бу—кешелек дөньясы каршында иң олы җинаятьләрнең берсе! Чү, тукта! Тукта! Актимер бит әле: "Айгөлнең дә муенында ике миң бар", диде. Шулай булгач, Айгөл дә минем кызым булып чыга түгелме соң?!

Бу минутта начальник хатынының күңеленә әнә шундый дөп-дөрес уйлар ургылып-ургылып килә иде. Ул ярым саташулы халәттә булып, кибеттән ничек чыкканын да тоймый калды. Өйалдында кибет ишеге ачылганны көтеп торучы кешеләр аның артыннан гаҗәпләнеп карап калдылар.

Кадрия, Шәфкать, Екатерина Павловна һәм янә Кадрия, апын-төпен атлаган җиреннән, исенә килеп, караса, баскыч турысында торган зәңгәр "Жигули"ны абайлап шунда таба бара башлады. Барып җитәрәк, машинаның сулъяк ишеге ачылып китте һәм Кадрия ире янәшәсенә кереп утырды.

Очлы күзле начальник шундук хатынының йончыган кыяфәтенә дикъкать белән карап, сулъяк колагындагы тешләнгән урынга, саркып торган канга һәм ватылган колак алкасына игътибарын юнәлтте:

— Улмы?!—диде ул кибет ягына карап.

Кадрия эндәшмәде. Хатынының су капкандай тын утыруын үзенчә аңлаган начальник, машинасыннан җилкәнеп чыкты да, тиз-тиз генә кибеткә кереп китте.

Биш-алты минуттан әйләнеп тә чыкты ул. Аның уң кулы бераз гына канга буялган булып, үзенең дә борыныннан кан тамчылап тора иде.

Ире машинага кереп утыргач, Кадрия түзмәде, истерикага бирелеп:

— Нишләттең син аны?! Ул гаепле түгел иде бит... Мин гаепле идем монда! Мин!..—дип кычкырды.

— Ә-ә, син гаепле идеңмени әле?—диде ире, шаккатып.—Димәк, колагыңны син аңарга, үз теләгең белән тешләттең, иеме?!

— Ие, ие! Үзем тешләттем, үзем-м!..

— Аһ! Шушы булдымыни синең миңа рәхмәтең? Ярар!... Ну, үзеңә дә күрсәтәм әле, күрмәгәнеңне! Күрсәтәм!..

Начальникның машинасы Казанга таба ук кебек очты.

Кадриянең ире төнге унике тулганда ниндидер хатын-кыз кәмәше ияртеп кайтты. Хужабикә үзе дивардагы келәмгә аркасын терәп, тезләрен кочаклап, өннән чыккандай, кушеткада утыра иде. Ире чишенеп, теге нәрсәне дә чишендереп, күрше бүлмәгә кереп югалгач та, шул рәвештә утыра бирде Кадрия. Аның өчен инде дөньяның кызыгы да, тормышның яме дә калмаган, беткән иде.

"Нишләргә?! Нишләргә инде хәзер?!"—дип өзгәләнде хатын.

Кинәт теге бүлмәдән сәер тавышлар ишетелде. Нәрсәдер дөпелләде, нәрсәдер шалтырап куйды. Аннары:

"Ой! Мама? Ой!.."—дигән ярым пышылдаулы, ярым иңрәүле хатын-кыз авазы белән тирә-юнь тулды. Шуның артыннан ук:

— Башынны тик тот дим... Кая үбим әле!—дигән ир-ат тавышы яңгырады.

"Башланды... Ирем миннән рәхәтләнеп, рәхәтләнеп үчен алачак шул юл белән!"—дип уйлады Кадрия, һәм кушеткадан төште дә, барып, валидол капты. Мәгәр күрше бүлмәдәге ләззәтле ыңгырашкан тавышларны ишеткән йөрәккә кайда инде ул тынычлану! Киресенчә, йөрәк ярсырга, чәбәләнергә тотынды, сикереп-сикереп тибәргә кереште. Күрше бүлмәдәге "үтергеч" тавышлар көчәйгәннән-көчәя генә иде...

Ниһаять, Кадрия түзмәде: "Життеме сезгә, юкмы, кабахәтләр?!"—диде дә, җавап урынына көлгән авазлар гына яңгырагач, үзен-үзе белештермичә, бәллүр вазаны әләктереп диварга орды! Әмма кая ул... Тегеләр отыры явызлана гына төштеләр!.. Шулчак, өзми-куймый, телефон шалтырый башлады. Кадрияне гүя ток тотты, аякларының хәле китте, бөтен җирен калтырау алды. Ул, әллә нинди куркыныч бер нәрсәгә баккандай, телефонга текәлеп торды да, ниһаять, тәвәккәлләп, трубканы күтәрде:

— Ал-ло!

Трубкада Кадриянең ахирәте, бухгалтер Феняның ни сәбәпледер каушаган, дулкынланган таныш тавышы ишетелде:

— Екатерина Павловна... Сез ишеттегезме әле?!

— Нәрсәне?!!

— Ой, коточкыч! Баярак кына... безнең сатучыбыз асылынып үлгән...

Кадрия кинәт башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китеп, гөрселдәп урындыкка утырды:

— Кайсы сатучы?! Син ни сөйлисең, Феня?!

— Теге... Аэропортта, промтовар кибетендә сатучы булып эшләгән инде... Исеме... Әйе, Актимер! Актимер бугай исеме!..

— Аһ! Үтерәсез сез мине, Феня, валлаһи... Кем ишеттерде сиңа бу коточкыч хәбәрне?!

Бәхетсезлегенә күрәдер, телефонда гөжләү барлыкка килде, җавап ишетелми калды.

— Нәрсә-ә?.. Нәрсә әйттең, Фенечка, кабатла әле яңадан, пожалуйста?!

Тфү, тагын гөжләргә тотынды инде әллә?! Әһә-ә... Кадрия трубканы колагына якын ук тотып, телефон эченә керердәй булып, тыңларга кереште.

— ... Аннары аның хатыны дигәне дә үзенең бертуган сеңлесе булып чыккан ди!.. Балалары да гарип булып туган икән!..

Кадриягә шушы хәбәр җиткән иде инде. Барысы да аңлашылды. Аның кулыннан трубка шуып чыгып, идәнгә төшеп китте. Хатын ике куллап башына ябышкан көйгә, ни үле, ни тере килеш, күрше бүлмәгә таба атлады. Ишеккә җиткәч, аның бер ягы бикле түгел икәнен искәрде. Типте, ишекнең бикле түгел ягы яртылаш ачылды. Кадрия эчтә, чит илдә эшләнгән тахтада теге зөбаниларның анадан тума калып, бер-берсенә сырпаланып ятуларын шәйләп өлгерде.

"... Анда... Актимер, балакаем, үлеп ята... Ә монда бу кабахәт, оялмыйча өйгә сөйрәлчек алып кайтып, ачыктан-ачык, күрәләтә безне мыскыл итеп, хур итеп..."

... Кадрия идәндә яткан гантельне алып, аны ничек итеп иренә таба

ыргытып җибәрүен дә сизми калды. Шуннан соңгы хәлләр төштә күргән кебек кенә. Хуҗа дигән адәм тәганәсе йөзе белән түшәмгә таба борылып, тынсыз-нисез катып калды. Аннары, теге өстерәлчек дуңгыздай чинап кышкы урамга чыгып чапты!..

Озак та үтмәде, өйгә милиционерлар, ак халатлы һәм халатсыз кешеләр кереп тулды. Алар гүя бу куркыныч канлы җинаятьтә бары Кадрияне генә гаепле санап, аңа ачуланып карап, иң әшәке теләкләр теләп, күрше бүлмәгә юнәләләр... Ә анда өстенә инде иягенә чаклы юрган ябып куелган Борис Сергеевич ята. Аның тирәсендә врач ханым белән шәфкать туташы... Ә Борис Сергеевич гүя үлмәгән, аңын гына җуйган. Юк! Аңын да җуймаган бугай... Әнә ич... елмая!

Кинәт Кадрия тетелеп-тетелеп көләргә керешге.

Погонына бәләкәй дүрт йолдыз таккан егерме биш-утыз яшьләрдәге милицонер хуҗабикәгә текәлеп карап торды да, ак халатлы иргә:

— Моннан хәзер безгә тамчы да файда юк!.. Үзегез белән алырсыз инде,—диде.

Шулчакны Кадриягә диван-караватт астыннан кемдер эндәште сыман:

— Капитанны макта! Аны аулакка чакыр!

Кадрия шундук бу сәер боерыкка буйсынды: капитан каршына килеп, сул кулы белән каләмен тартып алды да, уңы белән битеннән сыйпап:

— Ай, сез нинди куркәм! Синең хатының нинди? Ә минем капитанчикка бер гозерем бар... теге бүлмәгә кергәч, ярыймы!—диде һәм шаркылдап көләргә тотынды. Аннары, барып, ир врачны чеметте дә, янә тыелгысыз рәвештә көләргә кереште.

Ачуы чыккан врач:

— Тотып торыгыз әле шуны! Акылында түгел бит, әллә ни майтарып ташларга мөмкин!—дигәч, ике санитар егет хуҗабикәне култыклап алдылар.

— Ай, матур егетләр! Исемегез ничек сезнең?

— Мин татарча билмей!

— Я тоже!—диештеләр егетләр.

— Ялганлыйсыз ла! Беләсез ич, тәре корсаклар!—дип Кадрия егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә сарылды.

Капитан Кадриягә, сарык күргән бүредәй, зәһәр итеп карады:

— У-у, юха елан! Моның белән сак булырга кирәк!..

— Тегендә баргач, бик шәпләп тынычландырабыз аны, хөрмәтлем... Кечкенә кызлар хәленә төшкәнен тоймый да калачак!

— Капитанчик! А-а, капитанчик?! Әйдә...—дип, милиция офицерына күз кысты хуҗабикә. Аннары врач иргә телен күрсәтте дә, үрсәләнә-үрсәләнә елап җибәрде.

— Күптән шулай кирәк иде,—диде капитан тынычланып.

Ниһаять, ак халатлы һәм халатсыз кешеләр Борис Сергеевичны носилкага салып, бүлмәдән алып чыгып киттеләр.

Капитан бу фатирда булган хәлләр турында беркетмәгә пүнәтәйләрдән дә кул тамгасы салдыргач, тәрәзә каршында һәм ишек янында торган милиционерларга нәрсәдер әйтте. Шуннан соң тегеләр, гестапочылар шикелле өнне алырлык кыяфәт белән, Кадриягә килеп ябыштылар.

Хатынны милиция машинасына утырттылар. Әллә ашыгыч ярдәм машинасынамы икән? Юк, милиция машинасына ахры... Чөнки машина эчендә милиционерлар бар иде. Әллә врачлар идеме икән ул?! Ярар, кем булса да булгандыр. Ләкин араларында бер кабахәт утыра иде. Менә шул адәм тәганәсенә Кадриянең тиешсез урынына үтеп керергә һәм күкрәген авырттырып кысарга кем рөхсәт итте икән?!..

Мәгәр сары йортка барганда юлда эшләнгән бу мәгънәсезлек—алда, тегендә эшләнәчәк мәгънәсезлекләрнең баласы гына булган икән әле...

# ШИГЪРИЯТ



## Равил Фәйзуллин

### ШӘФӘКЪ АША ТАҢ АТА

* * *

Читән кору түгел,
иман беркетү!
Ышанам дисәң дә,
шикләр бер көтү.

Ышану, шиксез, бар
Илаһ бер Көчкә.
Гөнаһыңа җәза
булу тиеш тә!

Килми калмый бер көн
көтмәгән Сынау.
Чыныга Кеше, йә
бөтенләй сына...

Качсаң да, Адәм зат,
хакыйкать—табар.
Онытма, яшәүдә
ахирәт тә бар!

Гомердә бер гамәл:
табу-югалту.
Ярга кайту түгел,
Иманга кайту.

* * *

Шундый итепләр сөйлиләр!—
торасың шаккатып!..
Ялганнарын аңлаганга—
еларлык ятып.

Күпләр, бахыр, сәҗдә китеп,
тыңлыйлар оеп.
Киләчәген, язмышларын
бүкәнгә куеп.

Хакимияттә—тозаклар,
богаулар, бикләр...
Матур сүзләргә оялый
иблислекләр.

... Сөйлиләр! Алганнар мени
Күкләрдән вәхи...
Бу дөнья Чын-Ялганнан
тора, билләһи!

* * *

Ике дөнья—бер морҗа ла!
Калҗа ни дә, марҗа ни!
Дәртле уенда телдән төшми—
"и мани да, и җаный!..."

Чир ега... Баскан җир тетри...
Хыянәт-ук кадала...
Күккә багып ялварасың—
"И Әни дә, и Алла!.."

## Төрек мунчасында уйлану

Ятам төрек мунчасында.
Сөякләр эри...
Госманлы империянең
табасымыни!

Алтын Урда, ханлы чаклар
һаман истәме?
Әллә җитмиме төрекнең
эссе өстәве?

Әвәли массаж остасы!
Син—ит камыры!
Бу "җәллад"тан сау чыгармы
татар тамырым?

Ләүкәндә анадан тума
килмешәк ята.
Гүя бот күтәреп ята
тарихи хата!

Төреккә дә хаклы үпкә:
кирәк чакларда,
ирендеңме Казан җирен
килеп якларга?

Фиргавен илен туздыру
ник кирәк иде?
... Ярый диңгезләрең бар—
хәзер терәк әле!

Рәхәт, әлбәттә! Әмма
уй качамы соң?
"Тәрҗеман бабай" хыялы
чынга ашамы соң?

... Кайда монда Ата төрек?
кайда Али-Баба?
Тирлә дә кайт үз җиреңә,
чум үз дөньяңа!

## Монда бик тиз шәфәкъ бата...

*Диңгез буенда үз-үзем белән сөйләшү*

— Монда бик тиз шәфәкъ бата!
— Киләсе Үлем тиз килсен!

— Бездә таңнар сызылып озак ата!
— Яшьлек барыбер тиз уза.

— Сездә төнен нинди кош сайрый?
— Җан—күбәләк.
Барсын әйтеп йөрми кычкырып...

* * *

Ара сакла! Бар бит әнә
бармакларның аралары.
Якынаймагач тиелми,
һәм... ачылмый яраларың.

Табигый ерак якынлык!
"Дистанция!" дияр кемдер.
Туу-үлем рәттән булмас,
арада—нәни гомердер.

* * *

Һәм, ниһаять, бусы да булды!
Яптык бер сәхифә!
"Ах, ялгыштым!.." була алмый
кичә үткән кичә!

... Көткән сарык көтүендә
байтак бәрән булган...
Без Шигырьдә җайдак чакта
кемдер эрәм булган,
кемдер вәйран булган,
кемдер "бәйрәм" булган...

* * *

Ян, газаплан—
каңгырма гына!

Кыялар елый
яңгырда гына!

... Төшемә керде:
кабере югалган
Чыңгыз хан тора
яп-япан кырда!..

* * *

Яшәлгән... Күрелгән...
Тоелган... Татылган...
Бөтигә язылган
догалар онтылган...
Иш көннәр агыла
бер-берсе артыннан...

"Яндырам!" дисең дә...
Шәп инде яна алу!
Мәхәббәттә яну—
яңадан яралу!
... Миңа тик Шигырьдә
килә ала яңару.

* * *

Күпме булды гомеремдә
ул күчмә утраулар!
Һәркайсы җан экранында
материктай торалар...

Робинзон ук булмасам да,
уй-гамәл зурдан иде!
Һәрберсендә ыру-нәсел дип,
йорт-кура корган идем.

Казан асулы учакта
төтен дә тәмле иде!
Наз тулы ятак янында
чәчәк бәйләме иде!

Кударбалар эмәлләдем
балалар тибрәтергә.
Китап сүзләре чыгардым
гыйлемгә өйрәтергә.

... Җилдән микән, илдән микән,
миннәнме—нидән икән?—

тора-тора утрауларым
ярдан аерылып китә...

Пристандагы матрос кебек,
ыргак-баулар беркетәм.
Кушмакчы булып, китсен! дип,
күкрәгем белән этәм!

Аерылып китә утрау!
Шәп күренеш! Трагикомик
илаһи бер тамаша.
Офыклар—төсле музыка
колү катыш яшь аша.

Бар ул андый утраулар
Аккошта, Кабанда да...
Әйтмибез генә, бар алар
һәрберебезнең җанда.

## Шигъри попурри яки гомер фасылы

һәр ярыктан—кызлар күзли!
Учта елан могезе!
Баскан төшем—Җир уртасы,
тәхетендә—мин үзем!

Без төкергән җирдә гөл үсә!

Тимәгән тик тимәгән...
Әле яшьлек коймәгән!
Хәрабәләр торгызырга
безгә генә димәгән!

Их, метрополитен! Яраткач...

Яшьлектән китмим! Анда хет
швейцар булып калам!
Җиңгән әйтә: мин, ди, сиңа
алтмышта угълан табам!

Шундый эшләр, бохар шәкерте!

Җыерчыклар арасыннан
кырмыскадай үй йөри.
Дөньяда озак яшәгәч,
картаюлар мәҗбүри.

Кырыгымда кырда кар явар...

* * *

Халыклар берләшеп беркөнне
(БМОлар һәм аңа кермәгән
милләтләр, кавемнәр, ырулар...)
бер бөек фикергә килгәннәр:
“Әйдәгез, корыйк уртак бер
гөл-бакча—пантеон, дигәннәр.
Капкада—исеме дә аты—
“Беренче Мәхәбәт зираты!”

Җәннәте торсын ди бер якта
мондагы илаһи балкыштан.
Монда бит хыялда булса да,
гашыйклар яңадан кавышкан!

Шәфәкъләр юк икән бу җирдә!
гел яшьлек, гел гөлләр, гел ал таң!
Мең төрле телләрдә, рәшәдәй
тибрәнеп тора ди, изге сүз:
Яратам! Яратам! Яратам!..

... Мин дә еш ашкынам бу җиргә.
Табынам абына-абына...
Һәммәбез беренче ярларны,
беренче сөюне сагына.

## Шәлең түгәрәк түгел...

Шәлең түгәрәк бүген!
Күңел күбәләк бүген!
Илһам килгән көн бүген!
Бергә булган көн бүген!
Дөнья аяз бүген!
Һәр кузәнәк наз бүген!

Син сәҗдәдә, мин сәҗдәдә!
Әй, Ходай, биргәннәрең!
Дога итеп пышылдыйсың:
“Мәхәббәт пәйгамбәрем!”
Юктыр! Юктыр... Ул—Син! Ул—Син!—
Алиһәнең нәкъ үзе!
Гап-гади җир баласы мин,
бүген Синең—Нәүмизең!

Күңел күбәләк бүген!
Дөнья түгәрәк бүген!
Бәхет-тәхет биек булгач,
Күк тә тәбәнәк бүген!

... Нигә кинәт тынып калдың?
Уең—күктән югары!
Боланныкыдай күзләрдә

каян дым болытлары?
Нәрсәне исеңә төшереп,
кемнедер онытмавың?

... Төшме? Өнме? Бу челләдә
каян килә кар исе?
Кайдадыр сабый тавышы,
килә барып карыйсы...

## Бәлки...

Берәү вафат.
Дөнья кимедеме?

Туры йөргән авып төшеп,
туфрагына ятты гына.
Күрер күзгә
кабер-таучык артты гына!

Яңа дусың, ярың артты.
(кем белә?)
Бәлки, Дөньяң кимегәндер әле!..

* * *

Якыным да Син минем!
Ерагым да Син минем!
Зинданыңнан чыгар юлга—
чырагым да Син минем!

## Хастаханәдә

Ике халыкның баласы.
Соңгы сулыш—җан авазы.
Һаваларда чәкәләшә
азан белән чаң авазы.

* * *

Күңелгә шик иңде...

Мәхәббәт югалды
тынлыкта йотылган
авазым шикелле.

* * *

Һәркем үз чикмәнен ябынган.
Ефәк корты кебек тәренгән.
Кысык күңел, тишек җиң аша
“Коммунизм кыры күренә!..”

* * *

Минем кочакта эрисең...
Илнеңме—куенында?
... Җаным оча, бәргәләнә
кемнеңдер уенда.

## Яна вакыт безне яндырып...

Адымнарны сагайта.
Хатирәләр яңарта.
Әйтер сүзне сайлата.

... Йокысызлык офыгында
Шәфәкъ аша таң ата.

## Юаныч

*Ә. гә*

Таулар күчермәдем арырлык.

Ә шулай да,
хезмәтем бар—
соңгы юлда
үз-үземне
күтәреп барырлык.

*1998, июль.*
*Комкой. Төркия*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Госман Гомәр

# ШАҺМИРАН

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

### Икенче кисәк

Түрәнең койрыгына бастылар бугай...

Ишек яңагындагы кара төймә шактый югары беркетелгән иде. Карсак милиционер үрелеп азапланды. Бармак очы тию белән эчке якта тонык кына музыка уйнаганы ишетелде. Тонык, димәк, ишек ике катлы. Килүчеләр "Кем бар анда?"—дигән сорауны көттеләр. Әмма өн салучы юк иде. Өлкән лейтенант кабат үреләм дигәндә, ишекләрнең икесе тиң ачылып китте. Кемсәләр дәррәү эчкә уздылар.

— Сезне борчырга рөхсәт итегез!

Ул арада ишекләр автомат рәвештә ябылып та өлгерде. Керүчеләр өчәү иде: әлеге карсак милиционер һәм гражданнар киеменнән тагын ике әзмәвер. Кемнәр болар, ник килгәннәр, бу хакта нигә алдан хәбәр салмаганнар? Милициянең нинди йомышы төшкән тагын? Болары йорт хуҗасы өчен табышмак иде. Әмма ул моңа тамчы да борчылмады.

Төн кошлары кая аяк басуларын абайлап өлгергәнче каршыларына бозау чаклы, бер-берсенә бер тамчы судай охшаш ике овчарка килеп басты. Авызларына ит салуны көткәндәй, арт саннарына утырып, кызыл күзләрен кунакларга текәделәр. Хуҗа түръяктагы өстәл янында утыруын дәвам итте. Милиционер залга узарга дип, бер генә адым ясады, алабайлар яман ырҗаешып, аның юлын бүлде.

— Этләрегезне алыгыз!

— Алар кемнәр килүе белән кызыксына,—диде хуҗа тыныч кына.

— Лорд, тик утыр? —дип, әмер биреп карады милиционер. Сакчылар моңа да ырылдашып җавап кайтардылар.

Шаһназаров кәнәфидән күтәрелеп, коридорга таба атлады. Керүчеләргә урыннарыннан кузгалмаска боерды.

— Лордны беләсең, димәк. Тиле сүзеннән танылыр, дигәннәр. Монда Лорд юк бит. Инде үзегез белән таныштырыгыз, йомышыгыз ни?

— Мин—җинаятьләрне эзләү бүлегеннән, Юркин Николай Петрович, болар—безнең хезмәткәрләр.

---

Госман ГОМӘР (1933) — *"Уйна гармуныңны" китабы һәм берничә мажаралы повесть авторы. Казанда яши.*

Повестьның журнал варианты, аның беренче кисәге журналыбызның 1994 елгы 9 санында басылган иде.

Өлкән лейтенант таныкламасын алам дип, кесәсенә тыгылмакчы иде дә, Шаһназаров аны шып туктатты.

— Кирәкми, мин үзем. Күтәрегез кулларыгызны. Ягез, мин кемгә әйтәм? Өчегез дә! Менә шулай. Карагыз аны, бармакларыгыз гына кыймылдаса да, өзгәләп ташлаячаклар!—дип, искәртте тегеләрне, аннары этләренә мөрәҗәгать итте:—Малайлар, игътибар!

— Уһ!

— Уһ!—дигән тавыш чыгарды этләр. Алар чакырылмаган кунакларны менә-менә чәйнәп йотарга әзер торуларын белдереп ырҗайдылар. Шаһназаров иң элек офицерның кесәләрен капшады, пистолетын, таныкламасын алды. Әшнәләреннән бер пычактан гайре нәрсә табылмады.

— Кеше өенә корал, пычак белән йөриләр димени!—Үз алдына шулай сөйләнә-сөйләнә, хуҗа тагын залга кереп китте. Чакырылмаган кунакларга кымшанырга ярамаганлыкны әйтеп, бу хакта "малайлары"ның да исенә төшереп узды. Җавап: "Ыр-ыр, ыр-р..." Шулай булыр-ыр-р, янәсе.

Шаһназаров тегеләрдән алган әйберләрне өстәлгә таратты, халатының күкрәк кесәсеннән чыбыксыз телефонын тартып чыгарды, төймәләргә басып, тиешле саннарны җыйды.

— Мин әле бу. Ә, таныдыңмы? Гафу, төнгә каршы бимазалыйм. УГРОдан өлкән лейтенант Юркинны ачыклагыз. Николай Петрович. Кайсы бүлектә эшли? Кемгә буйсына? Көтәм алайса.

Хуҗа милиционерның өстәлдә яткан пистолетын кулына алды, аны әйләндерә-әйләндерә озаклап карады. Күптәнге корал, кара буявы инде уңып, шомарып беткән, тоткасы ялтырап калган. Пистолет корылган булып чыкты. Менә бит тагын үлем угы салынган үзенә! Бусы кемгә багышланган инде—миңамы? Шаһназаровның тәне эсселе-суыклы булып китте. Патроннарын алып кесәсенә салгач, ул иркен сулап куйды. Нидер исенә төшеп, тагын телефонын чыгарды.

— Елгыррак егетләреңне әзерләп тор. Әлегә берни дә юк. Ну, дүртне-бишне, машиналарында көтәрләр, миңа Кенәз белән Фара керсә, житкән. Борчылма, егерме-утыз минуттан үзем шалтыратырмын. Юк-юк, сиңа кузгаласы түгел. Телефонда бул!

— Кул арды, коралларыбыз юк ич, әгәр төшерсәк. Бәлки без бөтенләй китеп үк барырбыз, сезгә дә мәшәкать кимер. Дәү абый, ә?

— Кайдан беләсең минем исемне? Лордны да?

— Җибәрсәгез, барысын да онытырга сүз бирәбез,—диде милиционер, ялварып.—Без ялгышканбыз, үкенәбез хәзер.

— Зинһар, чыгарыгыз!

— Куллар салына, түзәр хәл юк,—диештеләр калганнары.

Яннарына барып, Шаһназаров әсирләрнең кулларын берәм-берәм төшерде. Этләре исә, хуҗаның бу гамәлен ошатып ук бетермичә, сәерсенеп, ыңгырашып куйдылар. Тегеләргә боргаланырга ярамаганлыгын кабат искәртте. Югыйсә, сөякләрегезне капчыкка тутырып озатырга туры килер, диде. Ә үзе берни булмагандай, әле бер бүлмәсенә, әле икенчесенә кереп йөрде. Ничә бүлмә икән соң монда? Тышта бер фатирның ишеге томаланган, димәк, ике фатир бергә кушылган, биш-алты бүлмәдән дә ким түгелдер, мөгаен. Ялгызы яши, диделәр ич. Нигә кирәк икән моңа шул чаклы бүлмә?!

Ялгышалар төн кунаклары. Кушылган ике фатирның бер бүлмәсе, кухнясы, бәдрәфе-ние белән—этләрнеке. Рәхәтләнеп үзләренчә яшәп яталар. Бу якның тәрәзәсе һәрвакыт ачык, шуңадырмы, өйдә яман ис сизелми.

— Дәү абый, ә, Дәү абый, бәлки безне чыгарып җибәрерсез?

— Ачыклагач,—диде хуҗа, кырыс кына.

Унбиш минуттан телефон шылтырады. Шаһназаров кәнәфигә чумды. Сөйләүчене игътибар белән тыңлады. "Алай, алай",—дип җөпләде, әмма үзе бер генә сорау да бирмәде. Ишек төбендәгеләр хафага калды.

Сизенәләр, сүз алар хакында. Бая елгыр егетләр турында да тикмәгә генә әйтмәгәндер бу. Борчылырлык та иде шул. Килеп кабулары, күрәсең...

Телефоннан сөйләшү тәмам. Шаһназаров өстәлдә бармакларын биетеп алды. Карасу-зәңгәрсу күзлеген киеп куйды, авызына затлы сигара капты. Берничә мәртәбә пошкылдатып төтен бөркеде.

— Үтенеп сорыйбыз, Дәү абый?

— Юркин, чын исемен ничек?

— Николай.

— Алдашма.

— Аллам орсын.

— Моннан өч ел элек өлкән лейтенант Николай Юркинны син үтердеңме?

— Менә тагын.

— Туры җавап бир?

— Мин беркемгә дә кагылмадым.

— Бу таныклама анык бит. Беләсеңме, мөртәт, кеше үтерүчене нишләтәләр?—дип, кызып китте Шаһназаров.—Андыйларның үзләрен дә дөмектерәләр. Җитмәсә, корал белән минем йортка басып кердең. Җавап тотарга туры киләчәк.

Ялган Юркин күз яшенә буылып еларга, ялварырга кереште. Әшнәләре аның башына тондырдылар, Шаһназаров этләрен чак-чак кына тыеп калды.

— Идәнгә утырыгыз,—дип боерды хуҗа тегеләргә.—Төрекчә иттереп. Менә шулай. Калганын егетләр хәл кылыр, алар беләләр.

Залга керешли хуҗа тагын телефоның алды.

— Миндә кызык бар, җибәр егетләреңне.

Шаһназаров эш тәмам, дигәндәй, тагын йомшак кәнәфигә инде. Төтен алкалары ясап уйнады. Хуҗаның тыныч кылануы, бигрәк тә аның телефон аша әледән-әле күрсәтмәләр биреп торуы ялган милиционерларны тәмам куркуга төшерде. Кем икән бу, Дәү абый?! Эчке эшләр министрлыгында берәр түрәме? Әллә дәүләт иминлегенекеме? Бәлки күләгәдәге Премьер-министрдыр, Президенттыр?! Күз ачып, күз йомган арада тешләде дә алды үзләрен. Юк, баш җитәрлек нәрсә түгел бу!.. Этләрен генә күр, телләрен "милиционер"ның колак яфрагына тигерәләр инде. Кыймылда гына, башыңны чәйнәп йотачаклар. Пистолет та, пычак та ярдәм итмәде. Ә хуҗа аларның ни эшләп йөрүләре белән бөтенләй кызыксынмый да. Берәү булса, тәмам тинтерәтер иде. Бу барысын да белеп бетергән—котылу юк болай булгач.

Ишек кыңгыравында музыка уйнап җибәрде. Этләрнең колагы торды. Хуҗа телефон төймәсенә басты—ишекләр ачылып та китте. Хикмәт менә нәрсәдә икән, кем бар анда дип, һич сорап йөрисе түгел. Монысын да телефон хәл итә. Егетләре, эһ дигәнче, килеп тә җиткәннәр.

— Кенәз, таныйсыңмы боларны?

— Яле, күтәр башыңны,—дип, Кенәз "милиционер"ның ияген учлап тотты.—Юк, ахрысы.

— Көчек бу,—диде Фара.

— Ә-әә, шул юлбасармыни, нишләп йөри ул монда тагын? Шаһмиран кисәткән бит инде теге чакта. Аңламаса аңламас икән, адәм актыгы.

— Минем утарны дәгъвалаучы, димәк. Ә мин аны бөтенләй танымыйм да.

Фара әсирләрнең өчесенә дә богау салды. Кенәз бу йортка ничек килеп чыгулары, адресны кемнән алулары белән кызыксынырга кереште. Аны Шаһназаров бүлдерде:

— Аларын тегендә ачыкларсыз. Ул, хәтта, минем Дәү абый икәнемне дә белә.

— Шулай ук мыни-и!..

— Моннан өч ел элек өлкән лейтенант Юркинны үтергән,—Шаһназаров кызыл тышлы таныкламаны сузды.—Менә шуның белән

йөри хәзер.—Эзләүдәге адәм. Мәрхүм Юркинның өч баласы ятим калган.

— Аны мин үтермәдем,—дип, телгә килде Көчек.

— Тагын саташкансың син, юньсез.

— Машиналарыгыз кайда?—дип кызыксынды Дәү абыйлары.

— Бакча ышыгында.

— Көчекнең формасын салдырыгыз, куртканны кидер—бертөсле булсыннар,—диде Шаһназаров.—Барыгыз, тәмам туйдырдылар. Авызларын бәйләргә онытмагыз. Калганын үзең ачыклап бетер. Һәм башкасын да...

Егетләр әзерлек эшләрен тиз тоттылар. Чыгар алдыннан Кенәз, Дәү абыйсын култыклап, читкәрәк тайпылды, пышылдап кына сорап куйды:

— Нишләтим, УГРОга илтимме?

— Юләрме әллә син?!

— Аңладым.

— Ераграк йөрегез. Бездән төтен таралырга тиеш түгел.

— Сез әйткәнчә эшләрбез, Дәү абый, исән булыгыз!

Автомат ишекләр ачылып ябылды да өй эче тынып калды. Шаһназаровның "малайлары", бүген эш житәрлек булды дигәндәй, ялкау атлап, үз бүлмәләренә ял итәргә кереп киттеләр. Рэкетчылар түгел, майор Килдебәков үзе килсә дә, шулай "зурлап" озатыр иде абзагыз, ул андыйлардан котылу чарасын бик яхшы белә.

* * *

Бандитларның иснәнеп йөрүе Шаһназаровның тынычлыгын алды. Теге атнада язарга керешкән мемуарын өстәлнең бер читенә үк этеп куйды. Менә бит ни кыланалар?! Ник килгән инде болар, фаразан? Таларга, билгеле. Ә бәлки бөтенләй юк итәргә үк уйлаганнардыр—кем белә? Юркин, имеш. Юркин буе житәрлек булгач, Дәү абый диләрмени аны, маңка! Калганын Кенәз карасын, әнә. Әмма информациянең бу кадәресе дә чыгарга тиеш түгел иде бит. Кайдадыр йомшак буын бар, димәк. Шаһмиранга әйтеп куярга кирәк, итәк-җиңен җыеп йөрсен. Шаһназаров кемнедер гаепләргә җыенмады. Бу Көчек дигәннәре теге чакта утарга килеп чыккан иде шул. Бару-кайтуны күзәтергә мөмкин. Дәү абыйны кемнән белгән ул? Хикмәт шунда. Ярар, аларын Кенәз ачыклап бетерер.

— Болар бар да чүп кенә, чүп кенә,—дип сөйләнде Әмир Шаһназаров үзалдына.

Ул фикерен икенче бер нәрсәгә юнәлтергә омтылды. "Татсиб" фирмасы юридик яктан юкка чыгарылды—монысы хәзер аны борчымый инде. Шулай кирәк булды, органнарны саташтыру өчен. Кешеләр белән эш һаман да катлаулырак. Мушка, Хәнҗәр дигәннәре читлектә утыра. Алга таба информация шулардан таралырга мөмкин. Тикшерүче Килдебәковның койрыгына басарга дип күпме әйтелде, сузып киләләр. Каты чикләвек, имеш. Каты чикләвеккә зуррак чүкеч тә бар бит аңа.

Шаһназаров телефон төймәләренә баскалады. Озын-озын пипелдәү генә ишетелеп торгач, борчыла калды. Ни булган моңа? Әллә номерлар ялгыш җыелдымы соң? Кабат җыйды.

— Ник дәшмисең, Гөлшәһидә?

— Егетләр кинәшергә кергәннәр,—дип аңлатты кыз, җавап бирми торуының сәбәбен.—Капка астыннан тагын Көчек шуышып чыккан монда. Просто, баеп алырга ниятләгән. Хәзер "Дәү абый" сүзен ачыклыйбыз.

— Карагыз, исе калмасын. Үзең минем янга җыенмыйсыңмы? Әйдә, кил, кәефемне җибәрделәр.

Таларга дип кергән рэкетчылар өй эчендәге байлыкны күрми дә калдылар. Бусагадан торып бүлмә санап маташалар. Этләрнекеннән тыш та Шаһназаровның бер үзенә биш бүлмә. Китапханәне исәпкә алмаганда һәммәсе дә байлык белән шыгрым тулы. Юк, келәм, бәллүрләр генә

түгел, алары мәрхүмә хатыннан калган мал, өйдә башкасы да җитәрлек. Әмир күп еллар буе сәгать җыю белән шөгыльләнә—хоббие шул. Сәгатьнең сәдәп кебек бәләкәеннән башлап, идәннән түшәмгә тигәннәренә чаклы бар. Соңгыларын хан заманыннан калган байлык, дип йөртә. Бәлки шулайдыр да, арада бернинди мөһер-мәгълүматсызлары күп. Алтын-көмештән коелган, ахак, зөбәрҗәт белән бизәлгән кул сәгатьләре бихисап—ике як шкаф шыплап тутырылган. Рэкетчыларга боларның берничәсе дә череп баерга җитәр иде үзе. Ә вентиляция коесына яшерелгән сейфларны алар барыбер таба алмаслар иде. Анда төрле заманда төрле илләрдә сугылган алтын акчалар, бизәнү әйберләре: алка, йөзек, беләзек, брошка, каптырма, билбау-камәр ише нәзакәтле мал. Боларын хәтта Шаһмиран да белми. Әмир ашыга-кабалана торган кеше түгел, берәүгә дә серен чишәргә ашыкмый, вакыты җиткәч, һәммәсе дә шул кызга калачак...

Узган ел, юбилейдан соң, бер талпынып куйган иде болай, әллә малны варисларыма тапшырыйммы икән, дип. Сабыр итәргә уйлады. Варислары үзегезгә билгеле: Ташкенттагы кызы белән Гөлшәһидә. Хәлләр үзгәребрәк китте бит әле монда. Фирманы таркатырга туры килде, янасы төзелмәгән. Бөтен мәшәкать тагын үзенә төшә, җиннәрне югарырак сызганмыйча да ярамас, ахрысы. Кем әйтмешли, тукталырга причал кирәк. Ул инде дулкын кагарлык, көймәне селкетерлек булмасын. Американы яңадан ачасы юк-югын. Заманасы башка. Дәүләт үзе тудырган мөмкинлекне файдалансаң, шул җиткән.

Гөлшәһидә тиз әйләнде. Аны күрүгә Әмирнең бөтен борчулары таралды, күңеле күтәрелеп китте. Тегесе дә эт җан түгел диген—Дәү абыйсының муенына сарылып, кечкенә якта борын төртеп чыгарга өлгергән сакал-мыекларына кайнар иреннәрен тиерде, шома битен куеп, рәхәтләнеп кытыкланды.

— Озаттым үзләрен.

— Онытыйк аларны.

— Бүтән борчымаслар.

— Әйдә, чәй куйдым,—диде Әмир, кызны кухняга чакырып.

Мондагы мәшәкатьләрне дә төймәләр хәл итә. Кухняда чит илдән кайтарылган комбайннар—ризыкны шулар хәзерли, шулар пешерә. Әмма хуҗа төнлектә алар белән булашуны кирәк тапмады. Барысын да Гөлшәһидә иркенә калдырды. Тегесе өстәлгә кетердәвек печенье, берничә төрле чикләвек, алма, әфлисун, заман ашамлыгы—банан ише җиңел ризыклар гына куйды.

— Ничек?—дип сорады Гөлшәһидә, суыткычны ачып.

— Сугыш чукмарын әйтәсеңме? Ал, әйдә!

Шаһназаров французларның "Наполеон" коньягын шулай дип йөртә. Соңгы елларда шешә ачу белән артык мавыкмаса да, Гөлшәһидәсе килгәндә "сугыш чукмары" белән бил алышмыйча калмый. Дәрт, дәрман өсти ул аңа, күңелен күтәрә. Бүген нәфесе төшеп тора тагын, берне дә, икене дә төчкертүе ихтимал.

Залга чыкканчы, баш саф чакта кайбер нәрсәләргә ачыклык кертергә ниятләде. Аны Килдебәков тарафыннан кулга алынучыларның язмышы кызыксындыра иде.

— Нишләргә җыенасыз?—дип сорады ул.

— Мушканы камерадашы дөмектергән бит, әйтергә онытып торам икән.

— Кайчан?

— Моннан ике көн элек. Тагын бер яңалык: кичә тикшерүче үзенең эш бүлмәсендә тәрәзә форточкасына асылынып үлгән—гаҗәп!

— Майор Килдебәковмы?

— Нәкъ үзе.

— Тагын ни?

— Бетте бугай. "Минем үлемемдә берәүне дә гаепләмәгез",—дигән язу калдырган.

— “Дело” ничек? Бу бик мөһим.

— Нинди “дело” булсын—юк хәзер андый башваткыч. Унжиде том язып тутырган икән, җүләр.

— Синең эшме?

— Эшен йомышчылар башкарды...—диде кыз.

— Әйдә, шул хөрмәткә!

Шаһназаров “Наполеон”ны әйләндереп каплагач, тәмам бушанып, хозурланып калды. Юка телемләп киселгән әфлисунны тәмләп кенә суырды, банан әрчеп ашады, рюмкаларны кабат тутырды.

— Чикләвеккә үрел!

— Сиңа да ватып биримме?

— Бер-икене,—диде хуҗа.

Инде барысы да ачыкланып бетте бугай, дип уйлады Гөлшәһидә. Тикмәгә генә чакырмаган икән, картлач. Борчыла, һәммәсен дә алдан күреп эш итә. Ә менә Шаһмиранга шушы алдан күрүчәнлек җитенкерәми, аңа һәрвакыт Дәү абыйсының әйтеп-искәртеп торуы кирәк. Мушка мәсьәләсендә Шаһмиран үзе белеп эшләгәч, әнә ничек куанды, артык сорау биреп азапламый, шул хөрмәткә күтәрә дә куя, күтәрә дә куя.

Ашыгыбрак нәтиҗә ясап маташа икән кыз, бетмәгән картлачның сүзе. Ярты-йорты гына сөйләшә торган кеше түгел шул ул.

— Син бернәрсәне оныттың бит, Гөлшәһидә,—диде ул тагын рюмка белән шаярып.

— Кара, искә төшми?!

— Мәскәү койрыгын әйтәм.

— Ә-әә, Хәнҗәрме?

— Аны анда калдырырга ярамас.

— Чыкты инде. Ялга җибәрдем үзен.

Табынны түгәрәкләп, Шаһназаров әкрен генә өстәл янынннан кузгалды.

— Рәхмәт, Гөлшәһидә, бөтен борчуларымны юып төшердең. Мин синең өчен яшим хәзер. Әйдә, залга чыгыйк. Иртәгә утарга китәм, боерган булса. Күңелем тынычланды. Иркенләбрәк уйларга кирәк. Саф һавада баш яхшырак эшли. Фирмасыз калу ярамас, дим.

Шаһмиран Дәү абыйсын бик яхшы төшенде. Димәк, зур эшкә тотынырга җыена. Ходай аңа башны да, сәләтне дә кызганмаган. Шулай сау-таза гына йөреп торсын инде. Күңелен күрергә кирәк...

— Душка кереп чыгыйм,—диде Гөлшәһидә.

Әмир карасу-көрән зебра бәрхете белән тышланган олы кәнәфигә чумып, кызның юынып чыгуын көтә башлады. Сугыш чукмары аның канын шактый кыздырырга өлгергән иде. Ул Гөлшәһидәнең һәрвакыттагыча иңенә ак томандай үтә күренмәле халат элеп чыгасын белеп тора. Вак-төяген бөтенләй киеп маташмый. Шушы гадәтен ярата ул кызның.

* * *

Сәүдәгәр Себерне, Уралны ярата. Азау тешен шул якларда чыгарды, тугыз ел буе тун җир чокыды, урман кисте, ташкүмер чапты, алтын эзләде. Менә ничә ел инде шул тарафтан мал ташый, фирманы аякта тота.

Теге хәерсез Мушка вакыйгасы вакытлыча Пермь якларына юлны япты. Товары үтемле иде. Радиоактив материалларны дөньяның төрле кыйтгасында бик теләп алалар. Доллар яңгыр булып ява. Бу табышны югалтмаска иде.

Мушканың үлеме Сәүдәгәрне аеруча куандырды. Әйтергә кирәк, монда Удмуртия кэгэбечеләренең дә хатасы бар. Сәүдәгәр белә инде: гаепләгә суд җинаять кылынган урында—Глазов шәһәрендә ясалырга тиеш иде. Ә алар Мушканы Казанга озаттылар. Мәсьәлә бик ансат кына чишелде дә куйды...

— Әлегә Пермьны онытып тор,—диде Шаһмиран, Сәүдәгәр бу хакта сүз кузгаткач.

— Ижауга ярыйдыр бит?

— Үзең чамала.

Сәүдәгәр өчен шушы ике кәлимә бик җиткән. Юлга җыенырга кирәк булыр.

Офистан чыккач, Тимерҗан җиде юл чатындагы юлчыдай катып калды. Соңгы көннәрдәге яңалыклардан аның күңеле ташый иде. Аз гына тотып куясы, кемнәндер иркәләнәсе, кемнедер иркәлисе килә. Кая барсын ди—Нурия янына инде! Тимерҗан "Чибәркәй" кафесы тарафына юл тотты. Ни өчен "Чибәркәй"ме? Анысын әзәри Синаннан сорарга кирәк. Ул хатыны Нурияне бик тә ярата, кафесына да аның исемен кушты, шунда ук үзен мөдир итеп тә куйды. Синан да Тимерҗан шикелле үк сәүдәне оештыру эшләре белән мәшгуль. Анда чаба, монда йөгерә—мал таба. Мал дигәне, туксан алты градуслы спирт. Кафеның арткы бүл-мәсендә, спиртка су кушып, аракы ясыйлар, бер литрдан алты-җиде шешә чыгаралар, аның күпчелеге шәһәр буйлап сибелгән кибет-палатка-ларга озатыла.

Синан—сәүдә корты. Сукмагы Татарстандагы барлык спирт заводларына салынган.

— Өнемме-төшемме,—дип каршылады Нурия Тимерҗанны, муенына сарылды. Кайнар иде чибәркәйнең сулышы. Тимерҗан мәгъшукасын нәфесләнеп кысты, кочагыннан ычкындырмыйча гына ишектәге ачкычны борып куйды.

— Акрын, түземсез, бу диванны син генә ватып бетерден инде,—дип шаяртты Нурия.

— Үзең дә хәйран чөясең, маладис.

— Ял ит, мин табын әзерлим,—дип, Нурия диваннан күтәрелде.

Шоколад суыра-суыра коньяк шешәсе тәмам бушатылды. Иркәләү, мактау сүзләре әйтелде. Акрынлап язгы караңгылык иңде. Әмма гашыйклар һич тә кайтырга ашыкмадылар. Авырлыктан диван берничә мәртәбә ыңгырашып-сыкранып алды.

— Кузгалабызмы соң?

— Синаның өйдәме?

— Чаба шунда.

— Бөгелмәдә ни калган аңа?

— Спирт белешкәндер.

— Ярый инде каптырмаганнар үзен.

— Рэкетчыларны әйтәсеңдер син, Тимерҗан.

Чыннан да Сәүдәгәр белеп үк бетерми иде. Рэкетчылар андагы предприятие директорыннан утыз биш миллион сум акча таләп иткәннәр. Калым түләүдән баш тарткач, тегене урманга алып барып эт урынына кыйнаганнар, үтерү белән янаганнар. Ык-мык итеп, ярым-йорты вәгъдә биреп, котылып кала. Кулга акча кермәгәч, директорны янадан эләктерәләр.

— Менә адресың, телефон номерың, хатының фәлән атлы, төгән җирдә эшли, кызыңның исеме болай, уналты яшьтә, фәләненче мәктәптә укый, улың Волгоградта хезмәт итә. Хата юкмы,—диләр рэкетчылар.— Булмаса, аларга да чират җитәр. Ә улыңны Чечняга олактырабыз, ул аннан болай да кайтмаячак. Түлә, дауай!

— Кайдан табыйм шул кадәр сумманы,—ди директор, кулларын җәеп.

— Исән каласың килсә, табарсың.

— Киметегез яртысын,—дип ялына директор.

— Болай да аз сорыйбыз әле,—диләр тегеләр.—Күп кәҗәләнсәң, тагын өстәрбез, шул.

— Юк, бит, ниШлим.

— Яхшырак эшләргә кирәк.

Директорның үнәченнән алып, бугазына пычак териләр. Ике сөйләшергә урын калдырмыйлар.

— Бу юлы алдый алмассың, яз вәгъдә кәгазенне.

Акча алуның көне, сәгате, урыны билгеләнә. Урыны—шәһәр уртасындагы азык-төлек кибете тирәсе. Калганы директор эше түгел, тик акчасын гына онытмасын, югыйсә, икеләтә түләргә туры киләчәк. Мәсьәлә башкачарак хәл ителергә дә мөмкин. Әгәр инде органнарга хәбәр салса—башын бетерәчәкләр, ул хакта каты кисәтәләр.

Анысын директор үзе дә чамалый. Әмма, рэкетчылардан котылам дип, фирманы чишендерә алмый ич инде. Ярый әле шуның белән генә канәгатьләнсәләр?! Әнә, болай да аз сорыйбыз, диләр, тиенен дә кимет-миләр. Почмакка китереп кысылган директор хәлне органнарга сөйләп бирергә мәҗбүр була. Дөрес эшләгәнсен, дип тынычландыралар аны.

Шуннан соң шәһәр күләмендә "директор" операциясе хәзерләнә. Дипломатка утыз миллион сумны (операция барып чыкмаган очракта биш миллионны яңадан эзләп килсеннәр өчен) санап салалар. Акчаның номерлары язып алына. КГБ һәм МВД хезмәткәрләре машиналарын читкәрәк яшереп, үзләре якын тирәдәге йортларга урнаша.

Көн салкынча. Директор юка киенгән. Кулында акча тулы дипломат, сәгатьләр буе кибет тирәсендә урала. Ләкин янына килүче юк. Өч мәртәбә кибеткә кереп, сыра алып чыга. Салкыннан һәм куркудан калтырана-калтырана шешә авызыннан сыра чөмерә. Эче яна күрәсең. Сактагылар бу галәмәтне елмаеп күзәтәләр.

Монысы ни тагын? Ике милиционер абзыйга килеп бәйләнә. Син нишләп бу тирәдә ураласың, имеш. Нигә өеңдә генә эчмисең? Мескеннең җиңеннән үк тарткаларга керешәләр закон кешеләре. Бөтен эшне бозачаклар, операцияне өзәчәкләр болар. Кизүдәге егетләр тиз генә рация аша шәһәр милиция идарәсе белән элемтәгә кереп, тегеләрне аннан алуларын таләп итәләр. "Объектны тынычлыкта калдырыгыз, хәзер үк ул тирәдән юкка чыгыгыз",—дигән каты әмер алгач, хәсрәт милиционерлар җәһәт кенә табан ялтырату ягын карыйлар. Рәхәтләнеп тәртип саклаганда ни кылана бу җитәкчеләр, һич анламассың?!

Аннан соң да әле шактый дерелди директор. Берзаман аның яныннан выжлап кына "тугызлы" машинасы узып китә. Кырган башлы ике егет утырган. Бераздан тагын пәйда була болар, ләкин туктамыйлар. Шул чак "тугызлы"га ниндидер "мигалка" иярә. Соңыннан ачыклаганча, шәһәрдә билгесез операция баруын шәйләп икътисадый җинаятьләргә каршы көрәш идарәсе хезмәткәрләре дә кузгалган икән. Әмма рэкетчыларны өркетергә шул җитә кала инде—операция өзелә.

Директор өенә кайтып, җылынырга да өлгерми, телефон челтери. Рэкетчылар икән. Үзләрен сатып, ни кылырга җыенуы белән кызыксы-налар. Хата ясадың, башыңны бетерәбез, дип яныйлар.

— Өч сәгать буе көттем. Нинди "мигалка" узуын мин кайдан белим, бәлки эш белән баручылардыр,—дип анлата директор.—Акча үзем белән, хәзер үк чыгарам.

— Ашыкма, көтеп тор, ташлама трубканы.

Телефон шактый тын торды, киңәшәләр, димәк. Хәзер үк чыгарам дигәч, кызыктылар, күрәсең.

— Бер сәгатьтән урынында бул, кара аны,—дип кисәтәләр рэкетчылар.

Дәүләт иминлек комитеты хезмәткәрләре өчен бер сәгать артыгы белән җиткән. "Директор" операциясе "камау" операциясе итеп үзгәртелә. Шәһәрдән чыгучы төп магистраль—урамнарга уникe милиция посты куела. Дипломатны алганнан соң, "тугызлы"ны тар тыкрыкка-тупикка кысрыклау каралган иде. Шулай килеп чыкты да. Кайсы тарафка юнәлсәләр дә, юлларында автоматлы постлар тора. "Тугызлы" аулак урамга борылырга мәҗбүр ителде—ә монда аларны дүрт яктан дүрт автоматчы урап алды. Кырылган башлар шунда ук җиргә сузып та салынды. Аларның кесәләрен-нән директорның утыз биш миллион сумга язган вәгъдәнамәсе табылды. Блокнотларында, инде үзегезгә билгеле булганча, гаилә әгъзалары турында мәгълүматлар язылган иде...

Тимержан хаталана, әлеге рэкетчылар арасында Синанның исеме телгә алынмый. Ул анда бөтенләй катнашмаган. Бу хакта Тимержанга Нурия бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Рэкетчылар аныкы бит.

— Бәлки.

— Синанынны якламыйсынмы?—дип кызыксынды Сәүдәгәр.

— Кирәге бер тиен. Әйттем бит инде: адәм түгел, арт бакчадан йөри, хайванча яши, дип. Яратмыйм шул гадәтләрен.

— Озак йөрмәс ул.

— Үзем дә шулайрак уйлап торам,—диде хатын, серле генә.

— Ул чакта инде без синен белән иркенләп Анталья комында кызынырга китәрбез. Фирмабызнын ял йорты шунда.

— Инде ничәнче мәртәбә вәгъдә итәсен.

— Уралдан йөреп кайтыйм инде,—диде Сәүдәгәр.—И-ии, онытып җибәргәнмен.

Тимержан Нурия муенына алтын чылбырлы алтын барс муенсасын кигезде. Тегесе Сәүдәгәрнен табак битен чәп иттереп үбеп алды.

— Рәхмәт инде, Аю бабам,—дип иркәләде ул Тимержанын.

— Барснын күзләрен генә күр әле син!—диде сәүдәгәр, үз бәясен арттырырга теләгәндәй.

Алтын барсның күзләренә энже бөртеге уеп куелган иде.

... Фирма ябылды дип, кул кушырып утырмассың бит. Ниятләгәнчә, Сәүдәгәр Ижау якларына юл тотты. Әшнәләре байтак анда. Кемнен нәрсә белән шөгыльләнүен белеп тә бетермәссен. Елан мөгезе кирәк дисән, анысын да табып китерәләр—долларынны гына кызганма.

— Ничә пушкы (пистолет) аласын?—дип сорады ижаулы.

— Күпме табасын?

— Унны, утызны, йөзне...

— Оhо!

— Йә, ничәне?

— "Макаров"мы?

— "Макаров".

— Иллене бир хәзергә,—диде Сәүдәгәр, әшнәсенен иненә шапылдатып.

— Берсе—егерме биш мен доллардан.

— Һәр унысына ун процент киметергә, килештек ич,—дип сатулашты алучы.

— Гафу ит, онытканмын.

— Үзенә дигәндә син шулай.

Икесе дә шаркылдап көлеп җибәрде. Сәүдәдән канәгать иде алар.

— Ничек алып китәргә уйлыйсын?—дип кызыксынды Ижау кешесе.

— Анысы минем эш. Синен коралны заводтан ничек чәлдерүенне төпченмим ич.

— Зинһар, сак кылан, безне төп башына утырта күрмә.

— Шүрләмә.

— Үзен беләсен.

— Икенче килүемә бер унлап "калашник" хәзерләп куй,—дип искәртте Сәүдәгәр.

— Карарбыз...

Тимержан, Ижаудан, әнә шулай, бернинди мәшәкатьсез, ул-бусыз гына баеп кайтып керде Казанга. Бер дистәсен шәһәрдә үк урнаштырды. Калганын Польшага алып китәргә булды. Анда "Макаров"ны хуп күрәләр. Кыйммәт йөри.

Варшавага, Җәвид Шәрәхтуллинга шалтыратты. Килештеләр, Брестта үзе каршы алачак. Берәр атна кунак булырсын, ди Варшава базары хуҗасы. Җәвид металл өчен бурычларын түләп бетергән иде. Шуна күрә, Тимержан кунак булып калудан шүрләмәде. Алар бер-беренә кирәкле кешеләр бит.

Бу юлы Сәүдәгәр КамАЗга кер юу порошогы, шампунь ише мал төяде. Башта ул пистолетларны порошок әрҗәсенә яшерергә уйлаган иде. Әлеге ниятеннән кире кайтты. Ник дигәндә, тамгачылар, гадәттә, товар арасында казынырга ярата. Куркыныч. Монда гап-гади юлны сайларга кирәк. Пистолетлар күз алдында торсын, әмма күренмәсеннәр, беленмәсеннәр. Хикмәт шунда. Эзләнсәң, шарикларыңны эшләтсәң, табыла икән җае. Теге чакта цирконий, борий, германий тимерләрен ничек озаткан иде бит Польшага. КамАЗга башта атлар төяде, аннары тимерләрне пычракка буяп, ат аягы астына тондырды—күз алдында кебек, ә шиклә-нерлек түгел. Берәүнең дә тизәк актарып йөрисе килми. Монысында да шулайрак эшләргә кирәктер бәлки.

Бердәнбер урын—машина астына асылган запас көпчәк. Ләкин аны да тикшерергә мөмкиннәр. Ә менә кабина төбәсендәге кабартылган камерага менеп житә алмаячаклар. Таптымы абзагыз әмәлен—тапты, нинди генә урын әле!

Җәвидкә туган-тумачаларыннан сәлам илтәсе булыр. Каклаган каз алырга кирәк—үлә шуның өчен. Базарда очрамаса, авыл җиренә чыгарга кала инде. Ансыз барырга ярамый. Колачлы егет Шәрәхтуллин, яшь белә. Менә кемнән үрнәк алырга кирәк аңа.

Тагын күздән югалдың, дип, Нурия үпкәләр инде. Шәбрәк бүләк сайлап аласы булыр үзенә. Ир-кәмәше—Синан—артык йөк, әлбәттә. Әйләнеп кайткач ук хәл итәчәк Тимерҗан ул мәсьәләне. Егетләрен дә туйдырып бетергән, Нуриясе дә гарык. Иртәгә—Варшава якларына сәфәр. Сәүдәгәр анын уңышлы чыгасына тамчы да шикләнми. Көпчәк камерасы эчендә ни барын, хәтта, шофер үзе дә белми. Сәүдәгәр нәрсәдән шүрләсен. Мондый сәяхәтләрне генә күргән лә ул.

* * *

Егетләрнең шулай анда-монда бәрелеп-сугылып йөрүләренә борчыла ук башлады Дәү абыйлары. Иркенләп уйлар өчен утарына килде. Байтактан күзгә чалынмагач, Шәмсетдин абзый белән Хөмәйрә апа тынгысызлана төшкәннәр. Үзен күргәч, бик тә куаныштылар.

— Җәй кайтып йөрмәссен, безгә дә күңелле булыр,—диде Хөмәйрә апа, кунагын тәмле чәй белән сыйлап.

— Бакчага чыгам хәзер.

— Алма елы быел,—дип, эләктереп алды Шәмсетдин абзый.—Теге кое янындагысында яфрак-фәлән шәйләнми, чәчәк кенә.

— Көзгә кисәрбез аны.

— Әкәмәт, үзе шау чәчәк ата, ә җимеше юк,—дип офтанды карчык.

Язның яме—алма, чия чәчәк аткан чак. Утар үзенә генә хас сихри бер утрау кебек бу көннәрдә. Илаһи хозурлык. Электә Казансу буйлары ханнарның сәйранга чыга торган урыны булган, дип сөйлиләр. Шулайдыр да. Тирә-юньдә юан-юан имәнлекләр, нарат, каен урманнары шаулап торган, ул чакта Казансу үзе дә ярларыннан ташып аккан. Урман эчләрендә, инкүлекләрдә камышлы, кош-кортлы, шул ук вакытта саф сулы күлләр җәйрәп яткан, яр буйларыннан чишмәләр ургыган. Илбасарлар яулап алгач, бу тирәләр тәмам таланган—урман киселгән, күлләр кипкән, җәнлек, кош-корт кырылган. Элеккеге матурлык мәңгегә югалган. Тарихчылар мондый күренешне, милли фаҗига буларак, язып та калдырганнар.

Бүген инде Казансу тирәсенә күпләгән бакчачылык ширкәтләре сибелгән, алар вак-төяк кишәрлекләргә бүленеп, йә бик зур коттеджлар, йә алачыктай бәләкәч өйчекләр белән шыплап тутырылган. Барысы да яшеллекне кысрыклау бәрабәренә. Шаһназаров утары ширкәтләрдән читтәрәк, урман култыгына сыенып утырган. Ә бакчасына, әйтерсең, кар явып киткән—ап-ак чәчәккә төренгән алма, чия агачлары күзне рәхәт иркәли, күңелне хушландыра. Нарат урманыннан искән йомшак җил, чәер

исен китереп, аны чәчәкләр хушбуе белән баета, тәнгә-җанга шифа өрә. Мондый хозурлыкка бигрәк тә бал кортлары куанышa. Аларның синдә гамьнәре юк, тәүге чәчәкләрнең тәмен татып калырга ашыгалар. Кортлар җәен усаллана—чагарга гына тора. Май кортлары—бакчачының чын дуслары, бал гына түгел, җимешне дә шулар булдыра бит бер караганда. Бу изге затларсыз чәчәкләр кысыр калыр, җимеш бирмәс иде.

Шаһназаров шулар хакында уйланып, кое янындагы ак болыттай кабарып утырган алмагачы янына килеп басты. Күр син моны, дөньясын капларлык пәһлеван бит! Ак та ак, бу да ак! Ә күзен карыйсың, өзеп алырлык алмасы булмый. Әмир монын хикмәтенә узган ел, тамырын актарып карагач төшенде. Теге елгы суыкта үзәк тамырга зыян килгән икән. Җир суының якынлыгы да тәэсир иткәндер бәлки черергә. Ә менә өстәге яшь тамырлар исән калган. Чәчәккә язгы дымны шулар бирә, ә җимешне түендырырга көч-куәте житенкерәми. Пәһлеван агач чикләвектәй вак алмалар белән канәгатьләнергә мәҗбүр. Тамырның, үзәкнең ныклыгы кирәк шул...

Күптән кисәргә уйлаган иде Әмир бу алмагачын, ничектер, кулы бармады. Әлеге аклык аңа яшьлегендәге Румыниядән килеп укыган бер чибәрне хәтерләтә. Кызы фәрештәгә охшаган иде. Авыр еллар булуга карамастан, гел ап-ак күлмәк киеп йөрде. Суга төшкән балдактай югалды шул инде ул фәрештә.

Абзагыз шактый гомер кичерде, күпне күрде, күпне белә. Аның җитмеш еллык гомере өч буыннан тора, дияргә мөмкин. Беренчесе—сугыш чоры, икенчесе—партия заманы, соңгысы—юк, картлык түгел, ничек диләр әле, базар мөнәсәбәтләре яшәеше. Әмир боларның берсен дә алып мактарга яки салып таптарга җыенмый. Сугыш чоры авырга туры килсә дә, ил белән бергә күтәрелде, шул ук вакытта максатчан да иде. Партия исә, Әмиргә заман аргамагына менеп җилдерергә ярдәм итте, кешедән ким яшәмәде, дәрәҗәсе дә, хакимлеге дә житәрлек булды. Тарих тәгәрмәче әйләнә дә әйләнә ул. Партия таркалды, империя җимерелде, хакимлек бетте. Җәмгыять, тамыры корыган алмагачтай, тәмам чирләде, үзәктән череде, ул утырган олы йорт бинасы кинәт гөпелдәп ауды. Шул черек нигездә башбаштаклык, җавапсызлык, караклык, ришвәтчелек, талау, үтерү тамыр җәйде. Монысын инде базар мөнәсәбәтләре, дип атадылар. Бернинди плансыз, житештерүсез, һәрбер эшне уптым-илаһи гына майтара торган базар. Алдакчылар базары. Шаһназаров менә шул базар мөнәсәбәтләренә үзенчә кереп китте. Аңардан син ник болай эшлисең, ник алай итәсең, дип җавап алучы юк. Кирәк икән, үзе хаким, үзе казый. Җәмгыять исә, тамырына зыян килгән чирле агачны хәтерләтә...

— Монысын кисеп, күзгә яшьрәкне утыртасы булыр,—дип, тәгаенләп куйды Әмир, алмагач кәүсәсенә суккалап.—Эш матурлыкта гына түгел, тазалыкта, ныклыкта шул. Кайберәүләр менә шуны оныттылар.

Әле тузан белән аралашырга өлгермәгән яз һавасы, чәчәкләр хуш исе Әмирнең сулышын киңәйтеп җибәрде, аның мие сафланды, башы яхшырак эшли башлады. Ә ул, тиле, рэкетчылар белән булышып, шәһәрдә, таш арасында ята. Нинди мәгънәсезлек, юк, кеше арасына чыгарга, хәрәкәт итәргә кирәк. Тукта-тукта, кабинетында элеккеге блокнотлары, телефоннар кенәгәсе бар бит аның. Бөтенләй онытып җибәргән. Әмир ашыгып, өйнең өченче катына күтәрелде. Төрле белешмәләрдән элеккеге танышларын барларга кереште.

* * *

Иртәнге якта утар янына кичерәк кенә вертолет-боралак төшеп утырды. Хуҗа аны капка төбенә чыгып көтә иде. Урыныннан кузгаласы итмәде, очучы үзе аның янына ашыкты.

— Исәнмесез?

— Саумысез.

— Ибраһим Габдуллин,—дип күреште очучы.

— Шаhназаров.
— Дөрес төшкәнмен, димәк.
— Без әле сезнең белән дуслашырбыз,—диде Әмир, бик үк җәелеп тормастан.
— Өч көн сезнең карамакта.
— Бик яхшы.

Шаhназаровның ни уйлаганын укучыга искәртеп куйыйк. Башта ул Әлмәттән ике-өч көнгә дип, шушы боралакны сорап алды. Исәбе— Татарстанны бер урап кайту иде. Нәкъ менә югарыдан күзләп. Яңа фирма өчен җирлек хәзерләү. Моны аңардан башка беркем дә майтара алмый. Хәтта вак-төяк министрлар да. Урыс әйтмешли, эчәгеләре нечкәрәк. Эшнең җаен, түмен белмиләр алар.

Зур сәфәргә кузгалды Әмир. Моннан утыз-кырык ел элек нефтьчеләр Тәтеш-Тархан тирәсеннән "кара алтын" эзләп маташканнар иде. Нәрсәдер таптылар да бугай, шулайрак хәтерендә калган. Әмир иң элек әнә шуны ачыкларга ниятләде. Киң Идел, биек-биек таулар, кишәрлекле-кишәрлекле урманнар. Әмма нефть вышкалары күренми. Шулай да түбәндә нидер шәйләнә. Шаhназаров төшеп утырырга әмер бирде. Боралак кунаклавын күргәч, кешеләр йөгерешеп килеп тә җиттеләр.
— Ни майтарасыз, егетләр?
— Су тутырабыз. Гаять шифалы.

Карасаң-баксаң, Тархан тауларыннан нефть эзләгәндә җир астыннан шифалы су бәреп чыккан икән. Тау чишмәләрендә дә шундый ук сихәтле су. Эшкуарлар чыганак янында үзләренең кечерәк кенә фирмаларын ачып җибәргәннәр. Су саталар, сум санылйлар. Булдыра егетләр!
— Нефть юкмыни?
— Кайдадыр бар бугай.
— Ә кайда?—дип төпченде Әмир.
— Ишетүебезчә, дәүләт аны кара көнгә саклый ди, ахрысы.
Без үзебез су белән эш итәбез.
— Табышлымы соң?
— Ә сез кем буласыз?
— Менә бу боралакның хуҗасы,—дип шаяртты Шаhназаров.
— Сәер, шулай да.

Күреп тора, су тирәсендә болганып рәт чыкмаячак. Аннары нефтьнең барлыгы-юклыгы да анык кына түгел. Егетләргә уңыш теләп, Әмир боралакка таба ашыкты. Күздә тоткан тагын бер ноктасы бар эшкуарның— Иж буйлары, Салагыш болыннары, элеккеге Красный Бор районы тирәләре.
— Көнчыгышкарак тот!—диде Шаhназаров, Чаллыны узгач.

Илленче елларда бу төбәктә табигать үзенең беренчел гүзәллеген саклый иде әле... Кеше аяк басмаган урманнарда аю, себеу сен ише киекләрне дә очратырга мөмкин иде. Кыр тавыгы, кыр үрдәге, көртлектәй кош-корт белән урман мыжлап торды. Чөнки урманнар җиләк-җимешкә, гөмбәгә бик бай. Ул Шаршады тирәсе! Әнә, үзе дә! Күпләр аны җирнең җәннәте, дип йөрттеләр. Чәй эчәргә берәр карчыкка төшсәң, самавыры кайнап чыкканчы абыстай бакча артындагы урманнан табагы белән кура җиләге яки карлыган җыеп керер иде. Иж буе урманнарында безнең якның барлык нигъмәт-җимешләре үсә. Шаршадыда халык арасыннан чыккан артист Шоңкар яшәгән, иҗат иткән, шунда күмелгән. Аның кабере, әнә тегендә, Саклау тавында. Үзе бер китап язарлык...

Салагыш шулай ук тарихи сала. Тик хәзер болыннарын Түбән Кама сусаклагычы басып киткән инде. Шаhназаров хәтерли әле, буровойлардан нефть урынына тозлы су фонтаны бәреп, бөтен болынны яндырып бетерде теге елларда. "Кара алтын" дигәннәре Волково авылы тирәсеннән табылса да, ятмалары бик чикле иде, аларны тиз суырып алдылар. Калмадымы икән соң шундый ятмаларның берәрсе? Бу кадәресен инде нефтьчеләрдән белешәсе булыр.

— Кара, теге йорт исән икән әле?

— Нинди йорт ул?—дип кызыксынды очучы Габдуллин.

Шаһназаров көлеп җибәрде. Үзалдына сөйләнеп бара икән ләбаса. Күп еллар узды шул инде бу вакыйгага. Нефтьчеләр эше белән танышырга килгәч, ничектер, колхоз идарәсенә дә сугылган иде. Хуҗалык эшләре белән кызыксынды. Шул вакыт идарәгә яман чәрелдәп бер хатын-кыз килеп керде.

— Авылны җир йота, әйдәгез тизрәк!

— Идарәдәгеләр дәррәү шул хатын артыннан чыгып йөгерде. Аларга Шаһназаров та иярде. Чыннан да авылны җир йота башлаган. Инеш буендагы бер йортның әйберләре урам уртасына ташылган, ә абзар-сарайлары инде тәмуг авызына төшеп киткән. Бакча башындагы карт өянкенең дә яртысы диярлек күмелгән, ул һаман упкынга шуыша. Астан шомлы гүләү тавышы ишетелә. Урамда басып торырга куркыныч. Өйләрдә кеше калмаган, күпләр басуга ук чыгып йөгергән. Ни булыр икән дип күзәтүчеләр дә, шүрләп, ары-бире сугыла, кая барып тотынырга белми, кычкыра, бакыра, елый, белгән догаларын укый, Ходайдан сабыр-шәфкатьлек сорап ялвара. Әмир дә шикләнә төште, бу мәхшәр ни белән бетәр икән, дип күзәтте. Әйтүләренчә, утыз-кырык метр озынлыктагы алты колач юанлыгындагы пәһлеван өянке, катлы-катлы итеп корылган карга оялары-ние белән бергә упкынга тәмам убылып бетте. Шуннан соң җир асты аждаһасының авызы томаланды. Тәмуг убыры, хәле киткән ерткычтай, соңгы мәртәбә уһылдап, бөтенләй тынды—авызы дөнья малы белән тыгылды. Упкын кырыенда дерелдәп торган йорт, ниндидер, могҗиза белән исән-имин калган иде. Әнә ул! Теге җәһәннәм казанын киртәләп куйганнар. Ахырдан бер әби авылдашларына өебезне шүрлектә онытылып калган менә шушы Коръән саклады, дип, изге китапны авылдашларына күрсәтеп йөрде. Бәлки шулайдыр да...

Боралакта очып узышлый Әмир шуларны күзәтте, хәтирәләрен яңартты, яшьлеген исенә төшерде. Нефть вышкалары бу тирәдән югалганнар инде.

— Җил куып эш чыкмас. Бүген без Красный Бор тавында кунарбыз. Шәп урын, искиткеч манзара анда. Татарстанның иң биек ноктасы. Борылыйк кире,—диде Әмир очучыга.—Авылга төшеп, яңа тоткан балык сатып алырбыз, уха пешерербез. Бәлки берәр кыр тавыгы да эләгер әле. Рәхәтләнеп ял итәрбез табигать кочагында.

Һәммәсе дә Шаһназаров әйткәнчә килеп чыкты. Төнге учак янындагы хозурлыкны әйтеп-сөйләп бетерерлек түгел иде. Аста, еракта-еракта төнге Чулман җәйрәп ята. Аның аргы ягында, якында кебек кенә, Минзәлә утлары балкый, сирәк-мирәк нефть факеллары җемелди. Ул тарафта "кара алтын" табыла әле, шуңа җемелди утлары.

— Йә, ничек?

— Әкият бу,—диде очучы Ибраһим.

— Иртәгә күрерсең менә.—Шаһназаров сүзен әйтеп бетермәде. Ул иртәгә ниләр эшләячәген алдан ук планлаштырып куйган иде.

Боралак таудан-тауга кунып оча да оча. Азнакай якларына да килеп чыктылар. Шаһназаровның бу тирәләрдә дә кайнар эзләре саклана әле. Әнә, ил башлыгы буларак сәяхәт итәргә, һәр тукталышында өчәр-дүртәр сәгать буе нотык сөйләргә яратучы Хрущев каенлыгы. Республика һәм район җитәкчелеге Никита Сергеевич хөрмәтенә шул каенлыкта әбәд-мәҗлес үткәргән иде. Казанда, партия өлкә комитетының Идел буендагы дачасында ук Хрущевка татарның тутырган тавыгы бик ошады. Татарстан буйлап сәяхәтенә дә ул шул ризыкны алырга кушты. Шаһназаров атаклы аш-су остасыннан бер адым да читкә тайпылмыйча тавыкны ничек хәзерләвен күзәтеп торды, пешеп җиткәч, аны хәсиятләп тәрдерде. Шушы тырышлыклары өчен Шаһназаровка һәм аш-су остасына соңыннан Ленин ордены бирелде.

Хәзер инде каенлыкны Хрущев исеме белән атап йөртәләр. Ә менә әбәд мәйданына бер истәлек йорты салып куйсалар, шәп буласы икән. Туристлар өчен дә кызык бит. Ул районның хәзерге яшь хакименә бу хакта әйтергә дип, чамалап куйды. Ни дисәң дә Хрущев авыл хуҗалыгында тулы бер инкыйлаб ясаган кеше. Онытылырга тиеш түгел.

Ык буенда, әнә теге, сулдагы урманлыкта Шаһназаровның шәхси умарталыгы бар иде, зур түгел—егерме-егерме биш оялык кына. Аны "Авангард" колхозы умартачысы Сөләй абзый (тулы исеме Сөләйман) карап торды. Шаһназаров алу-сату маһирлыгын, хәзерге тел белән әйтсәк, бизнесның тәмен шул чакта татып калды.

Боралак республикада үзенең искиткеч матурлыгы белән дан тоткан Чатыртау түбәсенә килеп кунды. Ни өчен Чатыртаумы? Ә сез, Азнакай якларына барып чыгыгыз, күрерсез нинди тау икәнен. Аста дугаланып-дугаланып Ык елгасы ага. Аның уң ягы—Урал тау итәкләре, сул ягында яшел болын җәйрәп ята. Менә шул гүзәллекнең урта бер җирендә Чатыртау калкып чыккан. Ерактан караганда ул чыннан да зур бер чатырны хәтерләтә. Кайсы гына тарафтан баксаң да шулай.

Чатыртауның тагын бер үзенчәлеге бар. Монда безнең якларда сирәк очрый торган җәнлек—сөркә (байбак дип тә әйтәләр, урысчасы—сурок) колониясе урнашкан. Чатыртау алар өненнән бал кәрәзенә охшап калган. Төннәрен монда йөзләгән сөркә күзләре нәкъ асылташлардай елтыраша. Боралак тавышыннан өркеп өннәренә яшеренгән җанварлар бераздан берәм-берәм баш калкыта башлады. Нинди гүзәл затлар! Бик матур түгәрәк йөз, шулай ук кечерәк кенә түгәрәк колаклар, ут янып торган түгәрәк күзләр. Өсләрендә кызгылт ялкын уйный. Тыюлыкның алтын хәзинәсе менә шушы җәнлекләр.

Тау астындагы болын-кырларда нефть суыргыч сиртмә-насослар эшли. Шаһназаров кармакны Чатыртаудан торып салырга ниятли иде. Кичке якка дип, район хакимияте башлыгын, төбәкнең берничә нефть "королен" үз янына, төнге мәҗлескә чакырды. Колхоз рәисе шашлык өчен сарык суеп килергә тиеш булды. Кара сарык чал, дип кисәтте Шаһназаров. Әле ул үзенең түрәлеген югалтып ук бетермәгән икән, баш өсте!—дип кенә җавап кайтардылар телефоннан сөйләшкәндә үк.

Чатыртау түбәсен төн буе машина фаралары яктыртып торды. Бер читтә учак җемелдәде—шашлык кыздырылды. Тау битләрендә бихисап йолдызлар—Сөркә күзләре елтырашты. Җанварлар бу сәерлектән хәйран калганнар иде. Зур эшләрнең Чатыртау түбәсеннән башлануын белми иде алар.

* * *

Шаһмиран Шымчыны үз янына чакырып китерде. Кичке якта офисның банкетлар залына кечерәк кенә, ләкин ифрат бай табын хәзерләнгән иде. Табында нәзакәтьле ризык, эчемлекләр. Бу кадәресен Шаһмиран белә инде. Дәү абыйлары юбилеен дә, әнә ничек зурлап үткәрде ул. Тансык тәгамнарны хәтта чит илләрдән кайтартты.

Шымчы бүген алар өчен иң кадерле кеше, күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәла-казалардан саклап калды.

Мәҗлес түрендә, әлбәттә инде, Кенәз янәшәсендә, янарак кына Польша-Алман якларыннан кайтып төшкән Сәүдәгәр дә утырды. Болар үзәк бишлекне тәшкил итүчеләр. Шуңа күрә Шаһмиран тел яшереп маташмады, Шымчы белән ачыктан-ачык сөйләште.

— Иң элек, хөрмәтле Александр Васильевич, сезгә олы рәхмәтебезне җиткерәм, кадрларны саклап калуда нык булыштыгыз.

— Кулдан килгәнчә,— дип, тыйнак җавап кайтарды Алаев.

— Фирма хәзергә үзенең эшен туктатты,—диде Шаһмиран.— Аңлыйсыздыр, шулай кирәк булды. Әмма мин моны вакытлы чара дияр

идем. Тиздән без башка исем белән теркәләчәкбез. Профильнең үзгәрүе бик ихтимал. Әзер торыгыз. Бу мәсьәләдә Дәү абый үзе кузгалды...

Яналык мәжлестәгеләргә ничегрәк тәэсир ясады икән дип, Шаһмиран һәркайсына сөзеп-сөзеп карады. Менә шунысы үтерә дә инде. Ичмасам, бораулап тишмәсен, текәлмичә генә сөйләсен иде. Сәүдәгәр үзендә бернинди гаеп сизмәсә дә, Шаһмиранның төбәп каравыннан шыр җибәрергә тора—кулы каты еланның. Башкалар алай ук дерелдәмидер бәлки. Эшкә урнашканда Тимержанга шактый эләкте шул Шаһмираннан. Бармагы белән корсагын тишсә, бөтенләй ычкынуы да ихтимал иде. Ходай саклады.

Офис хуҗасы өстәл тартмасыннан ялтырап торган ачкычлар алды да аларны бармагында әйләндереп уйный башлады. Менә күрегез, янәсе.

— Хәзер мин күңелле бер миссиягә керешәм,—диде Шаһмиран, урыныннан күтәрелеп.—Кичә фирма коллегиясе бердәм карарга килде. Майор Алаевның тырышлыкларын югары бәяләп, без аны "Джип" машинасы белән бүләкләргә булдык. Бу ачкычлар сезгә, хөрмәтле Александр Васильевич!

Артык сөрән салмыйча гына "ура" кычкырылды, чәпелдәтеп кенә кул чабып алдылар. Алаевны кочаклап үбүчеләр дә табылды. Чөнки бүген Шымчының дәрәҗәсе шул югарылыкта иде.

— Мине тагын шунысы куандыра,—дип дәвам итте Шаһмиран.— Хәзер "Шымчы"ның үз кадрлары бар, аны "фирма" диярге дә була.

Сөйләүчене Алаев бүлде:

— Шаһмиран, зинһар, мина карата ул ямьсез исемне кулланмасагыз икән. Кенәз белән без бу хакта килешкән идек, югыйсә.

— Әйе,—дип раслады Бакаев.

— Гафу, Александр Васильевич. Егетләр, сез дә ишетеп калыгыз, хөрмәт зур нәрсә безнең эштә. Александр Васильевич тагын шуны сорамакчы идем: Килдебәковны ничегрәк озаттылар соң? Җирләгәндә андый-мондый сүзләр чыкмадымы, дияем.

— Бөтен шартына туры китереп,—диде Алаев, теләр-теләмәс кенә.— Мәрәсим-митинг. Кайнар нотыклар. Зиратка кадәр өч йөз машина туктаусыз кычкыртып озатты. Матәм маршы. Ахырдан залп бирелде. Калганнары дәүләт сере, Шаһмиран...

— Ярый, Александр Васильевич!

— Шуны гына өсти алам. Матвеевның үлеме чишелешне тизләтте. Килдебәковтан соң "дело"ны үземә алдым. Ул хакта әйткән идем инде. Бу кадәресе җиңел булмады, әлбәттә, "дустымның" истәлеге хөрмәтенә" кайберәүләргә хәйран гына тәртергә дә туры килде. Битовны шунда ук азат иттем. Болар хакында бүтән сүз куертырга кирәкмәстер, дип беләм. Хәнҗәр үзе дә шапырынып, артык күзгә чалынып йөрмәсен—менә шулар, Шаһмиран. Ә "Джип" өчен рәхмәт!

— Сезгә, иптәш майор!

Шымчы Алаев дәүләт сере дигәндә, әлеге вакыйгаларның барышын, чишелешен күздә тотып әйтте. Ул кадәресен аңардан башка берәү дә тәгаен генә белми шул. Мушка-Матвеев камерасына икенче бер җинаятьчене ул урнаштырды, бурыч йөкләп. Чылбырлы реакциянең бер буыны рәвешендә, Мушканы дөмектерүче җинаятьче соныннан үзе дә дөнья белән бәхилләшкән. Майор Килдебәковның фаҗига алдыннан: "Минем үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез",—дип язуы шулай ук сер булып калды. Мантыйк буенча үзе гаепле, димәк. Ул нинди гаеп? Ни өчен үлемгә барган? Сораулар күп. Җавап кына юк. Хәер, мәетне тикшерү үткәрүчеләрдән берсе язудагы паста-караның бүлмәдәге ручкаларныкы белән һич тәңгәл килмәвенә шик белдергән иде дә Алаев аны шунда ук кисәтте. "Без үз-үзебезгә яла ягабыз булып чыга бит болай. Әманәт кәгазе мәрхүмнең үз кулы белән язылган. Әйдә, казынмыйк",—дип, тиз туктатты теге адәмне.

Төпченә башласаң, форточка бигенә бәйләнгән нәзек җепнең төп

шикелле таза Килдебәков гәүдәсен күтәреп торуына да шикләнергә мөмкин. Җитмәсә, мәетнең аяклары тәрәзә төбенә тиеп тора. Казынырга урын бар югыйсә. Дәүләт сере булгач, мондый вак-төякләргә генә игътибар итеп тормадылар, билгеле. Майор Алаев барлык нечкәлекләрне күзәтте, күп нәрсәне турыдан-туры үзе хәл кылды. Димәк, ул "Джип"ны көч түгел, эшләп алды. Шаһназаровны уйландырган черек система яки берниндм системасызлык монда да үз дигәнен җиренә житкереп башкарган иде.

—Сезнең Юркин күләгәсе ничек соң?—дип кызыксынды Алаев.

— Дәүләт сере,—диде Шаһмиран, бая Шымчы үзе әйткәннәрне кабатлап.

Мәҗлестәгеләр беренче мәртәбә рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр. Барысы да бушанып калды, ниндидер канәгатьлек кичерделәр.

— Ягез, уңышларыбыз өчен!

— Мин үзем гүзәл затыбыз Шаһмиран хөрмәтенә тотам. Аның тырышлыгына, житезлегенә таң калам; шул ук вакытта сабыр да. Беренче тост синең исәнлеккә, Шаһмиран!—диде Сәүдәгәр.

— Ялагайланма, Тимерҗан.

— Хак әйтәм.

— Тәкъдимгә кушылабыз.—Алаев урыныннан торып, Шаһмиран янына килде, нәзәкатьлелек белән кызның кулын сорады. Нәрсә бу? Алаев дерт итеп китте. Кул түгел—тимер тырма, каты, килбәтсез. Уңайсызланып, Шаһмиранның кул сыртына иренен тиереп алды.—Синең өчен, Шаһмиран!

Тост һәрберсе өчен аерым-аерым күтәрелде. Әмма берәү дә сүзнең ни хакында баруын ачыктан-ачык әйтеп тормады, теге яки бу вакыйгага карата аңлатма биреп азапланмады. Хәер, ул кадәресе таләп тә ителмәде. Үзенә кагылганын һәркем аңлады, тиешле нәтиҗәне ясады. Әлеге сөйләү стиле соңгы дүрт-биш елда тәмам камилләштерелгән иде шул. Мафия дисәләр, шуннан барысы да аңлашыла—артык сорау, артык хәрәкәт кирәк түгел. "Татсиб" фирмасында бу тәртип аеруча нык сакланды. Кызганыч, аны вакытсызрак ябарга туры килде. Хәзер инде мөһере дә юк, неон утлары белән язылган күрсәткеч панносы да алып ташланды. Аның каравы, әнә, яңасы баш калкыта, ди бит.

* * *

Мәҗлес түрендә кукраеп утырган Сәүдәгәр Польша-Алман якларыннан ничегрәк йөреп кайтты соң безнең? Ул үзе бу хакта әллә ни җәелеп китми.

— Хәлләр булды анда,—дип кенә җибәрә.

Дөньяны танып беләсең килсә, сәяхәт ит, читкә чыгып кара, дигәннәр. Тимерҗан әнә шуның дөреслегенә инанды. Югыйсә, Себерне, Уралны, атап әйткәндә, Магаданны, Колыманы аркылыга-буйга гизгән адәм. Пермь, Ижау, Чиләбенең дә һәр почмагы таныш аңа. Беренчеләрендә кайчандыр җан саклап интеккән булса, бу соңгыларында сәүдә итеп, мал табып, типтереп яшәде һәм бүген дә яши.

Тик моңа чаклы чит илдә булырга туры килмәде үзенә. Рәхмәт дусты Шәрәхтуллинга, ике атна буе дөнья оҗмахларын сәйран кылдырды. Вәт яши белә, ичмасам! Алдан килешенгәнчә, Җәвид Тимерҗанны Брест тамгалыгында каршылады. Ник дисәң, гадәттә, шулар ярата казынырга, товарның астын-өскә китереп бетерәләр. Польша ягында һич алай түгел, илләренә товар кергәнгә сөенәләр генә. Шушы хәлне искә алып, Шәрәхтуллин Варшава мэриясе вәкилләре, полиция солдатлары белән берничә машинага төялеп килгән. Аны безнең якта да яхшы беләләр. Сәүдәгәр сәфәре Татарстан Премьер-министрын каршы алудан һич тә ким булмады. Кая ул йөк тикшерүләр! Тамгачылар Шәрәхтуллин тирәсендә бөтерелеп кенә йөри. Берничә минут эчендә документларны әзерләп тә

бирделәр. Машина әрҗәсенә порошок түгел, бомба тәяп чыксан да сүз әйтүче юк. Әлбәттә инде, кешесенә карап...

Бу якларда Җәвидне "Сәүдә короле" (хәер, "Варшава короле", "Базар короле" дигән кушаматлары да бар) дип йөртәләр. Шулайдыр да. Былтыр Сәүдәгәр саткан спорт атларының бер өлешен, әнә, Япониягә кадәр озаткан. "Ту-4"ләрне очкычка төяп Мәскәү аша Австриягә җибәрүне дә ул оештырган иде бит. "Корольнең" биләмәләре, офислары Рәсәй, Польша, Алмания, Австрия, Швейцариядә генә түгел, Америка, Италия кебек илләрдә дә бар. Казан егете дөньяның яртысын үз йодрыгында йомарлап тота. Варшава—Шәрәхтуллин өчен мөһим бер үзәк, күзгә күренмәс жепләр күп илләргә шушыннан сузылган, ә жепләр Җәвид кулында. Шәхсән, ул үзе бу шәһәрне бик үк ошатып бетерми, пычрак, тәртипсез бер төбәк, дип исәпли. Рәсәй рэкетчылары Варшавага чыгып үтерешәләр. Чын сәүдә мәсьәләсендә барысы да профаннар. Өнәп бетермәгәнгә Җәвид базар янындагы өч катлы йортында бик сирәк кунып кала. Эштән соң һәр көнне Польшаның Көнбатыш төбәгендәге Утар-вилласына юнәлә. Утары—Висла елгасы буенда, Грудзенц шәһәреннән ерак түгел, урманлы, болынлы, күлле урында. Язын Висла ташыганда су басып китмәсен өчен, яр буйлап биек үр-дамба өелгән. Урманда киек-җәнлек, күлләрдә, Вислада балык житәрлек. Бу тирә авылларда яшәүчеләр терлек-туар, каз-үрдәк, тавык-чебешне күпләп асрый, арзан бәядән генә теләгәнчә сатып ал. Яшәү өчен уңайлы жирләр. Грудзенц беркадәр вакыт алманнар хакимлегендә торган. Соңыннан ул Польшага кире кайтарыла. Поляклар үзләре Гродно шәһәрен Белоруська биргән шикелле. Грудзенц, Белосток—элек-электән, үзләре әйткәнчә, "Казан татарлары" жирләре. Моннан алты гасыр элек Идел буеннан, Кырымнан күчеп килгәннәр. Бүген дә шунда көн күрәләр. Татарлар милләттәшләре Җәвидне үз итәләр. Биредә бөтенләйгә яшәп калырга да була. Грудзенц төбәгенең табигате, үпкәләрне сихәтләндерүче саф һавасы ошый Җәвидкә. Борынгы бабайларыбыз бер дә юкка Варшава тирәсенә сыенмаганнар, иркенлеккә, хөрлеккә, гүзәллеккә омтылганнар шул. Алар монда тиенгәннәр дә, гасырлар буе рәхәт чигеп яшәгәннәр.

Польша эшкуары якташы Тимержанга менә шул хозурлыкны күрсәтергә ниятләп куйган иде. Сәбәбе бар: товар-ишкә булган хөрмәт һәм ышаныч. Сәүдәгәр кайберәүләр кук вакчыл, тынгысыз түгел, бирәчәкне көтә белә, мал-акча даулап тинтерәтми. Җәвид үзе дә шундый, киң күңелле, товар йөртүдә иш кеше, хезмәттәшен беркайчан да авыр хәлдә калдырмас. Чит илләрдәге аркадашлары да аны әлеге күркәм гадәтләре өчен яраталар, ышаныч белдерәләр. Сәүдәсе дә гөрләп бара.

— Каклаган каздан соң, мин сине бер жиргә алып барам, дип вәгъдә итте Җәвид дустына. Хужа Казан күчтәнәченнән бинииһая канәгать калган иде.

Кичке мәҗлес гаять тәэсирле булды. Матур-матур тостлар әйтелде, эч катыргыч мәзәкләр сөйләнде. Ым кагып кына музыкага заказ бирелде. Нинди көйләр бит! Тимержанны һуштан яздырганы—Салих Сәйдәшевнең "Әдрән дингез"е, "Шәрекъ биюе". Көй әле дингез дулкыннарына күмелде, әле тауларга ашып тирбәлде. Күңелләр эреде, бераз гына сагышланды, моңланды. Гомумән, ресторанда кич буе гел татар моңнары агылды. Поляклар да монда күнегеп беткән, рәхәтләнеп тыңлыйлар. Җәвид ресторany Варшавада иң яхшылардан санала икән. Музыка тынып торган чакларда Җәвид дустыннан туып-үскән шәһәре, республика житәкчеләре, сәүдә кешеләре, эшкуарлар турында, театрларда нинди спектакльләр баруын, аларда нинди артистлар уйнавын сорашты. Равил Шәрәфи һаман да шулаймы, бер дә картаймыймы дип кызыксынды. Тимержан ык-мык итүдән узмады. Сәүдәдән тыш та тормыш барын ул шәйләми дә иде. Еллар дәвамында театр ишеген ачып кермәгәч, тегe яки бу артист хакында ни әйтә алсын соң! Җәвиднең житәкчеләргә карата биргән сорауларына да "белмим, әй, эшлиләр шунда, элеккеге урыннарында" диебрәк жавап кайтарды. Ә теле бар, төртгерә белә:

— Татарстанга Президент булып кайтырга җыенмыйсыңдыр ич, Җәвид?

— Премьер-министрлыкны тоттырсалар, Татарстан икътисадын ел дигәндә аякка бастырыр идем анысы. Нефть, электр энергиясе белән генә дә,— диде Шәрәхтуллин, хискә бирелеп.—Кем куя мине анда. Эшли белүченең кадере юк бит бездә. Ярар, ул якларын үзегез чамалагыз инде, дускай. Эш монда да муеннан. Теге айда Австриягә, Италиягә чыгып керәсем бар. Тын алырга да вакыт юк безнең.

— Машина турында онытма.

— Сөйләштек. Аларын күршедән генә алырбыз.

Бер мәл музыка тынып торган иде. Кинәт скрипка аваз салды. Шәрәхтуллин бармак шартлатып, маэстрога әмерен җиткерде. Оркестр салмак кына, йөрәкләрне телгәләп, җанны иркәләп "Тәфтиләү"не уйнарга кереште. Менә сиңа, кяферләр иле, менә сиңа Варшава! Тимерҗан Казанга кайтып сөйләсә, валлаһи, ышанмаячаклар. Татар моңына поляк кызлары йөзеп кенә йөри.

— Муеның кәкрәеп калмасын, Тимерҗан.

— Чибәрләр...

— Юдита!

— Хәерле кич,—дип сәламләде егетләрне кыз.

— Без кайтканны көт, менә, Сәүдәгәрне иркәләрсен,—диде Җәвид, Юдитаның йомшак җирен чәбәкләп.

— Тоткарланмагыз, алайса.

Ресторанга кергәч тә Җәвид Тимерҗанны шушы кыз белән күрештергән иде. "Ошаса—синеке",—диде татарчалап. Ник ошамасын ди, мондый су сөлеге...

Шәрәхтуллинның бер җир дигәне төнге бар, икенче төрле әйтсәк, фәхешханә булып чыкты. Сөйләргәме, әллә дәшми калу хәерлерәкме бу җәһәннәм базы турында? Тимерҗан үз гомерендә күпне күрдем, күпне беләм, дип йөри иде. Пычагымны да күрмәгән икән ул. Тәрәзәләре томаланып, уты сүндерелгән ресторан-барда чын мәхшәр. Әче төтен, хәмер, тир исе. Ирләре дә, хатыннары да анадан-тума, биючеләр, үбешәләр, әүмәкләшәләр. Бозыклык менә кайдан таралып ята икән ул! Дөресен әйтим, Тимерҗанның күзе кызыкса да, күңеле тартмады мондый баткаклыкка чумарга. Вәхшилек—шул гына. Нурия болар ише түгел, дип куйды, үзалдына сөйләнеп.

Җәвид кунагының кәефен бик тиз абайлап алды. Моны күргән кешеме соң?!

— Ярар, китәрбез!—дип тынычландырды Тимерҗанны варшавалы.

— Ничек күңелең тарта, Җәвид?

— Сиңа күрсәтер өчен генә.

— Юдита ошады,—диде Тимерҗан.

— Ул безне көтә.

— Бу тиләләрне күрсәтүең өчен рәхмәт анысы.

Тимерҗан Варшава пычрагына батканчы тизрәк фәхешханәдән чыгып сызу ягын карады. Гаҗәп: кем уйлаган аны шундый батырлыкка барыр, дип? Югыйсә, Казанда һәр җәелгән итәккә уралып егылырга гына тора. Мондагыларның кыюлыгы, әрсезлеге шурләтте бугай Сәүдәгәрне. Ни дисен, ул Җәвид дустының бу гамәлен барыбер хуплады, дөнья күрде, ичмасам.

— Каешланып беткән инде алар,—диде тегесе, ишектән чыгышлый.

Аның каравы, Тимерҗан төне буе Юдита кочагында иркәләнде. Юдита—озын буйлы, ак йөзле, ак чәчле, тыгыз тәнле, эһ, дигәнче туксан-тугызга бөтерелүче чын полячка иде. Кәләш түгел, тулы бер секс институты. Адәм башына килмәстәй кыланышлар ясап, Тимерҗанның өнен алды. Полячкаларның даны тикмәгә генә дөньяга таралмагандыр инде бу мәсьәләдә. Юл килеп йончыган Тимерҗанның кымшанып хәле калмаган иде, таң алдыннан эреп йокыга талды. Юдита күпме иркәләсә, төрткәләсә

дә, мичкә бүтән кымшанмады. Хатын-кызга—йомшак, йокыга каты кеше Тимержан...

Икенче көнне Җәвид кунакны Грудзенц янындагы утарына алып китте. Вислада су коендылар, комда кызындылар, балык каптырдылар, урманда сәйран кылдылар. Шәһәргә барып, музейларда йөрделәр. Грудзенцта алманнар тәэсире нык сизелә. Тарихи бәйләнеш үз эзен калдырган. Бу яктан өйрәнерлек нәрсәләр күп тарихчыларга. Ике милләт мәдәнияте бергә кушылган. Базары гаять бай—Тимержан бигрәк тә шунысына игътибар итте.

— Монда гел куллануда булган машина икән.

— Аның каравы, арзан. Төрекләр күп ташый.

— Алманиягә кайчан чыгабыз?

— Ничә араба кирәк соң сиңа?—дип кызыксынды Җәвид, машинаны төрекчәләп.

— Өчне-дүртне алырга исәп.

Алманиядә өч мең долларга менә дигән "БМВ"лар бар икән. Рәсәйдә аларны ун мәртәбә кыйммәтрәккә шудырып була. "Мерседес", "Опель"ләр чүп бәясе. Чакырт кешеләреңне, теге атнада чыгып керербез, диде хуҗа. Якын монда—нибары ике йөз чакрым гына.

— Казанга заказ бирик.

— Бирәсе юк, шунда ук тоташтыралар.

Килгәндә Сәүдәгәрнең планнары башкачарак иде. Җәвид Һиндстан мебельләре кайтуын хәбәр иткәч, КамАЗга шуларны төярмен дигән иде. Ял үзгәртте планнарны, машинасын болай гына кайтарып җибәрде. Шаһмиран тавыш куптармаса ярый инде. Шуңа да ул елан белән сөйләшмәскә булды. Шамил Бакаевка шылтыратты.

— Мин әле бу, Кенәз, Польшадан. Мебель беткән,—дип ялганлады Сәүдәгәр.—Машина буш китте. Икенче рәт инде. Шаһмиранга шулай диярсең.

Хәзер игътибар белән тыңла. Алманиягә чыгам. Арзанга арабалар бар. Ике шофер ияртеп Фараны җибәр. Бүген үк. Дүртне алам, дүртне. Маркамы? Күз күрер анда. Паспортларын, машина йөртү таныклыкларын онытмасыннар. Аэропорттан хәбәр салырсың, каршы алырмын. Калганын кайткач сөйләрмен. Хуш яме. Сау бул!

Әгәр Сәүдәгәрнең һәр тукталышын яза башласаң, китап битләре дә җитмәс иде. Алманиядән ыжгырып торган дүрт машинаны бик тиз алып кайтты. Рәсәй тамгачыларына кадәр аларны тагын Шәрәхтуллин озатып куйды, берничнди тоткарлык килеп чыкмады. Рәхмәт аңа! Шоферлар Казанга исән-имин кайтып җиттеләр. Шуңа Тимержан бүген мәҗлеснең түрендә кәпрәеп утырды да инде. Урамга чыккач, Варшавадагы төнге бар, аккошка ошаган Юдита турында сөйләп, Кенәзне бераз кытыклап алды.

— Икенчесендә үзем барам,—диде Шамил Бакаев.

Сәүдәгәр алып кайткан машиналар туктап калган фирма өчен беркадәр юаныч иде. Мебель турында Шаһмиран сүз кузгатмады. Тимержанның дәрәҗәсе Шымчыныкыннан ким түгел иде бу көннәрдә. Фирманы ул аякта тота бит хәзергә.

* * *

Чатыртау түбәсендә нефть корольләре Шаһназаровны олылап кабул иттеләр, кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә вәгъдә бирделәр. Әмма үзләреннән ерактарак тотарга телиләр иде. Бу кадәресен Әмир Мирзахановичның үзенә сиздермәделәр. Күп вариантлар тәкъдим итеп, күңелен күрделәр. Ниһаять, геологлар харитәсе буенча кайбер нәрсәләр ачыкланды.

Әле сугышка кадәр үк Чулман аша күпер салу проектын эшләгәндә

геологлар шактый җирне тикшереп чыгалар. Кайдадыр өлгереп җитмәгән ташкүмер, икенче урында зур тирәнлекләрдә нефть ятмалары барлыгы гомән кылына. Әмма эш өзелә. Сугыштан соң Мәскәү-Пекин автотрассасын салу идеясе калкып чыга. Тикшерену, җирне бораулау эшләре яңадан башлана. Бу юлы да геологлар Чулман буенда нефть ятмалары булуы ихтималын алга сөрәләр. Казаннан Питрәчкә кадәр килеп җиткән Мәскәү-Пекин юлы, ни сәбәптәндер, кинәт туктап кала, геологлар палаткаларын төйнәп, төзүчеләр техникаларына төялеп, бөтенләйгә китеп баралар. Шуның белән барысына да нокта куела. Тәҗрибәле карт геолог Шаһназаровка әнә шулар хакында бәян кылды, кулдан килгәнчә булышырга сүз бирде.

Әмир Мирзаханович нефтьчеләрне әлеге карт сөйләгән Чулмантауга алып килә. Монда биек-биек үрләр, тирән-тирән чокырлар, елгалар— һәммәсе урман белән капланган. Аста—Чулман-елга, унъяк кушылдыгы— мул сулы инеш, болын-әрәмәлекләр, колхоз басулары. Барысының да хуҗасы бар, Шаһназаров алар белән элемтә урнаштырырга тиеш булып чыга.

Чулмантау—элек заманда куәтле генә бер ханлыкның кирмәнеңытмасы булган. Тарихи һәм археологик чыганаклар да раслый моны. Тауның өч кат үр белән әйләндереп алынуы, таш койма нигезләре сакланып калуы да кире кага алмаслык дәлил ич. Риваятьләрдә ханның "Алтын базы" булуы, дошман якынлашкач "Алтын капка"ның кайдадыр мәгарәгә яшерелгәнлеге бәян ителә. Болары тарихчылар, археологлар эше, билгеле. Ә Шаһназаровка "кара алтын" кирәк. Әнә, тегеннәнрәк, бераз читтәнрәк. Тарихи ядкарьләргә зыян китермичә, тавыш-гауга чыгармыйча гына.

— Сарык көтүлекләренә тимичә Чулмантауны бораулап карарга исәп, рөхсәт ит,—диде Шаһназаров, таулар хуҗасы исәпләнгән шушы тирәдәге колхоз рәисе Әхәт Салихҗанов белән очрашкач.—Киләчәктә сезгә файдабыз гына тияр, дип уйлыйм.

— Район җитәкчеләре белән сөйләшеп карармын.

— Менә анысы кирәкми,—дип кырт кисте Әмир Мирзаханович.— Бу—минем эш, нефтьчеләр белән безнеке. Әлегә нәтиҗә юк, авызга су кабып тору кулай булыр. Моңа бөтенләй игътибар бирмәгез, барып чыккан тәкъдирдә—колхозны алтынга күмәчәкбез. Су кабу мәсьәләсен килештекме? Ярый алайса. Җаваплылык тулысынча минем өстә. Сездән бернинди информация чыгарга тиеш түгел. Хәтта, ниндидер, министр-фәлән килеп сорашса да. Хәер, ул кадәресенә үк юл куймабыз...

Тагын бер айдан ике үр арасында бораулаган җирдән нефть фонтаны бәреп чыкты. Түбәндәрәк факел кабызып җибәрделәр, ялкыны бер дә кирәкми канә, ансыз да ярамый, газ сакланса, җир астында шартлау килеп чыгачак. Югыйсә, бу гамәлне читләр күзенә күрсәтәсе түгел иде, нишлисең, нефть чыгару технологиясен бозар хәл юк.

Шул кичне үк Шаһназаров колхоз рәисе Салихҗанов белән кабат күреште, иркенләп сөйләште, бергәләп эшләүнең нечкәлекләрен аңлатты, алыш-биреш якларын килеште. Хәер, килешү дигәне бик гади. Колхоз рәисе элеккечә берни белми, бернәрсәгә дә тыкшынмый. Ә Шаһназаров фирмасы колхоз объектларына җылылык үткәрә, аны ягулык белән тәэмин итеп тора. Беренче чиратта, мәктәпкә, Мәдәният йортына, идарәгә, фермаларга һәм техника йортына җылылык үткәрү каралды. Барысы да бушлай. Ләкин Салихҗанов болар хакында ләм-мим сүз кузгатырга тиеш түгел. Кызыксынучылар табылса, әнә, Шаһназаровны күрсәтер. Шулай килештеләр.

Әмма, зурлап тотынабыз дигәндә районның җир эшләре бүлеге мөдире, мәхлук бер бәндә, тәгәрмәчкә таяк тыгарга маташмасынмы! Колхоз җирен, дәүләт байлыгын теләсә кемгә өләшә алмыйм дип, тиешле кәгазьләрне рәсмиләштерүдән баш тартты. Тегеләй дә, болай да якын килеп карады Шаһназаров—юк кына бит, кырт кисә дә куя шул мөртәт. Әйтерең бармы, кечкенә генә шөреп кисәге, ә эшне боза да тора. Хакимият башлыгына әйтер иде, анысы ялга олаккан. Нишләп нервы бозам соң

әле моның белән дип, Шаһназаров Казанга ук кайтып китте.

Сырхаулаган икән. Әллә инде жил каккан, әллә тагын теге юньсез адәмнең кыланышлары тәэсир иткән—Шаһназаров бер-ике көн ял итеп алырга ниятләде.

— Дөрес эшлисең, кузгалма, тынычлан, барысын да рәтләрбез,— диде Шаһмиран, Дәү абыйсын урын өстенә яткырып.—Кая, ул бәндәнең мәгълүматларын язып алыйм да егетләрне күреп килермен.

— Бәлки шулай кирәктер,—дип килеште Әмир.

... Вокзал янына өч "тугызлы" килеп туктады. Арттагы машинадан ике егет чыкты. Берсенең кулында бөкесе ачылган аракы шешәсе, аның муенына катыргыдан эшләнгән стакан кидерелгән. Як-якка карана торгач, эзләгән кешеләрен күреп тә алдылар. Вокзал стенасына терәлеп, асфальтка чүгәләгән бомж янына килеп, аңа аракы салып эчерделәр.

— Сиңа йомыш бар иде, Күчтә.

— Машина юаргамы?

— Юк—ла, деликатный эш.

— Нинди?

— Утыр, әйдә!

Бомж машина эчендә гырлап йокыга китте. Хәмер тиз тәэсир итте үзенә. Егетләр аны бимазалап маташмадылар, йокласын, соңгы рәхәте бу аның...

Кичке якта, яңа бораулаган нефть вышкасын үз күзләре белән күреп кайтсын дип, жир эшләре бүлеге мөдирен шулай ук машинага утыртып, каядыр, урман аланына китереп төшерделәр. Анда ике чокыр казып куелган иде. Мөдиргә шуның берсенә төшәргә боердылар.

— Сез нишлисез?

— Сикер, әйдә, сикер!

— Мондый шаяру булмый, егетләр.

— Сиңа ни җитми соң, падла!

— Мин—дәүләт хезмәткәре, закон бозудан куркам,—дип, акланмакчы итте мөдир.

— Чыннан дамы?—дип, егетләр мөдирнең ике култыгыннан алып, аны чокырга дөпелдәтеп төшерделәр. Шунда ук, җир өстендә башын гына калдырып, күмеп тә куйдылар.

Машиналарның берсеннән җирән сакалы инде агарган, теге пычрак бомжны житәкләп чыгардылар. Стакан тутырып тагын хәмер эчерделәр. Иплән кенә янәшәдәге чокырга төшереп бастырдылар да мөдир шикелле итеп күмделәр. Кайсыдыр машинадан чалгы күтәреп чыкты, аны алдан хәзерләнгән колгага саплады. Шуннан соң, палач әсирләренә якынлашты, күзләренә багып, башта тегеләрнең котын очырырга ниятләде. Менә хәзер күрсәтәм кемлегемне! Палач, бомж каршына туктап, теге мәхлукның баш очыннан ике мәртәбә чалгы чыжлатып селтәнде.

— Ни өчен, хлопцы?—дип телгә килде исерек бомж.

— Утыра бир!

— Ни өчен, ә?!

Өченче селтәнүдә кансыз палач, инде кешелек сыйфатларын югалткан, йорт-жирсез тилмергән мескен адәмнең гаепсез башын кыеп та төшерде. Баш кан вә туфракка буталып читкә тәгәрәде. Ни хикмәт, гәүдәдән аерылган баш, балалар тубыдай сикергәләп гел бер үк сүзне тәкърарлады: "Ни өчен? Ни өчен?!.." Аннары баш, телен тешләп, хәрәкәтсез калды. Күзләрендә биниһая гажәпсенү, сорау иде киселгән башның. Боларны күреп торган мөдир кинәт һуштан язды. Бераздан аны каберлектән казып чыгардылар, бомж башын гәүдәсе янына төшереп, күмеп тә куйдылар.

— Законны күрденме?

— М-м-мин кар-ш-шы түгел...

— Күптән шулай, диләр аны. Хатыныңны, балаларыңны да кызгана белмисең, сволочь!

— Алар—и-сән-ме сон?

— Иртән документлар әзер булсын, әйдә, машинага,—диде палач, мөдирнең артына типкәләп.

Әле көндез генә кәпрәеп йөргән, мафия егетләре белән иңбашы аша гына сөйләшкән мөдир, үзе белән ни булганын сизми дә калды. Ярты мәет иде ул бу минутларда. Ниндидер яман төш күк хәзер—машина эчендә. Әлбәттә, ул тиешле документларны җиренә җиткереп әзерләде. Ә тегеләр берни булмагандай аның тирәсендә бөтерелделәр. Кичтән капка төбендә дә, тәрәзә артында да шулар күләгәсе йөрде. Өендә хатыны, эштә хезмәттәшләре бер төн эчендә мөдирнең чәче агаруын күреп гаҗәпсенделәр, кинәт үзгәрүенең сәбәбен сораштылар, теге җавап кайтармады, моны кирәк дип тә санамады. Акылга утырган иде мөдир. Аның тизрәк пенсиягә чыгып, бакчасында казынасы гына килә иде хәзер.

* * *

Яңа төзелгән фирмага “Чулмантау” дигән исем бирелде. Эш кәгазьләре өчен генә әлбәттә. Бу юлы офиска күрсәткеч такталары бөтенләй куелмады. Дәү абыйлары рөхсәт итмәде. Кемгә кирәк ул?! Анда килеп-китеп йөрүчеләр юк, сак кешеләре дә генераль директор Шаһмиран. Исем-дәрәҗә рәсми кәгазьләр өчен генә. Элекке буфет-банкет заллары ябылды, аларның хаҗәте калмады. Бу чаралар исә, артык күзгә ташланмас өчен эшләнде.

Чулмантау арасындагы ялгыз вышка янына да электр миче белән җылытыла торган кечкенә алачыктан гайре нәрсә ясалмады, төзелмәде. Факел, читләрнең күзенә очкын чәчрәтмәсен өчен, тирәли биек коймa белән уратып алынды. Монда ни барын, кемнәр көн күрүен беркем белми. Промыселда нефтьчеләр белән Нурлыгаян Хәлитов дигән кеше җитәкчелек итә. Гади генә итеп әйткәндә—Нурлы. Бераз кимсетепме, әллә үз итепме, фирмадагылар аны шулай ярты исеме белән генә йөртәләр. Ә болай Нурлыгаян—эштә иң кирәкле шөрепләрнең берсе: үзе промысел мөдире, үзе нефть озатучы диспетчер, үзе үк азык-төлек юнәтүче, аш-су хәзерләүче һәм башка төрле вак-төякләрне башкаручы, хәтта, этне туйдыручы да. Акчасы килгәч, шыбырдамый, чәче белән җир себерергә дә риза.

Чыгарылган нефть, нигездә, Түбән Кама якларына озатыла. Кирәк чакта Чаллы, Әлмәткә дә барып җитә. “Чулмантау” фирмасы продукциясенә Башкортстанда сорау аеруча зур. Салават шәһәренә җибәрелгән “кара алтын” фирмага чиста бензин булып кайта. Авырлыгы шунда, кышын, су юлы ябылганлыктан, гел автотранспортны җигәргә туры килә. Биредә язылмаган катгый закон урнашкан: мөмкин кадәр кеше күзенә чалынмаска! Промысел тирәсендә көтү көтүче, бозау, каз-үрдәк караучы, түбәндә иген игүче колхозчылар да, хәтта, район җитәкчеләре дә мондагы кешеләр белән кызыксынмыйлар. Республика җитәкчеләренең очкычта яки боралакта күп мәртәбәләр промысел өстеннән очып узганнары бар, ләкин алар ялгыз вышканы, җемелдәгән факелны күрмәмешкә, белмәмешкә салышалар, җен зәхмәте тиюдән шүрлиләр, күрәсең.

Фирманың Чулман кичүендә зур гына ике танкеры тора. Аларны кыш буе нефть белән тутыралар да язын Идел буйлап каядыр түбәнгә алып китәләр. Банктагы хисапка валюта килеп кергәч кенә, товарның Төркия тарафына барып ирешүен беләсең. Фирманы көйләп җибәргәч, Кенәз белән Сәүдәгәрнең мәшәкатьләре артты. “Кара алтын”ны сатып алучылар белән өзлексез элемтәдә торырга кирәк. Транспорт хәрәкәте бик тә мөһим, инде әйтелгәнчә, ул күзгә арпа булып кадалырга тиеш түгел. Иң кыены шул. Аның өстенә Шаһмиран егетләргә тагын бер җитди бурыч йөкләде: промыселдан ераккарак, тау өстендә, ләкин урман эченәрәк офис-дача салырга. Бик тиз арада, кеше сизми дә калсын.

Кама урман хужалыгы осталары ай дигәндә гүрнәчәне күтәреп тә куйдылар. Өч катлы, биш почмаклы итеп. Чаеры саркып торган сап-сары нараттан. Янында ук сарай, мунча, келәтләре дә бар. Кыек-янакларның бизәген Казан рәссамы сызып биргән иде, төзүчеләр шул өлгедән күчереп ясадылар.

Шаһмиранга да, Дәү абыйларына да бик ошады дача. Әмир мунча мичендәге ап-ак кыр ташларына мөкиббән китте. Аларны кайдан җыйганнардыр да нинди оста тезгәндер шулай хәсиятләп. Аскы рәткә эре ташлар түшәлгән, ә өскә таба ваклый барып, ин ахырда бака кабыгыдай юкалары белән каплап куелган. Таш чүмәләдәй өелеп тора. Бер тустаган су җибәрсән, кызуы сәгатьләр буена житә. "Мунча профессоры"нын мондый галәмәтне тәүге мәртәбә күрүе иде.

— Шәмсетдин абзый белән Хөмәйрә апанны алып килергә кирәк, күрсеннәр,—диде Әмир, Гөлшәһидәгә күз кысып.—Без генә кинәнергә димәгән.

— Мондагы урманнар төрле үләнгә бик бай.

— Ә-ә, төнәтмәсез мунчаны син дә сизденме?

— Кенәзгә әйтермен.

— Сон инде—көз житте,—диде хужа.

Чәй янына утырганнар гына иде, капкадан кемнендер челтерәтүе ишетелде.

— Бикләгән иденмени?

— Барс бәйсез ич, шуңа.

Бимазалап килүче Нурлыгаян булып чыкты. Хужаларына сарык суеп менгергән. Түшкә суынганчы тизрәк казан асыйк, дип куырды Нурлы. Шаһмиран кичкә шашлык кына ясарбыз, дигән иде дә, кунак үзенекен тәкърарлады, имеш, анысы да булыр, ә менә яна суйган сарык шулпасы, казанда күпереп пешкән хуш исле ите тәнгә дәрт-дәрман бирә икән. Дәү абыйлары монысын мыек очына чорнап куйды.

— Кайдан алдың?

— Әхәт атна саен китереп тора.

— Канәгать, димәк.

— Механизаторлар йортына җылылык үткәргәнгә куанып бетә алмый, сезгә рәхмәт әйтергә кушты,—диде Нурлыгаян, әманәтен үтәп.

Промысел житәкчесе жиң сызганып, эшкә дә керешге. Күз ачып-йомганчы, сарыкны ботарлап та ыргытты: кабырга, корсак итләре, муен чалымы—шулпага, ботныкы—шашлыкка, боларын суыткычка тутырырга мөмкин. Шашлыкка серкә саласы түгел икән, аста, колхозга ферма төзүче әрмән махсус үлән үстерә, ди. Нурлы сумкасыннан шуны тартып чыгарды. Ул тәме, ул хуш исе—теленне йотарлык. Кыздыруын үзегез кыздырырсыз.

— Итне шәһәрнекеләр күк ваклап түгел, менә мондый эре-эре итеп турыйсы, ярты йодрык шае булса да ярый. Шаһмиран бер-икесе белән туя да туя инде.

Нурлы шулай сөйләнә-сөйләнә эшләде. Ике сәгатьтән шашлык кыздырырга әзер дигән сүз.

Ит белән эшне төгәлләгәч, нефтьче сарайдан имән пүләннәре күтәреп чыкты. Шашлыкка бары тик имән күмере генә кирәк, дип искәртте. Бу кадәресен Дәү абыйсы әллә кайчан белеп оныткан инде, ул Нурлы сүзләренә елмаеп кына куйды.

— Ярар, калганын булдырырбыз, әйдә, утырыйк әле шушында,—дип, Шаһназаров Нурлыны агач ышыгынарак житәкләде.

Әйтәсе килгән сүзләре, үгет-нәсихәтләре бар иде анын. Беренче чиратта, саклык чаралары. Промыселда беркемне кабул итмәскә, сорашучы-белешүчегә җавап бирмәскә. Андый-мондый хәл килеп чыга калса, шунда ук Шаһмиранны яки Кенәзне чакыртырга. Шаһназаров вак-төяк чыгымнары өчен колхоз рәисе Әхәт Салихжановка берничә "лимон" төшерергә кушты. Бушка сарык ашап ятмассын бит. Акчаны Шаһмиран бирер,

диде. Кисәт, түрәләр алдында каушап калмасын. Син берни белмисең, промыселга нефтьчеләр хуҗа... Һәм Шаһмиран.

— Төшендем,—диде Нурлы.

— Бар, көтәләрдер үзенне.

— Иртәгә нишлим?

— Үзебез дә китәрбез, рәхмәт!

Нурлыгаян, бар да тәртиптә, бар да тәртиптә, дия-дия, кулларын угалап, арты белән капкага таба чигенде. Ярыйсы гына егет, дип уйлады Шаһназаров мөдир турында. Ялагайлыктан тыш, ниндидер итәгатьлелек, уңганлык та бар үзендә. Эшне башкаруын гына күр син аның. Минутлар эчендә ялт иттерде дә куйды сарыкны, мин үзем, дип кенә тора. Шундыйларны алырга кирәк фирмага. Инде капканы ачам дигәндә, хуҗа кабат аваз салды:

— Әй, Нурлы, борыл, сүзем калган.

Шаһназаров Хәлитовка иң мөһимен җиткерергә оныткан икән бит. Чөнки бу эш Нурлыга нык бәйле булачак, аны читләтеп узарга ярамас.

— Пристань янындагы "Арышлы" колхозы рәисе белән элемтәләрең ничек?—дип кызыксынды хуҗа.

— Болай, исәнләшеп йөрибез.

— Анысы гына аз.

— Соң?

— Якыннанрак таныш. Үзем дә шылтыратырмын. Ике көннән Шамил Бакаевны җибәрермен, янына бергәләп барырсыз. Автохуҗалыкны аның территориясенә урнаштырасы булыр. Салкыннарга киткәнче җылы гараж салырга кирәк. Әнә, Шаһмиран дүртәр күчәрле тагын ун-унике майташыгыч машиналар алам, ди. Аларны ачык һавада тотмабыз ич. Колхоз рәисенә әйт: шәп шоферлар, яхшы механик, кирәкле кешеләрнең барысын да хәзерләсен. Гаражны ул салдырыр. Ә сез банктагы счетларын алып кайтыгыз. Шаһмиран хәл итәр. Менә нәрсә,— диде хуҗа, тагын нидер хәтерләп,—җиткер үзенә: колхозга файдабыз гына тияр. Тик ул шапырынып йөрмәсен. Төшендеңме мин әйткәннәрне?

— Боларын беләм.

— Шамилне көт.

Китә башлагач, Нурлы тагын кире борылды.

— И, сумкам калган икән!

— Гөлшәһидә, китер шул сумканы!

— Шаһмиранның исеме ничек соң?—дип гаҗәпсенде Хәлитов.

— Шаһмиранның исеме—Шаһмиран.

— Аңладым—Шаһмиран.

— Шулай, Шаһмиран!

— Рәхмәт, Шаһмиран, хушыгыз!

— Вәт дурак.—Гөлшәһидә исемен беренче тапкыр ишетүе иде Нурлыгаянның.

Гөлшәһидәнең шулпасы инде быгырдап утыра. Кухняга тәмле ис таралган. Әмир кәстрүл капкачын күтәреп карамыйча түзмәде. Нурлының баягы сүзләре тәкатьсез иткән иде аны. Яшь сарык ите чыннан да күперепме күпергән. Тизрәк авыз итеп, тәмен татып карыйсы килә, ифрат файдалы, ди бит.

— Ачма—тәме китә,—диде кыз.

— Белә икән Нурлы нәрсә ашарга!

— Авыл мужигы ич ул.

— Карарбыз, ни чыгар тагын,—дип йомгаклады сүзне Әмир, хәйләкәр елмаеп.

Чулмантау утары тагын нинди яңалыклар әзерләгәндер безнең эшкуарларга?! Сабыр итик.

* * *

Майташыгыч машиналарны "агач сумнарга" гына тоттырып җибәрмиләр шул хәзер, янки долларын чыгарып сал син аларга. Һәм күбрәк итеп сал. Акча санап маташсаң, әзер товар чит ил фирмаларына тәгәри дә китә. Кыйммәтрәктән, әлбәттә. Монда һич тә Сәүдәгәрсез ерып чыгу юк. Тиешле кешеләрне күреп сөйләшер, килешер— үз дигәненә ирешми калмас. Ата карак, диләр андыйлар турында, мафия тирәсендә булдыклы кешеләр исемлегендә йөри бу да. Шаһмиран машина операциясен тулысынча Тимерҗанга йөкләде. Димәк, Беларусь якларына юл тотарга. Бәлки әле, вакыты калса, Юдита янына да чыгып керер, виза-фәлән кирәкми хәзер, Җәвид барысын да җайлады теге чакта. Хәер, бу кадәресе икенче чираттагы эш. Шаһмиранга, әнә, куәтле машиналар кирәк.

Биржадагылар каты таләп куйды. Машиналар өчен жиде чан нефть китерәсез, вәссәлам! "Чулмантау" фирмасы өчен анысы да берни түгел. Ә менә аны ташып тутыруы айлар буена сузылачак. Килешми дә ярамый— техникасы кирәк. Валютадан баш тарталар. Нефть давай аларга—һәркемнең үз базары шул. Никадәр авырга төшмәсен, ялга китәр алдыннан Сәүдәгәр бу эшләрне барыбер башкарып чыкты. Яңа гаражга яңа машиналар кайтып тулды. Промыселчыларга эш җиңеләячәк, димәк.

— Шаһмиран, кайчан ял бирәсең, бик йончыдым,—диде Сәүдәгәр, кәнәфигә җәелеп.

— Тәмам бетерешкәнсең икән шул.

— Көлмә, пажалысты, чынлап әйтәм.

— Сине ябыктыра да, печтерә дә алмадым, ахрысы, Тимерҗан.

— Эшкә кергәндә котны алдын түлке, ябыктырам, дип.

Фирмачлар рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Бу инде ике араның тагын да җылынуын күрсәтә иде.

— Онытылган инде анысы,—диде Шаһмиран җитдиләнеп.—Җаның теләгән җиргә бар, җибәрәм, рәхмәт әйтеп озатам. Булдырдың, машиналар эшкә керешге—менә шуның өчен рәхмәт! Кая җыенасың?

— Белмим әле.

— Җәгъфәр бәй янына Дәү абый үзе бара, диюем.

— Җайларбыз анысын гына.

— Теге "Чибәркәй" чибәре беләнме?

— Үзеңнең хәлләр ничек соң, Шаһмиран?

— Төрттерәсең, ә!

— Шту син.

— Кияү юк бит, Тимерҗан, ичмасаң, син дә димләмисең.

— Беткән, ди.

— Бар, бухгалтердан күпме кирәк, шулчаклы ал—миңа шылтыратып маташмасын.

Менә шулайрак эшлиләр "Чулмантау" фирмасында. Рөхсәт, боерык, исемлек, кәгазь боткасы—берсе дә юк. Гомуми тәртип тә бозылмый. Эше дә төгәл, җиренә җиткерелеп башкарыла.

..."Чибәркәй" кафесындагылар Тимерҗанны төксе йөз белән каршыладылар. Һәрберсе үз эше белән мәшгуль булып кылана. Сөйләшү түгел, күтәрелеп тә карамыйлар.

— Әвенегез яндымы әллә?

— Жанса...

— Нурия кая?

— Белмәгәндәй итенмә,— диде җыештыручы мишәр карчыгы.

— Юньләп кенә сөйләш минем белән.

— Нәстә суләргә ди тагын.

— Мөдирегез кая диләр сиңа,—дип, Тимерҗан җыештыручының пумаласын тартып алды.—Нигә сырт йөнын күпертәсез?

— Синанны шартлатканнар, кәбәмне.

— Йә, йә?

— Нәстә, йә-йә. Машинасына бомба куйганнар да күккә оцырганнар, вәт.

— Кайчан бу?

— Төнлә. Иртән радиодан да сүләделәр.

Тимерҗан боларны чыннан да белми иде. Ул Бресттан соң гына кайтып төште. Шаһмиран әйтмешли, баш-аягы белән эшкә чумды бу арада. Ә менә Синан белән нәкъ шулайрак булырга тиешлеген белеп торды. Нуриясе эшне кызулаткан күрәсең. Бүген аларга барып, кеше күзенә чалынып йөрүне кирәк санамады. Шулай да җанын, нииндидер, корт кимерде, адәм үлгән бит. Хәлләре ничегрәк икән, берәр почмагы кителеп төшмәсен тагын? Нуриянең хәлен белергә егетләрен юллады.

Тегеләр озак юанмады, кайтып та җиттеләр. Тәртип, ди. Казанда яшәүче якташлары Синанның мәетен, җирләргә дип, махсус очкыч яллап, Бакыга алып киткәннәр. Нурия, башына сөлге урап, диванда ятып калган. Өчесен уздыргач, эшкә чыгам, Тимерҗан шунда килсен дип, әйтеп җибәргән. Синанның үлеме турында егетләр мишәр карчыгы сөйләгәннән артыгын хәбәр итә алмадылар. Тикшерүдә әлегә берниндн яктылык күренми икән. Бу заманда ату, шартлату бик гадәти нәрсәгә әйләнде. Милиция, тикшерүчеләр моңа үзләре дә тәмам күнегеп беттеләр шикелле. Әйтерсең, шулай тиеш.

Кешене машинасында яки ишек төбендә атып китәләр. Ә мәрхүмне җирләгәндә шул ук җәллад яисә киллерне яллаучы бәндә табут өстенә чәчәкләр куйган булып кылана, һич югында, каберенә бер уч туфрак ыргыта. Бусы да Дәү абый әйтә торган система галәмәте.

Башкалар ял да итә, тиешенчә типтерә дә. Сәүдәгәрне генә күр, ял дигәндә өтәләнеп тора. Ә менә Шаһмиранның ике ел буе тын алырга да вакыты юк. Бурсык, Мушка, Хәнҗәр вакыйгалары тәмам чыгырдан чыгарды. Ичмасам, Дәү абыйны озатасы иде Төркиягә. Күп йөгерде бу арада, мескенкәем, тикмәгә генә түшәккә аумагандыр теге көнне. Аны сакларга кирәк, борчылмасын, рәхәтләнеп ял итсен. Антальядагы биш бүлмәле виллалары ел әйләнә буш тора ич. Өлгерсә, Шаһмиран да барып җитәр. Бәрхет сезонын кулдан ычкындырмаска кирәк.

— Дөрес әйтәсең,—дип, хуплады Әмир тәкъдимне.—Мин икәүләп барырбыз дигән идем.

— Нишлим соң? Кенәз гел әмергә күнеккән, үзлегеннән кыл да кыймылдатмый. Кушсаң—бәрелеп үлгәнен дә белми анысы. Ә башны эшләтү юк. Ичмасам, теге ташбаш Сәүдәгәрне дә җибәреп өлгердем,—дип үкенде Шаһмиран.

— Берәр төрек малае алып кайтасы иде синең белән.

Гөлшәһидәнең башына ордыларлмыни. Аңлады да, төшенеп үк житмәде дә күк Дәү абыйсының сүзләрен.

— Нәрсә ул?—дигән булды.

— Әмир, кыз үзе искәрсен дипме, җавап кайтарырга ашыкмады, хәйләкәр елмаеп, бер як кашын сикертеп алды. Гөлшәһидә дә елмайды.

— Вариссыз каласың бит, кызый.

— Бу хакта сүз булмады ич моңарчы,—дип акланды кыз.—Искә алырга кирәк шулай да. Йә, нишлим?

— Калып тор.

— Алайса, мин килмичә, кузгалма. Диңгез һавасының шифасын татып яшә. Нигәдер, быел үзем дә ашкынам шунда,—дип тынычландырды Гөлшәһидә карт бүрене.

Гамәлләре элек сүзсез иде, бүген киресенчә, гамәлсез сүз куерттылар. Уй төшкән башларына. Аның каравы, барысы да ап-ачык. Төркия. Варис. Эш. Гамәл. Ничек өлгерер инде Шаһмиран?

* * *

“Татсиб”ка нокта куеп, “Чулмантау” тергезелгәч, ничектер, тормыш үз агымы белән, бертөрлерәк китте. Кибет, киоск мәшәкатьләре югалды. Иң мөһиме—Самат Килдебәков ише казынучылардан котылдылар. Тыныч юл белән эшләргә дә була икән югыйсә. Кеше, әнә шулай, үз язмышын үзе хәл итәргә дә мөмкин. Нефть чыга, Сәүдәгәр сата, Кенәз оештыра, Шымчы сакта тора, күзәтә, Хәнҗәр шулай ук үз бурычын оста башкара—тагын ни кирәк!

Дәү абый Төркиядә рәхәтләнеп ял итәдер инде. Мәшәкатьсез тормыштан Шаһмиранның жаны уйный башлады. Ничек төрттерә: варис-сыз каласың, кызый, ди ич. Дөрес сукалый, карт хәйләкәр. Моңарчы әйтми түзүенә дә рәхмәт инде. Өн салса, бәлки Шаһмиран уйлап та караган булыр иде, яше бара, анысын үзе дә белә.

Хәтерләсәгез, Шаһмиран берзаман Пермь якларында яшәп кайткан иде. Анда аның бер айлык нарасые, йөрәк парәсе калды җиде ятлар кулында. Зурдыр инде хәзер, укырга кергәндер. Исемен Җәүдәт дип яздырган иде. Әмма яңа әти-әниләре аны алыштырганнардыр мөгаен, фамилиясе дә Сәмитов түгелдер. Гөлшәһидәнең башында хәтәр уйлар бөтерелде. Ул бу хакта атна буе уйланды, ашау-эчүдән калды, йокысыз-лыктан интекте. Нишләргә, ни гамәл кылырга?!

Хәтәр уй аны Пермь кунакханәсенә китереп ташлады. Ярый ла улы риза булса. Белмәгән-күрмәгән кешегә ник ияреп китсен ди бала. Урлап кына качаргамы әллә соңгы чиктә? Кулдагы сумка гына түгел шул, тере җан, акырачак, бакырачак. Алып кайтканнан ары да әти-әнисен таптырачак, гомер буе шулай. Юк, үзенә аңлатып, төшендереп эшләргә кирәк моны. Димәк, үги әти-әниләре белән дә килештереп. Алар, билгеле, каршы торачак. Ә акча? Күп акча бәрабәренә, ана хакын хаклап ризалашырлар бәлки? Ни әйтсәң дә, малайның чын анасы ул—Гөлшәһидә ич. Миһербанлы булсалар, аңларлар, кызганырлар, күнәрләр. Шушы өмет аны хәтәр адымнан тыеп калды.

Шәһәрнең урманга барып терәлгән Наратлы урамындагы өченче йорт тирәсен күзәтте Гөлшәһидә. Иртән балалар берәмләп, икешәрләп, өчәрләп тә мәктәпкә юнәлделәр, төштән соң шаярышып, шау-гөр килеп өйләренә кайттылар. Туктатып берничә малайның исем-фамилиясен дә сорашып карады, юк Сәмитов фамилияле. Кайберләре шикләнеп:

— Нәрсәгә кирәк сезгә минем исем-фамилиям,—дип, китеп үк барды.

Чү! Менә бит ул! Үзе! Ул бит бу! Гөлшәһидә хәлсезләнүдән чак кына җиргә утырмады. Тач, үзенә охшаган лабаса, авыз-борын, күз-кабак, дигәндәй. Гөлшәһидәнең беренче сыйныфка кергәндә төшкән фотосурәте ич бу, шуның җанлы нөсхәсе.

— Бер генә минутка мөмкинме, улым?—дип туктатты малайны.

Аларның күзләре очрашты, бер-беренә текәлеп, икесе дә сүзсез-өнсез калганнар иде. Сынаулы карашмы, әллә инде тәмле телдән, ачык йөздән, моңлы күзләрдән шәфкатьлелек өмет итүме—ул кадәресе әле аларның аңына барып ук җитмәгән иде. Ике арада, нинди дер, җепләр сузылган, якынлык, ягымлылык, рәхәтлелек җепләре. Ниһаять, малай телгә килде:

— Мин сезне тыңлыйм, апа.

— Исемең Җәүдәт түгелме синең?

— Мин—Игорь.

— Фамилияң Сәмитовмы?

— Красноперов.

— Әйе, әйе, таныдым үзеңне, Красноперов шул. Әтиең—Иван Степанович, әниең менә... Мария, Мария...

— Мария Сафоновна,—диде малай.

— Дөрес.

— Хәзер алар өйдәме?

— Эштә, әни—сәгать биштә, әти алтыда гына кайта.

— Улым, менә нәрсә,—дип, каршына чүгәләде Гөлшәһидә бәләкәченең.—Кич сезгә килермен. Әти-әниеңнең якын танышлары мин. Ләкин бу хакта аларга әйтми торсаң яхшырак булыр иде—безнең сюрприз үзенә күрә. Син ризамы шуңа?

— Риза,— диде малай.

— Укучы антымы?

— Вәгъдә.

— Шоколад телисеңме?

— Чит кешеләрдән берни алмыйм.

— Гаилә дустыгыздан дамы? Рәнҗетәсең, улым.

— Алайса, бирегез, өйгә кайтканчы ашап бетерәм мин аны.

Гөлшәһидә сумкасыннан көчтәнәчен чыгарып бирде дә малайның ике як битеннән суырып үпте. Аннары иннек эзен ап-ак кулъяулыгы белән сөртеп куйды. Улының аркасыннан сөйде.

— Серне саклыйбызмы?

— Сез әйткәнчә булыр.

— Менә бу зур егетләрчә,—дип мактады Гөлшәһидә баланы. Фатирыгыз ничәнче әле?

— Унөченче.

— Ай, Аллам!

Кинәт хатынның йөзе агарып китте, уң кулы белән йөрәген тотты. Нинди шыксыз сан, унөчле! Нигә шундый санны исәптә йөртәләрдер?!

— Авырыйсызмы әллә, апа?

— Юк, улым, бар кер син.

— Кичкә чаклы, алайса.

Озаклап сөйләшеп торасы, ничек яшәвен беләсе иде, югыйсә, ярамый, күнеленә шик төшүе бар баланың. Гөлшәһидә теге чакта үзенең гафу ителмәслек хата җибәргәнен менә хәзер генә аңлады. Табиблар, бала тудыру йорты хезмәткәрләре барысы да сабыйны ятим итмә дип, ни ялындылар, ялвардылар, куркытып та карадылар—тыңламады шул. Менә тилмереп яшә инде хәзер...

Ишекне Игорь ачты. Ул шунда ук кухняга йөгерде.

— Әни, сюрприз, бездә сюрприз!—дип, кулларын чәбәкләп, биергә кереште.

— Кем бар анда, улым?

— Исәнмесез!

Мария Сафоновна Шураны шунда ук таныды—теге, баласын саткан хатын икән. Хуҗабикәнең йөзе агарып китте, ул гөпелдәп, урындыкка утырды.

— Ник килдегез?

— Сюрприз, сюрприз!

— Улым, бар, син кухняга кереп тор әле.

— Кермим.

Ана белән бала тарткалашып азапландылар. Гөлшәһидә үзен болай ук төксе каршыларлар, дип уйламаган иде, каушап калды. Сүзне кайдан, ничек башларга да белмәде. Аның күзләрен яшь томалады.

— Сөйләшергә дигән идем, Мария Сафоновна.

— Ни хакында? Хәер, барысын да атап сөйләмәсәгез яхшырак, бала тынлап тора.

— Әгәр риза булсагыз...

— Ул хакта авыз да ачмагыз, аңладым мин сезне,—дип кырт кисте Мария Сафоновна.

— Мин дә бит ана...

— Алданрак уйларга иде, газетага белдерү биргәнче. Гражданка Шура, шулай бит әле исемегез, гафу итегез, без үзебезнең кыйммәтле хәзинәбезне кемгәдер биреп җибәрә алмыйбыз. Бердәнберебез ул безнең.

Әнә, ишек, сезгә китәргә мөмкин, барыгыз, бар!

— Аз гына сабыр итегез, Мария Сафоновна, ирегез кайтканчы түзик.

— Ул да шулай диячәк. Әле катырак та әйтер.

Әкрен-әкрен, өзек-өзек булса да бәхәс дәвам итте. Мария Сафоновна отыры котырына барды. Шура гел кызгандырып, мескенләнеп сөйләде, ялынды, ялварды, кылган гамәле өчен бик нык үкенүен белдерде. Әчэннән бу йортка килеп керүенә гаять офтанды. Горурлыгы сынды бүген аның. Эшнең барып чыкмаячагы көн кебек ачык. Урлап кына китәсе калган малайны. Еллар уза торгач, улы да аңлар иде әле, үз әнисе ләбаса. Газизен үзләштерү аңа берни тормый иде бит. Тагын бер мәртәбә хата җибәрде.

Красноперов кайтып кергәч, өйдә бөтенләй давыл купты. Шураны этк әли-төрткәли үк башлады, тупас сүзләр әйтте, хәтта сүгенде дә. Игорь елап, кагылмагыз, ул яхшы апа, мин аны яратам, тимәгез, дип инәлгәч кенә, дулаудан туктап калды йорт хуҗасы. Күршеләренә кереп китте, аннан шактый сабырланып чыкты. Шул тынлыктан файдаланып, Шура үзенең шартларын житкерде:

— Мине дә аңларга тырышыгыз әле, Иван Степанович. Яшьлек хатасы һәркемдә була. Сезгә дә бәләкәчемне үстерүләре жинел генә бирелмәгәндер. Барысын аңлыйм. Һаман да бер бүлмәле фатирда яшисез икән менә. Теләсәгез иртәгә үк өч бүлмәлене табабыз. Миллионнар дими, миллиардлар белән сөйләшәм, сорагыз гына, күпме кирәк, шул чаклы бирәм.

— Капиталистмы әллә сез?

— Аннан да хәллерәк. Сорагыз: биш, ун миллиард. Күбрәген дә кызганмыйм, тик улымны гына кайтарыгыз.

— Акчаң үзеңә булсын.

— Кызганыгыз мине!

— Ә безне кем кызганыр?—дип, телгә килде Мария Сафоновна.— Без дә ятимнәр бит. Бөтен ышанычыбыз—шушы бала.

— Сез яхшылык белән китәргә теләмисез, ахрысы,—дип өстәде ире.

— Килешеп булмасмы дигән идем, Иван Степанович.

— Без бәдбәхет бәндәләр түгел бала сатып сәүдә итәргә.

Ул арада өйгә ике милиционер килеп керде. Күршеләре телефоныннан шылтыратып чакырган икән йорт хуҗасы аларны. Красноперов милиционерларның каршысына ук барып басты.

— Менә бу хатын бездән бала даулый.

— Нинди бала?

— Бер айлык чакта уллыкка алып үстергән, үз исемебезгә яздырган бердәнбер улыбызны кирәдән сорый.

— Гражданка, күрсәтегез документыгызны,—дип, милиционер Шурага мөрәҗәгать итте.

— Менә алыгыз. Иң элек мине тыңлагыз әле, зинһар,—дип, хатын паспортын закон кешеләренә сузды.—Красноперовлардан улымны таләп итмим, мәрхәмәтлек күрсәтүләрен генә үтенәм. Бирмиләр икән, алар ихтыярында. Инде төшендегезме эшнең нәрсәдә икәнен. Мин аларга болай да рәхмәтле.

— Бала болар исемендә ди бит, гражданка.

— Кызганыч, шулай икән шул.

— Димәк, сезгә китәргә мөмкин.

— Әлбәттә, әлбәттә. Тик, хөрмәтле Иван Степанович, Мария Сафоновна, соңгы мәртәбә улымны кочаклап үбәргә рөхсәт итсәгез иде, үтенеп сорыйм сездән?

Шураның күзләреннән мөлдерәп кайнар яшьләре акты, иреннәре дерелдәде, калтыранган кулларын алга сузып, идәнгә чүгәләде. Рөхсәт көтеп хәрәкәтсез калды.

— Нигә кирәк тагын монысы?—дип, Мария Сафоновна Игорьне үзенә таба тартты.

— Җибәрегез мине, ул яхшы апа!

Малай үги анасы кулыннан ычкынып, Шураның муенына килеп сарылды. "Сез еламагыз апа, кирәкми",—дип, аны юатырга ашыкты. Шура тилереп улын үпте. "Җәүдәтем, йөрәк парәм, бәгырь кисәгем, каласың бит читләр кулына, бөтенләйгә, мәңгегә каласың ич..."- дип тәкърарлады.

— Ярар, житте, артыкка киттегез,—диде Иван Степанович, улын Шурадан аерып алып.

— Рәхмәт сезгә,—дип, Гөлшәһидә ишеккә таба юнәлде.

Милиционерлар да аның артыннан урамга чыктылар. Бу күренештән алар шулай ук гаҗиз калганнар иде. Баласыз хатынны кызгандылар.

— Бүтән күренеп йөрмәсен,—дип, кычкырып калды Красноперов артларыннан.

— Апа, гражданка Сәмитова, алыгыз, паспортыгызны,—диде милиционер егет, татарчалап.

— Сез татармыни?

— Үпкәләмәгез инде, чакыргач, килмичә ярамый, эш бит...

Юк-барга бәйләнеп, болай да хәсрәтле ананы тинтерәтмәүләре, аны дөрес аңлаулары өчен, Гөлшәһидә милиционерларга рәхмәт әйтте. Эштән соң минем кайгымны юарсыз, дип, бер төргәк акча чыгарып тоттырды.

— Күп ич монда.

— Бер генә "лимон", алыгыз.

— Юк, булмый, артык күп,— диештеләр егетләр.

— Чын күңелемнән, үтенәм.

— Аңлыйбыз, апа, хәлегезне. Шулай да Красноперовларны бүтән борчымасагыз икән.

— Ялгыш килеп чыкты. Сезгә рәхмәт,—дип, Гөлшәһидә кунакханә ягына таба китеп барды.

Шуның белән сәяхәт тәмам. Өметләр өзелде. Мәңгегә, кире кайтмаслык булып өзелде өметләр. Бүгенге хатасы өчен Гөлшәһидә үзен беркайчан да гафу итмәс. Болай алып буламыни аю куеныннан алманы. Ни үкенеч! Инде алдан уйлаганны эшләү мөмкин түгел. Хәнҗәр белән Фараны алып килмәвенә офтанды. Кем белгән болай китереп орасын. Терсәк якын да бит, аны тешләп булмый.

* * *

Казанга күңеле тартмады Гөлшәһидәнең. Ни бар анда. Иң яхшысы—Чулмантау. Берәр атна ял итәр, бушаныр, ичмасам. Нурлы белән шашлык кыздырып тик ятыр. Пермьнән такси яллап кайтты. Промысел турына житкәч, шофер белән исәп-хисап ясап, машинаны үз юлына озатты. Трактор ачкан тар юлдан нефть вышкасына таба җәяү генә атлады. Будка ишеген ачып керсә, ни күрсен, Нурлы идәндә тәгәрәп ята, аһ-уһ килә.

— Нишләдең?

— Үләм, эчне бора.

— Ни ашаган идең?

— Ашаудан түгел, менә монда.—Ул уң як корсак астын угалап, тагын да яманрак акыра башлады.

— Сукыр эчәк, димәк.

Гөлшәһидә Хәлитовны район хастаханәсенә үзе алып китте. Диагноз куйганны көтеп торды. Чыннан да сукыр эчәк икән—Нурлыны шунда ук операция өстәленә салдылар. Инде нишләргә? Промыселны кемгә тапшырырга? Ким дигәндә, атна-ун көн ятачак әле ул монда. Айга сузылмаса

ярый әле, ничек килеп чыга бит операциясе Гөлшәһидә башын ике кулы белән кочып уйга калды.

— Ханым-әфәнде!

Күтәрелеп караган иде, каршысында телогрейка өстеннән зәңгәр чүпрәк халат кигән, башына колакчаларын як-якка тырпайткан малахай элгән бер бәндә басып тора. Таза, базык гәүдәле. Бераз шешмә кабаклы, күзләре кысынкы, ләкин ата мәченекедәй хәтәр елтырашалар. Ике бите авыл апайларының мич янында кызартып пешергән кабартмасыдай ялык-йолык итә. Димәк, бар яктан да сәламәт кеше. Сөйләшүен генә күр гыйбатның.

— Нинди интеллигент соң син?!—дип мыскыллы сорау бирде Гөлшәһидә, каршысындагы әзмәвергә.

Теге һаман әрсезләнә:

— Проблема, юктыр, бит, сеңелем?

— Сиптер, әйдә, әфәндем. Сиңа ни кирәк?

— Болай хафалангач, әллә машина проблемасымы дигән идем. Юл унае булса, әнә, безнеке базар мәйданында гына тора. Озакламый кузгалабыз.

Мондый кайгыртучы кешене рәнҗетүенә Гөлшәһидә унайсызланып куйды. Хәлгә керергә тырыша ич. Ә зыялылыгы кемнәрдәндер отып алган “кызыл” сүзләр генә булса кирәк.

— Утыр әле, абзый. Машина түгел, синдәй ыжгырып торган мужик кирәк миңа, бүген үк, менә хәзер үк. Эш башкарырлык мужик.

— Кит аннан! Өстенә генә бастың, ханым-әфәнде. Мин ул мужик, чынлап әйтәм, мәгәр.

— Тыңлап бетер башта, теленә салынма,—дип бүлде Гөлшәһидә.— Промыселда кешем калмады, сукыр эчәк белән монда китереп салдым үзен. Шуның урынына, төшенденме? Машинам бар ла анысы.

Гөлшәһидә матәм маршын көйләгәндәй, озын, күңелсез итеп сөйләде. Ә менә әңгәмәдәше гаять җәптәш, җор телле, үткен адәм булып чыкты. Бүген үк эшкә тотынырга әзер икән. Үзе кемме? Бер колхозның веттехнигы, ди. Авыру авылдашының хәлен белергә сугылган хастаханәгә. Туйган ферма эшеннән, гарык, башка җиргә урнашырга нияте бар, ди.

— Киләсеңме, соң?

— Менә паспортым үзем белән. Эштән азат итүен сорап, колхоз рәисенә хәзер үк гариза язам, алып кайтып тапшырырлар. Гыйнвар беткәнче ялда мин, ике елныкын алган идем.

Гөлшәһидә веттехникның паспортын әйләндерә-әйләндерә карады. Андагы мәгълүматлар белән танышты:

— Байталов Сагындык. Илле өченче елгы, милләте татар. Ә мин сезне казакъ дип торам.

— Казакъ дигәннән, бераз кан катышкан үзе.

— Анысы мөһим түгел. Өч бала язылган монда.

— Зурлар инде. Аларның үз тормышлары. Нишлим, машина киткәнче колхоз рәисенә гариза языйммы?

— Давай. Хатыныңа да.

— Анысына өлгерербез әле. Һы-һы. Кирәк булса, развод та алырмын.

Инде кич иде. Гөлшәһидә яңа хезмәтчесен туп-туры Утар-дачага алып кайтты. Эш тәртибе белән иртәгә иртәнге якта таныштырырга ниятләде.

— Байталов, киемнәреңне әнә тегендә, чоланга чыгарып ыргыт. Башканы киярсең.

— Исемем Сагындык.

— Минеке Шаһмиран, алайса.

— Шаһ—ми- ран? Һы.

— Ни булган?

— Әллә нинди, дики—мутный димме шунда.

— Синеке дә бик үк гадәти күренми анысы.

— Аны үземә дә әйткәлиләр,—дип, килеште Сагындык Байталов.

— Мунча яга беләсеңме?

— Менә тагын, авыл мужигына шундый сорау бирәләрмени! Тәмуггтан ут урлап булса да ягабыз аны, мунчаны.

— Дуй алайса, давай, дөрләт.

Ут урлап, шаккатырыйм дигәндә генә, нидер исенә төшеп, Сагындык кире борылды. Мондый кисәк очрашу, серле сөйләшүләр аңарда кызыксыну уятса да, кайсы ягы беләндер шөбһәләндерә дә иде.

— Карале, Шаһмиран, мин кая килеп эләктем була инде, ә?

— Шыр җибәрмә, ир бул,—дип, кырт кисте хуҗабикә. — Күрдең ич, промысел түбәндә, иртәгә төшәрбез. Бусы—дача, ял йортыбыз. Давай, сораусыз гына, яме!

"Беткән баш—беткән, ни булса—шул инде, дип, фикер йөртте Сагындык.—Акылына килсен әле Нәсимәсе, тәмам шашынды көнләшүдән, ике сүзнең берендә—аерылышабыз. Аерыл, ник! Урын җәеп яткырмый, мунча ягып кертми башлады. Кара моны, мунчадан тотынды. Кәттә, чукынган, әмма бик явыз күренә. Әмер бирергә ярата. Бирсен. Минем хатын түгел ич ул, бирсә. Нәсимә акылга утырачак әле түлке. Сагыныр, саргаер, алдыма килеп яшь түкмичә кайту юк. Үзе гаепле..."

Бу уйлары белән ул үз-үзен akларга тырыша иде бугай. Ә килеп капкан җире хәтәр күренә. Шаһмиранның, тьфү, шундый исем буламы, ире юк, ахрысы, эшне мунчадан башламас иде югыйсә. Ай-яй, йортҗирне, мунча-сарайларны җиткергәннәр дә инде! Бер дә бүтән түгел, министр-фәләннең аерылган хатыныдыр, мөгаен. Мунча эче җылына башлауга ишек төбеннән аваз салды Сагындык:

— Миңа нишләргә тагын?—Аның өй эчен дә күрәсе килә иде.

— Әнә, кар көрә, сарайда утын яр, кулың кычытса.

Шулай, ике сәгать буе тышта юанды хезмәтче. Мунча әзер булгач, Шаһмиран аңа сөлге, өр-яңа спорт киемнәре, бөркәнергә кайры тун чыгарып бирде.

— Яхшылап юын, мужик, колхоз исе калмасын,—дип озатты.

Сәер, ни өчендер, Шаһмиран мунча ишеген шакымады. Сагындыкның тәнен коры килеш саклап утырулары бушка булып чыкты. Ачуы кабарды, сулы чиләкне тибеп очырды. Ташка су тондырды да, ишекне ачык калдырып, алачыкка чыгып йөгерде. Күпме көтәргә инде?! Кире кереп, ләүкәгә үрмәләде, тәне кызарганчы чабынды. Күрсә-күрсен, әйдә, дип, мунча янындагы көрткә, ятып аунады. Юк, аңа илтифат итүче булмады.

Әмма табынны шәп хәзерләгән иде Шаһмиран. Хәмергә артык мөкиббән китмәсә дә, Сагындыкның күзе өстәлдә тезелешкән, Шаһмиран исеме шикелле дики-мутный шешәләргә төште. Кайдан табып бетергәннәрдер мондый сырлы-мырлы шешәләрне?! Казылык кына да берничә төрле, ул консерваларны санап бетерерлек түгел. Чучка салысыдай калын-калын итеп кызыл балык туралган, борчактай эре бөртекле кара икра куелган. Тавыкны бөтен килеш кыздырган, монысына кай арада өлгергәндер, унган нәмәстә икән аш-суга. Урман арасындагы йортта шул чаклы алма, әфлисун, банан, мандарин булыр дип, кем уйлаган, ну, өстәлне сөйләп бетерерлек кенә түгел, кәнишне.

— Кунаклар да буламы?—дип кызыксынды Сагындык.

— Син үзен кунак, җитеш әйдә!

Сыйланып туйгач, Шаһмиран кунакны гәҗит-журналлар өстәле янына чакырды, каршыдагы кәнәфигә утырырга боерды. Үзенә ошаган берәр шешәне алып килергә кушты.

— Исерешкәнче сөйләшеп куясы бар,—диде кыз.

Шаһмиран артык җәелеп тормастан, Сагындыкның вазифаларын санап чыкты. Нефтьчеләрнең эшен күзәтә, машиналарны кабул итә, аларны тәяп озата. Беркем белән элемтәгә кермәскә, берни хакында сөйләшмәскә. Хәзергә аш-суны үзе хәзерли.

— Нурлыгаян Хәлитов терелеп кайткач, үзара килешерсез. Син бәлки монда күчәрсең. Этне туйдырырга кирәк. Безнең эштә тугарылып йөрү, ниндидер үзешчәнлек тыелган. Эш гамәле—бетте-китте, башкасы кирәкми. Син шуларга ризамы?—дип сорады Шаһмиран.

— Түләү ягы?

— Гафу ит, колхоз икәнеңне онытып җибәргәнмен. Ничә миллион кирәк?

— Ә-ә?

— Ике житәрме хәзергә?

Сагындык телсез калды, куллары белән яңагын учлады. Шаһмиран шаярта дип уйлады.

— Йә?

— Безнең колхозның еллык кереме ич ул.

Бу кадәресен дә ачыкладылар. Шаһмиран шаяртмый икән. Гаиләсенә җибәрү өчен шунда ук ике "лимон"ны санап тоттырды. Фирма таләпләреннән аз гына тайпылсаң да, башың белән җавап бирәчәксең, дип кисәтте ахырдан. Шул урында әңгәмәгә нокта куелды.

Хуҗабикә Сагындыкны кунак бүлмәсенә озатты, тыныч йокы теләде. Хәйләкәр елмаеп, ишекне теге яктан япты. Болай да буламы икәнни соң? Вәт, әкәмәт! Дачада башка адәм заты юк лабаса. Сагындык ник мунча якты алайса?! Бөгәрләнеп ятар өчен шул тиклем иза чикмәсә. Аңламассың бу хатын-кызны! Авылда рәхәт, ичмасаң, китереп кенә кысасың. Кычкырып разбой салучы юк, ник авылга даның таратсын, ди. Сыер савучы гына булсалар да, ирнең кадерен беләләр инде авыл хатыннары.

Урын үзгәләдеме, әллә күрше бүлмәдән аяк тавышы ишетәсенә өметләндеме, Сагындыкның күзен йокы алмады, тик тәгәри бирде караватында. Тамагы кипте, чәй эчәргә дип, мыштым гына кухняга чыкты. Капшана торгач, плитәдәге чәйнекне шудырып җибәрде, дөбер-шатыр килде. Гөлт итеп ут кабынды. Шаһмиран икән. Чәйнек борыныннан голт-голт су эчеп тора иде Сагындык.

— Ой,—дип, арты белән борылды.

— Оялма, трусигың бар ич.

— Үлеп эчәсе килде.

— Тычканың бүрткән синең Сагындык, шуңа йокың качкан.

— Ачуланмагыз инде.

— Әйдә,—диде Шаһмиран аны үз бүлмәсенә чакырып.

Менә нинди була икән ул йокы бүлмәсе! Зур, зиннәтлелеге—искитмәле. Бер як стенага келәм урынына әкәмәт олы картина-сурәт эленгән: чыбылдык эчендә таза гына шәрә бер хатын ирен көтеп ята. Белә бит ул бу рәсемне. Тәтеш техникумында укыганда күргәне бар. Исеме ничек соң әле? Дания... Дәлия... Юк—ла, Даная, әйе, Даная! Аппетитны китерә инде бу, каһәр! Шаһмиранның ятагы ике кешелек икән, киң, иркен, чуклы-челтәрле, ап-ак урын-җир. Идәндә калын, йомшак келәм.

— Цирк күрәсең киләме?

— Нинди цирк?

— Бар, әнә, минем урынга ятып кара.

Шаһмиран өстендәге ефәк халатын салып, аны күккә чөйде, тар трусиктан гына калды. Тиктомалдан идән уртасында юләрләнергә керешге. Башта мәтән-чүкән атынып алды. Нәкъ цирктагыча. Шуннан тотынды бу галәмәтне күрсәтергә: әле баштүбән тора, әле куллары белән атлап китә. Аннары сыңар кулда килеш җил тегермәне булып әйләнә. Хәтта бер бармак очында гына да тора ала икән. Төрле фигуралар ясауны әйтәсе дә юк.

— Менә кара!

Ул стена кырыендагы калын тактадан эшләнгән кечкенә эскәмия янына килде, кул кырые белән берне генә бәрде—утыргыч чәрдәкләнеп очты. Балта белән чапты диярсең.

— Каным суына төште. Борчылма, яңасын ясарлар,—дип, Шаһмиран баягы шөгылен дәвам итте.

Иң ахырдан артын туңкайтып, Сагындыкны үртәде дә, әкрен генә, еландай сузылып, келәмгә ятты. Хәйран калып, дөньясын оныткан тамашачысына әмерен җиткерде:

— Мине урыныма күтәреп сал хәзер. Ә сиңа тагын бер тустаган коньяк җитми калган, бар, залга чыгып кер.

Сагындык кыюлык "малае" белән серләшеп кергәндә инде ут сүнгән, Шаһмиранның баш очында мәче башлы ябалак күзләре генә елтырый иде.

— Эләктерденме, Байталов, теге тычканны?

— Монда ич ул.

— Алайса, җибәр юрган астына.

Сагындык кабаланмыйча гына хатын янына үрмәләде. Шаһмиранның да Красноперовлардан үч аласы, Дәү абыйсын куандырасы бар иде...

Иртән Байталовны промыселда калдырып, Казанга кайтырга җыенды. Ике көннән синең янга Кенәз дигән кеше килеп чыгар, сорауларың булса, аның белән хәл итәрсез. Ул сине өйрәтер.

— Нинди Кенәз?

Шаһмиран кабынып ук китте.

— Сагындык, кабатлап әйтәм: беркайчан, беркемгә артык сорау да, сораштыручыларга ашыгып җавап та бирмә. Аңладыңмы шуны?

— Төшендем.

— Сынатма, давай.

— Тагын кайчан киләсең?

— Оныт син минем килгәнне, ярыймы. Сораусыз гына. Барсны туйдырырга онытма.

Шаһмиранның соңгы сүзләре гаҗәбрәк тоелды. Үзе түрә, үзе кайнар кочаклы хатын, үзе беренче мәртәбә күргәндәй кылана. Сәер шулай да. Аңла син бу җен кавемен!..

* * *

Казан үзенчә кайнап ята иде. Җан-фәрман президент сайлауларына хәзерләнәләр. Кенәз "Чулмантау" кыегына да Татарстан әләмен беркетеп куйган.

— Бу кадәресе кирәкме икән соң, Шамил?

— Йортлар идарәсеннән әйтеп йөрделәр.

Шаһмиран гомуми хәл турында сораша башлаган гына иде, телефон пи-пипләде. Кайбер кәгазьләрне күрсәтәсе бар, алып керәм дип, Кенәз кире чыгып китте.

— Кайда югалдың син, Шаһмиран?

— Кем әле бу, танымадым?

— Баермын, димәк.

— Майор түгелме?

— Нәкъ үзе. Тәҗел эш бар. Хәзер килеп җитәм, шунда бул,—дип кисәтте Шаһмиранны Шымчы.

Ул арада Кенәз дә әйләнеп керде. Кәгазьләрен өстәлгә җәеп, алардан нидер чүпләргә тотынды. Кая күпме товар озатылган, кайдан никадәр валюта күчерелгән. Кемнәрнең өлеше нинди, керем, чыгым...

— Ташла шул чүп-чарны. Ни өчендер Шымчы килә, бая ул шылтыратты. Тегенди-мондый эш юктыр ич?

— Килдебәков хатыны тузына ди анда. Бәлки шулдыр.

— Шулдыр, будыр, сүзне нәкъ менә шуннан башларга кирәк иде сиңа,— дип ачуланды Шаһмиран.—Рәтләп сөйлә, ичмасам.

— Үзе килсен инде.

Кенәз белгән кадәресен бәян кылды. Иренең үлү сәбәпләрен

ачыклауны таләп итә икән, ник тикшермисез дип бәйләнә, ди. Әлегә Шымчы тынычландырып җибәргән җибәрүен. Болай гына калдырмыйм, Президентның үзе янына барам!—дип чәпчегән. Сине көттем, киңәшер кеше юк монда, дип зарланды штаб түрәсе.

— Бер чүпрәк баштан да шүрләгәч, нинди Кенәз инде син!

Шамил Бакаев сөйләгәннәрне Шымчы сүзгә сүз диярлек кабатлап чыкты. Бүтән яңалыгы юк иде. Мәсьәләне тизрәк чишүне үтенде. Вакыт аз калды, бер атнадан хатынның кабат кузгалуы ихтимал.

— Тәкъдимең ни?

— Анысы инде, Шаһмиран, синә егетләрең эше,—диде Алаев, үзен бер читтәрәк калдырырга тырышып.—Бу мәсьәләдә күрәсе кешеләрем бар. Ашыгам, бигәйбә. Сезнең рөхсәт белән.

— Рәхмәт, Александр Васильевич! Тырыша күр, яман ис таралмасын, Дәү абый әйтмешли. Чыгымнан курыкма.

— Хикмәт хатында. Оныткамнмын, язып ал адресын, эш урынын да... Исеме— Мәгъруфә. Килдебәкова Мәгъруфә. Эштән нәкъ сәгать биштә чыга.

... Кичке якта Килдебәкова авыр сумкасын күтәреп өенә кайтып килә иде. Аның яныннан бераз уза төшеп чит ил машинасы туктады. Ике егет чыгып, фәләненче йортны ничек табарга дип сораштырды. Хатын ул йортның каршы якта, бакча эчендәрәк булуын аңлатырга керешгте. Шул чак кемдер, арттан килеп, аның авызын каплады, өстерәп, машинага кертеп тә салдылар. Күзләрен, кулларын машина эчендә бәйләделәр.

Шактый озак баргач, каядыр туктадылар, эт абалап торган ишек алдына, аннары өйгә алып керделәр, урындыкка дөпелдәтеп утырттылар, күзләрен чиштеләр. Мә, эч дип, кулына сулы стакан тоттырдылар, тынычланырга куштылар.

— Мине кая китердегез? Сез кемнәр?

— Сорауны без бирербез. Телләнмичә генә утыр.

Хатын дерелдәп, тәрәзәгә карады. Төн иде инде. Тәрәзәләрендә тимер рәшәткә. Йорт алдында биек койма шәйләнә. Эт һаман да абалый, котырынып өрә. Моның юньле җир булмавы күренеп тора. Бая машинадан чыгып сүз каткан егет тагын телгә килде:

— Анда карау файдасыз, апа. Шәһәр дә, авыл да юк монда. Әнә күрдең, биек койма, усал эт—бу яктан тыныч бул. Исемең фу, тел әйләнми, Мәг... Мәгъ-рү-фә, фамилияң Килдебәкова. Шулаймы соң?

— Ие.

— Килдебәкова, нигә дип үлгән кешене табутыннан кузгатасың син, анаңны сатыйм. Ә, алаймыни? Ирең икән! Безнең дә якын дустыбыз иде Самат. Үлгән—беткән, аны терелтеп булмый хәзер. Берәүне дә гаепләмәгез дип, язу калдырган бит үз кулы белән. Нәрсә, сезгә шул аңлашылмыймы?

— Балалары ятим,—диде хатын авыз эченнән мыгырданып.

— Шуннан?

— Үстерәсе бар ич. Башка ярдәмчебез юк.

— Кабердән кайтып үстерер дисеңме?

— Юк та.

— Ник сөйләшеп торасың шуның белән, ире янына олактырабыз— бетте-китте, вәссәләм.

Мәгъруфә курку катыш кинәт айныгандай булды. Уйнап сөйләшмиләр икән болар.

— Зинһар, хараплар итмәгез, сабыйларым хакына,—дип, ялварырга керешге.

— Сүзне шуннан башларга иде. Сабыйларыгыз безгә дә кызганыч, менә бит үзегез гаепле. Ник чабасыз тегендә-монда, прокурорга. Президент белән өркетәсез, понимаеш.

Күрше бүлмәдән уналты-унҗиделәр тирәсендә ап-ак йөзле ике кыз карап тора иде. Шофер егет аларны этеп, ишекне ябып куйды. Аннары

кызларның кем булуларын аңлатты. Язмышлары хәл ителгән фахишәләр болар диде.

Ярты ел буе үзләренә хезмәт итүләрен әйтеп мактанды. Беркая чыкмыйлар, чыга да алмыйлар. Әнә шул сакаллы кеше саклый икән үзләрен. Тагын ярты елдан туташларны гамәлдән чыгарачаклар. Ә алар урынына яңалары килер. Килдебәкова, хәтта, бу урынга да дәгъвалый алмый—яше узган, кызыксыз. Димәк, гамәлдән чыгарырга гына кала.

Хатын үзенә чын фаҗига килүен аңлап, илереп еларга, тагын да ныграк ялварырга, антлар итәргә кереште. Хәсрәт ачысыннан гына барган икән, бүтән йөрмәс тә, сөйләшмәс тә, үлгән артыннан үләр хәле юк. Зинһар, оланнар, башларымны вәйран итмәгез, кызганыгыз ике ятимебезне. Үстерим шуларны. Чыгарып кына җибәрә күрегез. Ни булганын, ни күрүем турында авыз да ачмаска сүз бирәм, ант итәм. Зинһар вә зинһар!..

— Нишлибез, егетләр?

— Тагын прокурорга чапсынмы? Дөмектерергә кирәк!

— Хатамны аңладым, оланнар, кыймагыз җанымны, ни әйтсәгез, шуңа риза,—дип ялынды хатын.

Теге йомшаграк сөйләшүче миһербанлысымагы кинәт берничә төргәк акча чыгарып, Мәгърүфәнең алдына ташлады.

— Биш миллион, туйдыр балаларыңны, ләкин тының чыкмасын, ләчтит сатып йөрисе түгел,—дип кисәтте.—Чишегез кулларын, бәйләгез күзләрен, өенә кайтарып куябыз.

— Кара аны, сука, икенче рәт сине монда ташып йөрмәячәкбез!

Бу юлы җан кыелмыйча калды. Өйрәнә бит егетләр дә бераз адәмчә эш йөртергә. Соңгы чиккә бармыйча да була икән хәл итеп. Шымчы тынычлансын инде, тәмам шыр җибәргән, югыйсә. Дәү абый ялдан йөреп кайткач, хәрби дәрәҗәсен күтәрергә кирәк булыр...

* * *

Сайлаулар узды, давыллар тынды. Инде борчылырлык нәрсә юк кебек. Нурлыгаян Хәлитов шифаханәдән савыгып кайткан, үз урынына баскан. Байталовны эт карарга куйган, хуҗалык эшләренә җигә башлаган. Монысы белән килеште Шаһмиран. Тик менә үзенең кәефе китеп тора, башы әйләнгәли, күңеле болгана, аппетиты булмаудан зарлана.

— Гел офиста ятасың, саф һава кирәк сиңа. Берәр атнага Казан-су буена ычкын,—дип тәкъдим итте Кенәз, кызны тыңлагач.

— Тәкә башы ашыйсым килә минем, Шамил.

— Ә!? Нинди тәкә?

— Белмим.

Кенәз, башын әле бер якка, әле икенче якка кыйшайтып, озак кына карап торды Шаһмиранга.

— Ну, даешь!

— Студент чакта Әстерханга помидор җыярга җибәргәннәр иде институттан. Шунда бер казакъ көтүчесендә кунакта булдык. Хөрмәт йөзеннән ул безне сарык башы белән сыйлады. Шуның тәме авыздан китми, бик ашыйсым килә,—диде Шаһмиран, ни әйтергә дә белмичә.—Чулмантауга ычкынырмын, ахрысы. Нурлыда сарык бар, тик беркөн ул баш дигәнен алып менмәгән иде. Чаңгыда да йөрми калам югыйсә. Карасана, март бураннары ничек котыра, дөнья күренми. Чаңгыда беренче разряд бит минем.

— Фара илтеп куяр.

... Язмышы тартып китердеме соң монда Шаһмиранны. Беренче көнне аның янына, хәтәр тузынып, бер хатын килеп керде. И, китте, и, китте тезеп:

— Минем ирем сездәме? Шушында, диделәр. Кая ул? Нәстә акайдың,

ирем кая дим? Кара, кара, нинди ир дигән була тагын. Маңгаенда менә-ә мондый, беләк буе мөгезе бар. Мир үгезедәй үкереп торган мужик үзе. Әйдә, вакытым юк синең белән әрепләшергә. Кая яшерден иремне? Әйт, кая ирем?! Күр әле, кәпрәюен! Гел генә белмәмешкә салыша. Пеләмәннуй Сагындык Байталовны белмәгән кешеләр дә бар икән, билләһи! Аны безнең якның ана этләре дә таный.

Сагындык хатынын күреп телсез калды. Әче Нәсимә дә сүз әйтер хәлдә түгел иде. Тынлыкны Шаһмиран бозды:

— Менә сине алырга килгәннәр, Байталов.

— Мин кайтмыйм.

— Тавыш куптарма.

— Развод сорап хат җибәрелгән, теләсә нишләсен,—дип акланырга керешкән иде дә, Шаһмиран кырт кисте:

— Әнә, паспортың, хезмәт хакыңны өстәл тартмасыннан ал! Йә, тиз кыймылда!

Сагындык теләр-теләмәс кенә кузгалды. Паспортын куен кесәсенә яшерде. Аннары өстәл тартмасын тартып ачты:

— Күпме алыйм?

— Теләгән кадәр.

— Бер миллионмы, икенеме?

— Җиттеме сиңа, Байталов, юкмы? Бишне, унны ал! Зинһар, күземнән генә югалыгыз!

Байталовлар җитәкләшеп ишеккә таба юнәлде. Ир хатынына йодрыгын иснәтте, тегесе җавап итеп телен чыгарып күрсәтте. Шаһмиран рәхәтләнеп көлеп җибәрде, аңа Байталовлар да кушылды. Ачулары таралды.

— Каты бәрелгәнгә үпкәләмә, җанаш, кунакка килеп чык,—дип чакырды әче Нәсимә Шаһмиранны, ишектән чыгышлый.

Өйгә ниндидер ят ис сеңеп калган иде. Җилләтергә дип, Гөлшәһидә тәрәзәне барып ачты.

* * *

Март бураннарыннан соң урман каз мамыгына төренеп, тынып калган. Чыршы-нарат кар түшәлгән кәүсәләрен чак күтәреп тора. Болай да ак каеннар тагын да аграк булып, акшарлагандай күренә, чуклы шәлен бөркәнгән кар кызын хәтерләтә. Дөньяда аклык, пакьлек хөкем сөрә.

Көз мәлендә нык җилләгән иде. Кыш бабай кырдагы бөтен байлыгын урманга китереп тутырган икән. Атна буе котырган март бураны да үз өлешен өстәгән. Гөлшәһидә чаңгыдан юри генә төшеп караган иде, бот тиңентен батты. Монда таудан шуу турында уйлыйсы да юк. Бераз йөреп кайтса гына инде. Атлый торгач, шактый юл алды чаңгычы, үпкәләр сафланыр, ичмасам, дип фикер йөртте ул. Кинәт урман аланына килеп чыкты. Җәен бирендә Сабан туе ясап, көрәш кенә оештырасы икән ләбаса. Бүген алан ак юрган япкандай кабарып тора, Сагындык битедәй шоп-шома. Гөлшәһидә күтәрелеп, агач башларына күз салды. Нинди әкият! Нинди хозурлык! Мин—җинүче!—дип кычкырасы килде аның. Әмма аваз салмады, тынлыкны бозарга базмады. Кыз, алан кырыендагы карачкыны күреп, туктап калды. Сунарчы этеме соң?! Кая хуҗасы? Эзе дә күренми. Гөлшәһидә эткә таба атлады. Кинәт теге йонлач та кузгалды. Бүре ич бу! Туп-туры килә. Ун-унбиш метр кала ерткыч туктады, иплән кенә утырды да чаңгычыны күзәтә башлады. Ары таба җибәрмәскә исәбе, димәк. Ә анда тирән елга-чокыр, өне шундадыр, күрәсең.

Нишләргә? Әлбәттә кире борылырга. Әнә бит, юл бирми, җибәрәсе килми. Гөлшәһидә кайтыр якка берничә адым гына атлады, бүре тыйтаклап божра ясарга кереште, юлны бөтенләй ябып куйды. Хәзер инде капма-

каршы якка килеп чүнкәйде. Гөлшәһидә чаңгыларын чокырга таба борган иде, бүре әүвәлге урынына юнәлде, ләкин баягыча утырмады, тирәли әйләнеп йөри башлады. Һаман тыйтаклый. Алгы уң аягы сынык икән ерткычның. Бәлки капкыннан ычкынгандыр, йә сунарчы ядрәсе тишкәндер. Димәк—ки, корбанын куып тота алмый башлаган—ач бүре. Хәтәр бу! Ташланырга җыена.

Җәйге чак булса, Гөлшәһидә ике дә уйлап тормас, сугышыр да, җиңәр дә иде. Монда бот тиңентен йомшак кар. Чаңгыда калырга шулай ук ярамый—кымшатмаячак та. Кыз кайтыр якка кузгалырга ниятләде. Бүре яңадан юл өстенә килеп басты. Инде ул утырмый, тешләрен шакылдатып ырылдый. Күзләре яман ялтырый. Гөлшәһидә сыңар чаңгысын, таякларын карга кадады, бияләйләрен кесәсенә салып, ялан кул калды. Бер чаңгысын сөңге итеп бата-чума бүрегә якынлашты. Ерткыч, урынында биеп тора башлады, сикерергә әзерләнде. Ике ара өч-дүрт адым гына. Бүре әле уңга, әле сулга ташлана, ыргылырга җайлы мизгелне чамалый. Гөлшәһидә чаңгы очы белән ерткычны чөеп җибәрде. Бу исә, җанварны котыртты гына, ул чинап, инде үзе ташланды. Чаңгы очы белән кыз бүрене муенынnan басып җиргә екты, әмма йомшак кар арасыннан ерткыч башын бик ансат тартып чыгарды. Сугам дип, чаңгыны күтәрергә ярамый, ерткыч бер генә сикерәчәк. Тинтерәтергә үзен. Әлегә аны этеп, чөеп кенә торырга мөмкин. Ниһаять, ерткыч яны белән килеп төште. Гөлшәһидә бар көче белән чаңгыга ятып, тегене карга батырды, котылырга ирек бирмәде, шуышып янына ук килеп житте, кул кырые белән бүренең умыртка сөягенә китереп тә орды. Сөяк чартлап сынды, ерткычның арт саны тотрыксызланды, асылынып калды. Ул инде сикерер хәлдә түгел иде. Чаңгы очы белән селтәп ыргытылган җанвар, яман чинап, чокырына таба шуышты. Сыңар аяк кына аны әллә ни өстери алмый иде инде. Гөлшәһидә артыгын каныгып маташмады, чаңгыларын киеп, дача ягына юнәлде.

— Ярый әле теге хатынның ирен үзенә биреп җибәрдем,—дип куанды Гөлшәһидә.

Бакаев ул сөйләгәннәргә ышанды да, ышанмады да. Бу бәладән Шаһмиран түгел, Кенәз котылды булып чыга әле монда. Әгәр кыз белән берәр хәл була калса, Дәү абый, беренче чиратта, Шамилнең башына җитәчәк иде. Ходай саклады.

— Инде, Шаһмиран, давай, ычкын Төркиягә, Дәү абый да кәтәдер,— диде Кенәз, катгый таләп куеп.

Кәефе бөтенләй ук көйләнеп бетмәгән иде әле офис хуҗасының. Күңеле болганып җәфалады, ара-тирә коскалады да. Әмма эченнән ңык сөенде, тикмәгә генә тәкә башына нәфесе төшмәгән икән—рәхмәт Нурлыга, туйганчы сыйлады, ичмасам. Атна буе дачада яшәсә дә, Гөлшәһидә Сагындыкны үзенә якын җибәрмәде. Оныт син ул кичне, бүтән кабатлама, исенә дә алма, дип кисәтте. Шуның белән мунча-цирк вакыйгасына нокта куелды.

Гөлшәһидә иртәгә Төркиягә, Антальядагы виллаларына очарга тиеш иде. Ашыгыч рәвештә офиска Нурлыгаян Хәлитов килеп керде.

— Нишләп йөрисең?

— Кенәз чакырды?

— Тәртипме соң?

— Ул-бу юк. Тик менә дачаны караучысыз калдырырга ярамас, дим.

— Тап бер юньлерәк адәм.

— Байталов килгән иде.

— Эзе булмасын! Кенәз белән хәл итегез.

— Сиңа хат калдырып китте,—дип, Нурлы Шаһмиранга конверт сузды.

Серле хат.

*"Исәнме-саумы, гүзәлләрнең гүзәле Шаһмиран—минем ялкынлы мәхәббәтем, алтыным, зөбәрҗәтем, татлы җимешем, мәңге онытылмас шаян колыным! Нишләттең син мине? Аерылганнан бирле ашым—аш, йокым йокы түгел... Барысы да үкенечкә булыр дип кем уйлаган аны! Ятсам-торсам, чыксам-керсәм, күз алдымда шәүләң тора, исләремдә гел син генә, җаныем, белмисең генә. Тыныч кына йоклап яткан йөрәгемдә нигәрга дип сөю утын кабыздың икән, Шаһмиран гүзәлем! Кабыздың да үзең ташлап киттең. Тилмереплар үлсен, дидеңме?!*

*Һай, ул беренче һәм соңгы төнебез! Аны оныту—дөньядан юк булу. Хәтерем беренче кичебез хәтирәләре белән яши. Бүлмәң—иркен болын, син шул болында уйнаклап йөргән колын идең ул кичне. Бәхетле, мең кат бәхетле идем мин ул кичне... Ә син шуларны онытырга дисеңме? Булмый да, булдыра да алмыйм, саргаеп үләрмен күк синсез.*

*Күз алдымда буй-сыннарың, түгәрәк алмаларың, сулышыңның кайнарлыгы әле дә җанымны өтеп-өтеп ала. Син онытсаң да, мин гомер-бакый оныта алмам, ахрысы. Очрашу, кавышу өмете белән яшим. Әгәр рөхсәт итсәң, качып түгел, законлы аерылып килер идем яныңа. Синнән хәбәр көтәм. Кавышуга өметләнеп калам.*

*Сагындык Байталов"*

— Дурак! Ду-у-ра-ак!—дип сузды Шаһмиран, хатны туксан тугызга ерткалап. Юк-бар адәмгә бәйләнсәң, шулай буласы билгеле. Ужым бозавы! Хатын-кыз күрмәгәндәй кылануын кара син аның. Хәер, ник сүгәргә әле аны, сагына-саргая бирсен. Рәхмәт әйтерлек бүләге калды ич, мәңге онытылмаслык. Юк, Шаһмиран яшертен генә күп тапкырлар искә алыр әле "пеләмәннуй" Байталовны—шунсыз булмый ул...

* * *

Кайнап торган диңгез, эре бөртекле алтын комлык. Шул комлы ярдан ук башланып киткән яшеллек, урман, биек-биек таулар. Яшеллек арасында ак ташпулатлар, виллалар шәйләнә. Сихри манзара. Таулар итәгендә Әмир Шаһназаровның ике катлы, берничә бүлмәдән торган вилла-дачасы. Йорты артык зур булмаса да, җиләк-җимеш бакчасы шактый мәйданны били, ишек алды уртасында җыйнак кына бассейны да бар. Моннан өч ел элек әзер килеш сатып алган иде. Анталья менә шул була инде! Рәхәтләнеп ял итә бир.

Антальяда яши башлагач, Әмиргә төрек малае тынгы бирми башлады. Хыялы белән ул аны муенына атландырып та йөри инде, диңгез, урман, тауларны күрсәтә. Ул Гөлшәһидәне чакырырга ниятләде.

— Билет кесәдә—иртәгә очам,—диде тегесе, хәл-әхвәл сорашкач та.

Гөлшәһидәнең килүе Әмир өчен бәйрәмгә әйләнде. Ул аны капка төбендә иртәдән бирле көтә иде. Алдан әзерләп куйган сүзләрен тезде:

— Бән сәне чок бәкләдем, чок өзләдем.

— Күр син бу төрекне,—дип, Гөлшәһидә Дәү абыйсының олы кочагына ташланды.

— Бән бираз түрекчә конушa билирим.

— Бән конушамуйорум шул,—дип көлде кыз.—"Бәкләдем" ни дигән сүз, бик хәтәр түгелме?

— "Көттем" сүзе.

— Ә нигә эзләдем дисең?

— Эзләдем түгел, өзләдем—сагындым дигән сүз була.

— Төрекчә әйбәт сөйләшә башладык,—диде Гөлшәһидә, кочакта килеш.

Чыннан да сагынышканнар иде алар бер-берсен. Мондый чакларда Әмир кызны озаклап ычкындырмый, аның кайнарлыгын татып рәхәтләнә.

Әмир ялдан канәгать булуын, хозурланып яшәвен әйтте. Ике атна элек Истанбулга барып, "Ак банк"тан Гөлшәһидә күчергән долларларны алып кайткан. "Шул тиклем салмасаң, нишлим аның белән, әнә, тик ята",—дип битәрләде кунагын. Шаһназаровның бүтән сөйләр яңалыгы юк иде. Комлыкка кызынырга да сирәк төшә, әүвәлгечә хатын-кыз белән аралашырга ашкынып тормый.

— Теге юан корсагынны очраттым,—диде Әмир, башка сөйләр яңалыгы калмагач.

— Кайттылар инде. Үзем җибәргән идем. Сәүдәгәр кемгә караганда да тырыша, аңа сүз юк.

— Җәгъфәр син ярата торган кефаль балыгы алып кайткан, күрәбезме?

— Бакча тагын да матурайган.

Гөлшәһидә керергә ашыкмый иде. Бу юлы Антальяга ашкынып килде, озаклап ял итәргә, Дәү абыйсын иркәләргә дип. Ә ул балык турында сөйли. Балык капты бит инде... Гөлшәһидәнең күзләре һәр нәрсәгә сөеп, иркәләп карый иде бүген.

— Былтыр мин утырткан Сөүт, Кабак агачларымы соң болар?

— Дымлы туфракта тиз үсәләр,—дип, Җәгъфәр-бәй, кунакларын өйгә керергә чакырды.—Боерыгыз, әфәндем! Ханым-әфәнде, эчкә узыгыз!

Антальядә бәйрәм башланыр сәгатьләр килеп җиткән иде, мәгәр.

* * *

Хатын-кызның осталыгы серне саклый белүдә. Акыллы җанбикә аны аз гына иртәрәк тә, чыпчык борыны кадәр кичегеп тә чишмәс, тиешле урында тиешле кешесенә тиешле вакытта, нәкъ тиешле дәрәҗәдә җиткерер. Бу инде ышаныч яулау, мәхәббәткә тиенү, уңышка ирешү дигән сүз. Мондый талант Гөлшәһидәне дә читләтеп узмаган иде. Ул тәвәккәлләде...

Истанбулдан Казанга чаклы очкычта Әмир Шаһназаровның тез өстендә төрек малае тирбәлеп кайтты. Фатир ишеге төбендә көтеп торган билгесез адәмнәр дә аның кәефен җибәрә алмады. Беренче генә килүләре түгел бит. Кемнәр булса да иртәрәк кузгалганнар, Шаһназаровка аяк чалырлык көч юк әлегә. Шулай да яманаты чыккан система төймәләренә басарга туры килер бәлки. Әнә, төрекләр ни әйтә: кылыч белән шаярма, ул ике яклы, диләр.

"Чулмантау" түрәсенең койрыгы озын, үзе шома йонлы, аны әләктереп алу мөмкин түгел. Дәү абыйларының ишек төбенә кемнәр килгәндер тагын?!.

*Икенче кисәк тәмам.*

# ШИГЪРИЯТ



## Флера Гыйззэтуллина

### Тамгалы таллар

*Хэтер хикэясе*

Бормалы-бормалы Зэй суы:
Эзлимен, табалмыйм каз-кошым.
Таңнарда каз булып каңгыра
Давылда адашкан язмышым.
Яралы, гаугалы яшьлегем
Зиһенне, хэтерне җилгэрэ.
... Балалар су керэ, гөж килэ,
Уйнаклап дулкыннар тирбэлэ.
Үкси җил, үкерэ:—Кач моннан!—
Бүгенең узганга ялгарлар:
Бу сулар хэвефле—чоңгыллы,
Бу ярда тамгалы таллар бар.
Энэ шул талларны, ярларны
Кайгылар басканга—астыртын,
Йөрэкнең ярасы яңара,
Иңемдэ тарала пар толым.
Өстемдэ—чияле күлмэгем,
Еракта—аерылган көннэрем...
Кайгыга ялгызым күнсэм дэ,
Ялгызлык дигэнгэ күнмэдем.
Дэвасын, чарасын тапмасаң
Ялгызлык моң суза тирэнгэ...
Шушы моң йөрэккэ тигэнгэ
Мин килеп сөялдем имэнгэ.
Чакырам баламның атасын,
Көч-куэт туплыйм да бар тынга...
Тавышым саңгырау... салкынга
Куш имэн тартыша ялкында.
Э Зэйнең аргы як ярында—
Яшьлегем юлдашы Ярулла!

Чын юлдаш булсын дип теләдем,
Теләгем килмәде кабулга.
Ир белән янәшә атларга
Җай-чара булмады бернинди.
Мин аны чакырам янЫма—
Яруллам:—Куркам,—ди, килмим,—ди...

* * *

Чын-чынлап яратсаң ярыңны
Мәхәббәт—гомерлек тантана!
...Мин тиздән яшь ана булачак.
Газаплы көннәрем башлана.
Карынымда нарасый кошчыгым,
Талпына оясын тарсынып...
Яруллам—рульдә! Без—юлда!—
Бүген дә кичәге маршрут:
Бер "вахта"—бер бөтен бригада
Йөрибез, юл салып юл артлы...
...Һәммәсе йөрәктә сызлар моң:
Кызлар—ун! Егетләр—уналты!
Юл буе:—И Язмыш!... Язмыш!...—дип,
Шул кызлар, егетләр җыр суза.
Халыкның эчкерсез җырлары
Көч-кодрәт иңдерә юлчыга.
Ул көнге бу җырның дәвамын
Җырларга куштым мин аңа да.
Шул чакта боерды бригадир:
- Ку, Ярул... чокырлар санама!!!
Ярулла ярата юлларның
Турысын—таудагын, аулагын...
(Тауларның теле юк әйтергә
Шоферның йөз грамм салганын!)
...Бу юлда постлар юк, туктатып
Шоферга игътибар итәргә:
Менә без тау ягы юлларын
Үкертеп кертәбез күпергә.
Керәбез... күрәбез күпернең
Кыйшыгын, чалшайган турларын
Һәм Зәйнең аргы як ярыннан
Күпергә зур көтү тулганын...
Тулалар мәәлдәп, бәәлдәп
Сарыклар, кәҗәләр... әҗәлләр!
Дөньяны онытып, кузовта
Җыр суза Хаҗиләр, Хаҗәрләр...
Бригадир кычкыра янә дә:
— Сез нәрсә, терәлеп каттыгыз!?
Сөрлегеп җимерек торбага,
Айкала-чайкала "вахта"быз.
Күпернең төпләре шартлагач,
Иң тирән турында елганың
Күрдем мин иремнең каушаудан,
Куркудан күзләрен йомганын.
Мин калдым кабина эчендә,
Ялгызы ташланды ул суга...
Турылап... өлгерә алмадым—
Рульне мин кыссам да учыма.

Мотордан атыла газ да газ!...
Аяклар тыяр көч тапмады.
...Ачынып көтүче суктымы?—
Йөрәктә чыбыркы шартлады.
- Авабыз!!!—Бетәбез!!!—Җыр катыш
Бригада тавышы чыңлады.
Әйтерсең берьюлы өзелде
Меңләгән мандолин кыллары.

* * *

Мин килдем аңыма—тулгаклап
Һуш җуеп, юк, озак ятмадым.
Чияле күлмәгем—кара кан!...
Кызалак кабина як-ягым!
Минем һәр уйланган уемнан,
Кулымнан, буемнан кан тама:
Ярулла, шушымы егетлек,
Без көткән бәби, туй, тантана?
Ярулла—җавапсыз... Качкандыр
Көтүләр таралган болынга.
...Нарасый кошчыгым җан бирде
Көтүче егетнең кулында.
Әмма мин баламның атасын
Чакырам, чакырам бар тынга...
Тавышым саңгырау, салкынга
Кушимән тартыша ялкында.
Кешенең ачы җан газабы—
Яшенле болытка тантана.
Киләчәк бәхетнең һәр төше
Анага: —Тудыр!!!—дип чаң кага.
Чаң кага алдан ук:—Алдасаң,
Тудыра алмасаң—янырсың!
...Балаңның сулышын тоеп та
Якларлык көч тапмау—авыр соң!

* * *

Ә көтү таралды, сибелде
Исереп, шашып кан исендә.
Ул көнне үземне каргадым
Мин—исән калганым өчен дә...
Ярулла тапмады бер чара
Язмышны үзгәртер чагында—
Исәрлек, шашкынлык, мөгаен,
Ургыла аның да канында:
Аның да чәчләрен җил тарый:
- Кайда сез, егетләр, кызлар?!—дип,
Илереп суларга ул карый.
Халыкны ярдәмгә чакырып
Янә ул кычкыра каравыл—
Бу кыргый, тарихи тавышны
Ишетә шикелле бар авыл...
Минем дә имгәнгән "җан-кошым":
Язмышым шулкадәр гаугалы...

"Кан коеш" бер эзсез калмады:
Тотынган талларым тамгалы!
Тормышның башыннан соңгача
Әллә һәр эшебез хаталы?!—
Безнең хис—күз-яшьләр дәрьясы,
Бу яшьлек—хаталар ватаны...

* * *

Кайчандыр без салган яңа юл
Тузанлый "КамАЗ"лар җилендә...
Җил кулын иркәләп минем дә
Пар толым тарала иңемдә.
Шул җилләр иркендә мин күптән—
Ир белән ирексез "тол" хатын!—
Күз төбәп кай якка китсәм дә
Узганга юнәлтә юл чатым.
Ирне дә, мине дә өркетә
Шул чакта имгәнгән ихтыяр:
Кыл уртак—өндә дә, төштә дә—
Бер тормыш—упкынлы ике яр!...
Мин беләм: шөкәтсез уйлардан
Ярулла эчә дә котыла—
Чәчләрен назларга үрелсәм,
Арага болганчык су тула.
Иясен танымый, тапмыйча
Картая назларым, картая...
Газиз Зәй, җаныма ял кая?
Тормышта мин сыяр яр кайда?
Әрәмгә уздырган гомернең
Тулгагы туктамый минут та...
...Әнә шул хәвефле көн өчен
Терелэй дөрлимен мин утта.
Уфылдыйм ярсулы су сыман
Ярга Зәй дулкынын бәргәндә.
Без кергән утлар да, сулар да—
Сусаудыр ашыгыч ярдәмгә.
Сусаудыр—сафлыкка, яшьлеккә
Ярдагы бу таллык... иманлек...
— Сөям!—дип, вәгъдәләр биргәндә
Без шушы иманга сөялдек.
Без шушы талларга төбәлдек,
Яр тулып тал яфрак яргандa...
Юк иде күңелләр түрендә
Бернинди мәкер дә, ялган да...
Без кылган гөнаһлар кимерме
Үкенеп сөйләүдән хатаны?
Яшьлек—хис, күз яшьле язмыштыр...
Ул—хәтер, хаталар ватаны!

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*



## Мәхмүт Галәү

# ЯШӘСЕН ИПИ БЕЛӘН СУГАН!

Сабир белән Исмәгыйль, бүген ял итү көне булуга карамастан, бөтен көннәрен трест идарәсендәге бер җыелышта уздырдылар. Бүген анда саклык режимын тормышка ашыру, аппаратны рационализацияләштерү кебек зур мәсьәләләр каралып, шуларның берсендә Сабир төп докладчы булып, Исмәгыйль исә җыелышта секретарьлык иткән иде. Шуңа күрә дә, башка кешеләр җыелышны берничә кат ташлап чыгып, тамак ялгаштырып керсәләр дә, Сабир белән Исмәгыйльгә алай итү мөмкин булмады. Алар хәтта иркенләп бер тәмәке тартып керергә дә вакыт таба алмадылар; тәмәкене дә, тышка чыгарга ирексез булганга, йөгерә-йөгерә әбрәкәйгә барганда гына кабызып, йотлыга-йотлыга суыргаладылар да, башка "йомышлары" беткәч, яртылаш көйрәгән папиросларын утлы килеш бер почмакка бәреп, тизрәк җыелыш бүлмәсенә чаптылар. Башкалар гадәттә бирелә торган берәр стакан шикәрсез чәйне бик кәефләнеп, балкашык белән бутый-бутый тәмләп яки тәмле итәргә тырышып эчсәләр дә, Сабир белән Исмәгыйль алдына куелган стаканнар суынып бетте. Салкын чәй эчүгә караганда кайнамаган чи су эчү, ни өчендер, яхшырак кебек тоела иде. Шул сәбәпле алар җыелышның башыннан ахырына хәтле графиндагы су белән тамак чылатып, эчәк чайкап утырдылар. Җыелыш беткәннән соң да Сабир доклад буенча үзенә бирелгән сорау кәгазьләрен рәтләп маташты, Исмәгыйль беркетмәне төзәтеп язарга кирәк тапты. Алар эшләрен бетереп китәргә әзерләнгәндә, бүлмәдә һичкем калмаган, хезмәтче хатын, идән щеткасы, чиләк һәм чүпрәкләр күтәреп, бүлмәне җыйнаштырырга килә иде инде.

Урамга чыгып, салкынча саф һаваны күкрәк киереп, иркен сулап иснәгәч, алар үзләрен әллә нинди бер исемсез авырудан айный башлаган кеше шикелле тойдылар. Арка-җилкә ватылган, чатнаган, буыннар-тамырлар талган, талчыккан; күз аллары томанлы; бөтен гәүдәләре арып хәлсезләнгән, башлары тубал хәтле булып зурайган, салмакланган кебек иде. Шушылар өстенә һәр икесенең эчәкләре тартышып, эчләре авырта башлады. Үзләренең иртәдән бирле ашамаганлыкларын, чыдап булмаслык дәрәҗәдә карыннары ачканлыгын алар хәзер генә аңладылар.

—Өйгә кайтсаң да, ашны ашап бетергәннәрдер инде,—диде Сабир.— Әллә берәр ашханәгә кереп кенә ашыйсы микән?

Бу сүзне Исмәгыйль дә эләктереп алды.

—Әйдә булмаса!—диде ул.—Барыбер бездә дә аш юктыр инде.

Сабир, кесәләрен актара башлап:

— Акча җае ничегрәк икән?—диде.

Алар икесе дә үз кесәләрендә нихәтле акча барлыгын һичбер вакытта белмәүчән һәм кирәге чыккач кына кесә актарып акча санарга керешүчән кешеләр иде. Бу юлы да шулай булды. Бер фонарь баганасы төбенә туктап, үз-үзләрен тенти башладылар. Кайсыбер кесәләрне кайтарып, салындырып төшерүгә хәтле барып җитәрлек итеп актарына торгач, кечкенә кесәләренең чүпле почмакларыннан, зур кесәләренең тәмәке тузанлы төпләреннән җыйнаштыргалагач, икәүсеннән һич көтелмәгән хәтле, ягъни биш-алты сум чамасы акча чыкты.

— Һууу... монда!.. Төн буенча типтерерлек акча чыкты бит әле!—диештеләр дә, чынлап бер "типтереп", арыган организмнарын "ял иттерергә" булдылар.

— Әйдә!—диде Сабир.

— Әйдә!—диде Исмәгыйль дә.

Киттеләр дә, шуннан ерак түгел генә бер ашханәнең якты ишек төбендә ыгы-зыгы кайнашып, мыжылдап яткан тәмәке сатучы малайлар, хәерчеләр, вак сукбайлар, исерек фахишәләр арасыннан ерып үтеп, эчкә атладылар.

Алар икесе дә революция аркасында түбәннән күтәрелгән кешеләр, ягъни ярлы крестьян катлавыннан чыгып, җаваплы эшләргә тартылган—хөкүмәт учреждениеләренә җитәкче итеп куелган выдвиженецлар иде. Һәр икесе сугышка чаклы авылда батрак булып, петраудан покраугача унөч сум акча, ике кием чабата, бер кием тула оек, бер алъяпкыч бәрабәренә кулакларга хезмәт иткәннәр; сука ягайлап, тырма артыннан йөгергәннәр; яңгырлы төннәрдә, әвен базының ачы төтене эчендә күзләреннән тамчы-тамчы яшь агызып, әвен киптергәннәр; аннары соң, сугышка алынып, юеш окопларда айлар буенча эшсез ятып бет туйдырганнар; Февраль революциясеннән соң, фронттан таеп үз авылларына кайткач, революция юлында актив эшләүчегә әверелгәннәр; Октябрь революциясеннән соң, кызыл гаскәрлеккә язылып, ирекле илне капитал ялчыларыннан саклау юлында зур батырлыклар күрсәтеп, иптәшләренең ышанычларын казанганнар; шул арада аз-маз укып та өлгергәннәр; сугышлар туктагач, тагын авылга кайткач, революция эзенә ныклап басып алганнан соң, элек—үз авылларында, аннан—волость төбәгендә, соңыннан—кантон үлчәвендә һәм иң ахырдан үзәктә актив рәвештә эшләүче булып киткәннәр иде. Алар икесе дә сирәк очрала торган кешеләрдән булып, бозыклык, эчке шикелле эшләр белән бер дә чуалмыйлар; исерүнең нәрсә икәнлеген белмиләр; хәтта сыраны гына да эчеп караганнары юк иде. Шуның өчен дә алар үзләренең бу көнге "типтерү"ләре ничек буласын, ни белән башланып, нәрсә белән бетәсен үзләре дә белеп җиткермиләр; тик карыннары ачканлыгын һәм кесәләрендә биш-алты сум чамасы акчалары барлыкны гына яхшы беләләр иде.

Болар килеп кергән ашханә алай бик үк түбәннәрдән булып чыкмады. Ука әйләнәле фуражка кигән швейцар аларны ишек төбендә каршы алып, пальто якаларына ябышты да, үзләреннән сорамыйча ук чишендерергә керешге. Сабир белән Исмәгыйль карышып тормадылар. Швейцар иптәшнең кушканын эшләделәр. Чөнки бер-ике ай элек кенә бурычка алып киенгән киемнәре әле тузып өлгермәгәннәр—өс-баш чибәр: яка-галстук шикелле нәмәстәкәйләр һәммәсе дә тиешенчә урынында һәм бик үк керле дә түгел, ул яктан куркыныч юк, биткә оят килерлек, дип әйтеп булмый иде. Ботинкаларның йөзләре бөтен булып, тәпи бармаклары күренеп тормаганлыктан, калошларны салдыруга да әйбер әйтмәделәр. Швейцар иптәшнең бу чаклы тырышлык күрсәтүе мондый вак пөхтәлекләргә өйрәнмәгән Сабир белән Исмәгыйльгә әллә ниндирәк тоелса да, алар ваксынып торуны үзләре өчен килештермәделәр: "Жалованье алгач, аңарга да азрак эшләргә кирәк бит ахыры",—дип уйладылар.

Швейцар иптәш тузып, таушалып, иске киндер кыяфәтенә кергән күн портфельләрне калдырып керергә кушкан иде, ләкин инде монысына кунаклар чын карышу белән карыштылар. Чөнки бу иске һәм ямьсез портфельләрдә җитәкче органнарның яшерен боерыклары, учреждениенең эш планнары—пролетариат дәүләтенең серләре саклана, боларны исә ашханә швейцары

кулында калдыру жинаять булачак иде. Шуңа күрә дә алар, швейцарның мыскыллы карашын күрмәмешкә салынып, портфельләрен үзләре белән алачак булдылар. Швейцар аларның бүрекләрен йомарлап, пальто жине эченә төйгечләп тыкты, кунаклар кулына бер якка номер сугылган майлы катыргы кисәге тоттырып, үзе калош йөзенә акбур белән кәкре-бөкре итеп зур-зур цифрлар сызгалый калды.

Сабир белән Исмәгыйль, кечкенә көзге алдында тарак белән чәчләрен тарагандай иткәч, саплы кечкенә щетка белән мыекларны, кашларны сыпыргалагач, залга керделәр һәм яфраклары утлы папирос белән төрткәнлектән тишекләнеп-челтәрләнеп ямьсезләнгән, үзе картайган, корыган хөрмә гөле ышыгындагы кечкенә өстәл артына урнаштылар.

Байтак көткәннән соң гына, биленә ак алъяпкыч бәйләп, беләгенә ак тастымал салган бер официант килде һәм:

— Ни боерасыз?—дип сорады.

Исмәгыйль, официантка таба борылып карамыйча, эре генә итеп:

— Карточкы!—диде.

Тышкы катыргысына алтынлы язулар баскан карточка шунда гына, җыерылмалы кызыл кәгазь белән уралган гөл чүлмәгенә сөяп бастырган килеш, өстәлдә тора икән. Официант, карточканы үрелеп алып:

— Рәхим итегез!—дип, Сабирга тоттырды да үзе бераз читкәрәк тайпылды.

Сабир карточканы актаргалады. Төрле битенә тукталып, дикъкать белән тырышып укып бакты. Ләкин һичбер нәрсәгә күңелен утырта алмады.

— Монда без ашый белерлек ашларны бөтенләй пешермиләр чамасы,— диде.—Мә, син карачы әле!.. Үзебез белгән берәр нәрсә тапмассың микән?.. Карын бик ач, берәр тәмлерәк, туклыклырак аш ашыйсы иде бит!—дип карточканы Исмәгыйльгә сузды.

Һәркемгә таныш аш исемнәрен французчага, немецчага, итальянчага әйләндереп язылган аш карточкасын инде Исмәгыйль "мөталәгә" итә башлады. Сабир исә, томаны ачылып килә торган күзләрен йөртеп, залны тамаша итәргә кереште.

Залда халык бик күп булмаса да, байтак бар. Исерекләр һәм исерергә чамалап утыручылар күренми, әлегә музыка да уйнамый: шау-шу бер дә юк. Зал шуңа күрә гадәттәгедән күп тыныч, көн буенча җыелышта утырып арыган организмны чынлап та азрак ял иттерергә мөмкин кебек тоела иде.

Залны җентекләп карап бетергәннән соң, Сабирның күзләре стенаның төрле җиренә элгән, ябыштырган һәм кадаклаган игъланнарга төште. Алар арасында, кофе, какао, кефир, һәртөрле сыра һәм эчемлек игъланнары белән бергә, "Свежие раки" дип язылганнары да бар иде. Шушыларны күрү белән Сабирның йөзенә әллә нинди бер шатлык төсе чыкты, чырае ачылып китте, әллә кайчан югалткан бер кадерле әйберен тапкандай тоелды. Ул мондый рак (кысла) игъланнарын һәм ашап утыручыларны гел күреп йөргән булса да, моңарчы үзенең рак ашап караганы юк иде; әллә кайчаннан бирле шул нәрсәне бер ашап карарга теләп йөрсә дә, бер дә туры килми иде. Менә бүген аңарга үзенең шушы теләгенә ирешү мөмкин кебек күренде. Эченнән шатлануы шуның өчен иде. Ул иптәшен карточка караудан бүлдермичә чак чыдады; Исмәгыйльнең: "Бу карточкадан мин дә юньле нәрсә таба алмадым",— дип башын күтәргәнен көтеп көчкә түзде. Мондый швейцарлы һәм хөрмә гөлле ашханәдә белеп аш сайлау мәсьәләсендә иптәшенең үзеннән артык түгел икәнлегенә күзе җиткәч кенә, бик саклык белән:

— Әллә рак ашап җибәрәбезме?—диде.

— Ник, ашасак, ашыйбыз да куябыз,—диде Исмәгыйль дә.—Аның өчен мөгезле булу кирәк түгелдер, бездәй үк кешеләр ашый ич!.. Типтерергә булгач, типтерергә кирәк инде!.. Чакыр!..

Үзләреннән күз алмыйча көтеп торган официантка Сабир ияк какты. Официант бу юлы, озак көттермичә килеп җитеп, өстәлгә җәелгән ак ашъяулыкка кулындагы ак тастымалы белән, гадәте буенча, чүп себергән төсле итеп берничә кат бәргәләп алгач, өстәл алдында тукталды.

— Сездә рак бармы?—диде Исмәгыйль.

— Бар, бар!.. Бик һәйбәт. Бүген генә Иделдән тотып китерделәр.

— Ничек бирәсез?.. Дистәләпме әллә өлешләпме?

— Дистәләп!.. Берсе егерме биш тиен тора.

Официант, көлдә пешкән бәрәңге төсле булып күренгән тоньк күзләрен кунакларның әле берсенә, әле икенчесенә йөртеп, боерык көтә иде.

Сабир:

— Кыйбатрак икән, каһәр!—дип бераз икеләнсә дә, Исмәгыйль:

— Монда кергәч, кыйбат дип утырып булмый инде: ашарга кирәк ич!.. Әллә нидә бер типтерүдән зарар булыр микәнни?—дигәч, каршы килмәде.

Официантка:

— Алайса безгә рак китер!.. Һәйбәт булсын!—дип боерык бирелде.

— Ничәне китерергә кушасыз?

Кунаклар бер-берсенә карашып алдылар. Сабирның:

— Бер дистәсе җитәр бит?—дип соравына каршы Исмәгыйль:

— Ваксынып маташмыйк инде, иптәш!—диде.—Җәйләкәләрен йолкып ташлагач, гәүдәсе бармак башы хәтле генә кала торгандыр әле аның!.. Монда кереп тә ач чыгар хәлем юк, әйт егермесен!.. Типтергәч, типтерергә кирәк!.. Акча җитәрлек бит әле!—диде.

— Егермене китер!—дигән боерык булгач, официант:

— Сыраны күпме китерим?—дип сорады.

— Кирәкми!.. Без эчмибез!—диделәр.

Тастымал тоткан кеше, бераз гаҗәпләнсә дә, эндәшмәде, карышмады, кушканны эшләде; ягъни бераздан соң, шактый зур савытка салган кызыл ракларны өстәлгә китереп куйды да, ишек төбендәге урынына барып басты.

Сабир белән Исмәгыйль, үзләренең ачлыкларына һәм авызларыннан су килә башлауга карамастан, савытка кул сузмадылар, ашарга ашыкмадылар. Бәлки, әллә нәрсә көткән бер кыяфәт белән, үзара әрле-бирле сөйләнгәләп юаналар иде әле. Бераз вакыт узгач, аларның чыдамнары төкәнгән кебек күренде, борчыла башлагандай кыланып, як-якка карангалый башладылар.

Боларның официанты үз урынында ишек төбендә юк, каядыр чыккан иде. Сабир, тәмам сабырсызланып, аның кергәнен көтәргә дә теләмәде: кечкенә тоз савытын рак салган табак читенә бәргәләп шакылдатырга керешә. Нинди дер бер ачу белән яңгыраган бу тавышка берьюлы ике официант килде. Сабир, кулларын җәеп өстәлгә куйган килеш, күзләрен рак салган савытка текәп, күтәрелеп карамыйча гына:

— Кайда күмәч, ник китермисез?.. Чәнечке, пычагыгыз кайда?—диде.

Официантлар, тегесеннән битәр гаҗәпләнсәләр дә, карулашып тормадылар: кушканны эшләделәр. Берсе хәзернең эчендә чәнечке-пычаклар китерде, икенчесе бер кечкенә тәрилкә белән күмәч китереп куйды.

Кунаклар һәр икесе элек күмәчкә сузылдылар. Берәр сыныктан беразын сындырып кабып чәйни-чәйни, берәр ракны чәнечке белән эләктереп алып алларындагы кечкенә тәрилкәләргә салдылар. Җәйләкәле ракларга тегеләй-болай төрткәләп, төрлечә әйләндергәләгәннән соң, тагын як-якка карангалый башладылар. Тагын официантны чакырырга туры килде. Бу юлы аның өстәл янына ук килгәнен көтмичә:

— Серкә, борыч, гарчитса!—дип соралды.

Официантның исе китүе көчәя төшсә дә, ул: "Бәлки, болар Кытай ягыннан килгән кешеләрдер; бәлки, ракны бүтән төсле итеп ашый беләләрдер!"—дип уйлап, соралган әйберләрне китереп бирде һәм үзе, бер читкәрәк китеп, җаваплы эшчеләрнең рак ашауларын кызыксынып карарга керешә. Бу вакытта залдагы халыкның күзе Сабир белән Исмәгыйльгә төбәлеп, һәркем: "Инде ни була?.. Илдә юк әкәмәтнең ни төслесен тудыралар?"—дип караган сымак бер әсәрү белән әсәреп карап тора иде.

Үзе белмәгән әйберне ашауга килгәндә Сабир Исмәгыйльдән батыррак булып чыкты. Ул, авызындагы күмәчен чәйни-чәйни генә, пычак очы белән горчица алып, тәрилкә читенә сылады, аның өстенә тоз салды. Аннан соң, серкә савытын алып, ракның сыртына әзрәк серкә түкте, борыч сипте.

Шуннан соң тәрилкә төбендә тырпаеп яткан ракка чәнечке-пычак белән һөҗүм итте. Ләкин ракның каты тәненә чәнечке батмады, аның сөяк санын пычак кисмәде. Чәнечке белән төрткәч, рак сискәнеп сикереп киткән шикелле була, пычак белән ышкыгач, мыеклары, кыскычлары кыймылдый, тырпая: кулны кысарга яки биткә сикерергә теләгән шикелле кылана иде. Шулай булса да, ямьсез ракның озынчарак гәүдәсен кыскычтан һәм мыеклардан үтмәс пычак белән ничек кирәк алай азаплана-азаплана тазарткач, Сабир тагын тәрилкә читендәге тозлы горчицадан пычак очы белән алып азрак сөртте дә тирес корты сыман сырлы әйберне авызына озатты һәм авыз эчендә байтак әвәләп, тешләре белән кыскалап азрак изгәләгәннән соң, кире чыгарып, тәрилкәсенә салды:

— Бер дә ит заты юк, бигрәк арыклары эләкте чамасы,—дип савытта яткан ракларның башкасына үрелде.

Исмәгыйль дә Сабирдан калышмады, ул да, Сабирны имам итеп, аңарга иярде. Ул эшләгән эшләрнең барысын да эшләде һәм, горчицаны күбрәк тондырганлыктан булса кирәк, ракның изелгән-яньчелгән гәүдәсен кире тәрилкәгә төкергәннән соң, тастымал белән телен сөртеп алды.

Нәкъ шушы вакытта залның төрле почмагыннан кычкырып көлгән тавышлар ишетелде. Якын-тирәдә утыручылар да үзара күзгә-күз карашып көлешүдән үзләрен тыя алмадылар, һәм алар да үзләрен нәрсәдән көлгәннәрен яшерә алмаслык дәрәҗәгә җитә язганнар иде инде.

Ләкин рак ашаучылар, һичбер нәрсәгә илтифат итмичә, үз эшләрендә дәвам иттеләр. Халыкның көлүен үз хисапларына алсалар да, тастымал белән тел сөртүдәндер, дип уйлап, итсез ракларны чәнечке-пычак белән ботарлап, серкәгә һәм горчицага буйый бирделәр, изеп-яньчеп тәрилкәгә төкерә бардылар. Зур савыттагы ракларның яртысы Сабир белән Исмәгыйль авызына кереп чыкты, калган яртысы да чәнечке-пычак белән имгәнеп калды, алар да горчицага буялдылар. Ач кунаклар исә һаман актарыналар иде. Ләкин, нихәтле актарынсалар да, раклар һәммәсе дә бертөсле арык, бердәй итсез—каты сөяктән генә гыйбарәт булып чыктылар. Шушынар тәмам ышанып житкәч, тагын официантны чакырмыйча булмады. Бу юлы инде аны Сабир белән Исмәгыйль икесе ике яктан ачуланып әрләргә керештеләр.

“Ачның ачуы яман!”—диләр бит әле. Менә монда да нәкъ шулай булды. Официантның:

— Сез үзегез гаепле, иптәшләр!.. Ракның ите булмый!..—дигән сүзләрен алар ишетмәделәр, тыңламадылар.

— Ни өчен болай алдыйсыз, итсез рак үләксәләрен кыйбат сатасыз?

— Ышанып ашарга керүчеләрне алдар өчен ашханә ачтыгызмыни?

— Без шуның өчен сугыштыкмыни?—дигән кебек сүзләр, итле рак таптыручы кунаклар авызыннан бер-бер артлы атылып чыгып, зур залда көчле булып яңгырадылар.

Тавыш шактый зурайды, ашханә мөдире килде, буфетчы да тавыш чыгаручылар өстәленә якынлашты. Официантлар Сабир белән Исмәгыйльне сарып алдылар. Ераграк өстәлләр алдында утыручы кунаклар да, аякка басып, тамаша итәргә керешкәннәр иде.

Әллә нихәтле акча түләргә мәҗбүр булып та, ач калган кунаклар куптарган бу дауның нәрсә белән бетәсен әйтеп булмаслык хәлгә кергәндә генә, шундагы халык арасында Сабир белән Исмәгыйльнең танышлары табылып, шулар арага керү аркасында гына мәсьәлә җайланды. Танышларының берсе аларга:

— Сез үзегез гаепле, иптәшләр!—диде.—Ракның ите булмый, аны тамак туйдыру өчен ашамыйлар, монда официантның да, ашханә идарәсенең дә гаебе юк, гаеп үзегездә... Белмәгән әйберләрегезне алдырасы түгел иде,—диде.

Сабир белән Исмәгыйль оялып тыңдылар, шул сәбәптән генә милиционер чакырылмыйча калды. Оялуларыннан рак төсле булып кызарган кунаклар, ашалмаган раклар белән берәр генә кабарлыклары тешләнеп калган күмәч кисәкләре өчен биш сум егерме тиен акча түләп, матур ашханәдән чыгып киттеләр. Акчаларының калган кадәресен дә ука әйләнәле фуражка кигән

швейцар учына төртергә туры килде.

Тагын саф һавага чыгып, карын ачлыгы тагын да ныграк сизелгәч, Сабир салмак кына итеп:

— Рак ашау дигән нәрсә Деникин армиясе белән сугышу кебек кенә җинел эш түгел икән шул!.. Ата-бабаң ашамаган нәрсәне ашыйм дип йөргәч, менә шулай була ул,—диде.

Исмәгыйльнең:

— Ул нәрсәнең рәтен син беләсеңдер,—диюенә ул:

— Чортым белсенмени аны!—дип куйды һәм:—Моннан соң сабак булыр үзебезгә,—дип өстәде.

Иптәшләр күрешеп аерылыштылар да, өйләренә кайткач суган белән икмәк ашап, тавыш-тынсыз гына йокларга яттылар. Шул кичтә алар һәр икесе, күз йомган саен алларында зур савыт тулы тырпайган, ямьсез раклар күреп, йокыга китә алмыйча байтак вакыт азапланганнар иде.

Шушы вакыйгадан соң алар ашханә кебек җирләргә бөтенләй кермәс булдылар. Ничаклы ачыксалар да, җыелышларда озак утырып, вакытында аш ашамыйча калырга туры килсә дә, форсат табылу белән туп-туры өйгә кайтып, шунда табылган азык белән канәгатьләнүчән булып киттеләр, һич булмаганда, икмәк белән суган ашап тукландылар.

— Яшәсен ипи белән суган!—дигән сүзләр алар өчен тирән мәгънәле дөрес тәгъбирләрнең берсе булып әверелде.

ИСКӘРМӘ

Мәхмүт Галәү ( 1886—1938) хәзерге укучыларга бик таныш түгел. Аның әсәрләре чирек гасыр чамасы басылмады, ә бу хәтле бушлык язучыны онытырырга да җитәдер. Ләкин М. Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани) онытылмады, илленче еллар ахырында аның башта "Болганчык еллар" һәм "Мөһаҗирләр" ("Муть", "Мухаджиры") романнары нәшер ителде, аннары бу әсәрләр русчадан Яхъя Халитов һәм Рәис Даутов тәрҗемәсендә бер китап булып чыкты, соңыннан аерым-аерым да басылдылар. Тәрҗемә ителүнең сәбәбе—әлеге романнарның төп нөсхәләре сакланмауда. Мондый хәл исә М. Галәү иҗаты хәзинәсе язмышына билгеле дәрәҗәдә хас, аның "Кабылсай" романы да, татарча басылмыйча, русчага тәрҗемә ителеп чыккан.

Әйе, М. Галәү әсәрләренең язмышлары катлаулы. Хәер, аның иҗаты да катлаулы-бормалы лабаса. Әдәбиятыбызның күренекле вәкиле Мәхмүт Галәү кайбер әсәрләрендә (аның романнары, хикәяләре, пьесалары, публицистик мәкаләләре ишле үк) заманынча "кызарып" китүләргә тартымлык очраштырса да, ул тормыш чынбарлыгын тасвирлауда асылда реалист булып кала.

Журналның "Татар хикәяләре хәзинәсеннән" бүлегенә Мәхмүт Галәүнең әсәрен сайлаганда, без аның дөреслеккә тулаем тугры булуын раслардай хикәясенә тукталдык. Хәер, укучы, әсәрне укыганда, җыелышта "ботка пешерү"не, "кухаркалар"ның түрә кәнәфиенә менүләрен аермачык күрердер. "Яшәсен ипи белән суган!" хикәясе беренче тапкыр язучының "Төеннәр" исемле җыентыгына (1928) кергән, аннары әдипнең тууына йөз ел тулу уңаеннан Татарстан китап нәшрияты шул ук исемдә чыгарган тупланмасында да бар. Бу басмага хикәя Рәис Даутов төзегән әнә шул соңгы китаптан алынды.

Әсәрне матбугатка әзерләүдә булышулары өчен, галим Равил Әмирханга һәм әдәбиятыбыз хәзинәсен саклый белүче Рәис Даутовка рәхмәтлебез.

Рәсемдә сез Мәхмүт Галәүнең "Чүлмәк тулгач" исемле китабының (1929) тышлыгын күрәсез. Анда, "Канлы тамгалар" атлы тарихи романнан өземтәләр, дигән аңлатма бар, ягъни китапны "Чүлмәк тулгач" һәм "Тоткын кунаклар" исемле өекләр тәшкил итә. Шунысын да искәртик, рәсемгә алынган китапның тышлыгында авторның аны Галимҗан Нигъмәтигә бүләк итүе язылган.

*Әсәрне журналда бастыруга*
**Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде.*

*Дуслар җыры*

# ТУКАЙЛАР, БАБИЧЛАР ЮЛЫННАН

*Хатирәләргә бирелсәң, әллә нәрсәләр искә төшә. Башкортның Равил Бикбаев дигән азамат шагыйрен кайчаннан беләм соң мин? 30 елдан артык икән. Хәтеремдә: 1968 елның 28 июле. Борынгы София шәһәре. Бөтендөнья яшьләренең IX фестивале ачылу көне. Халык мәш килә, ыгы-зыгы. Болгар иленә бөтендөнья кыйтгаларыннан бөтен яшь-җилкенчәк җыелган диярсең. Безне Авала тавы ягындагы бер мәктәп-интернатка урнаштырдылар. Фестивальнең тантаналы ачылышына әзерләнәбез.*

*Иркен юыну бүлмәсендә кара тутлы, чибәр бер егет, сөртенгән сөлгесен иңенә салган килеш, миңа озак кына карап-карап торды да, "нихәл, адаш?" дип кочаклап алды. Менә шулай танышкан идем мин Равил белән. (Андый җирдә— агы, карасы, сарысы дигәндәй— әллә нинди ыру-расалар тугланган җирдә үз телеңдә сөйләшкән кешене очрату уен эш түгел ул!). Дөрес, аңарчы да ишетеп, газет-журналларда бер-беребезнең шигырьләрен, сурәтләрен күргән булган инде, әлбәттә. Ни дисәң дә, без бит инде ул заманда Идел-Урал шигърияте͏ндә үзебезчә ат уйната башлаган егетләр... Без байтак җирләрдә йөрдек Болгариядә, күп кешеләр күрдек, болгар коньягын уртлый-уртлый байтак серләр дә сөйләштек... Искә төшерү дә татлы...*

*Бу айда Равил Төхфәт улы Бикбаевка 60 яшь тула. Теге чакта аңа 30 булган икән. Тумышы белән Оренбург өлкәсенең Покров районы Кунакбай авылыннан. Заманында шул яклардан М.Буранґулов, С.Агиш, Г.Амантай кебек күренекле кешеләр чыккан. Гаярь кыяфәте, ныклыгы һәм тәвәккәллегенә карап, башкорт казаклары ыруыннан түгел микән ул дип тә уйлап куя идем. Равил Бикбаев— галим шагыйрь. Бездә шагыйрьлеге дә, галимлеге дә мондый югары кимәлгә тәңгәл килгән шәхес юк та бугай. Аның хәзерге башкорт поэзиясе буенча төпле хезмәтләре— башкорт әдәбият гыйлеменең казанышлары саналырга хаклы. Башкортостанның халык шагыйре, Салават Юлаев премиясе лауреаты, филология фәннәре докторы, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе... Басылып чыккан китаплары да утызлап бардыр. Чөнки кырык еллап актив иҗат иткән Равил. Аның "Вокзал", "Карвансарай" кебек поэмалары 60 еллар башында ук киң билгеле иде инде. Соңрак "Тамгалы ук", "Җыр", "Күк әрем", "Система", "Ностальгия", "Сусадым— сулар бирегез", "Халкыма хат" һ.б. Поэмаларны безнең Илдар Юзеев кебек күп язды ул. Гомумән, аның иҗаты сокландыра да, уйландыра да. Һәрхәлдә, тирән һәм аңлаешлы фәлсәфә белән сугарылган шигырьләре, поэмалары үзләренең камиллеге, вакыйгалар тыгызлыгы җәһәтеннән аерылып торалар. Укыйсың да, бу Равил стиле, адаш әсәрләре дип горурланып куясың. Шагыйрьнең гомерлек темасы— үз халкының тарихын барлау, замандашларда— үткән белән бүгенгенең чагылышын ачыкларга омтылу. Аны Тукайлар, Бабичлар язмышы белән бергә бүгенге иҗатчыларның җәмгыятьтә кылган гамәлләре нык уйландыра, борчый. Шәехзадә Бабичка багышланган гыйльми хезмәтләре аерым бер казаныш саналырлык. Үткән ел аның Уфада "Шагыйрь сүзе— шагыйрь намусы" дигән күләмле китабы чыкты. Әдәбият үсеше турында уйланулар, төрле буын шагыйрь һәм язучыларның (китапта Г.Тукай, Х.Туфан турында да җитди мәкаләләр бар) иҗат портретлары һәм тәнкыйть мәкаләләре тупланган бу китапның исемен Равил Бикбаев дигән олуг шагыйрьнең иҗат кредосы дип уйлыйм мин.*

*Әйе, Равил туган, шактый гомер яшәгәнсең, күп хезмәт тудыргансың икән. Софиядә очрашканнан соң, без кимендә елына бер тапкыр очраша торганбыздыр. Очрашкан саен теге яки бу формада туган тел, туган әдәбият, ахыр килеп, халыкларыбыз язмышы турында сүз булмый калмый. Идел-Урал язмышы, уртак халыкларыбыз язмышы... Син хәзер шушы уртак зур пространствода үз фикерен, үз тавышын ишеттерерлек тали*

*шәхес (Башкортстан милләтләр ягыннан катлаулы республика, иминлек, татулык, рухи уртаклык дигәндә синең сүзең олы сүз булып яңгырый дип уйлыйм мин).*

*Берничә ел элек Казанда да бер томлык китабың чыккан иде. Аның исеме— "Сак-Сок". "Башкорт белән татар Сак-Сок кебек игезәкләр, алар мәңге бер-берсен эзләп, сагынып яшиләр..." дигәнсең ул китапта. Бик хак сүзләр. Сагыныша-сагыныша бергә яшәсеннәр, дип өстисе килә. Бу хис-тойгыны без тудырмаган, гомер бакый килгән туганлык ул. Юлайлар заманында да булган (бәлки, көчлерәк тә) ул, Тукайлар заманында да, безнең заманда да. Безгә бу изге эстафетаны балаларыбызга гына тапшырасы кала.*

*"Ни хәл, адаш?" "Исәндәме?" дип, XXI гасырның да фәлән дистә елларында уңышларыбыз өчен бергә-бергә сөенергә насыйп булсын!*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*19 октябрь 1998.*



# Равил Бикбаев

башкорт шагыйре

**ШИГЫРЬЛӘР**

## Җыр башы

Ак кәгазь битеннән элек
Ак карга төшә җырым.
Аланнарда җиләк булып,
Сутланып пешә җырым.

Язам таллар яфрагына,
Кошларның канатына,
Сак киекләр сукмагына,
Кызган юллар чатына.

Уйларым, таулардан ашып,
Кымыздай тора ташып.
Эш бүлмәм— Башкортстаным,
Өстәлем— Урал ташы.

Язам ак таңнар битенә,
Яшеннәр камчысына,
Уйчан эңгер куенына,
Ап-ак чык тамчысына.

Язам илләрне илләргә
Тоташтырган юлларга.
Сабыйларның карашыннан
Бөркелгән очкыннарга.

Уйларым, таулардан ашып,
Кымыздай тора ташып.
Эш бүлмәм— Башкортстаным,
Өстәлем—Урал ташы.

## Бер сүз

Бер сүз беләм. Адашканда юлларымны
Яктыртамын шул сүз белән.
Шул сүз белән, авырны да җиңел күреп,
Мин тауларга җилеп менәм.

Бер сүз беләм. Бабайларның васыяте
Шушы сүзгә сыйган сымак.
Гасырларның якты нурын, яхшы җырын
Ул үзенә җыйган сынап.

Башка сүзләр нур алырга җыелганнар
Шушы сүзнең тирәсенә.
Охшатырмын һәрчак аны телемдәге
Бар сүзләрнең йөрәгенә.

Ничәмә кат асылса да, атылса да,
Сатылмаган һич бер көчкә.
Яу купканда, сафлар буйлап, юлбашчыдай
Очтан-очка
Бу сүз очкан—
Башкортостан!

* * *

*Бер уйлаем Бохар китәргә,*
*Бер уйлаем донья котәргә.*

Халык җырыннан

Бохараның зәңгәр гөмбәзләре—
Сузылып барган кәрван зынҗыры,
Офыкларга аккан мамык кары—
Арыкларның таңгы моң-җыры...

Бакканым юк әле ул гөмбәзгә,
Очраткан юк әле ул таңны.
Шул хыялым гына балачактан
Төшләремә кереп буталды.

Төшләремдә ачык тәрәзләргә
Бәхет кошы сайрый гел кунып,
Һәр таң саен йортым нигезенә
Чайпалгандай диңгез дулкыны.

Бер күрергә, диеп, ят якларның
Таң нурына коеныр чакларын,
Талпынам да,
Тагын донья басып,
Тезгеннәрен салам атларның.

Күңелемнән шул мәл эшкә күмелеп,
Биттән әче тирем сыгыла.
Тик тагы да миңа тагылалар
Вак мәшәкать, ыгы-зыгылар.

Хыял гына ваклыклардан әрчи,
Әрчегәндәй җирне кар-боздан.
Шулчак таулар аша илләр күрәм,
Түшәм аша күрәм йолдызлар.

Сине эзләп җирдә яши икән
Син күрмәгән ерак матурлык,
Шуны уйлап, төннәр йоклый алмый,
Йолдызларга карап ятырлык.

## Тукай

Яз килгәнсең җиргә.
Яз көткәнсең.
Яз киткәнсең.
Язны сагынып.
Агыйделдә йөзә яз кояшы,
Дулкыннардан күзең чагылыр.

Күтәрелә тагын күк үләннәр,
Агыйделгә төшкән битләүдә.
Безгә килгәч, сабый үләннәрне
Кочаклагансың бит иң тәүдә.

Үләннәргә кояш нуры белән
Түгелгәндә моңы курайның,
Яшь үләндәй сабый чагың кайткан
Кырларыннан җырлы Кырлайның.

Идел тугаеннан колын кебек
Чабып үткән ерак узганнар.
Бишегеңне кара давыл йотты,
Син кояшка кулың сузганда.

Туган җирнең бер ятиме итеп
Мөһер баскач сиңа заманың,
Ятлар тупсасында калтыранып
Бозга катып туңды табаның.

Тик талпындың син таңнарга һаман,
Табаныңны боздан кубарып.
Шул бозларда янды күмер кебек
Юлларыңның канлы таплары.

Күшектең дә илнең күз яшендә,
Кояшында илнең кызындың.
Яшен ташы булып көйдерден син
Ил йөрәген тырнар козгынны.

...Агыйделдә тагын яз кояшы,
Кавышкан чак җирем күк белән.
Тукай кочаклаган туфрагымнан
Күтәрелә күкрәп яшь үлән.

* * *

*"...Без киттек. Башкалар килер".*

Казан Кремлендәге язулардан

Кайный Казан,
Бер гаме юк
Гашыйклар дөньясында.
Сөю хатлары укыймын
Кремль коймасында.

Таштан сыгыла кешенең
Елаганы, көлгәне:
"Мин сине өзелеп көттем,
Нигә килмәдең, җаным?"

Учка йомып йөрәк-кузны
Бу сүзләрне кем сызды,
"Синең эзләреңә басып,
Мин моннан синсез уздым".

Кайчан тугандыр бу гадәт,
Бозылмаган тик әдәп,
Минем егет кебек ярсып
Торуым гына гаҗәп.

Сәер дә соң... Давыл тынып,
Туармы бу тын көнем?
Мин киттем. Башкалар килер,
Башка йөрәк җилкенер.
Тик кайчан басылыр минем
Егеттәй җилкенгәнем?
Мине һичкем көтми монда,
Тик ник чыңлый колагымда:
Нигә килмәдең, җаным?
Нигә килмәдең, җаным?

## Снежана

Урамында Софияның,
Сусап калып, булдым хәйран:
Су сорасам, болгар кызы
Суза миңа салкын әйрән.
Кызның кыйгач кашларына
Карамаска җаным кыймый.
"Снежана!"—
Бер җыр булып
Колагымда исеме чыңлый.
Сүз тимәсен исеменә,
Күз тимәсен буй-сынына.

**Болгар кызы биргән әйрән**
**Ялкын сипте сусыныма.**
**Снежана! Снежана!**
**Бу сусавым бетмәс инде.**
**Табан көйгән эссе көнне**
**Йөрәгемә килеп инде**
**Куз шикелле кар бөртеге.**

* * *

**Дөнья нинди иркен!**
**Киңлекләрен**
**Уйда иңләп-буйлап**
**Чак кайтырлык.**
**Һималайлар сыйган бу дөньяга**
**Бер кәрлә җан сыймый.**
**Шак катырлык!**

* * *

**Үкендерә һаман ихлас күреп**
**Эч серемне сиңа чишкәнем.**
**Белгән булсам иде күңелеңнең**
**Капкын кебек ачык икәнен...**

* * *

*Чит илдә солтан булганчы,*
*Үз илеңдә олтан бул.*

**Борынгы сүз**

**Чит илләрдә солтан булмам,**
**Ләкин**
**Үз илемдә олтан буласым юк.**
**Барысына түзгән олтан булмам.**
**Илкәемне имгән,**
**Илкәемне изгән**
**Түрә табанында олтан булмам.**

**Олтан булмаганда горур бабам,**
**Олтан булырмени оныклары?**
**Күндәм олтан булып тапталганны**
**Гарьлегеннән җир чүплеккә бәрер.**

**Ирмен дигән ирме олтан булыр?**
**Чит илләрдә солтан булганчы ир,**
**Үз илендә олтан булганчы ир**
**Ил күкрәген саклар калкан булыр.**

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Флүс Латыйфи

# ЧИСТАЕНДА ЧИСТАРЫНДЫК, ТУАПСЕДА ТУПЛАНДЫК...

ЭССЕ

## Сүз җиме урынына

Фәннең теге яки бу өлкәсе белән кызыксынган, иҗади фикерләве белән аерылып торган балаларны ачыклау, бер-берсе белән таныштыру, табигать тарафыннан салынган әнә шул сәләт оеткысын тагын да үстерү, яшьләрне халкыбызның киләчәге хакына фәнни иҗатка тарту максатында моннан нәкъ биш ел элек балаларның "Сәләт" исемле җәйге компьютер лагере оештырылган иде. Казан дәүләт университетының бер төркем җанатар-энтузиастлары башлап җибәргән бу эш балалар күңеленә шул кадәр хуш килде ки, озакламый җәйге лагерь ел әйләнәсендә эшли торган "Сәләт" клубына әверелде һәм инде 1997 елда татар яшьләренең иҗтимагый "Сәләт" фонды буларак яңа эшчәнлек рәвешен тапты.

Компьютер лагере дип аталса да, җәйге аланда (аны балалар шулай дип атый) кибернетика һәм информатика сабаклары белән бергә, фәннең башка бик күп тармаклары буенча мавыктыргыч дәресләр үткәрелә. Һәм, табигый ки, иң беренче чиратта төп игътибар туган телне өйрәнүгә, әдәби телдә аралашу, сөйләшүне камилләштерүгә юнәлдерелә. Шулай булу очраклы хәл түгел, чөнки аланга балалар Татарстаннан гына түгел, ә бәлки татарлар тупланып яши торган Чувашстан, Мордовия, Удмуртия, һәм Башкортостаннан, Самара, Ульян, Пермь, Нижгар, Оренбург, Төмән өлкәләреннән, башка төбәкләрдән җыела. Узган ел Австралиядә яшәүче бер төркем татар яшьләре кунак булып киткән иде. Ә быел аннан унөч яшьлек Шәмсия исемле кыз бала аланга укырга һәм ял итәргә дип махсус килде.

Балалар шулай ук логика, тарих, психология, этика, эстетика, инглиз теле, татар дөньясы һәм татар әдәбияты, музыка һәм фольклор, математика, кызыклы механика кебек дәресләрдә дә бик теләп катнашалар. Хәер, дәрес дип аталса да, алар ялыктыргыч түгел, урман аланында, учак янында, су буенда яисә җәйге чатырда узган күнегүләр теге яки бу биремне ятлау, нинди дер өй эшләре башкарып килү кебек мәҗбүри шартларны күздә тотмый, киресенчә, фикер чарлау, хыялга бирелү, телгә салыну кебек уен-чынбарлык рәвешендә бара. Ә балачагында кайсы гына бала хыял канатында очмаган да үзен теге яки бу тармакта эшләүче нинди дер олы белгеч итеп күз алдына китереп татлы мизгелләр кичермәгән икән. Монда бер-береңнең сәер сыйфатларыннан көлемсерәү, мыскыллауга охшаш тәкәбберлекнең эзе дә юк. Киресенчә, хыялың никадәр баерак, фикерләвең никадәр гайре табигый икән, шулкадәр яхшырак та әле. Чөнки укытучылар үзләре дә сәлкешләр белән (бу сүзнең

мәгънәсен соңрак аңлатырмын) бергә әйтерсең лә бала чакларына кире кайталар, алар белән бергә уйлыйлар, уйныйлар, фикер үткенлегендә, зиһен йөгереклегендә ярышалар.

Укытучылары да кемнәр бит әле! Араларында күренекле галим, тарихчы академик Әзһәр Мөхәммәдиев, ике тапкыр фән докторы, профессор Рәис Бохараев, танылган композитор Мәсгудә Шәмсетдинова, дәүләт эшлеклеләре, язучылар, шагыйрьләр, профессорлар һәм доцентлар...

Инглиз теле дәресләре исә Америкадан яисә Англиядән килгән студент яшьләр, педагоглар катнашында уза. Балалар белән очрашуга күренекле артистлар еш килә. Кыскасы, аланда узган көннәр яшьләр күңелендә мәңгелеккә уелып кала торган хатирәле сәхифәләр алар.

Инде "сәлкеш" сүзенә аңлатма бирергә дә вакыт җиткәндер. Хикмәт шунда ки, аланда ел саен "Туган тел бәйгесе" үткәрү гадәткә керде. Әнә шундый бәйгеләрнең берсендә балаларга "Сәләт" аланына бәйле яңа сүзләр уйлап табарга тәкъдим ителгән иде. Сәлкеш сүзе шунда туды да инде. Сәлкеш ул—"сәләтле кеше" дигәнне аңлата. Ә алар белән җитәкчелек итүчеләр, ягъни—укытучылар, вожатыйлар, лагерь башлыклары—"җитәкбашлар" исемен алды. Бәйгедә һәм бәйгедән соң да әле балалар бик күп яңа исемнәр тәкъдим иттеләр һәм алар аланда кулланышка кереп тә китте. Әйтик, шахмат уенын аңлату өчен нишләп "шаһ уены" сүзен кайтармаска, чөнки борынгы заманда татарда ул шулай дип аталган, футбол нишләп "аяк тубы" булмаска тиеш ди әле?! Шулай итеп, шахмат чемпионы "шаһ батыры"на, баскетбол "кәрзин тубы"на, очко яки балл дигәнебез "тәңкә"гә ("Сәләт"нең Яшел Үзән филиалында быел очко урынына "сәлтин" сүзе куллана башлаганнар), ярыш судьялары казыйга әйләнде. Быел исә аланда тагын бер яңа сүз туды: вожатый урынына борын заманнан килгән әйдәман сүзе кайтарылды. Әйдәман—әйдәп баручы, алга өндәүче дигән мәгънәсендә кулланылган ич. Хәер, язмамда сәлкешләр тәкъдим иткән барлык сүзләрне китерү мөмкин дә түгел. Алар бик күп. Байтагы безнең өчен шактый яңа булган компьютер технологияләре өлкәсенә карый. Ничек кенә булмасын, балалар һәм яшьләр тел чисталыгын саклау, яңа төшенчәләрне белдерү өчен сүзләрне үзебезнең туган тел мөмкинлекләре аша ясау, борынгы тәгъбирләрне кайтару, киң кулланышка кертү кирәклеген аңлыйлар һәм шушы өлкәдә көчләрен сынап та карыйлар. Монысы иң куанычлысы. Кем белә, бәлки алар тәкъдим иткән яңа сүзләр туган телебездә тамыр җибәрер, ныгып та калыр әле. Яңа төшенчәләр белән бергә яңа сүзләрнең керүе, урнашуы гадәти хәл булган кебек, телгә уңайсыз чит тел сүзләрен туган тел казанында кайнатып үзләштерү дә табигый күренеш ич.

Үзеннән-үзе аңлашыла ки, сәлкешләр белән эшләү, дәресләр алып бару өчен гадәти мәктәпләрдәгедән аерылып торган, нәкъ менә сәләтле балаларга тәгаенләнгән аерым дәреслекләр, кулланмалар, китаплар да кирәк. Шул ихтыяҗны канәгатьләндерүне күздә тотып, яшьләрнең иҗтимагый "Сәләт" фонды хәзер шундый китаплар да чыгара башлады, Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында теркәлеп, нәшрият эшчәнлегенә лицензия алды. Быел, мәсәлән, Казан дәүләт университеты доцентлары Лениза Ризванова белән Әлфия Йосыпованың "Сәләт" аланында татар теле, Әлмәт татар гимназиясе укытучысы Рәдис Кәбировның логика укыту буенча үткәрелгән иң кызыклы дәресләре "Сәләт" дәресләре" сериясендә бер мең данә тираж белән аерым китап итеп чыгарылды. Ел азагына хәтле университет доценты Әнис Галимҗановның "Математик анализга кереш", тәҗрибәле укытучы Фәнил Таймасовның "Математика нигезләре", университет укытучыларының компьютерда эшләү тәҗрибәсен яктырткан "Информатика" китаплары да дөнья күрәчәк. Шунысы әһәмиятле, югары уку йортларында алып барылган дәресләргә нигезләнгән бу китаплар барысы да татар телендә. Һәм ул дәресләр университетта һәм педагогия университетында татар телендә үткәрелә дә. Болардан тыш композитор Мәсгудә Шәмсетдинованың балалар һәм яшьләр өчен язган җырларыннан төзелгән "Әй, дәрья, дәрья" исемле җыентыгын, ял итү һәм күңел ачу кичәләре оештыру тәҗрибәсеннән "Ял итәбез "Сәләт"тә" дигән методик ярдәмлек һәм башка кулланмалар, әсбаплар чыгару күздә тотыла.

Инде әйткәнебезчә, "Сәләт" фонды һәм клубы ел буе эшләсә дә, аның киң колач белән канат җәйгән чоры җәй айларына туры килә. Беренче тапкыр "Сәләт"

аланы 1994 елда Арчада үткәрелгән иде. Шуннан бирле ул күчмә җәйге алан дип атала. Аннан соң аланның чираттагылары Яшел Үзән шәһәрендә, Түбән Камада, Әлмәттә һәм быел инде Чистай шәһәрендә узды. Быелгы эшчәнлекнең исә тагын бер үзенчәлеге бар: сәлкешләр арасыннан да иң сәләтлеләрен сайлап "Сәләт" фонды, республика мәгариф министрлыгы, балалар һәм яшьләр белән эшләү комитеты, республика экология фонды, шәһәр мәгариф идарәсе алтмыш баланы Кара диңгез буена, Туапсе шәһәренә ял итәргә җибәрде.

"Татар дөньясы" һәм "Татар әдәбияты" дәресләре укытучысы сыйфатында миңа да җәйге алан эшендә даими катнашырга туры килә. Татарның акыллы, тәрбияле, сөйкемле, итагатьле балалары, яшьләре белән аралашудан алган тәэсирләр, мөгаен, гомерем буе күңелемдә якты бер истәлек-хатирә булып сакланыр. Ул аланнардан рухым баеп, җаным сафланып, яктырып кайта. Онытылмаслык сәхифәләр инде берничә язмамда чагылыш тапкан иде. Кызыксынган укучы аларны "Уяну" исемле китаптан *("Сәләт" китапханәсе нәшрияты, 1998, Казан)*, "Татарстан" журналының 1995 елгы 9-10 һәм 1996 елгы 9 саннарыннан укый ала.

Быел да миңа балалар белән бергә Чистайда һәм Туапседа булырга туры килде. Эссе рәвешендә язылган бу парчалар әнә шул истәлекле көннәр хакында.

## Юлда уйланулар

Бу вакыйгалардан соң инде ярты елга якын вакыт узды, әмма алар хәтергә килгәндә җанымны тетрәткән әчке бер дулкынланудан айный алмыйм. Күңелдә аңлап, тоемлап бетергесез хисләр өермәсе кузгала: кайчагында икеләнәм, кайчагында ул хис шом белән алышына, шул ук вакытта сокланам һәм горурланам да.

Чистайдагы лагерьдан без, автобусларга төялеп, өченче июльдә чыгып киттек. Алда—Биләр. Алда—борынгы бабаларыбызның тәүге башкаласы, кайчандыр дөньяның барлык кыйтгаларыннан килгән сәүдә кәрваннары, ярминкәләр гөрләп торган, һөнәрчелек, кәсеп-кәсебә, әдәбият һәм мәдәният шаулап чәчәк аткан җир. Заманында Көнчыгыш Европада иң зур калаларның берсе булган, халык саны һәм билгән мәйданы белән Парижларны, Лондоннарны ике-өч мәртәбә узып киткән бөек башкала—Биләр шәһәре хәрабәләре... Хәрабәләрдән ерак та түгел, кимсетү-кыерсыту, тыю һәм эзәрлекләүләргә карамастан, бүгенге көнгәчә кан-кардәшләребез изге санаучы Хуҗалар тавы һәм Изгеләр чишмәсе...

Профессор Альфред Халиков үзенең "Татарский народ и его предки" китабында язганча, "Идел Болгарының башкаласы Бөек Шәһәр дип атала һәм ул Болгарның иң зур шәһәрләреннән берсе була. 922 елда нигез салынып, 1236 елда монгол яулары тарафыннан һәлак ителгән бу шәһәрнең археологик калдыклары Иделгә коючы Чирмешән елгасының сул ярында—Биләр авылы янында.

Кала елгага таба авыша төшкән чагыштырмача яссы җирлектә урнашкан булган. Елга аръягындагы гаҗәеп матур тауда—болгарларның изге җире—"Җаушир" дип йөртелгән корбан чалу урыны. Аның янында гына тау итәгеннән ургылып куәтле чишмә агып чыга.

Кирпечтән, акташтан һәм агачтан салынган зур биналардан гыйбарәт шәһәр, бигрәк тә аның эчке өлеше, мөсафирларны таң калдыра торган булган. Заманында боларны үз күзе белән күрдем дип раслаучы Джевалики бу хакта менә ничек язып калдырган: "Моның корылмаларында Рум корылмалары белән охшашлык бар. Болар бөек халык. Бу—бөек шәһәр".

Еллар-гасырлар үткән, чорлар-дәверләр алышынган, әмма халкыбыз моннан мең еллар элеккечә, үзенең борынгы башкаласын, аның изге чишмәсен онытмаган. Риваятьләр белән өретелгән бу җирләргә ел әйләнәсендә ил сукмагы өзелми. Киләләр, иң изге теләкләрен әйтеп, аларның чынга ашуын юрап, теләкләрен дога рәвешенә кертеп, тау башындагы агач ботакларына кульяулыклар, чүпрәк кисәкләре бәйләп

калдыралар. Мәҗүсилек заманыннан ук килүче бу йолаларның әлегәчә дәвам итүе халкыбызның гореф-гадәтен, үз әхлагын, дөньяга үз карашын үтә бер үҗәтлек, тотрыклык белән сакларга омтылуы турында сөйли. Һәм бу, табигый ки, күңелләрдә эчке бер горурлык уята торган хасият тәдер әле. Татар гына түгел, хәзер инде бу якларда яшәүче урысы да, чуашы-марийы да тау янына килеп дога кылуны изге бер гамәл саный.

Республикада колач җәя барган "Сәләт" хәрәкәтенең биш еллыгына багышланган җыен бәйрәме—фестивальнең нәкъ менә монда—борынгы башкалабыз хәрабәләре янында үткәрелүендә эчке бер символик мәгънә дә ята. Балаларыбыз, бүгенге яшьләребез халкыбызның ерак үткәндәге бөеклеге, аның мәгърур тарихы белән якыннан танышырга, аны белергә һәм хөрмәт итәргә дә тиешләр. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк.

Фестивальнең программасы гаять бай, катлаулы, күпкырлы иде. Аңа Чистайдагы төп лагерьдан гына түгел, Арча, Әлмәт, Түбән Кама, Яшел Үзән һәм Казандагы филиаллардан, республикабызның башка төбәкләреннән дә оешкан төркемнәр килергә тиеш. Шуның өстенә алдагы елларда "Сәләт" лагерен үткән яшьләр—элеккеге сәлкешләр дә чакырылган. Кара исәп белән дә алты йөзгә якын сәлкеш киләсе. Алардан тыш тагын күпме укытучы, әйдәман, кунаклар, әти-әниләр, туганнар... Барысы да куандыра торган хәл. Бусы—мәсьәләнең бер ягы. Икенче яктан, коточкыч зур мәшәкать тә әле ул. Бу кадәр халыкны ашатырга-эчертергә, йокларга яткырырга да кирәк. Өч көн дәвам итәсе фестивальдә ниләр генә булмас дисең...

Ә хәзергә без юлда. Автобуслар шома асфальт юлдан тигез гөрелдәп чакрымнарны саный. Дүрт "Икарус"тан торган колоннаның алдыннан да, артыннан да җемелдәгеч утларын кабызган ГАИ машиналары тәгәри. Бала-чага рәхәтләнеп көлешә, уйный-шаяра. Көлсеннәр, шаярсыннар. Аларның шундый чаклары. Әмма житәкчеләр йөзендә җитдилек, яшерен борчу бар. Соңгы вакытта һава бозылып китү, бер айга диярлек сузылган эссе, кояшлы көннәрдән соң әле котырып яңгыр яву, әле көтмәгәндә җир өстенә көзге салкынлык иңү—япан кырда, Биләр хәрабәләреннән ерак та түгел Чирмешән суы буенда үтәчәк җыен бәйрәменә өстәмә мәшәкатьләр тудырмагае. "Сәләт"нең рухи җитәкчесе Җәүдәт Сөләйман, лагерьның алыштыргысыз директоры Хәлил Гайнетдинов, иҗтимагый "Сәләт" фонды директоры Алмаз Хәбибуллин, хәрәкәт ветераннары: Казан дәүләт университеты укытучысы Айрат Гатиатуллин, гыйльми хезмәткәр Марат Хәлиуллин, башка укытучылар, баштагы елларда сәлкеш булган, хәзер инде үзләре үк әйдәман булып лагерьга килгән Ләйсән Сөләйманова, Римма Әхмәтхановалар йөзендә дә мин шул борчылуны, шул яшерен уйлануларны сизәм.

Дөрес, лагерь буласы урын инде күптән билгеләнгән, инде байтактан ук анда безнең аръергард, борынгы хәрби татар термины белән әйткәндә, иравыллар, ягъни алдан барып урын әзерләүчеләр төркеме эшли. Монысы—безнең кулдан килгәне. Ә инде табигать үзен кайсы яктан күрсәтер, монысын бер Алла белә!

Уен-көлке, җыр белән килеп житкәнебезне сизми дә калдык. Автобустан төшүгә каршыбызга колач җәеп, бер төркем малайлар-кызлар ияртеп Түбән Кама татар гимназиясе директоры Рафаэль Азизов белән Әлмәт татар гимназиясе укытучысы Рәдис Кәбиров килеп чыктылар.

— Һы, Чистайдан килеп җитәргә еракты шул,—дип елмайды Рафаэль Миргасыймович бераз гына төрттергәндәй иттереп.—Без инде иртә таңнан ук монда...

1996 елда күчмә җәйге "Сәләт" лагерен кабул иткән шәһәр вәкилен беренче итеп очрату аеруча күңелле иде, әлбәттә. Шулай да, аның үзе шикелле үк төрттерүне кирәк тапты булса кирәк, Җәүдәт Сөләйман да шундый ук вәкарь белән җавап бирде:

—Әллә баштә күрешерсеңме дигән идем... Юк! Булмаса булмый икән. Тәки сәлкеш гадәте кереп җитмәде инде. Хәер, сез җитәкбашлар шул!..

Директорыбызның бер көн эчендә кояшта, җилдә каралып өлгергән йөзенә киң елмаю җәелде:

— Шулай булмыйни... Мин үзем монда безне колач җәеп син каршыларсың дип килгән идем.

Сүз иярә сүз чыкты. Чистай белән Түбән Кама сәлкешләре арасында танышлар

шактый күп икән, рәхәтләнеп гөрләшергә керештеләр. Ул арада безне Рафаэль Миргасыймович чәй табыны янына чакырды.

— Юлдан арып килгәнсездер. Без инде учак ягып аш әзерләргә дә, чәй куярга да өлгердек. Төш вакыты житкән, тамак ялгап алу зыян итмәс,—диде ул хужаларча.

Менә шушы кунакчыллык, һәркайчан бер-береңә ярдәм итәргә, аш-су уртаклашырга әзер булу, дуслык, аркадашлык хисе жыен бәйрәме барган көннәрдә беркайчан да сүнмәде, сүрелмәде. Хәер, ул сәлкешләр арасында табигый бер халәткә әйләнеп бара. Монда "Берәү—күпләр өчен, күпләр—берәү өчен" принцибының бозылганы да юк.

Эчкә жылы йөгерде. Көн матур, кояшлы иде. Көньяк тарафларыннан талгын



*Менә шушындый инде алар сәлкешләр.*

жил исә, арган йөзләребезне иркәләп сыйпый, назлый. Дөрес, без беренчеләр була алмадык. Түбән Камадан гына түгел, Әлмәт, Арча һәм Әлмәт филиалларыннан да сәлкешләр инде килеп житкән, инде чатырларын корып та куйганнар, әйберләрен урнаштырып өлгергәннәр икән. Алты йөзләп кеше сыйдырышлы сәлкешләр шәһәрчегенең беренче палаткалары—тәүге карлыгачлары инде балкып, күзне иркәләп утыра! Алдан билгеләп куелганча, һәр филиал аерым бер утар итеп корылган. Ямь-яшел чиксез киңлекләргә ак, сары, зәңгәр, кызыл төстәге биниһая зур чәчәкләр сипкәннәрмени. Тау башыннан караганда, алар бормаланып-бормаланып аккан йөгерек сулы Чирмешән буеның табигый манзарасы булып тоелалар, ирексездән әллә кайчангы борынгы бабаларыбызның жәйге сәйфияләре күз алдына килә.

Фестиваль буласы урынны, кайчандыр болгар бабаларыбыз тереклек иткән, уйнаган-көлгән, бәхетле көннәр кичереп яшәгән изге жирләрне карап йөрибез. Күңелләрдә шатлык та, бераз гына моңсулык та бар кебек.

— Кайчандыр Арчада кырык биш кешелек нәни генә төркемнән башланган "Сәләт" шушындый киң колач алыр дип кем уйлаган,—дип куйды әңгәмәдәшем, "Азатлык" радиосы хезмәткәре Алик Гыйльмуллин уйчан гына.—"Сәләт"нең үсәсенә, ныгыячагына ышана идек, шуны тели идек. Әмма бу көннәр болай тиз килеп житәр дип көтмәгән идем.

Актаныш егете Алик Гыйльмуллинның болай әйтергә тулы хакы бар. Ул "Сәләт"не оештырып жибәрүчеләрнең берсе, аның беренче әйдәманы, беренче

укытучысы да иде. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, ул исәпләү математикасы һәм кибернетика факультетында аспирантурада калды, "Шәкли фәһем" лабораториясендә эшли башлады. Республикабыз мөстәкыйльлеге турында Декларация игълан иткән, киләчәккә якты өметләр, зур хыяллар белән караган ашкынулы көннәр иде ул. Чит илләр белән аралашу артты, әллә кайлардан Казанга милләттәшләребез килә башлады, латин хәрефләре белән халыкара татар гәзите "Dənja"ның беренче саны басылып чыкты. Тынгысыз йөрәкле Алик боларның барысын да күрә, күңеленә сеңдерә һәм, табигый ки, вакыйгаларның эчендә кайнарга омтыла иде. Озак та үтми инглиз телен һәм компьютерларны бик яхшы белгән егетне "Азатлык" радиосының татар-башкорт редакциясенә эшкә чакырдылар. Шунда китте. Ерак илләр гизәргә, дөнья күрергә хыялланган егеткә гаепмени?!

Монысы истәлекләрдән. Ә әлегә без тарихи җирләрне, бәйрәм җыены буласы урыннарны карап йөрибез.

— Тегендә тагын нииндидер палаткалар тора. Ялгышмасам, ак халатлы кешеләр дә байтак. Алары кемнәр инде тагы?—диде Алик сәлкешләр шәһәрчегеннән бер читтәрәк аерым утрау булып урнашкан әфлисун төсендәге зур палаткаларга күрсәтеп.

Аликның соравы барыбызга да берьюлы әйтелсә дә, җавап бирү табигый рәвештә Җәүдәт Сөләйман җилкәсенә төште.

— Балалар фестивале бит,—диде ул.—Кунакларны да исәпләсәң, барысы меңгә якын кеше җыеласы. Табигать шартлары, үзегез беләсез, соңгы көннәрдә килделе-киттелерәк. Шуңа күрә, андый-мондый көтелмәгән хәл булмагае дип, республиканың Гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан аерым төркем килде, Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә күчмә госпиталь дә корып куйдылар. Анда аларның хуҗалыгы. Алла "Сакланганны—саклармын" дигән ди бит.

Мин шунда гына бу кадәр зур фестиваль үткәрүнең бөтен җаваплылыгын тирәнтен аңладым кебек. Алик та магнитофонын җайлап, Прагадан яңгыраячак тапшырулары өчен чираттагы язмасын әзерләргә керешге. Шунда уйлап куйдым, халкыбызның "Ерактан яхшырак күренә" дигән мәкалендә никадәр яшерен мәгънә, никадәр киная бар икән. Фестивальгә дип хәтта "Азатлык" хәтле "Азатлык" радиосыннан килгәннәр, ә безнең Татарстан радиосы исә бу хакта гап-гади информация дә бирмәде шикелле.

Әлегә без тарихи җирләрне, җыен бәйрәме—фестиваль буласы урыннарны карап йөрибез. Шул хакта язам. Ә күз алдымда хушлашу мизгелләре.

Бәйрәм тәмамлангач ук Алик Гыйльмуллин Прагага китәргә тиеш икән. Икенче көнне иртүк Казаннан чыгасы очкычка инде билеты да алып куелган. Аның белән хушлашырга бөтен әйдәманнар, сәлкешләр җыелды. Һәрберебез белән кочаклашып чыккач, аерыласы килмәгәндәй бик озак кулларыбызны кысып торды әле.

Машина янында икәү генә калгач, аның ни кичергәнен аңлаганымны белдерергә, хәлен уртаклашырга теләп сорап куйгандай иткән идем:

— Китәсе килмидер, Алик...

— Китәсе килми, аерыласы килми,—диде ул әллә ничек йөрәк түреннән чыккан басынкы тавыш белән.—Китәсе килми.—Һәм кинәт башын икенче якка таба борды.

Күрсәтергә теләмәсә дә күрдем, ерактагы якын кардәшебезнең, ерак араларны якын итеп кайткан дустыбызының күзләре дымлана төшкән иде бу минутларда.

Хәзер менә уйлыйм, әгәр китмәскә теләсә, Аликка нинди дә булса сәбәп табып белешмә ясап биреп булыр иде. Азмыни дөньяда алдан белеп бетерә алмаслык хәлләр. Авырып китте, гаилә хәлләре буенча дип һәм башка, һәм башка сәбәпләр табып. Русиядәге һәр ике белешмәнең берсе ялган булганына беркем дә шик китерми, әмма бу хакта кычкырып та әйтми. Әмма бу бит Алик, бу бит татар баласы! Хезмәт бар, эш сәфәре дигән нәрсәнең, ягъни командировканың да вакыт кысалары бар! Бәлки әнә шулай сүзендә тора белгәне өчен, әйткәнен һичшиксез үтәгәне өчен дә хөрмәт итә торганнардыр әле татарны.

Әлегә без фестиваль буласы урынны карап йөрибез...

Иравыллар сынатмаган, (Алексеевск районы хакимияте һәм мәгариф бүлеге

ярдәме белән, әлбәттә) сабан туе буласы урында колгалар күтәрелгән, капчык сугышы һәм башка уеннар өчен җайланмалар әзерләнгән, волейбол мәйданчыгы белән футбол кыры да әзер. Һәр төркемгә махсус учак урыннары эшләнгән, штаб өчен һәм андыймондый хәл була калса дип, берсе-берсе кимендә йөз кеше сыйдырырлык зур махсус чатыр да корып куйганнар. Сүз уңаеннан, ул чатырларны "Сәләт"кә Казанның ВИКО күргәзмәләр комплексы биреп торды. Шунысы кызык, теләсә нинди җил-давылда да тотрыклылыгын югалтмаучы, борынгы шәрекъ стилендәге бу "хан чатырлары" "Исә Болгар җилләре" дигән фильмны төшерүдә файдаланылган, шуның өчен эшләнгән булган икән.

Палатка-чатырлар кору, үзара танышу, иртәгәсе көннең планын тәгаенләү, һәр сәлкешкә кием формасы—"Сәләт" эмблемасы төшерелгән футболка һәм шундый ук бейсболка, үзебезчә әйтсәк, козыреклы түбәтәй өләшү белән көннең үтеп киткәне сизелмәде дә. Ә кичен штаб янындагы мәйданчыкта җырлы-биюле уеннар башланып китте. Сәгать унбердә йокларга яту вакыты итеп билгеләнгән иде. Әмма кая ул! Берберсен берәр ел күрмәгән яшьләрне болай гына аерырмын димә! Әле бер, әле икенче төркем килеп сорый башлагач, җитәкчеләр озак баш ватып һәм ялындырып тормыйча (хәер, алар моны үзләре үк эшләргә җыенган иде), кичке биюләрне, сәлкешләр әйтмешли, "дискәтүк"не тагын бер сәгатькә озайтырга рөхсәт бирделәр. Мәйдан яшьләрнең хуплау авазларына, алкышларга күмелде.

Әмма биюләр тәмамлангач та әле беркем дә йокларга ашыкмады. Су буендагы учак яннарында гитара, курай тавышлары ишетелде. Кайдадыр кемнәрнеңдер тыйнак кына көлгәне яңгырап куйды. Татарстанның барлык районнарыннан диярлек һәм Русиянең тугыз республикасыннан, өлкәсеннән, хәтта чит илләрдән килгән татар балаларының, яшьләренең үзара сөйләшер, аңлашыр нәрсәләре бик күп җыелган шул! Әйдә, танышсыннар, сөйләшсеннәр, фикер уртаклашсыннар, дуслашсыннар! Халкыбызның киләчәге шушындый яшьләр кулында.

Бәйрәмнең төп өлеше иртәгә буласы. Хәерле төннәр, Сезгә,олы җанлы нәни сәлкешләр, тынгысыз әйдәманнар, хөр фикерле укытучылар һәм җитәкбашлар, балаларыгыз белән бәйрәм итәргә җаен-вакытын тапкан ата-аналар, киң күңелле кунаклар!

## Чистарыну

Бер нәрсә дә гарасат буласын белдерми иде әле.

Сызылып таң атты. Дүртенче июль таңы. Хуҗалар тавы өстендә кояшның беренче нурлары чагылды, озакламый, тау итәгендә җәйрап яткан чатырлы шәһәрчек тә тулаем алсу нурга күмелде. Чирмешән буендагы әрәмәлектә кошлар сайрашты. Күк йөзе чалт аяз, ник бер болыт әсәре булсын да ник яфрак селкетерлек җил иссен. Көн шул кадәр матур, табигать шул хәтле ягымлы иде ки, җыен бәйрәме-нең әйбәт, теләгәнчә үтәсенә беркемнең дә шиге калмады. Ләкин моның давыл алдыннан була торган шомлы тынлык икәне ул чакта ник беребезнең башына килсен!

Әмма инде күпмедер вакытлар үткәннән соң уйланам-уйланам да, күңелдә тагын шик бөреләнә. Дөресен әйтим, әгәр дә боларның барысының да болай буласын белсә, беркем дә моны кабатларга батырчылык итмәс иде кебек. Бәлки, күрәселәр шулай булгандыр. Бәлки, "Сәләт"кә, сәлкешләргә һәм җитәкбашларга нәкъ менә шундый сынауны үтәргә, ут һәм су белән чыныгуны узарга кирәк булгандыр...

Болар инде бүгенге көн уйланулары. Ә ул вакытта без таң атуга җиң сызганып эшкә керештек. Фестивальнең программасы үтә тыгыз, һәр сәгатьне, һәр минутны алдан исәпләп куйганча файдаланганда гына да ерып чыкмалы. Иртәнге якта барлык төбәкләрдән килгән төркемнәрне тәкъдир итү. Ләкин ул гап-гади таныштыру гына түгел. Җиде тарафтан килгән җиде төркемнең һәркайсысы борынгы җиде татар дәүләте тормышыннан театрлаштырылган тамаша күрсәтерә тиеш. Димәк, моның үзенә генә дә кимендә ике сәгать вакыт узасы. Аннан соң, гадәттәгечә, сабан туе. Монысы "Сәләт" аланнарында ел саен уздырыла торган һәм иң күп кеше катнаша

торганы. Төшке аштан соң төркемнәр арасында футбол, волейбол ярышлары, янәшәдәге "Дубок" балалар лагере концерт мәйданчыгында татар җыры конкурсы, шигърияттә Сөләйман, фанилыкта исә Җәүдәт Сөләйман дип танылган иптәшебезнең "Күләгәләр" һәм без фәкыйрегезнең шушы фестивальгә атап "Сәләт" китапханәсе нәшрияты махсус бастырып чыгарган "Уяну" исемле эсселар китабын тәкъдир итү... Кыскасы, бәйрәм тәгәрмәче бар куәтенә әйләнә башласа, тын алырга да вакыт булмаячак. Ләкин әле болары баласы гына. Программаның төп өлеше иң азакка—төнгә калдырылган. Анысы—артистлар, музыкантлар һәм балаларның үзләре катнашында үтәсе тарихи-драматик тамаша-спектакль.

Халкыбызының бик борынгы чорлардан бүгенге көнгә хәтле үткән юлын фәлсәфи-лирик уйланулар аша сурәтләргә, аның бөеклеге һәм фаҗигасе сәбәпләрен күзалларга омтылыш ясаган "Кыйбла" дип исемләнгән бу тамашаның либреттосын Җәүдәт Сөләйман, музыкасын сәлкешләрнең якын дусты һәм остазы Мәсгудә Шәмсетдинова язды. Әлегәчә мондый үтә киң колачлы тамашалар кую омтылышы берничә тапкыр Казан стадионында гына ясап каралган иде. Анда барысы да кул астында. Яктырткыч прожекторлар да, киенү-чишенү бүлмәләре дә, башка уңайлыклар да... Ә кырыс табигать шартларында бу беренче тәҗрибә. Спектакльне куярга республиканың иң күренекле сәнгать эшлеклеләре алынды. Алар арасында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры режиссеры Фәрит Бикчәнтәй, шул ук театр артисты Әзһәр Шакиров, "Казан" милли мәдәни үзәгенең биючеләр төркеме, танылган музыкантлар, Уфадан рәссам-режиссер Таң Еникеев. Хуҗалар тавы, аның итәгендәге "Изгеләр чишмәсе" янындагы киң мәйдан тулысы белән халкыбызның гасырлар төпкеленнән килүче бай тарихын гәүдәләндергән искиткеч зур сәхнәгә әверелде.

Шөкер! Барысы да без көткәннән дә яхшырак бара. Тәкъдир итү уңышлы гына үтеп китте. Күз алдыбызда чал тарих сәхифәләре яңарды. Балалар һәм яшьләр, күп санлы кунаклар алдыннан дәһшәтле сәргаскәр Аттила яулары шаулап узды, исемнәре тарихта, җисемнәре исә каныбызда, нәселебездә калган борынгы болгар һәм кыпчак гаскәрләре тормышыннан хатирәләр яңарды, Казан мәмләкәте сурәтләре пәйда булды. Балалар кул астындагы һәр нәрсәне эшкә җиккәннәр. Якындагы әрәмәдәге тал чыбыклары ук-җәягә, казан капкачлары калканга, җәймәләр чапанга, сугышчан япмаларга әверелгән.

Фестивальне ачу тантанасына Казаннан, Чистайдан һәм Алекссевскидан республика, шәһәр һәм район җитәкчеләре дә килеп җитте. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисенең беренче урынбасары, шагыйрь Ренат Харис, Республика Министрлар Кабинеты рәисе урынбасары Илгиз Хәйруллин, мәгариф министры Фариз Харисов, балалар һәм яшьләр белән эшләү дәүләт комитеты рәисе Марат Бариев, "Татнефть" берләшмәсе генераль директоры Ринат Галиев, "Казан утлары" журналының баш редакторы Равил Фәйзуллин, Чистай һәм Алексеевск районнары хакимият вәкилләре һәм башка дәрәҗәле кунакларны мәйдан алкышларга күмде. Бу очрашуда сәлкешләр өчен дә, җитәкбашлар өчен дә тирән мәгънә бар иде. Димәк, сәлкешләр бәйрәме ул инде "Сәләт"неке генә түгел, ә бөтен республика күләмендә киң яңгыраш алган зур вакыйга. Һәм кунаклар бу хакта үзләренең саллы сүзләрен әйттеләр дә.

— Халкыбызның иң сәләтле кызларын, малайларын бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм,—диде Дәүләт Советы рәисе урынбасары Ренат Харис.—Ышанам, киләчәктә сездән милләтебезне, республикабызны киң дөньяга танытырлык тынгысыз галимнәр, фән эшлеклеләре, әдипләр, сәнгатькярләр үсеп чыгар. Кем белә, бәлки республикабызның егерме беренче гасырда булачак президенты да сезнең арагыздадыр. Кайда гына булсагыз да, кайсы гына тармакта эшләсәгез дә мин сезгә чын күңелемнән уңышлар, бәхет телим. Татарстан данын, татар исемен горур йөртерсез, дип ышанам.

Сабан туе, җыр бәйгесе, яңа китаплар белән таныштыру кебек чаралар нәкъ алдан күрелгәнчә узды. Дөрес, сабан туе вакытында яңгыр сибәләп алды алуын. Әмма кыска гына вакытка бәйрәмгә төрлелек кенә өстәгән җәйге җылы тамчыларга беркем дә игътибар итеп тормады. Көрәшчеләр көрәште, йөгерешчеләр йөгереште, уеннар дәвам итте.

Һәммәбез дә түземсезлек белән кичне көтәбез. Фестиваль программасының кадагы—бер ел буе диярлек әзерләнгән, никадәр көч, чыгым тотылган тамаша ич. Көткәндә вакыттан да акрын узучы нәрсә юк икән. Әле бит спектакль кич кенә дә түгел, ә тирә-якны тома караңгылык чорнап алгач кына узасы. Сценарий буенча шулай каралган. Бөтен мәгънәви эчтәлеге, эффекты ут һәм су уенына корылган тамаша!

Менә, ниһаять, җәйге кояшның җиз ләгәндәй зур тәлинкәсе баш өстеннән акрын гына көнбатышка таба тәгәрәде, еракта, бик еракта шомландырып үсеп килүче ертык болытларны бер генә мизгелгә кан төсенә манчып алды. Шул ук мизгелдә йөрәкләргә шом салып, күңелгә тәшвиш өстәп Чирмешән буйларында көтелмәгән оран яңгырады:



*Әле бернәрсә дә гарасат буласын белдерми иде.*

— Игътибар! Игътибар! Лагерьда гадәттән тыш хәл игълан ителә...

МЧСның чатырлар шәһәрчегеннән бераз читкәрәк куелган олы радиорупорлары телгә килгән икән.

— Игътибар! Игътибар! Лагерь җитәкчеләре, укытучылар, әйдәманнар, табиблар! Лагерьга таба зур тизлектә гаять көчле ураган, яшенле яңгыр якынлаша! Кичекмәстән чатырларны өстәмә рәвештә ныгыту, су үтмәслек итеп каплау чаралары күрергә! Балаларның барысын да кичекмәстән палаткаларга! Кабатлыйм... Ураган ун минуттан лагерь өстендә булачак.

Ун минут эчендә нәрсә генә эшләп өлгерергә мөмкин соң? Әйдәманнар, зуррак малайлар чатырларны тикшерергә, яннарындагы канаучыкларны тирәнәйтергә кереште. Өлкәннәр балаларны санарга, барларга тотындылар. Тизрәк! Тизрәк! Беркем дә тышта, җил-давылда калмасын!

Баштарак бик ерактан, тоныкк кына ишетелгән күк күкрәү авазлары якынайганнан якыная. Менә бөтенләй көтмәгәндә баш өстебездә күк йөзен утлы гигант кайчылар кисеп үтте, колакларны тондырып көчле гөрселдәү яңгырады. Шул ук мизгелдә әллә каян җил кузгалды, сызгырып, уйнап кына килгән һава дулкыны күз ачып йомганчы дәһшәтле өермәгә әверелде дә шәһәрчек өстендә хуҗа булып

котырынырга тотынды, учактан утын пүләннәрен алып ыргытты, анда-монда аунап калган әйберләрне һавага чөйде. Палатка түбәсенә эре тамчылар бәрә башлады, эһ дигәнче алар тоташ бер агымга әйләнде һәм тирә-якны куе караңгылык томалап алды.

— Бетте. Болай булгач "Кыйбла" булмый. Бер еллык эшебез юкка чыкты,— дип куйды кемдер. Аның авыр итеп көрсенгәне ишетелде.

Барыбызның да күңелләрендә бөреләнгән шикне тел белән әйткән кешегә җавап бирүче, каршы эндәшүче табылмады. Барыбызны да шул хис, авыр тойгы били, чарасызлык, көчсезлек изә. Шундый матур, шундый әйбәт башланган иде бит! Ә тышта ураган котыра, палатка түбәсен, стеналарын су ташкыны кыйный, яшен яшьни, күк күкри. Тышта су, җил һәм ут стихиясе.

Яңгыр мәңгелеккә килгән шикелле котырып, усалланып яуды-яуды да, ничек кинәт башланган булса шулай кинәт кенә туктады да. Давыл гарасаты Хуҗалар тавындагы агач ябалдашларын салкын кочагына суырып тагын бер кат болгатып алгач каядыр көнбатышка таба китеп югалды. Яшен кайчылары инде, әнә, ерак офыкны телгәли.

Палаткалардан чыктык. Әле генә яланаякларыбызны иркәләгән яшел үлән келәме тоташы белән су астында. Болыты белән төшкән мондый яңгырдан соң тауга күтәрелү түгел, хәтта Чирмешәннең яңгырда җебегән үзле кызыл балчыклы текә, тайгак ярыннан күпергә үтүне дә күз алдына китерергә мөмкин түгел иде инде.

Җәүдәтнең йөзе кара коелган. Башка җитәкчеләрнең дә кәефләре шул чама. Иреннәр кысылган, карашлар кырыс. Салкында бер өемгә укмашкан каз бәбкәләре шикелле палаткаларга кереп оялаган сәлкешләрнең акрын гына быдыр-быдыр ни турындадыр сөйләшкәне ишетелә. Чатырлар шәһәрчеге киеренке тынлыкта. Ул нидер көтә, ул сабыр итә.

Киеренке бер халәттә ике сәгатьләп вакыт үтте. Инде караңгы төшәргә дә күп калмады. И җәйге яңгыр, и мәрхәмәтле җәйге болын! Аяк астындагы су күзгә күренеп җиргә сеңеп бетте, күк йөзе ачылды. Күңел төпкелендә, әллә каян гына үрләп өмет чаткысы пыскый башлады. Ә бәлки... Ә бәлки...

Ни кылырга да белми чатырлар арасындагы үзәк мәйданда басып торабыз. Беркем дә әлегә хәлиткеч сүзне әйтергә кыймый. Әмма беләм, сизәм, күпләребез бер нәрсә турында уйлый. Күз карашлары, әйтелеп бетмәгән сүзләр шул хакта сөйли. Шулай күпме торган булыр идек, билгесез, яныбызга МЧС төркеменең башлыгы килеп туктады. Барыбызны да күзеннән кичерде һәм акрын гына сүз башлады:

— Егетләр... Хәлегезне аңлыйм... Ы-ы... Бер еллык хезмәт... Кызганыч, әлбәттә. Ул болай җиңел генә юкка чыга аламы... Җир дә кипшерә кебек...

Ул әле суза, әйтеп бетерергә кыймый. Әмма тел төбендәгесен аңладык, тойдык. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен куелган кешеләр башлыгы үзе үк безгә гадәттән тыш хәл тәкъдим итмәкче түгелме?!

— Кыскасы, минем конкрет тәкъдимем бар,—диде ул, ниһаять, күбрәк ымлыклардан торган кереш сүзен тәмамлап.— Чирмешәннең теге ягына чыга алсак, спектакльне уздырып була кебек. Шулаймы?.. Анда асфальт, баскычларда да сак өчен кешеләр куярга мөмкин. Иң куркыныч урын—Чирмешән яры. Без менә уйлаштык, киңәштек. Ярдан төшкәндә һәм күпердә метр саен безнең кешеләрне, сезнең әйдәманнарны, укытучыларны тезеп тере коридор ясыйбыз. Һәр баланы кулыннан тотып, җитәкләп, кирәк булса күтәреп аргы якка күчерәбез. Аннан соң—дилбегә сезнең кулда.

Барыбыз да җиңел сулап куйдык бугай. Чөнки бу инде хәл итеп булмаслык тоелган мәсьәлне хәл итә башлауга таба беренче адым иде. Дөрес, алты йөзгә якын баланы тайгак текә ярдан су буена төшерү, такталары ләм белән капланып, шомарып беткән күпердән берәмләп чыгару, аннан соң тар баскычлардан тауга алып менү җиңел булмас. Әмма... Бу инде тик тору, кул кушырып нәрсәдер көтеп утыру түгел.

Тәвәккәлләдек! Лагерь өстендә чакыру авазы яңгырады:

— Барыгыз да "Кыйбла"га, Хуҗалар тавына!

Шуны гына көтеп торган кебек эреле-ваклы палаткалардан сәлкешләр аланга сибелде. Кечке эңгер-меңгердә аларның сөенеп көлешкәне, сөйләшкәне ишетелде. Бәхетебезгә, җир дә шактый җиллләп өлгерде. МЧС кешеләре барлык автобусларны,

машиналарны елга ярына китереп тезделәр. Сигнел буенча алар барысы берьюлы фараларын кабыздылар һәм... инде куе караңылыкка төренә башлаган яр буе ут көлтәләренә күмелде.

Балаларны ничек чыгарганыбызны, Изгеләр чишмәсе янына ничек барып җитүбезне тасвирлап тормыйм. Иң мөһиме—Хуҗалар тавы буйларын җәйге куе караңгылык чорнап алганда без барыбыз да тамаша буласы урында идек инде.

...Менә оркестрның беренче аккордлары яңгырады. Изгеләр чишмәсе янында нефтьчеләр тарафыннан торгызылган биналар, борынгы стильдә эшләнгән беседкалар, айваннар, агач ябалдашлары өстендә һаваны прожектлорларның төрле төстәге ут кайчылары телгәли башлады. Күккә җемелдәвек чәчәкләрне хәтерләтеп фейерверк утлары ыргылды һәм... тамаша башланды. Бу минутларда без барыбыз да гүяки инде моннан мең еллар элек булган вакыйгалар эченә кереп чумган идек.

Тамаша ахырына якынлашып килә. Таулар арасында төркиләр бабасының иңрәү авазы бәргәләнә:

Бер имәнгә—йөз балта,
Бер йөрәккә—ун пычак.
Янгырга чыдый учак,
Җилләрдә дөрли учак.
Давылга өермәгә дә
Бирелмәс иде учак.
Туфан басты өстән,
Гарасат төште күктән...
...Учак әле өскә калкыр
Форсат килеп бер,
төптән.

Тамаша белән шул хәтле йотылганбыз ки, тау өстендә яңадан ургылып болытлар кайный башлаганын беркем дә шәйләмәгән. Аны без башларыбызга беренче эре тамчылар килеп төшкәч кенә сиздек. Шул ук минутта, кемнеңдер ишетелми генә биргән әмеренә буйсынгандай, сафлар өстендә дистәләрчә кулчатырлар кабынды.

...Яңгыр котыра, яңгыр уйнаклый, явызланып битләргә, шәрә беләкләргә бәрә. Караңгы күк йөзен яшен утлары телгәли. Ачулы җил кузгалды, ул кулчатырларны, балалар өстендәге юка киемнәрне йолыккалый, эре тамчыларны ян-яктан, кырыйдан сыларга тырыша. Ә сәхнәдә тамаша дәвам итә. Менә күккә тагын ут көлтәләре ыргылды һәм котырып яуган яңгыр, ыжгырган җил тавышларын күмеп, оркестрга йөзләрчә сәлкешләр тавышы кушылды:

Тәңре, синнән үткен зиһен сорыйм,
Кояш, синнән, рухи чисталык.
"Сәләт"—дәүләт, Сәлкеш—яңа татар,
Ан-фәһемгә гашыйк бу халык.

Җир-йорт безгә очар канат бирде,
Кыйбла булды "Сәләт" аланы.
Җан җепләре бәйли сәлкешләрне,
Якын итеп ерак араны.

Рәхмәт, Тәңрем, татар теле өчен,
Татар теле—җиһан ачкычы.
Сакла, Тәңрем, сакла "Сәләт" илен,
Хакыйкатьнең тәүге баскычын.

Бу минутларда кичергән халәтемне аңлатырлык сүзләр таба алмыйм. Кулымнан килсә, салкын яңгырда манма булган һәр сәлкешне кочагыма алыр, тыным белән өреп җылытыр идем. Ирексездән күзләр дымланды. Бу, һичшиксез, олы йөрәкле нәни сәлкешләрнең уртак эш, уртак максат хакына кылган беренче батырлыгы иде. Мин аны башкача бәяли алмыйм. Боз катыш яуган яңгырны сизмичә дә күкрәк киереп "Сәләт" маршын җырлаучы балаларны күргән башка кешеләр дә нәкъ шундый хисләр кичергәндер дип беләм.

Сөерсенер хәлләр иде шул бу! Тамаша бетүгә яңгыр да, җил дә туктап калды.

Тагын һава ачылды, каралҗым күк гөмбәзендә безне үртәгәндәй йолдызлар җемелдәшә башлады. Табигатьнең бу шаяруын (шаяру гына микән?) аңлар, аңлатыр хәлдә түгел идек. Хәер, аны без әле бүген дә аңлата алмыйбыз һәм аңлата да алмабыздыр. Бу ураган, бу яшеңле, бозлы яңгыр бара тик шушы төбәктә генә булган. Соңыннан без моны синоптиклардан да, бу якларда яшәүчеләрдән дә белештек. Арабыздан кемдер: "Тынычлыкларын бозган өчен Хуҗалар ачуланды, ризасызлыкларын шулай сиздерде. Изге җиргә музыка, шау-шу алып килгәнне яратмадылар",— дип үзенчә фәлсәфә куертырга да маташкан иде. Ләкин аңа күпләр каршы төште. Гөнаһсыз балалар Изге җиргә Изге теләк белән килде. Бәлки бу яңгыр, бу гарасат аларның шушы юлдагы ныклыкларын, мәсләкләренә тугрылыкларын сынау булгандыр. Һәм... тагын бер нәрсәне әйтмичә кала алмыйм: әгәр алар булмаса, тамаша-спектакль ул кадәр үк үтемле дә булмас иде әле. Әйтерсең лә Хуҗалар тавы, Изгеләр чишмәсе, болытлар, яңгыр, яшен һәм җил—халкыбызның үтә дә авыр, бормалы, җиңү тантанасы җиңелү, изелү ачысы белән аралашкан борынгы тарихын сурәтләгән спектакльгә кушылды.

И алланың рәхмәте! Бозлы яңгыр астында торган алты йөзләп баланың ник берсенә салкын тисен, ник берсе булса да төчкереп карасын! Арада егет-кыз булып килүче үсмерләр белән бергә башлангыч класс укучылары—Мордовия кызы Җәмилә, Казан баласы Булат Мөбарәкҗанов, Австралиядән килгән Шәмсия Вәли кебек сабый вә сабыялар да бар иде бит әле.

Ул көнне таңны без учаклар янында каршы алдык. Чирмешән суы аша сузылган сират күперен яңадан кичеп лагерьга кайтуга зур-зур учаклар тергезеп җибәрдек. Балалар да, өлкәннәр дә алар янына сарылды, өс киемнәрен киптерергә, җылынырга кереште. Кайнар чәй әзерләнде. И балачакның гөнаһсыз мизгелләре! Әйтерсең, яңа гына бозлы яңгыр астында манма булмаганнар, күшекмәгәннәр, туңмаганнар. Учак янында уен-көлке дәвам итте.

Өстәмә гөнаһ аласым килми, шулай да мин бу вакыйганы—Хуҗалар тавындагы мажараны—изге тау иясләренең сәлкешләрне, аларның ныклыгын, бердәмлеген, дуслыгын һәм, ахыр исәптә, аларның уртак максатка бирелгәнлеген ут һәм су ярдәмендә сынап караулары булды дип расларга батырчылык итәм. Шунысы куанычлы, без аны уңышлы үттек, рухи яктан чистарынып, җисмән пакьланып кайттык.

## Ач сәлкеш—кипкән бәлеш

Без яңадан Чистайда—"Раздолье" пансионатында. Бөтен эш яңадан гадәти эзенә төште. Иртәнге якта дәресләр, очрашулар, көндезен һәм кичен сәяхәтләр, экскурсияләр, уеннар, кичәләр, аланның бетмәс-төкәнмәс ыгы-зыгысы. Иң мөһиме шунда, ни генә булмасын, аланда бөтенесе дә уен, шаяру белән үрелеп бара. Хәер, моның өчен җитәкбашларга да, укытучыларга да артык баш ватып торасы юк. Барысын да балалар һәм... әле үзләре дә кайчандыр сәлкеш булган әйдәманнар хәл итә. Ә аларның хыяллары чиксез.

Төшке аш вакыты. Ашыкмый гына ашханәгә юнәләбез. Ишек төбендә исә безне швейцар булып киенгән балалар каршы ала.

— Хәерле көн!—дибез гадәткә кергәнчә.

Әмма борын асларына очлары кәкрәеп өскә күтәрелгән, "а ля Буденный" рәвешендәге мыек ясап куйган, ватман кәгазеннән форменный фуражка сыман нәрсә әтмәллләп кигән һәм чын швейцарларча итагать иясенә әверелгән "егет"ләребез ишекне каерып ачарга ашыкмады.

— Керү хакы—бер җыр яисә шигырь. Теләгән кеше бию белән дә түли ала,—диде аларның берсе.

Икенчесе кырыс тавыш чыгарырга тырышып өстәп куйды:

— Күрмисезме, абый, монда бит ат башы хәтле хәрефләр белән язып куелган! Тик бер шарты бар, түләү татар акчасы белән!..

Гажәпләнеп җилкә җыеруымны күреп "швейцар"ыбызның йөзенә мәрхәмәт билгесе чыкты.

— Соң, абый,—диде ул елмаеп,—татарның акчасы бер генә ләбаса! Җыр да бию, шигырь дә мәзәк. Тагын ни белән түли аласың инде...

Шунда гына игълан тактасына күз төште. Чыннан да, барысы да алар әйткәнчә иде. Кизү торучы "Биш татар" төркеме ашханәдә үз тәртипләрен керткән икән. Уен шартларын кабул итмичә ярамый. Чөнки инде арттан килеп тезелергә өлгергән сәлкешләр дүрт күз белән көтә: җитәкбашлар буйсынырмы-юкмы? Нишлисең, без инде буйсынырга күнеккән. Колагыма, кем әйтмешли, аю баскан кеше булсам да үзем иң яхшы белгән дип исәпләгән һәм башкаруда әлләни осталык таләп ителмәгән "Утыр әле яннарыма" җырын такмаклап бирергә туры килде.

Кердек, өстәл янына утырыштык. Янибызга "кара фрак" кигән, ап-ак күлмәк өстеннән "күбәләк" тә кадап куярга онытмаган озын буйлы егет—Әлмәт сәлкеше Илдар кулыбызга ил агаларына, анда да әле олуг юбилейларында гына бирелә торган ялтыравык тышлы папка китереп тоттырды. Тышына зур хәрефләр белән "Меню" дип язылган булгач ачтык та телсез калдык. Исемлектә ниләр генә юк!

"Кабымлыклар" дигән бүлектә ризыклар саны бишәү булып чыкты:

*Ак шәрабта тондырылган кальмар (сигезаяк).*
*Кыздырылган бака ботлары.*
*Artichokes in olive oil (зәйтүн маендагы артишоклар).*
*Кара уылдык.*
*Кызыл уылдык.*
*Диңгез кәбестәсеннән салат.*

"Беренче аш" бүлеге бераз ярлырак анысы. Официантларыбыз нибарысы дүрт төрле аш тәкъдим итә. Хәер, зәвекълары начар түгел. Балаларга тамак ялгар өчен ташбака шулпасы, харчо, украинча борщ һәм шампиньонлы аш тәкъдим ителә иде.

Икенче ашка исә итальян пиццасы, төрекчә кебаб, флотча спагетти, алмага салып пешерелгән каз яисә кыздырылган күркә сайларга мөмкин. Десертка—шампан шәрабындагы ананас, виктория җиләге белән сөт өсте, авокадо, маракуйя һәм наранья. Оят булса да, дөресен әйтим, җир йөзендә ярты гасырдан артык яшәп тә мин бу исемлектәге кайбер ашларны кабып карау түгел, аларның ни-нәрсә икәнен дә белмим һәм тормыш болай барса белүем дә шикле.

Авыздан килә башлаган суларны йотып, исемлекне өйрәнүне дәвам иттерәбез. Әһә! Менә эчемлекләр бүлеге.

*Sprite.*
*Coca-cola.*
*Fanta.*
*Төрле соклар.*

Монда инглизчә язылган атамаларга исегез китмәсен: алан әшли башлаганнан бирле татар һәм инглиз телләрен белү төп таләп итеп куела, сәлкешләр шул шартны тиешенчә үтәргә тырыша. Хәтта, үзенә күрә "language security"—туп-туры тәрҗемә иткәндә, тел сагында торучы аерым төркем дә оештырып җибәрделәр. Күптән түгел генә шундый бер сөйләшүнең шаһиты да булдым әле. Австралиядән килгән Шәмсияне бер төркем балалар чорнап алган. Татарчасы чамалырак Уфа "егет"е бәйләнепме бәйләнә бит моңа. Әмма ни генә әйтмәсен, Шәмсиябез итагатьле елмая, килешле итеп иңсәләрен күтәреп куя да бер үк сүзләрне кабатлый:

— Гафу итегез, мин урысча белмим!

Аннан ничек тә булса бер кәлимә урыс сүзе әйттерергә тырышкан "егетебез" инде үзе аптырап иңсәләрен җыерды.

— Урысча белмәгән татар кызын гомеремдә беренче тапкыр күрүем,—диде ул акланганлай.

Сәлкешләр рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Аның караны, татарчаны да инглизчәне дә биш бармагы кебек белә, төрекчә сөйләшә, японча аңлый,—диде арадан берсе.—Урысчасын өйрәнүе дә озак булмас...

Австралидәге милләттәшләребез бик аз санлы булуга карамастан, туган телне, динне, гореф-гадәтләрне кадерләп саклыйлар. Шәмсиябез бер кочак видеокассета да алып килгән булып чыкты. Аларны карап без көнгерәләр илендәге татарлар тормышыннан шактый мәгълүмат алдык. Әйтик, сабан туйлары, корбан бәйрәмнәре үткәрелә, гаилә бәйрәмнәре уртак тантанага әйләнә, күмәкләшеп җырлыйлар, бииләр, күңел ачалар. Шушы нәни генә Шәмсиябез теттереп татарча да, башкортча да бии икән. Видеофильмда гына түгел, "Сәләт" концертларында да без аның осталыгын күреп кинәндек, яратып алкышладык.

Ярый, болары әлегә калып торсын, менюны өйрәнүне дәвам иттерик. Алкогольле эчемлекләрдән без фәкыйрьләрегезгә 1879 елгы Шато Марго, Каберне, Peter Mertes кебек затлы шәраблар тәкъдим ителә, алардан тыш инде без азмы-күпме белгән, татып караган шампан шәрабыннан да авыз итәргә мөмкин. И замана балалары! Башларына килгән: менюның астына эре хәрефләр белән "Официантларга чәйлек бирергә онытмагыз!!!" дип тә язып куелган иде.

Уенны дәвам иттерәбез.

— Без салкын кабымлыкка кыздырылган бака боты, беренчегә ташбака шулпасы, икенче ашка төрекчә кебаб, десертка авокадо алыр идек. Эчемлек инде... анысы сезнең карамакта. Ни бирсәгез шуңа ризабыз...

Илдар житди кыяфәт белән заказ дәфтәрчегенә нидер язарга керешә.

— Яхшы... яхшы,—диде ул үз бәясен белгән яхшы официантларча бераз алга таба иелә төшеп.—Тамак ялгап алу өчен безнең ресторанны сайлаган кешеләргә без чиксез шат. Ы-ы... Әмма, гафу итегез! Бүген кайбер теләкләрегезне үтәп бетереп булмас. Бака ботларына Франциягә заказ биргән идек. Кызганычка каршы, бүгенге партияне китереп житкерә алмадылар. Самолетны Парижда тоткарлаганнар.—Илдар үзе дә көлеп жибәрүдән чак кына тыелып тора иде булса кирәк, борын астына ябыштырган кәттә мыегы мәзәк кенә селкенеп куйды.—Шуңа күрә, Чистай күлендә яңа гына тотылган свежий бакалар пешкәнче сабыр итеп торырга туры килер. Ә ташбака төяп чыккан очкычыбыз Тын океан өстендә давылга юлыккан. Менә-менә килеп житәргә тиеш. Әйе, ы-ы... Тагын... Һиндстанда йөк төяүчеләр баш күтәргән. Шунлыктан, авокадоны бер-ике сәгатьтән генә китереп житкерәчәкләр. Әлегә мин сезгә кабымлыкка кыяр белән помидор салаты, беренче ашка токмачлы шулпа, икенчегә бәрәңгеле кәтлит тәкъдим итә алам. Эчемлек, гадәттәгечә, татар чәе. Шикәре, рәхим итегез, өстәлдә...

"Метрдотель" заказ кабул итүгә, "официант" кызлар әйтелгән аш-суны күз ачып-йомганчы өстәлгә китереп тә житкерделәр. Йөзләрендә елмаю, телләрендә тәмле сүз: "Ашыгыз тәмле булсын!" Болары да тәрбия чарасы. Аш өстәле янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, кунак сыйлау йоласы шулай сеңдерелә. Ә ашханә "курслары"н бер генә сәлкеш тә үтми калмый, чөнки һәр отряд—аланда әйтелгәнчә төркем—чиратлап ашханәдә кизү тора. Бусы да язылмаган канун.

Инде кулларыбызга кашык алып, кем әйтмешли, тәгам жыя башларга да мөмкин. Каршымда утырган әйдәман—Гөлназ күз карашы белән генә алдымда яткан кәгазьгә ымлый. Монда безне тагын бер сюрприз көтә икән. Компьютерда жыелган һәм лазерлы принтерда басылган затлы кәгазь битендә "Сәлкешләрнең ашханәдә үз-үзләрен тоту кагыйдәләре" тасвирланган иде.

*— Синең белән баручы кыз синнән кечләрәк булса, аны алдан үткәрү сәламәтлегеңә зыян китермәс.*

*— Порциянең иң зурысын алырга тырыш: әниең синең өчен борчыла.*

*— Күбрәк аша. Ач сәлкеш—кипкән бәлеш.*

*— Күбрәк физрук белән бүлеш. Әнис абый белән дус булсаң, иртәнге гимнастикадан котылу мөмкинлеге туар.*

*— Тәлинкәңдәге чебенне кума: аның да ашыйсы киләдер.*

*— Күршең берәр кая китеп торса, аның тәлинкәсен чистарту—синең изге вазифаң.*

*— Чәеңдәге шикәр тәмсез булса—ул тоз, төчкертсә—ул борыч.*

*— Исеңдә тот, ашханәдән чыкканда пешекчеләргә рәхмәт әйтмәсәң, киләчәк ашың әллә була—әллә юк.*

*Ашларың тәмле булсын, сәлкеш!*

Аз да түгел, күп тә түгел. Барысы менә шушылар. "Кагыйдәләр"дәге теләкләр ярымшаяру, ярымчын, дигәндәй, аш алдыннан көлешеп алу өчен безгә житди сәбәп булды.

Бәлки мин уен-көлке, шаярту, шаянлыклар хакында күбрәк тә яза торганмындыр. Ләкин чынлыгы шул бит. Уку-укыту процессы, дәресләр турында никадәр язылган, тагын никадәр язылыр әле. Ә инде балаларның, яшьләрнең дәрестән тыш вакытлары, аның ничек узуы, мина калса, күпләр өчен кызыграктыр да әле. Чөнки бу укытучыларның да, ата-аналарның да игътибарыннан читтәрәк кала торган өлкә. Теләмәгәнлектән түгел, ә мөмкин булмаганлыктан. Класстагы егерме-утыз баланың кайсы кайда нишләп йөрүен шәһәр шартларында гомумән дә белеп бетерү мөмкин түгел ләбаса.

Аланда исә алар барысы да күз алдында, барысы да бергә. Тагын шунысы кызык: әйдәманнар һәм укытучыларның байтагы үзләре дә "сәлкешләр"нең яшьтәше диярлек, барысы да кайчандыр "Сәләт" мәктәбен узган студент яшьләр.

"Раздолье"да сәлкешләрнең тәртибендәге "сәерлекләр"гә беренче булып пансионат эшчесе Самат абый игътибар иткән икән. Иртән дә кичен дә чәчәк түтәлләрендә казынучы, кулына себерке тотып әле анда, әле монда себеренгәләп, чисталык өчен көрәшеп йөрүче мишәр агае сүзгә бик юмарт булып чыкты.

— Әллә нинди сәер балалар сезнең,—диде ул көннәрнең берендә гадәттәгечә корпус янындагы беседкада ил-көн, дөнья көтү, бала-чага хакында гәп куертып утырганда. Эштән бирчәйгән бармаклары арасына кыстырып, җайлап кына тәмәкесен йомшартып алды. Миннән нинди дә булса җавап та, тәэсир дә ишетмәгәч, әйткәнен аңлатып бирергә телгәндәй тагын дәвам итте.—Сез килгәч эшләве дә күңелле булып китте әле. Тыштан керәсе килми...

Абзыйның һаман болай да чиста сукмакларны себергән булып йөрүенең сере шунда ачылды.

— Ул сәерлекне нәрсәдә күрәсең, Самат абый. Безнең өчен гап-гади балалар, татар балалары инде,—дидем мин әңгәмә җебен ялгар өчен.

— Әллә ничек... балалар кебек тә түгел алар,—дип куйды Самат абый. Аннары озак кына уйланып утырды.—Дөресен әйтим, балалар киләсен белгәч, мондагы кешеләр белән "Уф, шулар гына житмәгән иде", дип борчылган идек. Бу бит өлкәннәр пансионаты. Тынычлыкка, акрын-салмак эшкә күнеккән инде. Моннан элегрәк шулай шәһәр балаларын ял иттергән иделәр. Әстәгыфирулла! Алар киткәч тә бер атна буе чүпләрен җыеп, ваткан әйберләрен төзәтеп бетерә алмый интектек. Тагын шулай булыр дип шиккә төшкән идек инде.

Сорау биргәнемне сизми дә калдым:

— Шикләрегез акланмадымы?

— Кая ул,—дип кул селтәде мишәр агае.—Киресенчә, рәхәт булып китте. Пансионатка татар җаны керде. Иртән торасың үзебезчә музыка уйнап җибәрә, кичләрен биләр рәхәтләнеп, анысы да татарча. Юкса, монда ятып туган телне тансыклый башлаган идек инде. Чистаена кайтсаң да шул ук телсезлек бит... Ә тәртипләренә килсәк, зурлар да бу кадәр чисталык сакламас, мин сынайтым...

Барысы да ачыкланды шикелле. Сүз тәмам. Инде кузгалырга җыенганымны күреп, Самат абый тагын нишләптер мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Ә шулай да балаларыгыз сәер сезнең,—дип кабатлады ул мине сынарга телгәндәй көлемсерәп.—Бер карыйсың, ун-унбиш яшьлек бабайлар инде, валлаһи. Кулларын артка куярлар, башларына мең уй төшкән кеше шикелле салмак кына атлап йөрерләр. Икенче карыйсың, күзләренә ышанмыйсың, нәкъ сабыйларча юк кына нәрсәдән кызык табып шаярырга, көлешергә тотынырлар. Әле кайчагында мин аларның ни хакында сөйләшкәннәрен, нәрсә язганнарын да аңламый башлыйм.

— И-и-и, абый, алар бит замана балалары. Хәзер әнә компьютерлар, видеоплейерлар, синхрофазотроннар... тагын әллә нәрсәләр... Без аңламаслык итеп сөйләшсәләр дә гаҗәп түгел.

— Аларын әйтмим мин. Әле татарча сөйләшкәндә, дим. Татар сүзләре белән

сөйләшкәндә. Әнә, кара, син берәр нәрсә аңлыйсыңмы?—Агаем якындагы корпусның ишегенә беркетелгән язуга күрсәтте.

Укытучы егетләребез яши торган бүлмә ишегенә эленгән, инде планерка саен тугланганлыктан, ятлап өлгергән гадәти көн тәртибен күз алдына китереп мин игътибарсыз гына:

— Аңлыйм, әлбәттә,—дидем.—Көн тәртипләрен язып элгәннәрдер инде.

— Анысы шулайдыр... Ну, син... иптәш, башта укы әле син, укы! Укып кара...

Моңа кадәр артык игътибар иткәнем юк иде, шулай да бик гозерләгәч укымыйча булдыра алмадым һәм үзем дә сизмәстән Самат агай шикелле үк гаҗәпсенеп баш селкүемне сизми дә калдым.

Көн тәртипләре болайрак икән:

6.30 Уяну.
6.55 Милли көйләр ярдәмендә аланны уяту.
7.00 Әнис Фәритовичның рухи эшчәнлеге. *(Монысы безнең физкультура җитәкчесе була инде).*
7.30 Пакьлану.
8.20 Иртәнге ням-өфт.
9.20 Балаларны азаплау. *(Аз да түгел, ким дә түгел).*
12.00 Төшке ням-ням-өфт-хырт.
13.00 Алан мәшәкатьләре.
14.00 Үле сәгать.
16.00 Хырт-хырт.
17.00 Бүлмә әгъзаларының үз эшләре белән маташу вакыты.
19.00 Кичке ням-ням-өфт.
20.00 Матур кызлар белән бию.
21.00 План буенча төнге өфт-хырт.
22.30 Сәлкешләрнең йокларга таралуларына кызыгып карап тору.
23.00 Утны өзү.
23.00 Әйдәманнарны чыбыркылау.
...Төнлә яшереп гәзит чыгару. Вакыт калса—йоклау.

— Самат абый, боларның төтеннәре туры чыга чыгуын, әмма вак-төякләрдә ни әйтергә теләгәннәрен мин үзем дә бик аңлап бетермим шул,—дияргә мәҗбүр булдым. Самат абый акрын гына кеткелдәп куйды.

— Соң... мин дә шуны әйтәм түгелме соң?

Укытучыларның берсе—янәшәдән генә үтеп баручы Мәдехурга мөрәҗәгать итмичә булдыра алмадык. Ясалма акыл лабораториясе хезмәткәре Мәдехур Әюпов исә көлеп кенә куйды:

— Шул көн тәртибе инде ул. Тик үзләре өчен үзләренчә язганнар гына...

— Мәсәлән, ням-ням-өфт дигәннәре, яисә хырт-хырт дигәннәре нәрсәне аңлата инде.

— Ням-ням—ул кайнар аш дигән сүз. Төшкә аш та, икенчегә кайнар ризык та бирелә. Димәк ике ням, ягъни ням-ням килеп чыга. Ә хырт-хырт—печенье йә булмаса коржик ише нәрсә. Бер-ике мәртәбә хырт-хырт иттең дә бетте... Шул гына...

— Ә өфт дигәннәре?

— Анысы—эчемлек. Өфт иттең дә эчеп бетердең дигән сүз.

Самат абыйга кушылып рәхәтләнеп көлдек.

Менә шулай яшәп ятабыз инде!

## "Татар буласым килә..."

И Кара диңгез, Кара диңгез! Кара түгел, ә яп-якты, зәп-зәңгәр икәнсең лә син! Ул зәңгәрлекнең дә нинди генә төсмерләре юк! Сыек зәңгәр төс кинәт кенә куера да, көтмәгәндә яшькелт-зәңгәргә әверелә, тагын куера, каралҗым

яшелдән кинәт янә куе зәңгәргә әйләнә. Дулкыннар уйнаклый, дулкыннар белән бергә төсләр уйнаклый. Йә, ходаем, ул төсләргә кушылып безнең күңелләр уйнаклый. Ышанасы килми, җир йөзендә моннан да мәһабәт тагын берәр күренеш бар микән?!

Дингез тарафыннан усал җил өрә. Баш бирмәс дулкыннар пляжны зур судан аерып торган калын һәм биек бетон валларны сикереп кенә узалар да чал кергән көдрә башларын чуерташлы ярга китереп оралар. Әйтерсең лә алар кемнәндер гафу сорый, өзгәләнә, бәргәләнә, тамчылар томанга әйләнеп чәчләргә, иреннәргә куна. Дингез суы тозлы икән ләбаса! Шунда әллә нишләп башыма кётелмәгән бер уй килде: бәлки бу су дингез буенда яшәгән Кырым татарларының, фаҗигале язмышка дучар башка халыкларның ачы күз яшьләреннән тозлыга әйләнгәндер.

Шактый җилле көн булуга карамастан, яр буенда халык җитәрлек. Һәркемнең үз гаме гамь. Кемдер кояшта кызына, кемнәрдер ярсулы дулкын белән ярыша-ярыша колач салып йөзә, дулкын сыртында тирбәлә. Әмма, шторм вакытында коенырга ярамый, дип баштан ук кисәтеп куелган безнекеләр дингезгә сикереп төшәргә ашыкмый. Яр буенда гына торабыз. Әмма мең-мең чакрымнардан ашкынып килгән балаларны, яшьләрне ничек кенә тыеп тормак кирәк. Күзләренең ялтыравыннан,



*Саумы диңгез, и Кара диңгез!*

сокланып аһ итүләреннән күрәм, сизәм, һәркемнең башында бер уй: һичбернигә карамый дингезгә, шаулы дулкыннар кочагына ташланасы иде!

И гүзәл диңгез! Әллә балаларның ни уйлаганын аңлыйсың, сизәсең микән? Бер-берсен куып шаярышкан дулкыннарың кинәт артка чигенделәр дә ерактан йөгереп килеп балаларны баштанаяк суга коендырдылар. Диңгезнең мондый хикмәте дә бар икән. Күз ачып йомганчы манма су булган балалар чыр-чу килеп, өсләрен дә салып тормыйча яр буендагы дулкын иркенә бирелде.

Туапседан ерак түгел "Яз" пансионатында өч катлы бинаны тулысы белән диярлек безнең карамакка тапшырдылар. Икенче көнне иртән торуга ул инде танымаслык булып үзгәргән иде. Ишек өстендә "Сәләт" флагы җилферди, зур хәрефләр белән "Раушан" дип язылган плакат пәйда булган. Анысы безнең лагерь исеме. Борынгы телебездә бу сүз пакь, чиста, саф дигәнне аңлаткан. Аның янында ук игъланнар тактасы. Көн тәртибе, төркемнәр исемлеге, игъланнар, элеккеге сугышчан листокларны хәтерләткән нәни гәзитләр... Һәм барысы да татар телендә.

Казаннан компьютер һәм принтерлар алып килгән идек. Минитипографиябез төне буе эшләп чыккан димәк. Шулай итеп, пансионатта башкалардан аерылып торучы, үз рухи дөньясы,үз кайгы-мәшәкатьләре белән яшәүче татар утравы барлыкка килде.

"Сәләт" аланында гадәткә кергәнчә, монда да бөтен аралашу, уеннар, тәрбия эшләре—барысы да туган телдә. Туапседа, "Яз"да эшләүчеләрне, ял итүчеләрне иң гаҗәпләндергәне шул булды, ахрысы. Рәсәйнең төрле якларыннан килгән, шовинист ук булмаса да, үзен "беренче сортлы" халык дип санарга күнеккән урыс агай-апайлары каяндыр килеп чыккан "татарчонок"ларның үз телләрендә сөйләшеп, җырлашып, биешеп йөрүләрен башларына сыйдыра алмый интектеләр. Бу аларга нииндидер бер гайре табигый хәл булып тоела иде булса кирәк.

Беренчеме-икенчеме көнне үк шушындый бер сөйләшүнең шаһиты булырга туры килде. Күрәм, диңгез буеннан кайтып килүче бер төркем балаларны безнең корпуста торучы һәм үзен "казак атаманы" дип таныштырган, шактый гына кызмача бер агай туктаткан. Кыяфәте бер дә хәерхаһ булырга охшамаган. Сәлкешләргә күз-колак булырга өйрәнгәнлектән, тукталып сүзләренә колак салырга мәҗбүр булдым.

— Эй, вы, пацаны... Сез нишләп урысча сөйләшмисез?—диде "өлкән агаебыз" гөбедән чыккандай калын тавыш белән. —Әллә...—Әмма теле көрмәкләнгәнлектәнме, әллә уйлап җиткермәгәнлектәнме җөмләсен тәмамлый алмады.

Аның соравына өлкәнрәк малайлардан берсе сорау белән җавап кайтарды:

— Ә без нишләп урысча сөйләшергә тиеш ди әле?

Казак атаманы бер мәлгә телсез калгандай булды. Чөнки җавап үтә бер катлы булып тоелса да, төбендә исә баш бирмәскә омтылыш ярылып ята иде.

— Как так,—диде атаман.—Сез бит Русиягә килгән...

Малаебыз югалып калмады:

— Русиягә килгән һәр кеше урысча сөйләшергә тиешмени? Англиядән килгән инглиз яшьләренә дә шундый таләп куяр идегезме?

— Ләкин бит сез инглизләр түгел...

— Әмма без урыслар да түгел. Без бит татарлар! Безнең үз телебез бар.

Бу сүзләрнең чын күңелдән нинди горурлык белән, никадәр ышанып әйтелгәнен ишетсәгез иде сез!

Казак агае авыз эченнән сүгенде, мыгырданып куйды һәм кул селтәп китеп барды. Үзеннән бер баш түбән дип исәпләгән ниндидер татар балаларының үзләрен инглизләр белән тиң куеп сөйләшүләре аның ачуын чыгарганы күренеп тора иде.

Әле безнең сәлкешләргә милли горурлыкларын таныту, милләтебезгә ихтирам уяту, беркемнән дә ким булмыйча мондагы яшьләрдән байтак мәсьәләләрдә өстен икәнлекләрен раслау өчен шактый вакыт үтәсе, игълан ителмәсә дә, һәр адымда үзен сиздереп торган мәкерле "салкын сугыш"та җиңеп чыгасы да бар иде.

Уголовниклар кануниятлары белән яшәргә күнеккән Русиядә һәрбер шәһәрдә җирле "авторитет"лар була. Яшьләр арасында да шулай. Бу беркемнән дә сер түгел. Туапседа да шулай булачагын азмы-күпме тәгаенлый идек без тәгаенлавын.

Беренче сынау, татар яшьләренең "кылын тартып карау" килгән көнне үк булды. Бию кичәсе иде. Диңгез буенда заман ритмнары белән бергә татар көйләре яңгырый. Кечкенәдән җаныбызда, күңелебездә тамыр җәйгән таныш моңнар кайтавазы таулар-кыялар арасында бәргәләнә, аннары колач җәеп Кара диңгез өстенә тарала. Чит җирләрдә үз көйләреңне ишетү, үзебезчә биюләрне күрү бигрәкләр дә рәхәт, тансык икән шул! Әмма күрәм, мәйданчык тирәсендә күзгә күренмәс ниндидер ыгы-зыгы тоемлана. Ниндидер шом күләгәсе уйный.

Күңелдә төерләнә башлаган тәшвишле уйларымнан чыга гына алмыйм бит. Көтелмәгән ниндидер бер яман хәл булыр сыман. Лагерь җитәкчеләреннән Алмаз Хәбибуллинны читкәрәк чакырып сорыйсы иттем:

— Алмаз, нишләптер күңелем тыныч түгел. Син бер-бер хәл сизмисеңме?

— Борчылма, Флүс абый, барысы да тәртиптә. Аңлашырбыз. Беренче тапкыр түгел бит,—ди бу...

Болай ди икән, үзеннән-үзе аңлашыла, димәк, нәрсәдер булган.

— Җанымны кыйнама инде, Алмаз, әйт турысын, ни булды?

— Юк ла, берни дә юк,—диде ул һаман да ис китмәгән кыяфәт белән.—Безнең

бер малайның күзлеген салдырганнар... Шул гына...

— Соң...

— Сон, дип... Менә хәзер аңлашабыз. Алардан чапкын килергә тиеш.

Имәндә икән чикләвек! Бу бит инде безнең төркемне сынап карау дигән сүз! Куркып калмаслармы, җебеп төшмәсләрме? Әгәр беренче көнне үк баш исән, лагерьда ял көннәре беткәнче "жирле"ләрнең табаны астыннан чыкмаячаксын. Шуларны аңлатмакчы идем. Ләкин авыз ачарга да өлгермәдем, якындагы куаклар арасыннан авызы-борыны нәрсәгәдер буялган бер малай кисәге килеп чыкты да Алмазның җиңеннән тартты, үз артыннан барырга кирәклеген аңлаткандай башы белән ым какты.

— Чапкыннары килде, мин киттем,—диде Алмаз.

ВМК факультетын тәмамлаган, хәзер исә читтән торып юридик факультетта укып йөрүче Алмазыбыз нинди сүзләр, нинди дәлилләр тапкандыр, Туапсеның яшь ышпаналары белән ничек сөйләшкән-аңлашкандыр, анысы миңа караңгы, әмма шуннан соң безне бүтән борчучы булмады. Ахырдан гына белдем, күзлекне кире кайтару өчен хәтта ниндидер "салым" түләтергә дә җыенган булганнар икән.

Бию кичәсе дәвам итә. Әйтерсең лә уңышсызлыкка очраган "Күзлек операциясе" дә, ике арада "югары дәрәҗәдә" аңлашу да булмаган, Туапсе егетләре мәйданчыкка әйләнеп кайтты. Хәзер инде аларның ничек тә булса өстенлекләрен башкача күрсәтергә теләячәкләрен әле белеп бетермәгәнбез икән. Хәер, монысы яшьләр арасында табигый хәлдер инде. Бусы да озак көттермәде. Егетләр нәрсә хакындадыр җыелып сөйләшеп алдылар да уртага озын буйлы, киң җилкәле егет чыгып басты.

— Кем озаграк бии? Чакырам, рәхим итегез,—диде ул ирен чите белән генә елмаеп. Туапсеның озын-озак җәйләрендә дискотекалардан кайтып кермәгән "бию короле" монда, һичшиксез, өстен чыгачагын белә һәм инде үзен җиңүче дип хис итә иде булса кирәк.

Аңа каршы нечкә озын буйлы, чандыр гәүдәле Әлмәт егете Артур Шәрәпов чыгып басты.

— Башладык!—дип кычкыруга магнитофоннан житез ритмлы көй агыла башлады. Ул кызганнан кыза, торган саен тизрәк һәм дәртлерәк яңгырый. Егетләрнең аякларына, кул, гәүдә хәрәкәтләренә күз иярми. Тыпырдап, чүгәләп, гәүдәләренә әллә нинди башка сыймаслык бөгелешләр бирә-бирә биилләр дә биилләр. Инде кул чабып, такмаклап торучы кызларның тамаклары карлыкты, инде менә-менә кемдер арып аяктан егылыр сыман тоела башлады. Әмма музыка туктамый. И, Туапсеның "бию короле"! Кем белән ярышка чыкканыңны беләсеңме соң син?! Бу бит Артур, бу бит Әлмәт кенә түгел, бөтен Казан, Татарстан егет-кызларын шаккатырган егет, "Сәләт"нең бию чемпионы! Егетләр инде мөмкин булган бөтен хәрәкәтләрне ясап чыктылар кебек һәм кинәт... Артур аркасына таба бөгелеп төште дә куллары белән җиргә таянып, түгәрәк ясап әйләнә-әйләнә биергә кереште. Көндәш егет тә шундый ук хәрәкәтләр ясарга тотынды. Шулай күпме дәвам иткән булыр иде, билгесез, Туапсе егете хәлдән таеп торып басты һәм авыр сулап клуб стенасына барып сөялде. Әле һаман биюен дәвам иттергән Артурны сәлкешләр күтәреп алып күккә чөйделәр. Мәйданда аларның күмәкләшеп кычкырган тантаналы авазлары яңгырады:

— "Сәләт"—чемпион! "Сәләт"—чемпион!..

Бу инде, һичшиксез, бернинди алдаусыз чын һәм тулы җиңү иде.

Шул чакта кемнәрнеңдер сөйләшкәне колагыма чагылды:

— Кемнәр соң сез? Барыгыз да шундый оста биючеләрмени?

Җавапка кыска һәм горур тавыш ишетелде:

— Әйе!

Сез кемнәр? Безгә әле мондый сорауларны шактый күп ишетергә туры килер. Әмма бу беренче кичтә Туапсе яшьләре, Рәсәйнең төрле якларыннан килеп "Яз"да ял итүчеләр сәлкешләр белән чын-чынлап кызыксына башладылар. Һәм сорауларына тиешле җавапны да алдылар. Сәлкешләргә карата хөрмәт хисе әнә шулай тамырланды.

Бу ихтирамны, бу тануны без көндәлек эшебез, үзара мөгамәләбез, тәртибебез, табигатькә, кешеләргә булган мөнәсәбәтебез белән дә расларга тиеш идек әле.

Екатеринбург яшьләре белән КВН кичәсендә көч сынашу, тапкырлыкта, шаянлыкта, җыр-биюгә осталыкта өстенлегеңне раслау да, яшьләребезнең тыйнаклыгы һәм бердәмлеге дә, дуслыгы, үзара ярдәмчеллеге, ерактагы якын кардәшләребезне—Кырым татарларын эзләп табып, аларны кунакка чакыру, хөрмәт итү дә әнә шул ихтирам бинасының кирпечләре булды. Көннәрдән бер көнне, ял итүчеләр арасында гомердә булмаганча, лагерь ихатасын җыештыру буенча өмә игълан итеп, эш кораллары сорап кергәч пансионат директоры башын чайкап әйтәчәк сүзләр дә алда әле.

— Сез мине көннән-көн ныграк гаҗәпләндерә барасыз,—дигән иде ул. Һәм бу сүзләрдә татар яшьләре белән соклануны аңлавы кыен түгел иде.

Җирле егетләр, ниһаять, сәлкешләрне таныдылар, заман биюләренә генә түгел, татарча биюләргә дә бик рәхәтләнеп кушыла башладылар. Безнең кызлар белән култыклашып әйләнү дисеңме, кара-каршы тыпырдау дисеңме, берсе дә калмады. Һәм бу аларга бик тә ошый иде. Әмма... бу хәл көтмәгәндә үз егетләренең игътибарыннан читтә калган шул ук җирле кызларның ачуын чыгарды.

И хатын-кызның хәйләкәрлеге! Яшь булсалар да, болар да шул кавемнән бит. Һич көтмәгәндә егетләреннән "колак какканны" аңлаган кызлар ничек тә булса бу бердәмлекне, бу түгәрәкне бозу чарасы күрергә тиешләр иде. Алар аны тапты да. Берберсенә тотынып, ачы тавышлар белән кычкыра-кычкыра түгәрәк эченә бәреп керделәр дә бөтен хәрәкәткә каршы төшеп тулганырга керештеләр. Бу бернечә тапкыр кабатланды. Биюнең яме китәсе көн кебек ачык иде. Шул чакта, белмим, кайсысыдыр әйттеме-юкмы, әмма сәлкешләр бер-берсенең иңеннән кочып тыгыз түгәрәк ясадылар. Инде алар арасына җил дә үтеп керерлек түгел иде.

* * *

Ташлы-таулы, кипарислы-пальмалы борынгы Туапсе җире! Син бәлки беренче тапкыр үз күкрәгеңдә татар яшьләренең дәртле күмәк биюләрен тойгансыңдыр, Идел буйларыннан килгән ашкынулы көйләргә колак салып изрәгәнсеңдер. Ләкин олы йөрәкле сәлкешләр үзләре белән яшерен моңнарын, гомерләрендә беренче зур югалту ачысын да алып килгәннәр иде сиңа!

18 июль... "Сәләт"нең, сәлкешләрнең кайгы-матәм көне. Моннан нәкъ бер ел элек "Сәләт"нең якын дусты, күренекле әдәбиятчы, "Идел" журналының баш редакторы Фәиз Зөлкарнәйнең автомобиль һәлакәтенә юлыгып арабыздан мәңгелеккә киткән көне. Шул көнне бер үк вакытта ике җирдә—Казанда һәм аннан меңнәрчә чакрым еракта—Кара диңгез буендагы Туапсе шәһәрендә Фәизнең еллыгы, аны искә алу көне үткәрелде.

Бергәләп дустыбызның тормыш юлын, иҗатын, Әлмәттәге "Сәләт" аланында бергә үткәргән көннәрне искә төшердек. Талантлы шагыйрь, олы җанлы кеше иде Фәиз. Аның турында сөйләгәндә, хатирәләр уртаклашканда, шигырьләрен укыганда сәлкешләрнең күзләрендә яшь бөртекләре күрдем мин. Олы кайгыны йөрәкләренә сыйдыра белгән сәлкешләр аеруча якын, кадерле иде миңа бу минутларда.

Кеше кайгысын, кеше фаҗигасен аңлый белү... Андый хис бик сирәкләргә генә бирелә. Һәм безне олы фаҗигага дучар булган халык—Кырым татарлары белән очрашу, танышу, алар дучар булган фаҗиганең бөтен тирәнлеген аңлап дуслашу мизгелләре дә көткән икән.

Шәһәргә татар яшьләре килү хакындагы хәбәр Туапседа, аның янындагы бистәләрдә бик тиз таралып өлгерде. Инде безнең татарча сөйләшүгә дә, татарча җырбиюләргә дә гаҗәпләнмиләр, шулай булырга тиеш дип кабул итә башлаганнар иде. Татарстанның суверенитетын да, республика президентын, аның акыллы, сабыр сәясәтен дә искә төшерделәр. Һәм барысына да сәлкешләрнең үзләрен лаеклы тота белүләре сәбәп булды.

Диңгез буеннан җәяүләп кенә Туапсега таба барыш иде. Үзара әңгәмә куертып, шаярышып бара-бара яныбыздан атлаучы, яше буенча ир уртасы чамасы бер кешенең сүзләребезгә колак салып килүен абайламый да калганбыз. Бераздан ул үзе сүз кушты:

— Сез татарлармы әллә?—диде ул безгә якыная төшеп.


— Әйе,—дидек.

— Ишеттем, беләм... Татарларның сәләтле балаларын җыеп, бергәләп ял иттерүләре, аларның итагатьле, тәртипле булулары хакында Туапседа сокланып сөйлиләр,—диде ул һәм яр өстеннән диңгезгә таба асылынган кыяларга күрсәтеп сүзен дәвам итте.—Ә сез беләсезме, моннан ерак түгел, ялгышмасам, өченче тарлавыкта булса кирәк, тулы бер татар авылы бар бит. Казанныкылар да, Кырымныкылар да яши иде анда. Хәзер ничектер, белмим...

Абзыйдан тарлавыкка ничек үтү хакында бәйнә-бәйнә сорашкач, Туапседан кайтышлый шул авылга сугылырга сүз куештык.

Текә таулардагы кәҗә сукмакларында, кыргый алмагач, слива, башка җиләк-җимеш, чия куаклары һәм без танымаган әллә нинди төрле агачлар баскан, үрмәле үсемлекләр белән чәбәләнеп, чуалып беткән тау битләрендә бик озак адашып йөрдек. “Таба алмыйбыз, ахрысы, икенче тапкыр килеп эзләп карарбыз”,—дип инде кул селтәргә җыенганда гына ниндидер йортлар янына килеп чыкканыбызны сизми дә калдык. Беренче капканы шакыдык. Безнең кемне эзләвебезне белгән марҗа түтәй артык гаҗәпсенү күрсәтмәде.

— Әйе, әйе, торалар иде. Хәзер инде күбесе Кырымга кайтып китте. Монда



*Кырым татарларында кунакта.*
*Сулдан икенче һәм өченче: Гайшә апа һәм Әхмәт Мәмәтовлар.*

шул ике-өч гаилә, картлар гына калды,—диде ул күзләрен кыса төшеп.—Минем каршыда да татарлар яши. Исеме артык катлаулы, әйтергә телем әйләнми.

Кырым татарлары—күршесенә исеме артык катлаулы тоелган Гайшә исемле апа һәм аның ире Әхмәт абый белән шулай таныштык. Ун ел күрешми торган якын туганнары килгәнмени! Кая утыртырга, сыйларга ни-нәрсә куярга белми кухня тирәсендә тыз-быз килгән Гайшә апага карыйм да сокланам. Аның җыерчыклар баскан, әмма картларча матурлык, садәлек бөркелеп торган йөзеннән елмаю китми, телендә берсеннән-берсе тәмле сүзләр. Телләребез дә, кунакчыллык кебек гадәт-йолаларыбыз да бер икән ләбаса! Әйтерсең лә без меңнәрчә чакрым үтеп Кара диңгез буендагы биек таулар арасына поскан тарлавыкта яшәп ятучы Кырым татарларында түгел, ә бәлки үзебезнең Мөслим якларындагы гап-гади авыл өендә. Аерма булса,

шул җиләк-җимеш күплектә һәм табигатьнең үзгәлегендә генәдер.

Сөтле чәй, Кырым татарларынча сөтле кофе янында сүзгә сүз ялганды. Ике сәгать эчендә туган йортын ташлап китәргә мәҗбүр ителгән Кырым татарларының, кулына нибарысы бер чемодан алырга рөхсәт итеп туган өennән куылган яшь кызның аяныч язмышы күз алдыбыздан узды. Ләкин Гайшә апа беркемгә дә үч сакламый. Барысын да гап-гади иттереп, үткәндәге сагышлы хатирәләр итеп кенә сөйли дә сөйли. Шаккатарлык бит, сугышка кадәр үк шәһәр мәгариф бүлегендә эшләгән, югары педагогик белемле кызга сөргендә инде хәтта балалар бакчасында савыт-саба юучы булып эшләргә дә рөхсәт итмиләр.

Сугышның башыннан ахырынача фронт юлларын узган, күкрәген сугышчан бүләкләр бизәгән һәм... җиңү көнендә кулга алынып милләттәшләре янына сөргенгә озатылган Әхмәт абый белән табышу, коточкыч шартларда исән-имин калып гаилә кору—боларны тасвирлау өчен күләмле аерым бер язма кирәк булыр иде. Әмма, ничек кенә булмасын, Гайшә апа белән Әхмәт абый исән калганнар, үз дөньяларын корганнар, угыллар-кызлар үстергәннәр. Йорт-җирләре, каралты-куралары төзек, ишегалдында мәһабәт армуд (груша), алма, өрик (слива) агачлары, өй алдындагы мәйданчыкка түбә хасил итеп өскә үрмәләгән йөзем куаклары. Йөзем күләгәсе астында зур аш өстәле, урындыклар. Җәй көннәре һәрвакыт шушында, тышта үтә икән.

Туапсега килеп урнашуларына да утыз елдан ашкан икән инде.

— Ул чакта бик каты чирли башладым мин,—дип сөйли Гайшә апа.—Табиблар яман шеш таптылар. Һичнәрсә ярдәм итмәячәген дә беләм инде. Табибәм дус кеше, әрмән хатыны иде, шул әйтте: “Сиңа бу як һавасы ярамый, булдыра алсаң, туган ягыңа кайт. Бердәнбер котылу юлы шул. Котылсаң, шунда котыласың. Башкача дәвалап булмый”,—диде. Кырым татары икәнлегемне әйткән идем, күзе шар булды. Безгә бит Кырымга кайту түгел, ул хакта сөйләү дә тыелган иде. Уйланып утырды-утырды да тагын киңәшен бирде: “Гайшәкәем, һич югы Кырымдагыча климат булган җирне эзләп кара. Бәлки...” Шулай иттереп менә бу якларга килеп чыктык. Мин бит Ялтада туып-үскән кыз. Монда да нәкъ Ялтадагыча Кара диңгез, шундый ук култык, хәтта Аю-Дагка охшаган тавы да бар. Әнә ерак та түгел шундый ук порт күренеше. Кыскасы, охшаттык без бу җирне. Тәвәккәлләдек тә, Әхмәт белән килеп төпләндек менә.—Гайшә апа моңсу гына елмаеп куйды.—И алланың рәхмәте! Шушында куәчкәч тәки аякка басып киттем бит. Хәзер ул чирнең ни икәнен дә белмим.

Җитмешнең өске ягына чыккан Гайшә апа, күз тимәсен, сәламәтлегеннән зарлана торган кешегә охшамаган. Дуслыгыбыз шулай башланды. Моннан соң да без алар янына әле тагын берничә мәртәбә килдек. Килгән саен капчык-капчык тутырып, алтмыш балага ике-өч көнгә җитәрлек итеп алмасын, грушасын, сливасын төяп җибәрделәр. Ә инде аларның үзләрен, күршеләре Ләйлә апа белән Тавидә апаны “Раушан”га чакырып кунак итү, аларга багышлап махсус кичә һәм концерт оештыру (концертта Кырым татары—Дамир исемле егет тә Кырымча биеп күрсәтте) лагерьның иң истәлекле вакыйгаларыннан берсенә әверелде. Төз сынлы, төскә матур, чибәр татар балаларын күргәч Гайшә апа һәм аның юлдашлары йөзендә чиксез соклану, ярату билгеләре күрдем мин.

Туган җир газиз шул. Аның һавасы да, туфрагы да, суы да шифалы дип юкка әйтмәгәннәр. Хәтта туган җирендәгегә охшаган икенче бер як һавасы да Гайшә апаны әнә шулай үлем тырнагыннан йолып калган.

Санаулы көннәр бик тиз уза да китә. Менә инде без Туапсе белән, кунакчыл “Яз” пансионаты белән хушлашабыз. Озатуга, «Раушан» лагерен ябу тантанасына монда дуслашып өлгергән танышларыбыз, хәтта тулы составы белән ял йорты хезмәткәрләре дә килгән. Мондый хәл пансионатта бик сирәк, бик олы кунакларны озатканда гына була торган хәл икән. Лагерьга килгәннән бирле безнең арада буталган алты яшьләр тирәсендәге Данил исемле малай да шушында. Җитен кебек ап-ак чәчле, ак йөзле бу малай, нишләптер, беренче күрүдә үк кыяфәте белән нәкъ үзенә охшаган, шундый ук ак чәчле, ак йөзле Мәдехур дигән егетне үз иткән иде. Иртән дә аның



*Менә без дә кунакчыл җир белән хушлашабыз.*
*Бу язманың авторы язучы Флүс Латыйфи (сулда) һәм республика "Сәләт" хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе шагыйрь Сөләйман мәңгелек агачы—секвойя янында.*

янына килә, кичен дә хушлашып чыга торган булып китте. Хәтта шаяртып аларны "аталы-уллы" дип йөри башлаган идек инде.

Хушлашканда төрле теләкләр әйтелә бит. Яшенә күрә бик акыллы Данил да безгә бәхетле юл теләп, тагын килергә чакырып маташа. Мәдехур нәни дустының кулыннан алып мондый очракларда гадәттә балаларга әйтелә торган соравын бирде:

— Данил, ә син үскәч кем булырга телисең?

Малай бер минут та уйланып тормады, чатнатып җавап бирде:

— Минем үскәч, сезнең кебек татар буласым килә.

Тирә-яктагылар шаулатып көлеп җибәрде. Данил исә оялып башын аска иде.

Хәзер дә үкенәм, "Оялма, нәни дустым! Бу ояла торган нәрсә түгел, ә бәлки горурлана торган сыйфат", дип башыннан сыйпыйсым килсә дә, нишләптер ул чакта җае чыкмый калды. Нәниләр ялгышмый белми. Димәк, сәлкешләр үзләренең дуслыклары, үз-үзләрен тотышлары, шаянлыклары, кешеләргә һәм әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтләре белән дә бу кечкенә малай күңелендә соклану, аларга охшарга теләү хисе уятканнар. Бусы инде аның иң мөһиме!

Димәк, Туапсе җирендә татар балалары, яшьләре турында якты истәлекләр калды.

*1998 ел, октябрь.*

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# КЕЧЕ КИРМӘННЕҢ ОЛЫ РИНАТЫ

ЯЗУЧЫ РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Бөек шагыйребез Г. Тукай үзенең мәгълүм шигырендә: "бер чишмә бар, якын безнең авылга ул", дип яза. Әнә шул чишмә бик тә серле, шифалы, шагыйранә илһамлы булып тоела. Әгәр ул чишмәсе булмаса, Кушлавыч авылы татар халкының рухын дөньяга таныткан бөек шагыйрьне тудыра да алмас иде кебек.

Чишмә—дөрестән дә, табигатьнең хикмәтле һәм могҗизалы күренеше, яшәешнең саф нигезе бит ул. Әнә Ринат Мөхәммәдиев тә үзенең Мөхәммәт Мәһдиев турындагы бер истәлегендә Тукай чишмәсенең әле бүген дә кешеләргә сихәт биреп, дәртле тибүенә сокланып яза:

"—Тыңла,—дип, дәү бармаган иреннәренә тидерде Мөхәммәт абый.— Ишетәсеңме? Шаулый... Тибә...

Мин дә сагаеп тыңлыкка колак салдым.

—Тукайны тудырган илаһи көч исән. Исән икән әле...

—Шагыйрьгә, аның бөеклегенә турыдан-туры мөнәсәбәттә бит бу чишмә. Нәни Апушның балалыгыннан калган бердәнбер җанлы шаһит.

Мөхәммәт абый... чишмәнең читенә үк килде. Ике кулы белән таш өстенә таянды да, йөзтүбән ятып су эчте. Йотлыгып-йотлыгып эчте ул Тукай чишмәсенең суын. Гомер чишмә күрмәгәндәй эчте. Мин исә тизрәк үземә дә чират җиткәнен көтеп, аерым бер төрле сусау белән сокланып күзәтеп тордым аны".

Югыйсә, Ринат Мөхәммәдиевне чишмәләр белән шаккаттырып буламы инде? Аның Мамадыш төбәгендәге Кече Кирмәнендәге кебек чишмәләрне тагын кайсы якларда табарсың икән? Су буе тоташ чишмәләрдән генә тора диярсең! Алар тау битләреннән дә агып төшә, агачлар арасыннан да кайнап чыга, болын үләннәре арасыннан да тыйнак кына тибә. Чишмә... чишмә... Һәрберсенең үз суы, үз моңы! Тукай туган авылдагы бер, әмма берәгәйле чишмә суыннан авыз итү өчен М. Мәһдиевтән соң Р. Мөхәммәдиевнең сусап үз нәүбәтен көтеп торуын язган урынны әлеге истәлектән кат-кат укыйм, кинәт шушы күренешнең тирән мәгънәсен ачкандай булам.

Чишмәләр мәңгелек. Кечкенә Габдулла, бер ишектән сөрелсә, икенчесенә керә-керә, кулдан-кулга ил буйлап михнәт чигеп йөрергә чыгып китте дип тормаган, янадан-яңа буыннарга сихәт биреп, аккан да аккан Кушлавыч чишмәсе. Әнә Гариф Ахуновның Өчиле авылы бүген бөтенләй үк юкка чыккан, ә чишмәләре исән! Р. Мөхәммәдиевнең Кече Кирмәне, ышануымча, беркайчан да бетмәс. Чөнки дәүләтле, шанлы һәм горур чакларыбыздагы элгәрләребез үз тәннәренә дәва, зиһеннәренә куәт алган әлеге чишмәләрнең нindидер тагын бер үзлеге бар кебек тоела миңа. Алар үзләренең суын эчеп үскән токымнарны шушы тирәдән читкә җибәрмиләр, үз яннарына тартып торалар. Киткәннәре дә, Ринат кебек, авыл белән бәйләнешен өзми яши.

Тукай чишмәсенең суы тәмен, аның шигърияте тәэсир көчен, әйе, һәркем үзенчә татый. Ринат аларны башта туган авылы мәктәбендә, аннан Казан университетында тәмләп карады. Аспирант чагында һәркайсы әдәбиятыбызның үзенә күрә асыл чишмәсе булган Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Кәрам, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти һәм башка каләм әһелләребезнең иҗатларын өйрәнеп, "Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары" дигән темага диссертация язды. Ул аны

кайда яклады дисез? Мәскәү дәүләт университетының үзендә! Башкала галимнәренә татар сүз сәнгате үсешенең бик әһәмиятле этапларын һәм тенденцияләрен әнә шундый җитди хезмәткә нигезләнеп күрсәтеп бирү галимнен шәхси эше генә түгел иде. Диссертацияне яклауда катнашкан галимнәр фикеренчә, бу тулаем татар әдәбиятының зурлыгы һәм затлылыгын раслау буларак кабул ителде. Һәрхәлдә Мәскәү галиме Роберт Бикмөхәммәтовның шундый югары бәя бирүе хәтердә уелып калган.

Шуннан соң аның тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге хәзерге әдәбиятыбыз тарихына үзенә бер сәхифә булып кереп калыр. "Әгәр без янмасак..." (1980), "Якутлар табыладыр вакыт белән" (1983) кебек тәнкыйть китаплары, газета-журналлардагы мәкаләләр... Каләм әһелләре арасында аны "усал тәнкыйтьче" дип йөртә башладылар. Аның ул елларда язганнарын бүген укып карыйм да: юк, усал түгел, ә гадел, әдәбиятның бүгенгесе һәм киләчәге өчен ихлас кайгыртучы тәнкыйтьче, диясе килә.

Каләм әһелләренең шундыйлары була, алар беренче әсәрләре белән үк җитлеккән язучы икәнлекләрен раслыйлар. Ягъни вакытларын өйрәнчеклек чорына сарыф итеп тормыйлар. Р. Мөхәммәдиевкә килгәндә, ул әдәбияттагы өлгерү чорын әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме белән шөгыльләнү чорында кичерде. Сиксәненче еллар башында үзенең язучы талантына ия икәнлеген күрсәтте. Башкалар язганнарга бәя биреп, аларны тәнкыйтьләп "аргач", әйтерсең лә, "чын әдәби әсәр менә шундый була ул", дип, үзе иҗат итеп күрсәтергә теләде.

Ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятыр, дигәндәй, яшь тәнкыйтьченең күңелендә проза әсәрләре бөреләнеп өлгергән икән, моңа бер дә гаҗәпләнергә кирәкмидер. Башта ул бөреләр балалар өчен хикәяләр рәвешендәге җимешләр бирү өчен чәчкә атты. 1979 елда басылган "Яңа елга күчтәнәч" дип исемләнгән китабы Р. Мөхәммәдиевкә аеруча кадерле һәм якын. Чөнки ул, бик юка гына булса да, язучылык сукмагыннан кереп китүдә беренче адым иде. Һәм ул, тупланган хикәяләрдән күренгәнчә, ышанычлы адым булды.

"Беренче умырзая" повесте исә татар әдәбияты хәзинәсенә өстәлгән җитди бер казаныш буларак кабул ителде. Мин әлеге әсәр белән Г. Бәшировның "Җидегән чишмә" романы арасында рух якынлыгы, бик күп уртаклык күрәм. Рәхимҗан белән Гайнан образлары күңелләренең матурлыгы, табигатькә булган мәхәббәтләре ягыннан бертуганнар кебек тоела.

Умырзая—тәүге чәчәк, елның иң матур, саф фасылы булган язның беренче хәбәрчесе. Кешенең унҗиде яшьлек вакытын да әнә шул язга тиңләргә мөмкин, ул—кеше тормышындагы яз башы. Р. Мөхәммәдиев умырзая белән унҗиде яшьлек егет-кызларның уртак якларын күрсәтүнең гаять отышлы бер җаен тапкан. Умырзая яшьләр өчен аларның бөтен гомеренең юнәлешен билгеләүче, язмышларын хәл итеп куючы бер кодрәтле көч чыганагы булып әверелгән, дөресрәге—алар шуңа ышанганнар.

Сюжетның мавыктыргыч, вакыты-вакыты белән моңлы булуын тәэмин итү өчен Р. Мөхәммәдиев үз геройларына бик матур бер ырым тәкъдим итә: беренче умырзаяны өзгәндә, кеше нинди дә булса теләк теләргә тиеш. Әмма үзең өчен изге булган шул максат-омтылышыңны сер итеп саклау мәҗбүри. Рәхимҗан, Фазыл, Зәйнәп, Фаягөл—урта мәктәп тәмамлап килүче бу егет-кызларның—һәммәсенең дә уртак бер хыялы бар: шәһәргә китү. Зәйнәп белән Фаяз өчен бу—әлегә бердәнбер теләк икән. Ә Рәхимҗан исә, шуңа өстәп, Зәйнәп белән мәхәббәттә уртак тел табарга, ә Фаягөл Рәхимҗанны үзенеке итеп күрергә омтыла. Фаяздан башкалары умырзая чәчәген өзгәндә күңелләренә килгән теләкне башкаларга әйтмиләр, яшереп сакларга тырышалар. Ләкин аларның гөнаһсыз күзләре ул серне асылын әйтеп тора.

Китеп карыйлар алар калага... Ләкин Нурлы Аланда туып үскән яшьләр үзенең туган җиреннән аерылып та китәргә мөмкин, әмма, туфрагыннан кубарып, яңа урынга утыртылган гөл кебек, ул авырый, җирси башлый. Тернәкләнеп китсә—яши, тамырларына ят мохиттә хәл кереп китмәсә, аның язмышы инде бетүгә хөкем ителгән була. Фаяз, әнә шулай сагыну авыруы белән чирли-чирли байтак еллар түзә, авылны юксынуы аның һәр хатыннан сизелеп тора. Зәйнәп исә, сер бирмәскә тырышып, бер хәрбигә кияүгә чыга, балалар үстерә башлый. Фаягөл өчен исә хакыйкать ачык: сөйгән кешең кайда булса, шул җир матур булып тоела. Аның ярата алу сәләте күңелдә хөрмәт уята.

Рәхимҗан күңел дөньясының байлыгы ягыннан яшьтәшләреннән нык аерылып тора. Тәхфәт бабасы аның күңеленә туган авылга, берсеннән-берсе матур чишмәләргә,

табигать могҗизасы булган атларга карата ярату орлыкларын салган, аларның шунда ныклап урнашып, тамырланып шытым җибәрүләрен тәэмин иткән. Башта ул да, модага ияреп, авиация институтына кереп карый. Ләкин самолет, техниканың иң югары казанышларыннан берсе булса да, һич тә табигатьнең җанлы сулышы белән тиңләшә алмый икән. Рәхимҗанга техника дөньясы үзе дә, аның тирәсендә йөрүчеләр дә ят, сәер тоела. Бабасының үлеме аның моңарчы күңелендә бик үк ачык булмаган теләген ныгыта—ул авылда яшәргә, атлар тирәсендә кайнашырга, чишмәләр тавышын тыңларга, яшел чирәмнән аерылмаска тиеш икән. Бу—аның өчен табигый мохит. Биредәге кебек гүзәл чишмәләрне тагын кайдан табарсың? Чегән чишмәсе, Фазыл чишмәсе, Ризван каеннары чишмәсе, Карт тирәк чишмәсе, Ялгыз чишмә... Һәрберсенең үз тәме, яме һәм тарихы бар. Авылның борынгысын, аңа бәйләнешле риваятьләрне яхшы белгән Төхфәт бабасы сөйләгәннәр хәтергә тирән уелып калганнар икән. Аларны тыңлагач, Рәхимҗан күңеленә килгән иң беренче сорау мәгънәлелеге белән игътибарны җәлеп итә. "Нигә мәктәптә туган авыл тарихын укытмыйлар икән? Мәктәптә бит, бабай, күбрәк борынгы Рим һәм Греция тарихын өйрәтәләр безгә. Үз авылың, аның кешеләре, чишмә һәм урман сулары турында сөйләшергә вакыт калмый. Кызык килеп чыга", ди ул. Р. Мөхәммәдиев, шул рәвешле, бу мәсьәләне 1984 елда— әле рәсми идеология татар халкын тарихсыз кавем дип исәпләгән бер чорда әйтә. Ул әле мәсьәләне "нигә татар халкы тарихын өйрәнмибез" дигән рәвештә куймый, дөресен әйткәндә ул шартларда алай әйтә дә алмый иде. Рәхимҗанның бабасы авызыннан "җитәр, улым, андый чаклар да җитәр",—дип әйттерүе шулай да киләчәккә өмет уятып калдыра иде.



*Сулдан уңга:* ***Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Әминә Җәлилова, Ринат Мөхәммәдиев, Шәмси Хамматов (утырганнар), Нил Юзиев, Рафаэль Мостафин.***

"Беренче умырзая"—Р. Мөхәммәдиевне язучы итеп таныткан әсәр, ул аның алдагы барлык иҗатына кереш булып кабул ителә. Чыннан да, язучының шуннан соңгы иҗаты әлеге повестьта күтәрелгән мәсьәләләрне тагын да тирәнәйтү, тәгаенләү һәм образлырак сурәтләү юнәлешеннән үсеп китте. Г. Исхакый өчен дә "Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәре иҗатының кереш сәхифәсе булган иде бит. Дөресендә, бу повесть үз иҗаты өчен генә түгел, XX йөз башының байтак каләм әһелләренә дә этәрелеп китү өчен таяну ноктасы хезмәтен үтәде. Шуның кебек, Р. Мөхәммәдиев тә егерменче йөзнең соңгы ун-унбиш елындагы әдәбиятыбызның йөзен, аның кыйбласын билгеләүче иҗатчылардан берсе булып әверелде.

Язучының индивидуальлеге турында сөйләшкәндә аның гомуми агымнан

аерылып торган якларына, үзенә кадәр булган традицияләрне үстерүгә керткән өлешенә игътибар итәләр. Ә традицияләргә килгәндә, Р. Мөхәммәдиев аларны әдәбият галиме буларак та, иҗатчы сыйфатында да яхшы белә. Иң мөһиме—ул фикерләрне һәм хисләрне тулы белдерергә мөмкинлек бирүче телебезнең байлыгын яхшы файдалана. Аның әсәрләрендә тел чатаклыкларына төртелү шактый сирәк күренеш. Ул һәр сүзнең анык асылын, гомуми контекстта әлеге тәгъбир алып килә торган мәгънә һәм тойгы йөгөн сизгер тоеп эш итә. Бу җәһәттән аның повестьлары аеруча җентекләп эшләнгән. "Беренче умырзая", "Ак кыялар турында хыял", "Истәлек өчен—Гыйлемханга" кебек әсәрләрнең теле башка каләм әһелләренә үрнәк булып хезмәт итә ала. Әлеге җәһәттән "Ак кыялар турында хыял" әсәре (1985) аеруча нечкәләп, нәфис итеп эшләнгән. Бу повесть һәм темасы, һәм образлары, һәм үзәккә куелган мәсьәләләрнең үткенлеге белән татар әдәбиятында яңа сүз иде.

Бу очракта Р. Мөхәммәдиевнең укучыга әйтергә теләгән төп фикерен аерып алу җиңел түгел. Күпчелек укучылар аның аеруча күзгә ташланган беренче катламын гына күрәләр. Әйе, автор әсәрдә фәлсәфи фикерләү остасы буларак чыгыш ясый. Башлары болытларга ашып, өскә сузылган ак кыялар—карап торышка мәһабәт, әмма серле. Аларның тышкы күренешләре үк ниндидер тылсымлылыкка, билгесезлеккә ишарәли, ә эчке төзелешләре, алардагы эчтәлек кеше өчен укылмаган китап булып кала. Р. Мөхәммәдиев әдәбиятыбызга ак кыялы тауларга бәйләнешле гаҗәеп кызыклы фәлсәфә алып керде. Хәзерге татар җирлегенең үзендә андый таулар юк. Әмма борынгы болгар, кыпчак әби-бабаларыбыз заманында, алар Кавказда, Кара диңгез буйларында да үз булып гомер кичкәндә, булган бит ул таулар, булган! Тау-кыялар Р. Мөхәммәдиев әсәрендә символик мәгънәгә ия. Автор биредә җисмән тауларны гына түгел, бәлки халкыбызның элек-электән үзен башка кавемнәрдән һич тә ким-хур сизмичә, киресенчә, дәүләтчелеген тәэмин итүдә бик күпләр хыяллана да алмаган биеклекләргә ирешеп гомер кичергәннәрен дә искәртә. Әсәрнең бер үзенчәлеге—аның эзоп теле белән, тел төбе мәгънәләре белән язылуында. Юк, телендә генә түгел, анда сурәтләнгән Микәй исемле тау кәҗәсе образы да, шулай әйтергә яраса, "эзоплык" чаралары ярдәмендә тудырылган.

Микәй—ерак таулар иленнән безнең якларга алып кайтылган тау кәҗәсе. Әлбәттә, ул иң әүвәл үзенең тышкы кыяфәте белән бездәге кәҗәләрдән нык аерылып тора. Көмеш төсендәге йомшак йоны гына да ни тора! Шул йоннан бәйләнгән шәл, бияләй ише әйберләрнең даны бөтен тирә-якка тарала. Җитмәсә әлеге кәҗә тәкәсе бик үрчемле булып чыга, аның авылда шундый ук нәфис йонлы күпсанлы токымы да үсеп китә. Монысы—күзгә күренеп торган аерымлыгы. Ләкин Микәйнең төп үзенчәлеге аның холкында. Әлеге кәҗә тәкәсе җанына-тәненә салынган ниндидер "кодлар" буенча шуны сиземмли: ул үзенең табигатенә ят-чит булган мохиткә килеп эләккән. Томанлы рәвештә генә хәтерендә сакланган хатирәләр дә аның кайдадыр ак болытлар артындагы таулы-кыялы яклардан икәнлеген искәртеп торалар. Һәр җан иясенең үз мохитында һәм табигый яшәү рәвеше белән гомер кичерүе генә аның тормышын бәхетле, җайлы итә. Эчке омтылышы Микәйне дә һәрвакыт өскәрәк, биеккәрәк ымсындыра. Ул хуҗасының каралты-курасындагы иң биек ноктага—түбә кыегының очына—менеп баса, "күкрәкләрен киерә төшеп, башын турайта һәм күнеле булганчы" карашын еракларга төбәп тора. Шулай итеп, ак кыялар илен күрергә хыяллана. Әнисенең әйткәне исеннән чыкмый: "Ак кыяларда гына сез рәхәтләнеп иректә йөри алырсыз". Ә тау кәҗәләре өчен иң куркыныч җан ияләре—кешеләр. Аю, бүреләрдән котылып була, ә кешеләр—аяусыз. Аларның мең төрле хәйлә-мәкерләре бар, ди әниләре.

Менә шушы урында иректәге тау кәҗәләренең һәм Микәйнең кешеләр турындагы фәлсәфәсендә нык аерымлык барлыкка килә. Микәй—иркеннән мәхрүм ителгән, үз теләге белән түгел, бәлки кешеләр тарафыннан тәкъдим ителгән шартларда яшәргә мәҗбүр булган тау кәҗәсе. Шул ук вакытта ул кешеләрнең аңа карата нинди явызлык кылганлыкларын дөрес итеп бәяли алмый. Аны, бер караганда, ашаталар-эчертәләр, җылы урында асрыйлар, яраталар. Ул гоманлавынча, кешеләр һич тә начар түгел кебек.

Әйе, коллар да үз хәлләренә әкренләп күнегәләр бит. Шул гайре табигый хәлне нормаль яшәеш дип уйлый башлыйлар. Башкача гөман итмәсен өчен, аны үзенең кол хәленә тагын да күнектерә төшәргә кирәк. Ч. Айтматовның манкорты сыман, ул хәтерен җуярга тиеш. Г. Исхакыйның "Инкыйраз..."ы да, шундый хәтәрдән

сакланырга чакырып, чаң сугу иде бит. Ә кешене дөрес юлдан яздыруның сыналган алымнары бар. Аларның берсе—эчүгә сабыштыру. Беркемгә баш бирмәгән, үзенчә яшәгән, ата-бабалар горурлыгын кадерләп саклаган Микәйне аек акыллы чакта баш идереп, читләр ихтыярына тулысынча буйсындырып булмый. Шуңа күрә кешеләр аны юлдан яздыру гамәленә керешәләр. Башта әкренләп тәмәке тартырга, аннан инде аек акылның иң явыз дошманы—аракы эчәргә күнектерәләр. Исереклек халәте ихтыярны үзле балчыкка, балавызга әйләндерә. Эчүчелек хиреслегенә бирелгән җан иясе—яшәү мәгънәсен әнә шул зәһәр сыеклыктан гына эзли башлый. Баштарак "аны ак хыялларыннан аерырлык көч, гомумән, юктыр ул" дип нык күңеллелек күрсәткән Микәй өчен ерак офык артларындагы үзен тартып торган көч әкренләп сүнә, бетә. Бу аны ахыр чиктә һәлакәткә китерә.

Татар халкы өчен ак кыялар—бөек дәүләтле чорлар. Аның канында, җанында шул вакытлардан калган затлылык, үз-үзен хөрмәт итү, киләчәккә ышаныч белән яшәү кебек сыйфатлар бар. Тәмәке тартуга, эчүчелеккә сабышу әсәрдә Микәйнең ак хыялларын соры тутык төсенә керткән кебек, татар халкының да затлылык тамырына балта чабуның иң үтемле кораллары шулар. Аларга өстәп наркомания, җенси азгынлык дигән афәтләрнең ябырылуын да искә алганда, Микәй хәленә төшү хәтәре тагын да арта. Р. Мөхәммәдиевне кулына каләм алырга мәҗбүр иткән гамь шушы. "Ак кыялар турында хыял" повестеның әһәмиятен, кайберәүләр эшләгәнчә, бары тик Микәй атлы тау кәҗәсенең сәер язмышын сурәтләү белән генә аңлатырга тырышу язучының максатын үтә гадиләштерү булыр иде. Болай итү әсәрнең тел төбендә яткан иҗтимагый кыйммәтле фәлсәфәсен бөтенләй аңламау булачак; ул бер үк вакытта Р. Мөхәммәдиевне кеше, шәхес, язучы, фәлсәфәче, иҗтимагый эшлекле буларак дөрес бәяләү мөмкинлеген бирмәячәк. Ә бит, дөресен әйткәндә, бу әдибебезнең бөтен иҗаты һәм эшчәнлеге әнә шул ак кыяларга омтылу булып кабул ителә. Әлеге әсәрдә Р. Мөхәммәдиевнең иҗат үзенчәлеген билгеләгәндә күренекле тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин иң алгы планга заманча фикерләү хасиятен чыгарган иде. Моның белән килешергә кирәк. Бездә, бүгенгене язып та, фикерләү дәрәҗәсе белән кичәге күзаллауларга нигезләнеп каләм кыштырдатучылар бар. Ләкин бүгенге әдәбият мәйданы андыйларны кабул итми, иртәгәге көн өчен алар шулай ук кирәкле булмаячак. Заман белән бергә атлау, бүген язганда вакытны узып уйлау сәләтенә ия булу—иртәгәге укучылар өчен дә кызыклы булып калуның бердәнбер дөрес юлы.

Р. Мөхәммәдиевнең әсәрләре, сүз дә юк, иң әүвәл бүгенге укучыга юнәлгән. Ләкин, ышанып әйтергә мөмкин, аның әсәрләре егерме беренче гасырның әдәбият һәм тарих белән кызыксынучылары өчен дә кирәк булачак. XX гасырның соңгы ун-унбиш елы кебек уникаль чорның тарихта булганы юк. Советлар Союзы кебек гаять зур илнең, дөресрәге, илләр иленең, алай гына да түгел, беренче карашка тимер белән кыршауланган социаль-икътисади системаның яшәүдән туктавы иҗтимагый тормышта, халыклар, милләтләр, аерым шәхесләр, гап-гади кешеләр язмышында никадәр үзгәрешләр китереп чыгаруы әле бик күп буыннар өчен өйрәнү объекты булып калачак. Моны инде Р. Мөхәммәдиев иҗатыннан башка эшләүне күз алдына да китереп булмый. Аның әсәрләре һәм хезмәтләре Татарстанга, татар халкына бәйле мәсьәләләрне ачыклау өчен генә түгел, бәлки тулаем элеккеге империя күләмендәге хәл-әхвәлләрне күзаллауда да файдалы булачак. Тарихка "үзгәртеп кору" еллары дип кереп калачак әлеге чор турында байтак язылды һәм язылып тора. Ләкин Р. Мөхәммәдиев каләменнән төшкән әсәрләр һәм язмалар күбрәк ышаныч уяталар. Чөнки алар мәсьәләне тирән белеп, төбенә төшеп, үз заманына гадел бәя биреп тудырылганнар.

Күпләр өчен бу "үзгәртеп кору" дигән галәмәт көтелмәгән нәрсә булгандыр. Ләкин Р. Мөхәммәдиев моның эчке эволюциясен алданрак күз алдына китерде. "Кенәри—читлек кошы" әсәре язылу нәкъ менә шуның нәтиҗәсе иде. Ул җәмгыятьнең халык күзеннән җиде кат бик астында тотылган яшерен серләрен ачып салды, театрдагыча әйтсәк, үзләрен дөньяның кендеге дип йөрткән кешеләрнең яшәү мәйданы өстендәге пәрдәне күтәреп куйды. Табигатьнең кеше күзеннән ерак гүзәл почмакларында биек койма, усал этләр белән уратылып алынган зиннәтле "мәхәббәт утраулары"нда үзләрен күкнең җиденче катында дип исәпләгән бу бәндәләр кәеф-сафа кылуның нинди генә төрләрен белмәгән! Холыкларындагы иң үсеш алган як—ерткычлык инстинкты. Язучы аларны арысланнар өеренә охшата. Ерткычлар төркемендәге кебек

үк, биредә дә ныклы иерархия кабул ителгән. Аның иң югары баскычында югары дәрәҗәдәге житәкче Лев Белялович тора. Аннан бер баскыч кала—сәүдә базасы директоры Арслан Сәхипович. Әшнәләрнең араларына кыл да сыярлык түгел. Кырык-илледән узган бу азгын ирләр, хатыннары һәм балаларыннан качып, биредә төрле тәтәйләр белән типтерәләр. "Болар кемнәр?" дигән сорау туа. Җавап бер—җәмгыять тәненә сыланган сөлек-паразитлар. Алар эч серләрен үзләре "кенәри" дип атаган сәяркәләре алдында да ачып салмыйлар. Бу соңгылары аларга бары тик ятакларын ямьләндерү өчен генә кирәк. Дөресен әйткәндә, "кенәри"ләргә карата боларның үз мөнәсәбәтләре бар. "Кенәри озак яшәми,—диләр алар,—алышынып торулары хәерле". Түгәрәк корсаклы бу "арсланнар"га наз бүләк итүче фахишәләр, кульяулыгы шикелле, атна саен чистага алышынырга тиеш икән. Язучы биредә сурәтләнгән Асия кебек фахишәләрне тәнкыйть итү белән бергә, аларның бәхетсезлек сәбәпләрен дә ачып күрсәтә, анализлый. Шуңа күрә әсәрнең стиле сабыр һәм колачлы.

Җәмгыятебездәге мондый тискәре күренешләрнең соңгы еллар җимеше генә түгеллеге бәхәссез. Р. Мөхәммәдиев романда шактый ерак елларга күз ташлый. Кешеләрдә бер-беренә ышаныч бетә баруын, әйләнә-тирәдәгеләргә ачу туплану процессын әкренләп ача бара. Моны ул Фидаил һәм Гыйлем образлары мисалында уңышлы эшли. Гыйлем дигән кешенең бәхетсезлек сәбәбе утыз жиденче еллардагы террор булса, сугыштан соңгы буын вәкиле Фидаил дә—житәкчелектәге нәкъ шул ук административ-бюрократия методы корбаны.

Р. Мөхәммәдиев язганнар—типик. Менә шул типиклык җанны өшетә дә. Куркуга, таякка нигезләнгән тәрбия күреп үскән буыннар психологиясендә әле дә хәвефләнү өстенлек итә, әнә шул хәл иркенәеп китәргә комачаулый. Ә арсланнар өеренә исә манкортлар, наркоманнар кирәк. Әйе, наркоманнарның күбрәк булуы кирәк аларга. Шул бер-ике укол өчен үзләренә эттән дә тугрылыклы хезмәт итүчеләр җайлы аларга. Чөнки мондыйларны кирәк икән, бер олы корсакның ымлавы буенча юк итеп тә була. Наркоман Жантимерләр—шул ук Микәйләр бит инде алар.

Шушы укылганнар янына тормышның үзендәге күзәтүләрне дә кушкач, Р. Мөхәммәдиев әсәрләрдә күрсәтеп биргәннәрнең хакыйкать булуы сискәндереп җибәрә. Шулар янына А. Гыйләжевның "Балта кем кулында?", Т. Галиуллинның "Тәүбә", "Элмәк" романнары да өстәлгәч, без яши торган җәмгыятьнең никадәр авыру булуы тәмам ачыклана. Ә авыруны савыктыру өчен, аңа дөрес диагноз кую мөһим. "Кенәричитлек кошы" романы белән "Истәлек өчен—Гыйлемханга" повесте әнә шул авыруның нидән гыйбарәт булуын ачыкларга ярдәм итүче әсәрләр булды.

Кешене башка тереклек иясләреннән аера торган сыйфатлар байтак. Шуларның берсе, ихтимал, иң әһәмиятлесеДер—аның матурлыкны бәяли белүе. Шушы хис аны кеше иткән, ул йорт-җирнең, кием-салымның, эш коралларының һәм үзе яши торган мохитенең җайлы, уңайлы гына түгел, бәлки матур булуын да кайгырткан. Нәтиҗәдә меңнәрчә еллар буе кешелек тарафыннан никадәр гүзәллек байлыгы тупланган. Фән, техника, белем, сәнгать үсеше шушы затлы хисне тагын да үстерергә тиеш иде. Әмма киресе килеп чыга. Җыр-моңнарыбызны гына алыйк. Аларда бик нечкә борылышлар, тирбәлешләр, фәнчә итеп әйткәндә, мелизмнар бетеп бара түгелме? Бүген теләсә кем чыгара торган җырларның сүзләре татарча булмаса, аларны һич тә үзебезнеке дип таный алмас идек. Шуның кебек хәлләр төзелешләрдә дә күзәтелә. Шәһәр җирләрендә салына торган күпкатлы йортларның үз йөзен аерып алу мөмкин түгел, алар игезәкләр кебек.

Язучыны сүз рәссамы, дибез икән, бу әсәрендә Р. Мөхәммәдиевнең әлеге сыйфаты шактый тулы ачыла. Бигрәк тә Гыйлемханның күңел дөньясын ачуда, аның үзенә очраган кешеләрнең холык-фигыльләрен төгәл штрихлар ярдәмендә күрсәтеп бара белүендә күренә бу. Нәҗипнең—бөтен нәрсәгә бары тик матди кирәклек ягыннан гына бәя бирүче кешенең—коры, буш, туры сызыклы "фәлсәфәсе" Гыйлемхан кебек бай, нечкә хисле зат янында шыксыз булып тоела. Гыйлемханның күңел матурлыгы, әгәр аның янәшәсенә әлеге Нәҗип куелмаса, шулай тулы, тәэсирле булып ачыла алмас иде.

Әсәрнең бөтен егәре, кызыксындыру көче шушы ике кешенең холык-фигыль каршылыгында, күңелләренең гаять төрле булуында. Гыйлемхан белән Нәҗипне язмыш олыгаеп барганда гына очраштыра. Ләкин бу ике кеше гомер буе бер-берсенең антиподы булып яшәгәннәр икән. Нәҗип Гыйлемханның ата-ана нигезенә йорт

салган. Өй түренә Гыйлемханның әтисе утырткан өч каенның икесен кисеп ташлаган (каеннан ни файда, җимеш-фәлән бирми, янәсе). Бу нәфис агачларның матурлык сирпеп утыруларын бәяләргә сәләтле түгел ул. Гыйлемханга күк чәчәк төшерелгән истәлек яулык бүләк иткән Миңсылуга өйләнгән өйләнүен, ләкин аның кадерен беләме икән ул? Мондый исәп-хисап белән генә эш итүче, үз фикере һәм зәвыгы булмыйча, бөтен алымын бары тик башкалардан калышмыйм дип кенә ясаучы бу бәндә кешенең җанын, ай-һай, аңлый ала микән? Авылдашларына матурлык бүләк итәргә теләгән Гыйлемханны да, үз бизмәне белән үлчәп, "шабашник" дип атый ул. Әлеге күренеш исә конфликтның иң югары ноктасы булып чыга. Үзенең игелекле омтылышын аңламаган бу "бригадирга" тәрәзә йөзлекләре ясаудан Гыйлемхан баш тарта. Әлеге ике кешенең бер-берсен аңламавыннан башланган конфликт, шул рәвешле, чишелми генә түгел, бәлки тагын да кискенләшә төшә.

Сәнгатьчә камил эшләнгән әсәрдә бер генә деталь дә артык булмый, ул сюжетны оештыруда хәлиткеч әһәмияткә ия була. Гыйлемханнар йортын сүткәндә, Нәҗипнең хатыны Миңсылу балта остасының эш кораллары салынган тартма табып ала. Берәү булса, бу затлы әйберләрне, кирәксә-кирәкмәсә, үзендә калдырыр иде. Әмма Сылу (Миңсылу) алай итми, тартманы Гыйлемханның авылдагы дәү апасына кертеп бирә. Кырык елдан соң туган авылына кайткач, Гыйлемхан, әлеге өтерге, кискеч, ышкыларны кулына ала һәм шулар ярдәмендә кешеләр күңеленә матурлык тойгылары иңдерердәй әйберләр ясарга дәртсенә. Гыйлемхан шуңа гаҗәпләнә: ул авылга кайтмый торган дүрт дистә ел эчендә кешеләрнең күңеле шул кадәр ярлыланган, инде аларны бу авырудан йолып алу мөмкин дә түгел кебек. Ул дәү апасының өен матурлап-бизәп куйгач, авылда шушы эшне бәяләрдәй кеше дә табылмый. Газета фотохәбәрчесе, очраклы рәвештә төшереп алып китеп, сурәтне бастырып чыгармаса, әле һаман да күрүче булмас, киресенчә, өйне нәкышләүгә бөтен талантын, йөрәк җылысын биргән Гыйлемханны сәер кеше дип санауларын дәвам итәрләр иде. Газетадагы бу рәсемне һәм аның астына язылган мактау сүзләрен беренче булып колхоз рәисе күреп ала. Газетада үз авылы хакында хуплау сүзләрен күрү аның күңеленә сары май булып ята. Ул Гыйлемханнан үзенең өенә дә тәрәзә йөзлекләре ясавын үтенә. Шуннан соң председательдән күрмәкче, бөтенесе дә остага гозер белән киләләр. Ләкин Гыйлемхан шуны сизә: аларның берсе дә моны матурлыкка омтылудан түгел, бәлки кешедән калышмыйм дип кенә эшли. Әгәр колхоз җитәкчесе тәрәзә йөзлеген кирәксенмәсә, әлеге Кордашлар да, Нәҗипләр дә йөзлекләрне һич авырсынмыйча каерып ташларлар иде. Р. Мөхәммәдиев, сизгер күңелле язучы буларак, әле сиксәненче елларның икенче яртысында ук кешеләр күңелендә барлыкка килгән шушы тутыкны күреп алган. Мондый хәлгә ул "Ак кыялар турында хыял" һәм "Истәлек өчен—Гыйлемханга" әсәрләре белән дә үзенең мөнәсәбәтен белдерде. Бу начар тенденция, кызганыч, тормышта һаман да тамырлана бара.

Һәр язучының төп омтылганы—иҗатының килер буыннарга да кирәкле булуы. Иманым камил: Р. Мөхәммәдиев, бүгенге язучы булган кебек, киләчәкнең дә әдибе. Ул шактый ерак үткәндәге хәл-әхвәлләрне сурәтләгәндә дә киләчәктә кызыксынып укылачак каләм әһеле булып кала белә.

Әйтик, XX гасырда илебез тарихында тирән эз калдырган Мирсәет Солтангалиев шәхесен әдәби әсәрдә гәүдәләндерү киләчәкне күздә тотып та башкарылган дияргә җөрьәт итәм. Юк, хакыйкатькә хилафлык итеп, Р. Мөхәммәдиев әлеге шәхесне идеаллаштыру юлыннан китми. Мәгълүм булганча, М. Солтангалиев, сәяси эшлекле буларак, гаять каршылыклы һәм шуның нәтиҗәсендә фаҗигале язмышка дучар булган кеше. Иң аяныч шунда: аның иленә, халкына, милләтенә изгелек кылам дип эшләгәннәре тискәре нәтиҗә бирә.

Үзәгенә мондый каһарман куелган романда документаль эслүбнең һәм публицистиканың кайбер алымнары кулланылуы да табигый. Әмма роман ныклы кул белән, сәнгать кануннары нигезендә язылган. "Сират күпере" әсәренең иҗтимагый аңыбызны үстерү җәһәтеннән булган әһәмиятен, язучының осталыгы камилләшүдәге бик мөһим бер баскыч булуында ассызыкларга кирәк. Әдәби җәмәгатьчелек һәм дәүләт даирәләре романның мәүзуг һәм сәнгати яңалыклыгын, аның пәйда булуының гадәттән тыш вакыйга икәнлеген лаеклы бәяләделәр—авторга 1993 елда Г. Тукай исемендәге олы бүләк бирелде.

Аннан соң шунысы да бар: мондый күренекле шәхеснең образын тудыруга

теләсә кем алына алмый. Андый әсәрне язучы үзе дә сурәтли торган каһарманы югарылыгында торырга тиеш. Чөнки тудырган героеннан үзеннән дә югары була алмый. Р. Мөхәммәдиев үзе дә язучы гына түгел, сиксәненче-туксанынчы елларның күренекле сәясәтчесе, дәүләт эшлеклесе дә иде. Менә ун елга якын инде ул—Татарстан Язучылар берлегенең рәисе. Россия Федерациясе Югары Советы депутаты һәм президиум әгъзасы, абруйлы бер комиссиянең рәисе буларак та ул Татарстанның хокукларын кинәйтү өчен аз тырышлык куймады. Үзенең сайлаучыларына тугрылыклы булды. Мәскәүдә Ак йорт дип йөртелгән бина һөҗүмгә дучар булган көннәрдә дә ул үз иманыннан тайпылмады. Шуның белән һәм шәхес, һәм язучы буларак үзенең бөтен характер иясе икәнлеген раслады. Мина шулай тоела: килер бер көн, Р. Мөхәммәдиев үзе талантлы бер яшь каләм әһеле әсәренең герое булып сурәтләнер әле. Ә хәзергә ул үзе шул хәвефле көннәр турында "Утлы таба өстендә" әсәрен укучыларга тәкъдим итте. 1993 елның сентябрь-октябрь айларында Мәскәүдә булган вакыйгалар турында шулай гадел бәя биреп, бөтен тулылыгы белән язылган башка бер әсәр әлегә күренми. Ул бездә гаять киң яңгыраш алды, 1996 елгы әдәби казанышларыбызның иң күренеклесе булды.

Язучы беренче карашка җан тетрәткеч хәлләрне булганынча, бер эзлеклелектә генә бәян итә кебек. Әмма аның һәр күренешкә, һәр вакыйгага үз бәясе, мөнәсәбәте бар, шул контекстта авторның үз җаны, үз күңел дөньясы ачыла. Аның уйланулары ярдәмендә вакыйгалар, шәхесләр үзләренә бәрабәр бәя ала. Бу бәя—укучы хөкеме белән туры да килә.

XX гасыр татар әдәбиятының үсеш дәрәҗәсен киң масштабларда яңгыраткан каләм әһелләре булды. Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәрим исемнәрен әйтү дә безгә күп нәрсә турында сөйли. Гасырыбыз ахырында Ш. Галиев, Р. Миннуллин да халыкара мәйданда олы бәя алдылар. Шулар рәтендә без хаклы рәвештә Р. Мөхәммәдиевне дә атыйбыз. Аның "Сират күпере", "Утлы таба өстендә" әсәрләре Төркиядә һәм башка илләрдә дә киң танылды, тугандаш илнең югары дәүләт бүләкләренә лаек булды. Әле менә 1998 елның май аенда ул Төркиянең Истанбул һәм Конья калаларында үз әсәрен яратып укучыларның зур төркемнәре белән очрашты, кардәш илнең радио һәм телевидениесеннән чыгыш ясады. Әйтергә кирәк, бу язучыбызны Төркиядә туган Татарстаныбызда кебек беләләр, хөрмәт итәләр. 1996 елның мартында мин Р. Мөхәммәдиев белән бергә Төркиянең башкаласы Анкарада язучылар корылтае эшендә катнашырга туры килде. Мин шунда бу ил язучыларының безнең Ринат Мөхәммәдиевне никадәр үз итүләрен күрдем.

... Әле кайчан гына әдәбиятта яшь тәнкыйтьче, яшь язучы булып йөргән Р. Мөхәммәдиев тә иллесен тутырды. Үткән юлында ярты гасыр вакыт җәйрәп ята. Куанычлысы шул: биш дистә ел гаять нәтиҗәле узган. Кирмән чишмәләре төрле-төрле булган кебек, әлбәттә, бу еллар да бер-берсенә охшамаган, аларның һәрберсе аны уттан алып суга салган, төрле хәлләрдә сынап караган, чыныктырган. Нык үзәк-ле Р. Мөхәммәдиев торган саен каләменә ныграк ябышкан, халкының ихтыяҗларын тирәнрәк аңлый төшкән. Аның иҗаты киң колачлы Иделебез сыман елдан-ел ныграк агымлы, колачлырак була барган.

Әйе, Идел дәрьясы атлап кына чыгарлык инештән башлана. Әмма ул әллә ничәшәр чакрымлы булып киңәйгәч тә гөрләвек сыман агып чыккан урынына рәхмәтледер кебек. Шуның сыман, Р. Мөхәммәдиев иҗаты да бүген тармаклануын, көч-куәт алуын дәвам итә. Тик ул беркайчан да үзенең Кече Кирмәнгә икәнлеген онытмый. Шул газиз авылның чишмәләре аны олы Ринат итеп үстергәннәр бит. Ничек инде моңа рәхмәтле булмыйсың!

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

*Мәдәниятебез тарихына*

# А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ



Казандагы А. М. Горький музеена 1940 елда нигез салынган. Ул 1880 елларда байбичә Беляева торган һәм 1886-1887 елларда Алеша Пешков (М. Горький) икмәк пешерүче булып эшләгән йортта урнашкан.

Әле 1928 елда туган як тарихын өйрәнүче галим Н. Ф. Калинин үз укучылары белән Горький исеменә Соррентога (Италия) бер хат юллый. Бу хатка Казан шәһәренең узган гасырның 80 елларын сурәтләгән картасын да сала һәм Горькийдан элек үзе яшәгән урыннарны билгеләп күрсәтүен үтенә. Алексей Максимович билгеләп кенә калмый, аларга тулы ачыклык кертеп хат яза, үзенең фотосурәтен дә җибәрә. Менә шулар буенча танылган тарихчы Казанда Горький торган урыннарның рәсемнәрен ясый. Н. Ф. Калинин һәм музейның беренче директоры М. Н. Елизарова, өлкән яшьтәге казанлыларның истәлекләренә таянып, кыска гына вакыт эчендә музейның мемориаль өлешен, төгәлрәк итеп әйткәндә, икмәк пешерә торган подвалны торгызуга ирешәләр.

Бөек рус язучысы А. М. Горький безнең шәһәребездә дүрт ел гомерен үткәрә һәм истәлекләрендә аны "тормыш университетларым" дип атый. Биредә ул яшьлегенең иң әһәмиятле аралыгын—кешенең шәхес буларак формалашу чорын кичерә. Шуңа күрә дә ул: "Чыгышым белән Т. Новгородтан булсам да, рухи яктан мин Казанда тудым",—ди. Менә шушы вакыйгаларны истә тотып, музей төп игътибарны әдипнең Казан чорына юнәлтә. Биредә XIX гасыр күренешләрен чагылдырган "Горький һәм Казан", "Горький иҗатында Казан" бүлекләре бар.

1968 елда А. М. Горькийның 100 еллыгына музейның икенче катында "Горький һәм татар әдәбияты", "Казан сәхнәләрендә Горький пьесалары", "Горький һәм Шаляпин" кебек зур мөстәкыйль бүлекләр ачыла.

Озак еллар эшләү дәверендә музей Горький һәм Шаляпинга кагылышлы кызыклы, кыйммәтле коллекция туплады. Мәсәлән, 1946 елда Горькийга багышланган беренче конференциягә килгәч, кайчандыр аның белән бергә эшләгән А. Деренков һәм Н. Щербатова XIX гасырның ахырларына караган лампа, чәйнек, самовар кебек кызыклы тарихи экспонатлар бүләк итәләр. Әнә шундый кечкенә материаллардан башланган фонд хәзер 50 меңнән артык берәмлекне тәшкил итә.

Музейның мемориаль фонды да гаять бай. Биредә Горькийның язу өстәле, ул утырган кәнәфи, язу әсбаплары саклана. Хатыны Е. П. Пешкова иренең 1928 елда Казанга килгәндә кигән күлмәген бүләк итә. 1965 елда улы Максимның хатыны Надежда Пешкова музей хезмәткәрләренә Горькийның шәхси коллекциясеннән 200 дән артык китап тапшыра. Әлеге китаплар арасында философия, этнография, рус, чит ил классикасы, әдәбият белеменә караганнары да бар.

А. М. Горький музеенда язучы шәхесен ачыкларга ярдәм итүче кызыклы, оригиналь фотоматериал тупланган. Алар әдипнең Мәскәү, Т. Новгород, Кырым, Соловки, Мануйловка, Сорренто, Париж, Берлин һ. б. төбәк-шәһәрләрдә яшәгән вакытларында төшерелгән.

Музей алып барган киң кырлы эшчәнлекнең тагын бер мисалы итеп совет

язучыларының автографлы китаплары җыелмасын күрсәтә алабыз. Бирәдә К. Федин, М. Исаковский, С. Маршак, К. Паустовский, Е. Евтушенко, В. Шукшин, Г. Бәширов, Г. Кутуй, Г. Ахунов, А. Шамов, Г. Минский, Ш. Галиев, Г. Ибраһимов һ. б. бик күп татар, рус, башка милләт вәкилләренең әсәрләре саклана.

1940 елда Горький музеенда бөек җырчы Ф. И. Шаляпин иҗатын өйрәнү үзәге төзелә. Һәм Горькийга караган материаллар белән рәттән, Шаляпин турындагы материаллар да җыйнала башлый. 1949 елда җырчының кызы Ирина Шаляпина музей коллективы чакыруы буенча Казанга килә. Шул вакытта аның соравын истә тотып, Богоявления чиркәвеннән Федор Шаляпинның туу көне теркәлгән метрика кенәгәсе табып алына. Ә Мәскәүдән исә тагын бер уникаль экспонат—артистның шәхси рояле кайтарыла. Аның тарихы гаять кызыклы.

Рояль 1896 елга кадәр Савва Мамонтовның шәхси операсында тора. Шул елны театрда янгын чыккач, хуҗасы аны Шаляпинга бүләк итә. Инструмент соңгысының фатирында 30 елдан артык саклана.

Җырчының фатирыннан музейга имән урындыклар, Японидә эшләнгән кофе сервизы һ. б. шәхси материаллар тапшырыла. 80 еллар ахырында Шаляпинның Америкада яшәүче оныгы Ирина Казанда кунак булып китә һәм артистның театр костюмыннан берничә әйберне бүләк итә. Быел җәй көне музейда Шаляпинның тагын бер туганы—оныгының кызы Дассия Робертсон-Шаляпина булып китте. Бабалары, талантлы, бөек җырчы Шаляпин йөрәгеннән чыккан "Казан минем өчен дөньядагы барлык шәһәрләрнең иң матуры, кадерлесе" дигән сүзләре дә аларны әнә шулай тартып китерәдер, бәлки.

Әйе, музей Горький һәм Шаляпинның туганнары белән тыгыз элемтәдә тора. Соңгы елларда гына да алардан яңа материаллар алынды. Үзләре дә музейга булган игътибарны киметмиләр. Кадерле кешеләре яшәгән Казанга, аларның тормышы, иҗаты турында якты истәлекләрне җыйган, саклаган йортка ешрак килергә тырышалар. Мәсәлән, музейның 50 еллыгына багышланган тантанада иң кадерле кунакларыбыз—Горькийның оныклары Дарья белән Марфа Пешковалар булып киттеләр.

А. М. Горький музее татар һәм рус әдәбиятын яктыртуда киңкырлы эшчәнлек алып баручы мәдәни үзәкләрнең берсенә әверелде. 1942 елдан бирле бирәдә яшь каләм ияләренең әдәби берләшмәсе, китап сөючеләр җәмгыяте эшләп килә.

Ел саен С.-Петербург, Мәскәү, Харьков, Тамбов, Уфа, Т. Новгород, Казан, Ижау, Чабаксар, Киров шәһәрләреннән килгән зур галимнәр катнашында Горький һәм Шаляпинга багышланган фәнни конференцияләр оештырыла. Музей ярдәме белән шәһәребездә А. С. Пушкинга багышланган шигырь кичәләре, Славян мәдәнияте көннәре үткәрелә.

Музей хезмәткәрләре II Бөтендөнья Татар Конгрессы көннәрендә дә актив катнашты. Әлеге истәлекле вакыйгага багышлап Татарстан Фәннәр Академиясе, Берләштерелгән дәүләт музее катнашында "Мөхәммәдьяр һәм аның заманы" (1997) дигән күргәзмә ачылды.

Соңгы бер-ике ел эчендә генә дә татар рухын чагылдырган кызыклы, кабатланмас күргәзмәләр еш ачыла бу бинада. Мәсәлән, 1996 елда борынгы татар каллиграфиясенең матур үрнәкләрен туплаган "Татар шәмаилләре", татар күн эшкәртү традициясен дәвам иттерүче Наилә Кумысникованың "Күннән мозаика", рәсем сәнгатендә милли һәм шәрекъ традицияләренә таянучы Рөстәм Шәмсутов кебек авторларның иҗатлары аша халкыбыз мәдәниятен яктыртуда тәүге адым ясалган булса, 1997 елда исә Коръәнгә багышланган "Изге китап", "Татар кульязма һәм беренче басма китабы", сынчы Бакый ага Урманче, шагыйрь, рәссам Ренат Харис, рәссам Илгизәр Хәсәнов, беренче татар хатын-кыз рәссамы Гайшә Рахманкуловаларга багышланган күргәзмәләре изге максатка нигезләнгән бу эшчәнлекне тагын да тулыландыра төште.

1998 ел ике каһарманыбыз—Горький һәм Шаляпинның юбилейлар елы. Шул сәбәпле бөтен игътибар әлеге истәлекле вакыйгалар тирәсенә тупланды. Февраль аенда Горькийга—130, Шаляпинга 125 ел тулу уңаеннан алар иҗаты, тормышы турында музей архивларыннан, Мәскәү, С.-Петербург музейларыннан алынган яңа, кызыклы тарихи материалларны җыйган "Олы тормыш сәхифәләре" дигән күргәзмә ачылды.

1998 елда галим, әдәбият белгече Ибраһим ага Нуруллинның туына да 75 ел тулды. Бу вакыйгага багышлап музей хезмәткәрләре тарафыннан галимнең иҗатын чагылдырган күргәзмә оештырылды, аның укучылары, хезмәттәшләре, якыннары катнашында искә алу кичәсе уздырылды. Шуны да әйтергә кирәк: берничә ел элек мәрхүмнең архивы музейга тапшырылган иде. Әлеге архивта Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый шәхесләренә кагылышлы документлар, фотографияләр бар.

А. М. Горький музее милләтләр дуслыгы йортына әверелеп бара дисәк, һич тә арттыру булмастыр. Чөнки бирелә рус әдәбияты белән параллель рәвештә, күргәнегезчә, татар мәдәнияте, әдәбиятын да пропагандалауга зур урын бирелә. Бу бинада АНКО—милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясе эшләп килә. Чуваш, украин, немец, яһүд һ. б. милләт вәкилләрен берләштәштергән бу оешма үз халкының мәдәниятенә багышланган төрле кичә, күргәзмәләр оештыра. Мәсәлән, бу уңайдан "Немец китаплары тарихыннан", "Н. Рерих картиналары репродукциясе" (Нью-Йорк музее фондларыннан), һинд рәссамы Шри Чинмой иҗатын яктырткан "Сәнгать фонтаны" кебек күргәзмәләрне атап үтәргә мөмкин.

А. М. Горький музееның япон милләте вәкилләре белән бәйләнешләре да ныгый төште. 1998 ел дәвамында гына да көннәрдә һәрчак аерым бер кызыксыну уята торган бу ил мәдәниятенә кагылышлы берничә кичә үткәрелде. Яз башында Казан халкы Татар-япон информацион-мәдәни үзәге оештырган "Япон язы" фестивален ачу церемониясендә "икэбана үрү сәнгате"нең серләренә төшенгән булсалар, август аенда исә, 1996 елдан Япониянең Россиядәге илчесе итеп билгеләнгән Такэхиро Того әфәнде белән очраша, аның рәсемнәре белән таныша алдылар. Әлеге тантаналы вакыйга уңаеннан "Хыяллардагы Япония" дигән балалар рәсемнәре күргәзмәсе дә ачылды.

Япония белән А. М. Горький музее арасындагы тәүге бәйләнешләр моннан дүрт ел элек үк урнаштырыла. 1994 елда Япониянең Россиядәге илчелеге тарафыннан музейда "Япония курчагы" күргәзмәсе куелды. Ике ел элек Япония белән тагын бер кызыклы очрашу насыйп булды. "Хәзерге заман Япон гравюрасы" дип аталган авангард стилендәге рәсемнәр күргәзмәсе үткәрелде.

Мондый кызыклы вакыйгаларның безнең музейда оештырылуы очраклы гына түгел. Язучы А. М. Горький үзе дә Россиядә яшәүче халыклар арасында мәдәни, әдәби бәйләнешләр урнаштыру эшен башлап җибәргән шәхес. Ф. И. Шаляпин исә, кабатланмас талантлы җырчы, артист һәм, гомумән, кешелекнең бөек казанышы буларак, бер генә милләткә түгел, ә барлык халыкларга да хезмәт итә. Дөньякүләм атаклы бу җырчы үз тавышының көчлелеген, аһәңлелеген нәкъ менә борынгы моңлы, озын татар җырларын тыңлап үсүе белән бәйләп аңлата.

Менә шундый кызыклы очрашулар үткәрү белән бергә, музей инвалид, ятим балаларны, күп балалы гаиләләрне, сугыш һәм хезмәт ветераннарын, өлкән яшьтәге кешеләрне дә онытмый. Балалар өчен кышын Чыршы бәйрәмнәре оештырылса, олылар белән төрле кызыклы кичәләр уздырыла.

Шәһәребезнең Хатын-кызлар советы, "21 гасыр хатын-кызлары" интеллектуаль клубы да әһәмиятле утырышларын, очрашуларын музей белән берлектә алып бара. Шуларның нәтиҗәсе буларак, 1997 елда бирелә Тел, әдәбият, сәнгать институты оештырган һәм хатын-кыз рәссамнары эшләрен җыйган, табигатьнең асыл затлары гына тоя, сурәтли ала торган "Аның күзләре белән" дигән гаять матур, кызыклы күргәзмә туды.

Музей коллективы һәрдаим иҗади эзләнүләр алып бара. Бүгенге көндә туган төбәгебезнең әдәби хәятын, тарихын яктырткан яңа экспозиция төзү турындагы карашлар тикшерелә. Булачак концепциянең нигезендә ерак үткәнебезне, татар һәм рус әдәбияты тарихын, аларның үзара бәйләнешләрен тулы чагылдыру максаты ята.

* * *

Бүген—элекке идеаллар җимерелеп, яңаларын тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр тулысынча булмаганда, һәм иң мөһиме, гасыр ахырында халкыбызның үткәненә—мәдәнияте, тарихы, әдәбиятына йомгак ясау кирәк. Кирәк кенә түгел, ә сорала да, чөнки нәкъ менә шул нәтиҗәләргә нигезләнеп, киләчәгебезне күзалларга тиеш булабыз.

Милләтнең яшәү рәвеше, үсеш дәрәҗәсе аның мәдәниятендә чагыла. Тормыш-чынбарлыкны исә матур әдәбият яктырта. Әдәби әсәрләр халкыбызның күңел хәзинәсен, аһ-зарларын, борчу-кайгыларын ничәмә-ничә гасырлар аша бүгенге буынга китереп җиткергән. Бөек сүз осталары Котб, Х. Кятиб, С. Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Г. Кандалый, З. Бигиев, Акмулла һ. б. шул юлда меңъяшәр имәннәрдәй үлемсез әсәрләр калдырган.

Ә егерменче йөз татар әдәбияты тарихка нинди әһәмиятле ачышлары, әдип-шагыйрьләре белән кереп калды соң?

Милләтнең рухи халәте, үсеше, мәдәнияте өчен борчылган, аны кайгырткан Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Камал, Дәрдмәнд, С. Рәмиев кебек олуг шәхесләрне нәкъ менә XX гасыр тудырды. Әлбәттә, зур югалтулар да кичерде

әдәбиятыбыз бу йөзьеллыкта. Ничә елга бер туа торган якут ташыдай кадерле шагыйрь— Г. Тукайсыз калды, Явыз Иван яуларыннан соң мөстәкыйльлеген югалткан, аны кайтарудан тәмам өметен өзгән халыкны йокысыннан уятучы, уяту гына түгел милли азатлык өчен көрәшкә өндәүче Г. Исхакый кебекләре чит илләрдә тилмерде. Россиядә совет хөкүмәте урнаштырылгач, милли идеалларына хезмәт итәргә хыялланган, халкының бәйсез дәүләттә яшәве өчен көрәшүен дәвам иткән Г. Ибраһимов, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ф. Әмирханнар исә большевистик идеологиянең корбаннарына әверелде. Алар белән янәшә атлаган күпме татар зыялылары да шул фаҗигага дучар ителде. Авыр, аяныч югалтулар. . . Әмма бу бөек затлар башлаган изге гамәлләр милләтнең үзаңын үстерү, яшәешне дөрес чагылдыру, аның ялгышларын, уңыш-казанышларын дөрес күрсәтү, милли идеалны, милли образларны иҗат итү—болар буыннан буынга тапшырыла килде, революциягә кадәрге әдәби традицияләр дәвам итте. Әлбәттә, бу чорда аларны ачыктан-ачык әйтеп булмый иде. Мондый очракта язучыларның күбесе символизм, "эзоп теле" кебек алымнар аша укучының аңына тәэсир итү мөмкинлекләрен таптылар. Шуңа күрә 20-30 еллар татар әдәбиятын тикшергәндә аеруча сак, игътибарлы булу сорала.

Татар әдәбияты үз үсеш чорында ике тапкыр зур яңарыш кичерә. Берсе—XIII-XVI йөзләрдә булса, икенчесе XX гасыр башына туры килә. Яңа гасырга әдәбиятыбыз барлык жанрлары формалашкан, мәгърифәтчелек реализмын уңышлы үзләштергән хәлдә килеп керә дип күрсәтә әдәбият галиме Ф. Галимуллин. Ә 1905 елгы беренче рус инкыйлабыннан соң тагын да зур тизлек белән үсеп китә.

1917 елга кадәр, ягъни 10-15 ел эчендә әдәбиятыбыз тематика, сәнгатьчәлеге ягыннан яңа баскычка күтәрелә. Әдәбият аерым бер кешене шәхес дәрәҗәсенә җиткереп, игътибарны аның яшәү фәлсәфәсенә юнәлтә, җәмгыятьтәге уңай-кире күренешләрне, аларның нәтиҗәләрен ачыктан-ачык сурәтләүне бурыч итеп куя. Менә шундый шартларда әдәбият мәйданына бүген классик язучыларыбызга әверелгән Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, Г. Камал, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Н. Думави кебек үткен сүзле, милләт җанлы каләм осталары чыга. Әдәбият өлкәсендә алар күтәргән шәхес азатлыгы, көрәш-тартыш идеясе, милли-мәдәни үсеш, хатын-кызның тормыштагы урыны кебек гаять әһәмиятле мәсьәләләр җәмгыятебезнең асылын аңларга ярдәм итте һәм бүгенге әдәбият та аларны үзенә шигарь итеп алды.

1905-1907 елгы мәгълүм вакыйгалардан соң сүз ирекe бирелгәч тә, милли азатлыкка омтылган татарларда вакытлы матбугат барлыкка килә. Татарлар яши торган барлык төбәкләрдә газит-журналлар чыга башлый. Петербургта—"Нур"; Казанда—"Казан



*Алеша Пешков эшләгән пекарня һәм ул эшләгән өстәл.*

мөхбире", "Йолдыз", "Азат", "Таң йолдызы"; Җаекта—"Фикер", "Әлислах"; Оренбургта—"Урал", "Вакыт" газитләре аваз сала.

Шул ук вакытта төрле журналлар да чыга. Җаекта—"Әлгасрел җәдит", "Уклар"; Оренбургта—"Карчыга", "Чүкеч"; Әстерханда—"Туп"; Казанда—"Яшен", "Ялт-йолт". Бу журналлардан беришләре (Казанда—"Аң", Оренбургта—"Шура") татар әдәбиятын үстерүдә, халыкның зыялы катлавын матур әдәбиятның яңадан-яңа үрнәкләре белән таныштыруда зур өлеш кертәләр. Икенчеләре исә, (Оренбургтагы "Дин вә мәгыйшәт", Казандагы "Дин вә әдәп "журналлары) халкыбызны дини, милли рухта тәрбияләүне бөек максат итеп, гореф-гадәтләребезне саклау, пропагандалау эшләре алып баралар.

1914 елның җәендә башланган I Бөтендөнья сугышы, ул китергән ачлык-фәкыйрьлек чынбарлыкны реалистик сурәтләү юлына баскан татар әдәбиятын борчыган темаларның үзәгендә торды. Язучылар үткен актуаль социаль мәсьәләләрне тагын да кыюрак күтәрделәр, яшәешне яхшыртуның теге яки бу юлларын күрсәттеләр.

Көрәш-тартыш идеясен, шул идеяне тормышка ашырган каһарманнарны беренчеләрдән булып әдәбият мәйданына Г. Исхакый алып чыкса, ул елларда тагын бер танылган әдип—Гафур Колахметов тә хезмәт ияләрен бәхетле итү көрәштән башка була алмауга басым ясады һәм бу темага "Ике фикер", "Яшь гомер" әсәрләрен багышлады.

Халыкның илдә барган вакыйгаларны үзгәртергә тиешлеген, бу вазифаларның аеруча эшче сыйныфына—пролетариатка йөкләтелүен чагылдырган әсәрләр татар әдәбиятында да ешрак күренә башлый. Әйтергә кирәк, бу күренеш беренче чиратта, рус әдәбияты йогынтысы астында бара.

XX гасырның 10 нчы елларында рус әдәбият мәйданында Максим Горький исеме, фигурасы калкып чыга. Кимсетелгән халыкның аһ-зарын, мәнфәгатьләрен, тормышын чагылдыру белән бергә, рус язучысы соңрак большевикларның көрәш лозунгларына әверелгән революцион фикерләр белән дә чыгыш ясый.

Татар әдәбиятында эшчеләр сыйныфына багышланган, аларның революцион көрәшкә күтәрелүен сурәтләгән мәгълүм әсәрләр нәкъ менә Горькийга ияреп язылган. Мәсәлән, Г. Колахметовның "Яшь гомер" пьесасының 1908 елда басылып чыккан вариантында, дөресрәге, титул битендә "Ошбу пьеса мәшһүр рус мөхәррире Максим Горькийга тәкълидән язылмыштыр" дип күрсәтелә.

А. М. Горький иҗаты башлангыч чорында Г. Камал өчен дә үрнәк булып тора. Күренекле татар драматургы А. М. Горькийның "Тормыш төбендә" пьесасындагы "Кояш чыга да бата" җырын үзенең "Бәхетсез егет" драмасына кертә. Шунысы кызык: әлеге җырны Горький бик яратып җырлый һәм башкара торган була. Г. Камалның "На дне" драмасын да татарчага тәрҗемә итүе мәгълүм.

Ә инде А. М. Горький әсәрләрен рус эшчеләре генә түгел, татар хезмәт ияләре дә яратып кабул итүе сер түгел. Революция алды елларында, аеруча 1917 елгы октябрь күтәрелеше көннәрендә танылган "Сәйяр" татар театр труппасы аның "Мещаннар"ын сәхнәгә әзерли. Бу хакта "Кояш" газитенең 1917 елгы октябрь саны хәбәр итә. Соңрак шул ук басма Мәскәүдә Вакытлы хөкүмәтнең пролетариат кулына күчү шатлыгы уңаеннан спектакльнең кичектерелүе, алдан алган билетлар белән киләсе тамашага да керергә рөхсәт ителүе хакында белдерү ясый. Бу фактны дәлилләүче кечкенә генә бер деталь сакланган. Ул—татар телендә куелган "Мещаннар" спектакленең программасы.

Татар язучыларының рус пролетар әдәбияты җитәкчесе булган А. М. Горький белән элемтәдә торуы берьяклы гына булмый. А. М. Горький, алда әйтеп киткәнчә, үзе дә татар әдәбияты, мәдәнияте белән ныклап кызыксына. Бу кызыксыну әле октябрь революциясенә кадәр үк туа һәм татар әдәбиятын рус укучысына җиткерергә теләвендә дә ачык чагыла.

1912 елда ук әле Горький Россиядә яшәүче башка милләтләрнең әдәбиятларына багышланган аерым җыентыклар чыгару уена килә. Латыш, әрмән, яһүди әдәбиятлары белән рәттән татар әдәби ядкарьләрен туплаган җыентык өстендә дә эш алып барыла. Ике бөек язучы, җәмәгать эшлеклесенең бер-берсенә язышкан хатлардан күренгәнчә, А. М. Горький бу мөхим эштә нәкъ менә татар әдипләренннән иң эресе, иң күренеклесе булган Гаяз Исхакыйга таяна[1]. Мондый мәҗмуганың әзерләнүе хакында Г. Исхакый Ф. Әмирханга язган бер хатында да хәбәр итә (1912 ел, 13 июнь). Һәм аннан аеруча уңышлы дип тапкан үз әсәрләрен җибәрүне үтенә. Шул ук хатта әлеге җыентыкка Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй һәм Г. Исхакыйның үз әсәрләре кертелергә тиешлеге әйтелә.

---

1. Бу хакта күренекле галим, профессор И. Нуруллин беренчеләрдән булып матбугатта чыгыш ясаган иде. Кара: "Татарстан", 1993 ел, №2, "Вопросы литературы", 1988 ел, №4.

Г. Исхакыйга язган хатларның берсендә Горький татар әдәбияты, аның бүгенгесе, үткәне турында тәнкыйди характердагы берәр мәкалә язарга кирәклегенә басым ясый. Рус телендә мондый мәкалә язуны Г. Исхакый үзе белән бергә "Ил" газетендә эшләгән тәнкыйтьче Нәҗип Гасрыйга йөкли. А. М. Горький аны, стиль кытыршылыклары булган урыннарына бераз төзәтмәләр кертеп, "Современник" журналының 1911 елгы 4 санында бастыра. Н. Гасрый язган бу мәкаләнең кулъязмасы (күчермә формасында) А. М. Горький музеена да куелган.

А. М. Горький Гаяз Исхакыйга рус матбугатына чыгарга, аның әсәрләрен рус укучысына таныттуда да зур ярдәм күрсәтә. Мәсәлән, Горький булышлыгы белән "Шәкерт абый" хикәясе "Современник" журналында (1913 ел, 4 сан), "Алдым-бирдем" пьесасы "Заветы" журналында (1914 ел, 6 сан) дөнья күрә.

Горький янә бер хатында Г. Исхакыйдан "Өч хатын белән тормыш" әсәренең тәрҗемәсен җибәрүне үтенә "татар тормышының бер үзенчәлеге буларак, рус укучысына да аеруча кызыклы һәм бик вакытлы булыр иде", ди.

Г. Исхакый Горькийга 1914 елның мартында "Зөләйха" фаҗигасенең тәрҗемәсен юллый һәм Мәскәү яки С.-Петербург вакытлы матбугатының берәрсендә бастыру мөмкинлеген күреп булмасмы дип өметләнә. Әмма бүгенге көндә әлеге әсәрнең XX гасыр башы рус вакытлы матбугатында басылуы хакында мәгълүматлар табылганы юк. Ә Г. Исхакыйның танылган "Зөләйха" пьесасын 1917 елның маенда I Бөтенроссия мөселман корылтае көннәрендә, Мәскәүдәге "Корш" театрында "Сәйәр" труппасы сәхнәгә алып менә.

А. М. Горький Г. Исхакыйдан татар язучылары, мәгърифәтчеләре (Ф. Кәрими, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Г. Исхакый, Г. Тукай), аларның эшчәнлеге турында тулырак мәгълүматлар сорап, кызыксынып кына калмый, ә авыр вакытларда Г. Исхакый чыгарып килгән "Ил" газетенә акчалата матди ярдәм дә күрсәтә.

Г. Исхакый белән бергәләп төзелгән татар әдәбиятына багышланган мәҗмуга, кызганычка каршы, дөнья күрми. Шулай ук Г. Исхакыйның рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләр җыентыгы да билгесез сәбәпләр аркасында басылмый кала. 1928 елда Казанга килгәч, аларның ни сәбәпле чыгарылмавы турындагы сорауга А. М. Горький бик гади итеп "Тәрҗемәләре начар иде",—дип кенә җавап кайтара. Тик бер нәрсә уйга сала: Россиядә яшәүче төрле милләт вәкилләре әдәбиятына багышланган бу сериядән революциягә кадәр әрмән, латыш, фин әдәбиятлары җыентыклары (1916-1917) чыгарга өлгерә. Чиратта татар әдәбияты җыентыгы була. Октябрь инкыйлабыннан соң илдә хәлләр кискен үзгәрә. Башта барысы да хезмәт иясе азатлыгы өчен көрәшкән революционер—әдипләр төрлесе төрле "ярда" торып кала. Милләт азатлыгы өчен көрәшүче Г. Исхакый эмиграциягә китәргә мәҗбүр ителә. Горький исә, революция, аның казанышларын күзәтү, бәяләү белән мәшгуль була. Тора-бара үзе үк патша хакимиятен җимерүгә өндәгән бөек бу пролетар язучы большевиклар алып барган сәясәт белән килешми башлый. Яңа җәмгыятьнең ялгышларына ишарә итеп, "Новая жизнь" газетендә революция һәм мәдәниятка багышланган "Несвоевременные мысли" дигән мәкаләләр циклын башлап җибәрә. Соңыннан ул аерым җыентык булып басыла. Әлеге мәкаләләрдә революциянең җимерүче көчкә әверелүе хакында, халыкның рухи дөньясын, мәдәниятен саклап калу кирәклеге турында да гаять үткен, әһәмиятле фикерләр бар. Бу мәкаләләр—инкыйлабның әхлакый-иҗтимагый казанышларын алга сөргән, сәясәт белән әхлаклылыкның аерымлануына, социализмның соңгысыннан ерагаюына каршы чыккан һәм иҗтимагый үсештә, яңа җәмгыять төзелешендә сыйнфый, гомумкешелек башлангычларын каршы куюны инкарь иткән пролетар язучы, көрәшче революционерның инанулары. Менә шундый вакыйгалар аркасында югарыда телгә алынган әдәби җыентыкның чыкмый калуы да мөмкин.

А. М. Горький—гаять катлаулы, каршылыклы шәхес. Аны өйрәнгәндә ул яшәгән чорны, мохитны бик яхшы белү сорала, чөнки Горькийның иҗаты да, әдип, җәмәгать эшлеклесе буларак үзе дә сәясәт белән тыгыз үрелгән. Октябрь революция казанышларына, әлеге революция тудырган шәхесләргә мөнәсәбәте дә бер төрле генә түгел аның. Шул ук "Несвоевременные мысли" циклында ул ике тип революционерларны аерып күрсәтә. Аның фикеренчә, "вакытлы гына" революционерлар һәм "гомерлек" ("вечный") революционерлар була. Беренчесенә карата Горький түбәндәге билгеләмәне бирә: "...вакытлы гына, бер көнлек революционер... революцион идеяләрнең мәгънәсен, гомумкешелек, гуманитар эчтәлеген бозудан, кирегә үзгәртүдән, бозыклыкка әверелдерүдән... дә тайчанмый".

Вакытлы революционер догмалардан азат була алмый. Ул үз эшенә, кешеләргә

битараф. Революцион идеяләргә тугрылыклы булырга антлар эчсә дә, күңелендә инсаннарга карата кўралмау, нәфрәт саклый, дип кисәтә А. М. Горький. Бюрократия, ришвәтчелекнең җәелүе, житәкчеләрнең үз кул астында эшләгән хезмәттәшләренә түбәнсетеп каравы, дорфалык—болар барысы да әнә шул "вакытлы"—ялган революционерлар тудырган сыйфатлар, ди.

Икенче төр көрәшчеләр—"гомерлек" революционерлар—кешелекне камиллеккә илтүче, кешелек тудырган асыл идеяләр массасын кабул итеп алучы, яңа җәмгыять төзүчеләрнең рухи житәкчесе. Ул теләсә кайсы ижтимагый төзелештә яшәсә дә, аңардан беркайчан да канәгать була алмаячак, чөнки кешелек дөньясы бертуктаусыз алга бара һәм бу хәрәкәттә яхшыдан үтә яхшыга, камиллеккә омтыла, димәк бер урында гына таптанып тора алмый" , дип яза А. М. Горький. Әлбәттә, мондый революционер һичкайчан да үз идеаллары өчен гаепсезгә меңнәрнең канын түгәргә ашыкмый. Чын мәгънәсендә үзгәреш яклы кеше буларак, алар мәдәниятнең асылын адәм баласының рухи үсешендә күрәләр.

Гаять кызыклы, уйландырырлык һәм бүгенге җәмгыятьнең торышы белән бик тә аваздаш фикерләр болар.

Ләкин "мәдәниятнең ижатчысы", аны тудыручы дип Горький бары эшчеләр сыйныфын, пролетариатның алдынгы өлешен генә таный, калган халыкка исә надан мәгънәсендә—"мужик" лар дип карый. Бу ялгышуларның бик тирәндә яткан үз сәбәпләре бар. Шуларның берсе— яшь вакытта Казанда, дөресрәге, аннан ерак түгел Красновидово авылында алган тәэсирләре белән бәйле. Дусты, күп тапкырлар сөргендә, төрмәләрдә булган революционер Михаил Ромасев (Ромась) чакыруы буенча ул 1887 елда әлеге рус авылына барып чыга. Ромась биредә лавка тотканлыктан, Алешага да аның белән бергә сату итәргә туры килә. Буш вакытларда исә ул сала "мужик"ларының гореф-гадәтен, тормыш-көнкүрешен өйрәнә. Авыл кулакларының котыртуына ияреп, бер төркем крәстияннар Ромасьны кыйнарга килиләр. Аларның авыр йодрыгын Алешага татырга насыйп була. Менә шул вакыйгалардан соң авыл кешесе —Рәсәйнең төп халкы, туендыручысы Горькийның хәтеренә стихияле көч, "караңгы", белемсез, яңалыкны аңламый торган бәндә булып кереп кала.

Горькийның революциягә кагылыш-лы тагын берничә кызыклы фикеренә тукталасы килә. Аның уенча, сәясәт ярдәмендә генә "яңа кеше" тәрбияләп булмый, "революцион үзгәрешләр тудыручы алымнарны догмаларга әверелдереп, без хакыйкатькә түгел, ә киресенчә, һәлакәткә илтүче ялгышларга гына юл ачабыз". Шул ук вакытта революциянең тышкы бер көч кенә түгеллегенә дә басым ясый һәм "әгәр бары революция кешене хөр, күркәм (благородный) итә икән, димәк бу революция инсанның үз эчендә, үз *психологиясендә* барырга тиеш" дип саный Горький. Шунысы кызык, мондый фикерне бөек татар язучысы, милләт азатлыгы өчен янып йөрүче Гаяз Исхакый да, әле 1917 елгы инкыйлабка кадәр үк, үз әсәрләре мисалында күтәреп чыккан иде.



*Ф. И. Шаляпинның шәхси рояле.*

Татар әдәбиятында Горький традицияләре хакында сүз йөрткәндә, XX гасыр башының тагын бер күренекле әдибенә—Шәриф Камалга тукталмый китү мөмкин түгел. Күренекле галим, әдәбият белгече Мөхәммәт ага Гайнуллин аны Горькийның шәкерте дип атый.

Дөрестән дә, Ш. Камал—үз ижат эшчәнлеген, Горький үрнәгендә, эшче халыкның тормыш-көнкүрешен тасвирлаудан башлап, үз әсәрләрендә хезмәт темасын яктыртуга зур урын биргән кеше.

XX гасырга аяк басканда татар тормышында да эшчеләр сыйныфы үзенә бер урын били. Татар эшчесе җәмгыять тормышында да актив катнаша. Аның мәнфәгатен яклаучылар, аны кайгыртучылар барлыкка килә. Матур әдәбиятта да бу сыйныф тормышын чагылдырган әсәрләр, эшче образын үзәккә куйган образлар туа. Бу теманы ныклап яктыртырга керешкән әдипләр арасында Ш. Камал да була. Яңа җәмгыять

төзүчеләр дип ул да эшчеләр сыйныфын саный. һәм алар тормышын, көнкүрешен яктыртуны беренче әсәрләрендә үк максат итеп куя. Хезмәт иясенең яшәешен реалистик сурәтләү белән рәттән, әдип аларның рухи дөньясын ачуга да зур игътибар итә. Тәүге әсәрләрендә ("Уяну", "Козгыннар оясында") эшче халкының тискәре сыйфатларына күбрәк урын бирелә. Авыр хезмәт, күңелсез тормыш эшчеләрне тупасландыра, миһербансызлык, кешелексезлек кебек асыл сыйфатларны бик азлары гына саклап кала. Соңгырак чор әсәрләрендә исә ("Акчарлаклар", "Матур туганда") Ш. Камал да кеше рухының нечкә кичерешләрен, психологик кичерешләрне оста сурәтләүче әдип буларак танылa. Эшче, хезмәт иясенең кешене тупаслата, әхлакый сыйфатларын җимерә торган коточкыч шартларда яшәвен чагылдырган вакыйгалар белән бергә, үкенү, соклану, явызлану, аптырау, шатлану, үрсәләнү кебек психологик мизгелләрне дә тыгыз аралаштырып, үреп бирә. Ш. Камал әсәрләре мисалында җәмгыятьтә киләчәге зур булган эшче сыйныфының яралуы, тууындагы беренче манзаралар күз алдына килә. Тырышып, гадел хезмәт ярдәмендә тамак ялгарлык акча тупларга омтылган эшчеләрнең күмәк хезмәтен сурәтләгәндә әдип татар милләтенең күркәм гореф-гадәтләрен, йола-бәйрәмнәрен дә әсәр тукымасына мул кертә. Эшчеләр тормышын яктырткан мондый әсәрләрдә интернациональ дуслык идеясе дә калкып чыга.

* * *

Үз әсәрләрендә интернациональ дуслык, революцион күтәрелеш идеяләрен алга сөргән, шул сәбәпле XX гасырның 10 нчы елларында ук кимсетелгән халыкның яраткан язучысына, татар әдипләренең дә кайберләре өчен рухи остазга әверелгән А. М. Горький октябрь инкыйлабыннан соңгы вакыйгалар (ачлык, гражданнар сугышы, элекке зыялыларны, мәдәни учакларны юк итү) белән килешеп бетә алмый. Азат-хөр җәмгыять төзү кирәклеген күрсәткән "давыл хәбәрчесе" иске тормыш богауларын бары революцион күтәрелеш ярдәмендә генә өзәргә мөмкин дип аңласа да, революциянең кешелекне камиллеккә илтүче көч булырга тиешлегенә басым ясый. Большевиклар сәясәтенең дөрес түгеллеген тәнкыйтьләүдән курыкмаган бу язучы 1921 елда В. И. Ленин "инициативасы" белән Россиядән китәргә мәҗбүр була. Бу вакытта сәламәтлеге дә какшый башлаганга, башта ул Германиягә барып дәвалана, соңыннан Италиягә юнәлә.

Горький биографиясендә кызыклы мизгелләр бик күп. Шуларның берсе—аның В. И. Ленин белән мөнәсәбәте. Гәрчә, яшьлектә, 1880-1890 елларда, бер үк шәһәрдә (Казанда) яшәп, бер үк революцион оешмаларга катнашсалар да, язмыш аларны тәүге кат бары 1905 елда Петербургта чыга торган "Новая жизнь" газете редакциясендә очраштыра. Шул вакыттан башланган дуслык 1917 елгы октябрь борылышына кадәр дәвам итә. Революция тудырган кайбер үзгәрешләр Горькийның Ленинга булган карашларын да үзгәртә, һәм аларның дуслыгы берничә елга өзелеп тора. Әлеге ике бөек шәхес арасындагы дустанә мөнәсәбәт бары 1919 елда, Ленинга һөҗүм иткәннән соң гына кабат яңартыла. Алар күбесенчә Мәскәүдә, Горькийның беренче хатыны Е. П. Пешкова фатирында очрашалар. Соңгы очрашу вакытында (1921) Ленин аңа илдән китәргә тәкъдим ясый.

Карашларының әнә шулай кинәт аерылуына һәм илдән китәргә мәҗбүр булуга да карамастан, А. М. Горький Ленинга багышлап "Кеше" ("Человек") дигән очерк яза. Юк, өстән, партия карары белән түгел, ә нәкъ менә үз күңеле кушуы буенча.

* * *

1928 елда, 60 яше тулган көннәрдә, А. М. Горький Россиягә кайта. Бу сәфәрдән күп алда ул туган илендәге язучылардан, укучылардан, хәтта партиянең кайбер вәкилләреннән хатлар ала. Барысы да аны кайтырга өнди. Халыкның зыялы катлавы әле 20 еллар башында ук большевиклар сәясәтенең кырыслыгын тәнкыйтьләгән, курку белмәс Горький яңа җәмгыятьтәге сәяси көчләүләргә тәэсир итәр, хакыйкатьне күрсәтер дип өметләнсәләр, партия хөкүмәте вәкилләренә үзләре тоткан юлның "дөреслеген" аклардай авторитетлы кеше кирәк була. Бу эш беренче чиратта халыкның аңына матур әдәбият, матбугат аша житкерелергә тиешлеген истә тотып, әле күптән түгел генә революциягә дан җырлаган Горькийдан да "уңайлы" шәхес табылмый. Димәк, коммунистлар идеологиясен "дөрес" яктыртуны, әдәбиятта пропагандалауны башкартырдай язучы итеп куллану максатыннан көтәләр аны.

Шул кайтуында, 3-4 августларда, А. М. Горький Казанга да килә. Бу сәфәрендә аны улы Максим Пешков озатып йөри, кызыклы очрашуларны фотога төшерә. Язучы утырып килгән "Урицкий" теплоходын Кама Тамагында татар яшьләреннән, язучылардан торган делегация каршы ала.

Горький "Казанское подворье" (хәзерге "Казан" кунакханәсендә) туктала. Кунакханә каршына аны котларга бик күп халык җыела. Танылган рус язучысы аларны кайнар сәламли. Кичен исә ул Зур театрда (хәзерге К. Тинчурин театры) шәһәр советының киңәйтелгән утырышында чыгыш ясый. Һәм яшьләргә, шәһәребез зыялыларына карап түбәндәге сүзләрне әйтә: "В книге "Мои университеты" рассказано о том, как я жил здесь, в Казани. Но на самом деле, в Казани я пережил больше горьких минут, чем это изображено в моих сочинениях. Но нет худа без добра. Вот сегодня я уже возмещен за все пережитое в Казани сторицей... Однако, я должен сказать следующее: по сравнению с теми делами, которые совершаете вы в этот период, пережитое отдельными личностями—это мелочи" . *(М. Гайнуллин. Горький и татарская литература. Татгосиздат, 1944).* А. М. Горький шулай ук "Кызыл Татарстан" гәзите редакциясендә дә була.

Горькийның Казанга килүе уңае белән Татар мәдәнияте йортында (хәзерге ТЮЗ) концерт әзерләнә. Аның җитәкчесе Шамил Усманов була. Бу кичәдә (1928 ел, 4 август) танылган баянчы Илялов, Хисамов, җырчы Асия Измайлова (ул вакытта әле Ш. Усмановның хатыны) чыгыш ясый, С. Сәйдәшевның "Дим буенда", "Мәйсәрә" әсәрләре, татар халык көйләре яңгырый. Шушы ук кичәдә танылган язучы Г. Кутуй Горькийның татарчага үзе тәрҗемә иткән "Песня о буревестнике" хикәясен укый.

Әлеге истәлекле очрашу хәтирәсен саклаган тагын бер кызыклы материал бар. Ул—Кави Нәҗминең "Шобага" хикәясе һәм Горькийга язган хаты: "Дарю на память свой рассказ, который является несовершенным, неотшлифованным образцом моего творчества (1928 ел, 4 август)" .

Горький Казанга килгәч бик күп татар язучылары белән очраша. Бу вакыйгаларга рәссамнарыбыз күп кенә әсәрләр багышлаган. Мәсәлән, А. М. Горький музее залларында Г. Минский һәм Г. Кутуйның А. М. Горький белән очрашу вакыйгасын мәңгеләштергән картина саклана. Авторы—Бикташев.

Үз заманының бөек язучысы булган Максим Горький белән очрашу, аралашу К. Нәҗмигә генә түгел, Ш. Усманов, Сәрвәр Әдһәмова, Г. Кутуй кебек егерменче елларда әдәбиятка килгән ялкынлы йөрәкле башка язучыларга да иҗат дәрте өсти.

Татар язучылары, шагыйрьләре, зыялы яшьләре аны 1930 елда да Татарстан җөмһүриятенең 10 еллыгын бәйрәм итү көннәренә чакыралар. Әмма Горький килә алмый, шулай да тантаналы бу бәйрәм белән кайнар котлап телеграмма җибәрә.

* * *

1928-1929 еллардан башлап, 1934 елга кадәр Горький бер идеясен тормышка ашырырга тырыша. Бу—20 елларда үзара көрәшкән төрле әдәби төркемнәрне бергә берләштерү, аларны совет әдәбиятының бердәм, нык нигезенә әверелдерү. 1928 елда Л. Авербахка әйтелгән бу фикере язучының төрле чыгышларында, башка шәхесләргә язылган хатларында да еш кабатлана. Гәрчә, ҮК каршында РАПП вәкилләре дә, А. М. Горький да партия әдәбият белән идарә итүне үз кулына алырга тиеш дип барсалар да, партиягә йөкләгән бу бурычны алар төрлечә аңлыйлар.

РАПП һаман да әдәбият белән үзе генә идарә итәргә омтыла, моңа партия тарафыннан боерык-күрсәтмәләр көтә. Ә Горький исә, ҮК ярдәме белән нигезен барлык әдәби агым, юнәлешләрнең бердәмлеге тәшкил иткән совет әдәбиятын тудыру планын тормышка ашырырга тели.

Бу хакта ул Госиздат җитәкчесе А. Б. Халатовка юллаган хатында ачык хикәяли[1]. Әлеге хатта түбәндәге юллар игътибарны җәлеп итә: "Партия слишком мало обращает внимание на литературный фронт. Это плохо. Всесоюзным педагогом является партия в лице ЦК... Или партия руководит литературой, или она не умеет руководить ею. Нужно, чтобы умела, нужно созвать "врагов" под одну крышу и убедить их, в необходимости строгого единства".

Әлеге хаттан күренгәнчә, Горький Россия әдәбиятында барган барлык бәхәс-

---

*Нәкъ менә А. Б. Халатов аша Горький Сталин һәм партия вәкилләре белән элемтәләр алып барган.*

дискуссияләрдән хәбәрдар булган һәм моңа тискәре караштa торган. Әдәбияттагы бу көрәш төп максаттан—совет иленең эшче, хезмәт иясе массасын тәрбияләүдән ерагайта дип санаган.

Россиягә икенче кайтуында да, ягъни 1931 елның маенда, Горький бу карашын үзгәртми, нык тора.

1931 елда Горький һәм РАПП житәкчеләре арасында хезмәттәшлек башлана, алар беразга якынайгандай булалар. РАПП язучылары сәнгатьтә I бишьеллык каһарманнарын сурәтләү бурычын куялар, хезмәт алдынгыларын әдәбият мәйданына өндиләр. Шул җәһәттән кайбер язучыларны завод-фабрикаларга әдәбият түгәрәкләренә житәкчелек итәргә, эшче халыкның тормышын тулы яктырту өчен материаллар җыярга җибәрәләр. А. М. Горький исә РАПП вәкилләренең бу адымын меңнәрчә хезмәт ияләренең белемгә, фәнгә, ижатка тартылуы, ягъни мәдәни инкыйлабның яңа этабы дип кабул итә.

Ләкин РАПП житәкчеләреннән аермалы буларак, А. М. Горький эшче яшьләр иҗат иткән әсәрләргә аек бәя бирә, аларны чын әдәби ядкарьләр рәтенә кертергә мөмкин түгел ди. Андыйларга профессиональ язучылар иҗат иткән әсәрләрне алмаштырырдай итеп түгел, ә бәлки матур әдәби үрнәкләрне тудыру өчен кирәкле "материал" дип карый.

Горькийның РАПП житәкчеләре (Л. Авербах, Н. Шушканов һ. б.) белән якынаюының берничә сәбәбе бар. Беренчедән, язучы РАППның кайбер планнарын, идеяләрен, әдәбияттагы башлангычларын үз итсә, икенчедән, соңгылары да Горькийның кайбер зур максатларын тормышка ашырырга булышлык итәләр. Янә бер моментны күздән ычкындырып булмый, 1931 елның ахырында РАППның иске житәкчеләре—"налитпостовцы" (Л. Авербах, В. Ермилов, В. Киршон, А. Фадеев) һәм яңа "башлыклар"ы (Ф. Панферев, В. Ильенков, В. Ставский һ. б) арасында туган катлаулы, куркыныч бәхәстә РАППның иске вәкилләрен Горький белән якынаю коткарып кала. 1931-1932 елның кышында Л. Авербах, А. Афиногеновның Горький янына Соррентога (Италиягә) баруы да бәлки шуның белән бәйледер, һәм Горький янында соңрак Фадеев һәм В. Киршон да булган дигән карашлар бар.

РАПП житәкчеләренең А. М. Горький белән, соңгысының большевиклар партиясе вәкилләре белән тыгыз бәйләнешендә сәяси сәбәпләрдән тыш, шәхси моментлар да бар әле. Л. Авербахның сеңлесе—Горькийның якташы, ОГПУ житәкчесе Г. Ягоданың хатыны, ә аның әнисе (чыгышы белән ул да Т. Новгородтан) агалы-энеле Свердловларның сеңлесе булганлыгы мәгълүм. Кайчандыр Зиновий Свердловны Горький уллыкка ала. Ләкин Зиновийны Сталин лагерьларыннан йолып калуда бу факт та ярдәм итми.

Совет әдәбиятында сәнгатьчә эшләнеше ягыннан түбән әсәрләр иҗат ителүе 1920-1930 елларда әдәбият мәйданында барган каты бәхәсләр, төрле әдәби агым, төркемнәрнең эшчәнлеге, дөресрәге, көрәше белән бәйле. Мәсәлән, РАППның яңа житәкчеләре "Октябрь" журналы тирәсенә тупланалар (баш мөхәррире Ф. Панферов). 1932 елда Л. Авербах Горькийга язган бер хатында "..."Правда" битләрендә совет әдәбиятын алга җибәрә торган түгел, иң күп дигәндә, урта кул диярдә яраган әсәрләрне, китапларны совет язучысы өчен үрнәк дип игълан итәләр",— дип зарлана. А. М. Горький исә бу эшләрне "мәдәниятнең түбән тәгәрәвенә, әдәбиятның гадиләштерелүенә китерә" дип саный. Горькийның РАПП житәкчеләрен (тәгәлрәге, "авербахчылар" ны) яклап "Известия" дә бастырган мәкаләләре дә соңгыларының язмышын хәл итә алмый. 1932 елның 24 апрелендә ҮК "Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору" дигән карар кабул итә. Бу карар нигезендә 20 елларда әдәбиятта партиянең таянычы, терәге булган РАПП юкка чыгарыла. Гәрчә, бу күренешне Горькийның күптән көткән хыялы—әдәбиятта хакимлек итәргә омтылуының тормышка ашуы дип карасалар да, Горькийның үзе өчен дә көтелмәгән хәл була ул.

Әлеге карар Горький 1932 елда Россиягә кайтырга тиеш булган көннәрдә кабул ителә һәм бары тик язучы совет дәүләте чикләрен кичкәннән соң гына халыкка җиткерелә. Алексей Максимович исә мондый карар белән килешмәвен белдерә *(Л. Спиридонова. М. Горький: диалог с историей.—Наука, 1994).*

Билгеле булганча, РАПП үзе үк партиянең әдәбияттагы идарәсе иде. Аның эшчәнлеге партиянең үзәк комитеты тарафыннан контрольдә тотыла. РАПП житәкчеләре дә эчке сайлаулар, тәкъдимнәр аркасында түгел, бәлки югарыдан төшерелгән боерыклар буенча алмашынып килә. РАППның тоткан юлы ҮКның матбугат бүлеге билгеләгән юлга әверелдерелә. Ә аның башында исә Борис Волин тора. Үзе дә әдәбиятчы-"раппчы" буларак, ул—партиянең барлык карарларын, боерыкларын җиренә җиткерергә тырышкан кеше.

РАППта житәкчеләр, әйдәп баручы язучылар бер-бер артлы алмашынып кына

торган. Җитәкче урыннардан төшерелгәннәр "халык дошманы", "корткыч" дип игълан ителгән. 20 еллардан башланган әдәбиятны зарарлы "элементлар" дан чистарту күренеше тиз арада гадәти хәлгә әверелеп китә. Гаепсез килеш "халык дошманы" ярлыгын тагарга ярдәм иткән яңа буын җитәкчеләр, язучылар таякның рәхимсез башы үзләренә төшкәч, ягъни шундый ук бәлаларга юлыккач, аптырап калалар. Коммунистлар партиясе уйлап тапкан иң ерткыч, мәрхәмәтсез бу "уен" нең асылын исән калучылар бары тик соңлап кына аңлый алганнар.

РАПП җимерелгәннән соң Совет язучылары берлегенең оештыру комитеты төзелә. Аның почетлы рәисе итеп А. М. Горький билгеләнә. Рәисе вазифаларын И. М. Горнский, сәркәтип вазифаларын В. Я. Кирпотин башкара.

Кайвакыт Горькийны Сталинның сәяси карашларын яклауда гаепләгән сүзләр дә ишетергә туры килә. Соңгы елларда бу гаепләрне артык инкяр итмичә, язучының әдәби-иҗтимагый эшчәнлегендәге төп юнәлешләрне күрсәтергә омтылган хезмәтләр дә дөнья күрә башлады. *(В. Баранов. Горький без грима,—М., 1996; С. Сухих. Заблуждения и прозрения М. Горького,—Н. Новгород, 1992).* Аларда Горький Сталин "социализмы"ның рәхимсез, чын йөзен бераз кешелеклерәк, мәдәниятлерәк итү өчен көрәшүче буларак сурәтләнә. Дөрестән дә, ул шәхес иреген кысуларга, партиянең җәмгыятьтә генә түгел, әдәбият өлкәсендә дә бюрократларча формаль, коры боерулар белән идарә итәргә омтылуына каршы чыккан кеше. Элегрәк елларда бу күренешләр РАПП аша башкарылса, хәзер исә әдәбият белән түрәлек итәргә яңа төркем—"партияле-язучылар", "коммунист-язучылар" килә.

Шуны әйтергә кирәк, партияле булу-булмауга карамастан, әдәбиятта чын талантларның өстенлек итүе өчен, әдәби телнең сафлыгы, язучының исә белемле, һәрнәрсәдән хәбәрдар, зыялы булуы өчен көрәшне Горький Язучыларның I съездына кадәр дә, аннан соң да алып бара. Аның фикеренчә, парбилеты булган, билгеле бер дәрәҗә белгән кеше әле җисеме белән дә гаделлек, дөреслек яклы коммунист дигән сүз түгел.

Фикердәше, якын танышы Л. Б. Каменевның С. М. Кировны үтерүдә гаепләнүе, аннан соң бөек язучының һаман да халыклар юлбашчысы Сталин турында очерк язмавы, үзе оештырган язучылар съездында партиясез әдипләрне югары күтәрүе—болар барысы да Сталин алдында Горькийның дәрәҗәсен төшерә. Аңа карата матбугатта каты тәнкыйть сүзләре белән чуарланган мәкаләләр күренә башлый. Җавап рәвешендә Горький да мәкаләләр яза, ләкин, архивлардан табылган бүгенге мәгълүматларга караганда, алар матбугатка үтмиләр. Димәк, аның сүз ирекге кысыла, хәтта аралашу мөмкинлеге дә тарайтыла.

Горькийның әдәби-иҗтимагый эшчәнлеген күзәтеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Совет әдәбиятының асылы бертөрле, соры булуы, сәнгатьтә идея эчтәлеген читкә кагып, тышкы формалар белән мавыгу аны да канәгатьләндерми. Ә менә Горькийның 30 елларда ясаган чыгышлары, әдәби телнең сафлыгы, каләм иясенең культуралылыгы өчен көрәше әдәбият-сәнгать эшчәнлеген каты контрольдә тоткан хаким сыйныф тарафыннан әдәбиятта бердәм "авторитар" стиль, ныклы бер метод—"социалистик реализм" алымын урнаштыру өчен оста файдаланылган. Әдипнең теге яки бу язучы әсәрендәге кимчелекләргә карата тәнкыйди чыгыш ясавы була, партия идеологлары бу каләм осталарына каршы аяусыз көрәш башлыйлар, ул шәхесләрнең үзләрен генә түгел, иҗатларын да халык хәтереннән, тарих битләреннән сызып ташларга тырышалар.

Дөрес, Горькийны гөнаһсыз дип исбатларга җыенмыйбыз. Гаять катлаулы, каршылыклы шәхес ул. Мәсәлән, аның төрле юнәлештә иҗат иткән—пролетар, крәстиян язучыларына, "юлаучылар" га мөнәсәбәтен генә алыйк. Крәстиян язучыларына, аларның әсәрләренә гомере буе тискәре мөнәсәбәтен үзгәртмәгән хәлдә, калган ике төркемгә карашлары үзгәреп торды. Югарыда утыручы хөкүмәт вәкилләре бу үзгәрешләрне бик тиз "тотып алып", совет әдәбиятын, җәмгыятен башкача уйлый белә торган, хөр фикерле адәмнәрдән "азат итә" тордылар. Кайвакыт Горький иҗатын якын итүләре, аның белән шәхси таныш булулары да соңгыларын фаҗигадән коткарып кала алмады.

Рус әдәбияты, андагы төрле процесслар турында сөйләгәндә без аларның татар әдәбиятына да кагылуын, тәэсир итүен күрсәтми үтә алмыйбыз. Татар язучылары, шагыйрьләре дә ирексездән илдә, әдәбиятта барган сәяси бу көрәшкә тартылалар.

Мәгълүм булганча, 1920 елда Татарстанда яңа матбугат оешу язучыларның илһамланып эшкә керешүенә сәбәпче була. Рус әдәбияты үрнәгендә "Октябрь", "Часовой", "Завод" кебек әдәби төркемнәр барлыкка килә. Аеруча, "Октябрь" әгъзалары "социализм өчен хезмәт итү, буржуазия, мещанлык, динчелек идеологиясенә каршы көрәшү" кебек лозунглар белән коралланып, татар язучыларына йогынтысын көчәйтергә тырышалар.

Ул елларда татар әдәбиятын да идеологик максатларда файдалану күренешләре күзәтелде. Аның төп оештыручылары Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми, Г. Кутуйлар иде. Мондый юнәлеш вәкилләре "иске әдәбият үзенең чикләнгән кануннары, буржуаз җәмгыятьне сурәтләве, дин әһелләренә дан җырлавы белән бергә себереп түгелергә тиеш" кебек идеяләрне алга сөрде. Шул сәбәпле 1917 елга кадәрге гаять талантлы сүз осталарыбыз (Дәрдмәнд, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Исхакый, Ш. Камал, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич h. б.) "чүплек башына" чыгарылып ыргытылалар. Бай мирасыбызны шулай кире кагып, татар мәдәниятен мең еллык тамырларыннан аерып кую иде бу. Аның ачы нәтиҗәләрен бүген татыйбыз. Билгеле бер шәхес иҗатын, исемен юк итү, пычрату тиз булса да, милләте өчен башкарган фидакарь хезмәте халык хәтерендә озак саклана. Әмма бөтен бер җәмгыять ялганга корылганда хакыйкатьне киләсе буыннарга җиткерү җинел эш түгел. Бәлки шуңадыр да милләтебезнең асыл затлары турында чын, дөрес тулы мәгълүматларны бүген дә җыеп бетерә алганыбыз юк.

40-50 елларда галимнәребезнең зур тырышлыгы белән Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирханнарның исемнәре кабат әдәбиятыбызга кайтарылды, уку йортларында алар иҗаты өйрәтелә башлады.

Алда әйтеп үтелгәнчә, Октябрь инкыйлабы һәм аннан соңгы еллардагы әдәбиятта байтак яңа исемнәр пәйда була. Иске тормышны үзгәртеп коруга багланган өметләрнең акланмавы, яңа җәмгыять төзүгә рухланган яшьләрнең иҗади дәртен сүндерә алмый. Ул еллардагы әдәбият "авызыннан ялкын һәм төтеннәрен бөркетеп торган янартауны хәтерләтә" ди Т. Нурмөхәммәтов (*Җидегән йолдыз яктысы , "Мәдәни җомга" , 1998, 19 сан).*

1929 елда бер төркем татар язучылары Г. Ибраһимов янында Ялтада булып кайталар. Ләкин репрессияләр дулкыны башлангач, милләтчелектә гаепләнгән (дөрестән дә большевик тәмугында үз милләте өчен көрәшкән) Г. Ибраһимов белән элемтәдә булган (сөйләшкән, күрешкән, хат алышкан) һәр татар зыялысына бу хакта исенә төшерәләр. Күпләр өчен бу очрашу гаепләү акты булып яңгырый.



*Ф. И. Шаляпинның оныгы Дассия Робертсон-Шаляпина музейда кунакта (1998 ел)*

Соңгы вакытларда Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнү бераз сүлпәнәйгәндәй булды. Моңа аның Совет дәүләтендә калып, совет татар әдәбиятының күренекле вәкиленә әйләнүе дә тәэсир итми калмагандыр. Ул коммунистларга ярарга тырышкан, аларга җайлашкан дигән фикерләр дә бар. Ләкин галимнәребез раславы буенча, Г. Ибраһимов революциягә кадәр ни дәрәҗәдә милләт җанлы кеше булса, илдә большевиклар хаки мияте урнашкач та бу инануыннан баш тартмаган, ягъни халкына хезмәт итү, аның азатлыгы өчен көрәшүдән туктамаган. Аның 1927—1928 елларда Татарстан республикасының 10 еллыгы көннәрендә ясаган чыгышында төрле өлкә, төбәкләрдә яшәгән татарларның берләшергә тиешлеге, бер мәдәниятле ия булган төрки халыклар арасында милли элемтәләр урнаштырырга кирәклеге хакындагы әһәмиятле фикерләр яңгырый.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов әсәрләренә яңача караш, милли реализм күзлегеннән чыгып ясалган тикшерүләр таләп ителә. Әдипнең 20 - 30 еллар татар зыялылары өчен җитәкче, яшь язучылар өчен өлге булуы, аның иҗаты белән дә, шәхси тормышы белән дә һәрдаим кызыксынып торуларын А. М. Горький музеенда саклана торган кызыклы фоторәсем дә дәлилли. Анда татар язучыларының 1929 елда Ялтада Г. Ибраһимов белән очрашу мизгеле сурәтләнгән.

20-30 елларда Казанда төрле кызыклы мәдәни кичәләр оештырыла. Мәсәлән, 1930 елның 15 маенда Казанда "Такташ һәм Кутуй" кичәсе үткәрелүе хакындагы афиша сакланып калган. Татар яшьләренең яраткан шагыйре—күк йөздәй зәңгәр күзле, артка

тарап куйган, бераз дулкынланып торучы җитен-сары чәчле Һади Такташ, һәм бер елмаюы белән генә дә меңнәрчә хатын-кызны үзенә гашыйк итә торган, укучы күңеленә рухи матурлык җырчысы булып кереп калган Гадел Кутуй шигырь сөючеләр алдында чыгыш ясыйлар. Г. Кутуй үзенең—"Заман", "Безнең курай", "Бала", "Кеше", "Сәлимә", "Талаш", "Тән фронты", Һ. Такташ исә "Җавап", "Мәхәббәт тәүбәсе", "Мокамай", "Алсу", "Син дошманым минем", "Чигенү", "Күләгәләр", "Үтеп барышлый", "Киләчәккә хатлар", "Нәни шаяртулар" кебек әсәрләрен укый. Шунда ук тамашачылар "Такташ белән Кутуй шагыйрьләр", "Такташ белән Кутуй язучылар" темасына Г. Галинең докладын тыңлыйлар. Кичәдән соң сорауларга җавап бирү, ике бөек шагыйрь иҗатына багышланган күргәзмәне карау оештырыла.

Гадел Кутуй 30 елларның икенче яртысында татар зыялылары темасына багышланган хикәяләре белән дә танылып өлгерә. "Тапшырылмаган хатлар", "Илһам", "Солтанның бер көне", "Вөҗдан газабы", "Сагыну" кебек әсәрләре аны үлемсез итте. Ә менә Һади Такташның язмышы аянычлы. 20 елларда аңа "колак җырчысы", "анархист", "индивидуалист" дигән ярлык таккан булсалар, безнең көннәрдә дә Такташ исеме тирәсендә моңа охшаш чыгышлар тагын ишетелә башлады. 90 еллар башында аның "Мокамай", "Алсу"лары шул чордагы хәлләрне бозып күрсәтә, "Күмелгән кораллар", "Камил" пьесалары исә вульгар социалогизм шаукымына юлыккан әсәрләр рәтенә керә дип тәнкыйтьләүчеләр дә табыла. Әмма Такташ иҗатында игътибар ителергә тиешле бер идея бар: ул да булса—аның иҗат нигезенең асылында нәрсә ятуы. Заманында шагыйрь "Иҗадиятем турында" мәкаләсендә "яңа заманның яңа шигърияте иске классика казанышлары дәрәҗәсендә булырга тиеш" ди һәм ул классика казанышларын чорга җавап бирерлек яңа баскычка күтәрү кирәклегенә басым ясый *(Гайнетдинов М. Такташ һәм такташлык турында. "Казан утлары", 1991, 1 сан).*

"Тормышны, идеологияне нигездән яңарту революция, партия, совет дәүләте тарафыннан гына башкарылырга хаклы", әдәбиятны шушы максатка ирешүдә бер корал гына дип санаучы "пролетар" юнәлеш вәкилләре Такташның фикердәшләренә, беренче чиратта аның үзенә ташланалар. 1923 елда "Чаян" журналында шагыйрьгә каршы тәүге пычрак тәнкыйть сүзләре атыла. Әдәбият белгече М. Гайнетдинов фикеренчә, аңа "бүген безгә билгеле булмаган нииндидер формаларда" көчле басым ясаулары да бар. Чөнки шагыйрь үзенең элеккеге иҗатыннан рәсми рәвештә баш тартуын белдергән "Такташ үлде" дигән шигырь яза. Әмма эзәрлекләүләр тукталмый. Шул ук 1923 елда К. Нәҗми дә "Такташизм" дигән мәкалә бастыра *("Татарстан" газете, 1923, 2 декабрь).*

Үз халкының язмышы турында уйланырга җөрьәт иткән милләтебезнең асыл уллары әнә шулай үз замандашлары тарафыннан яклау тапмыйча, аңланылмыйча, кыйлган гамәлләренә дөрес бәя ала алмыйча бер-бер артлы юкка чыгарылалар. Татар әдәбиятының һичшиксез талантлы шагыйрьләреннән берсе Һ. Такташны ул чорда "юлаучылар" төркеменә кертәләр. 20 еллар "пролетар" әдәбияты исә аның иҗатының гыйсъянчылык сыйфатларын өнәп бетерә алмый, чөнки Такташ—"алдынгы яңарыш юлбашчысы, намус көрәшчесе". Төрле ялган гаепләргә дә карамастан, шагыйрьлек миссиясенә тугъры калган Такташ бүгенге татар әдәбиятының ядкарьләре саналырга хаклы "Мокамай", "Алсу", "Киләчәккә хатлар" кебек әсәрләрен тудыра алган. Әлеге әсәрләрендә ул, үзе әйткәнчә, "миллионнарның йөрәк хисен җыеп йөрүче, туып та әле исем бирелмәгән хисләренә исем бирүче" булып гәүдәләнә.

Үткен телле, ялкын йөрәкле Такташ гомеренең соңгы көннәренә кадәр "Азат хатын", "Авыл яшьләре" журналларын чыгаруда катнашу белән бергә, "Чаян" да да хезмәттәшлек итеп килә. А. М. Горький музеенда аның "Чаян"да эшләвен дәлилләүче "таныклама"сы саклана.

Азат тормыш, җәмгыять төзү өчен килгән яңа буын яшьләре арасында 19 яшендә большевиклар партиясенә тугрылыклы калырга ант иткән Шамил Усманов та була. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәясәт бүлеге җитәкләгән бу коммунист 1923 елда Солтангалиевне яклап чыгыш ясый, һәм алып барган сәясәтләренең асылына ишарәләп, коммунистлар партиясен "кара русчылык"та (шовинизмда) гаепли. Татарстан җөмһүриятендә дәүләт теле буларак татар телен дә калдыру мәсьәләсен дә күтәреп чыга.

Сәяси эшчәнлек белән бергә әдәбият өлкәсендә каләмен сынарга да өлгерә Ш. Усманов. Аның гражданнар сугышын яктыркан "Памирдан радио", "Легион юлы", "Кичеккән фәрман" әсәрләре татар сугышчыларының каһарманлыкларын сурәтлиләр һәм әдәбиятыбызның үлмәс исемлеген тәшкил итәләр. Әмма 1937 елда кулга алынгач аңа нәкъ менә шушы әсәрләре өчен җавап бирергә туры килә. Аларны "милләтчелек" рухында "язылган" әсәрләр дип игълан итәләр. Кайчандыр бер "иҗат арбасы" нда утырган

каләмдәшләрен Ш. Усмановка "милләтче", "вәлидичелекне пропагандалаучы" дигән ялган гаеп тактырып, уртак максат—милләтенә хезмәт итү уе белән янган кешеләрне партия идеологлары үзара каршы куялар. Алай гына да түгел берсе тарафыннан икенчесен юкка чыгарталар.

Ә. Ш. Усманов үз халкын сөйгән, аның мөстәкыйльлеге, киләчәге өчен борчылган "милләтче"—большевик, әсәрләрендә уңай герой итеп татар сугышчыларын сурәтләми кемне сурәтләсен?! I Татар бригадасы комиссары Ш. Усманов үзе күргән, чынбарлыкта булган вакыйгаларны чагылдыра. Шулар аша инкыйлабның кеше акылына һәм рухына ясаган тәэсире ачыла.

А. Горький музее архивында Ш. Усмановның берничә шәхси әйберләре белән рәттән "Подпоручик Даниловның үлеме" хикәясенең русча кулъязмасы да саклана. Әлеге әсәр Горькийга юлланган була. Горький исә аңа төзәтмәләр керткән һәм хикәягә кыскача гына бәя биргән.

Әлбәттә, авторның психологик моментларны, тискәре геройның эчке кичерешләрен тасвирлаган урыннарны ул елларда гомумән кабул итмәгәннәр. Бүгенге көн өчен аларның әһәмияте зур булырга мөмкин. Әлеге күренешләр Ш. Усмановның да революциягә кадәр үк формалашкан татар әдәбияты традицияләренә таянуы турында сөйләмиме?! Бәлки әлеге язучының әсәрләре дә инкыйлабтан соңгы чорда татар халкының азатлыгы, мәдәни үсеше өчен көрәш тарихын яктырткан әсәрләр исемлеген тәшкил итәргә хаклыдыр?!

А. М. Горькийның татар әдәбиятына мөнәсәбәтен күрсәткәндә аның 1935 елда язучы, Горький музееның беренче директоры М. Н. Елизаровага язган хатындагы түбәндәге сүзләрен игътибарсыз калдырсак, 30-40 еллар татар әдәбияты үсешенең мөһим сәбәпләреннән берсенә күз йому булыр иде. "Я горячо желаю яркого рассвета татарской поэзии и прозы, но это может быть достигнуто только очень строгим отношением к задачам литературы" *(М. Гайнуллин. Горький и татарская литература.—Казан, 1944)*.

Революцион рухлы чор әдәбиятында Горький үзәк фигураларның берсе саналганда бу сүзләрнең этәргеч көче гаять зур булган, яшь татар язучыларына иҗат дәрте өстәгән. Мәсәлән, күренекле татар драматургы Ф. Бурнаш 1937 елда Горькийның "Ана" романын татарчага тәрҗемә итә.

Революциягә кадәр үк ул "шигъриятнең иң югары нокталарда торган" 11 әсәре белән таныла. Ә 1917 елда драматургия өлкәсендә дә көч сынап карый һәм әдип исемен үлемсез иткән "Таһир—Зөһрә", "Яшь йөрәкләр" пьесаларын яза. Беренчесен 1918 елда Г. Кариев сәхнәгә куя. Әлеге әсәрләрдә милли әдәбият традицияләре дәвам иттерелә. Ләкин соңрак—совет хөкүмәте елларында иҗат ителгәннәрендә ("Хөсәен мирза", "Камил карт") совет идеологиясенең аерылгысыз билгеләре булган "кызыллык", пионер, комсомол эшчәнлеге, дин әһелләреннән көлү кебек күренешләр әсәрләренең милли асылын күмеп китәләр. Шул сәбәпле бүгенге көн укучысы аларны күреп бетермәскә мөмкин. Әмма партиячел тәнкыйть моны тиз тоеп ала һәм Ф. Бурнашка, әдәбият галиме А. Әхмәдуллин язганча, "эшче-крәстиян әдәбиятын агулаучы" дигән тамга сала.

Беренче тапкыр Ф. Бурнаш Казанга 1920 елларда килә һәм Г. Ибраһимов фатирында туктала. Башкалада яшәү дәверендә ул Г. Тукай, Дәрдмәнд, К. Тинчурин иҗатларын өйрәнә, аларга үз бәясен бирә.

1927—1928 елларда драматург буларак танылып өлгергән Ф. Бурнашны Татар академия театрының җитәкчесе итеп куялар. Шул елларда ул Ш. Усманов, К. Нәҗмиләр белән бергә "Октябрь" төркемен оештыра. Ә 1933 елдан әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнергә керешә. 1933—1938 еллар аралыгында Тургеневның "Аталар һәм балалар", Толстойның "Хаҗи Морат", Островскийның "Корыч ничек чыныкты", Пушкинның "Евгений Онегин", Горькийның "Ана романнары өстендә эшли.

Ләкин совет әдәбиятында соцреализмның "атасы" саналган А. М. Горький әсәрен—большевиклар үз эшчәнлегендә лозунг итеп күтәргән "Ана" романын тәрҗемә итү дә Ф. Бурнашны "милләтчелек"тә гаепләүдән коткарып кала алмый. Сталин репрессиясе елларында хаксызга шәһит киткәннәр арасында ул да була.

1934 елның 29 июлендә Казанда Совет язучыларының I Бөтентатар корылтае була. А. М. Горький музее архивында әлеге корылтай утырышының беркетмәсе (копиясе) саклана. Анда күрсәтелгәнчә, идарә составына түбәндәге язучылар кергән: "К. Нәҗми, К. Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Хәсән Туфан, Ләбиб Гыйльми, К. Тәхвәтуллин, З. Ризванов, Б. Красный". Кандидатлар исемлегенә исә

"Ш. Камал, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази" исемнәре теркәлгән. Бу вакытта идарә рәисе Кави Нәҗми була.

Әмма 1936 елның 26 октябрендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты "Татар совет язучылары оешмасының эшчәнлеге турында" дигән карар кабул итә. Бу карар нигезендә нәкъ ярты елдан соң (1937 елның апрель-маенда) Кави Нәҗми һәм татар язучыларының күпчелеге кулга алына. Татар совет язучылары идарәсе рәисе итеп Ләбиб Гыйльми куела. Ләкин алар берсе дә бу урында озак тукталып тормыйлар. Сталинның үлем конвейеры татарның зыялы катлавын тизрәк юкка чыгарырга ашыга.

Совет язучыларының I Бөтенсоюз корылтаенда делегатлар итеп Татарстан язучылар идарәсеннән А. М. Горький һәм аның белән берлектә Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, К. Тинчурин, Г. Гали, Г. Нигъмәти, Г. Толымбай, Ф. Сәйфи, И. Гази, Л. Гыйльми сайланалар.

Әлеге корылтай хакында Гаяз Исхакый Берлинда үзе нәшер иткән "Яңа милли юл" журналында "Кызыл әдәбият" дигән мәкалә бастыра (1934, 9 сан).

1918 елда большевиклар идеологиясе белән килешмичә чит илгә киткән Г. Исхакый, Й. Акчура, Г. Терегулов, Ф. Туктаров Россиядә барган сәяси вакыйгалар белән кызыксынып торалар. Совет хөкүмәте үткәргән милли сәясәт, дингә каршы һөҗүм, әдәбият-мәдәният өлкәсендәге үзгәрешләр, татар халкының зыялы катлавын юкка чыгару аларны борчый һәм кулларына каләм алырга мәҗбүр итә. Коммунистлар алып барган мәкерле эшчәнлекне бигрәк тә Г. Исхакый каты тәнкыйтьли. Мәсәлән, татар совет әдәбиятының торышын чагылдырган бер язмасында ("Яңа милли юл", 1937, 8 сан) югарыда телгә алынган татар совет язучыларын тәнкыйть утына тота. Әлбәттә, 1917 елгы октябрь революциясенә кадәр чәчәк атарга өлгергән татар әдәбиятының 20—30 еллардагы халәтен күрү (ә ул вакытта әдәбият чыннан да авыр чор кичерә) татар әдәбияты-мәдәниятен үстерүгә гомерен багышлаган Г. Исхакый өчен авыр булгандыр.

Музейның татар әдәбияты бүлегендә Хәсән ага Туфанның трубкасы саклана. Ни кызык: зур булмаган менә шушы шәхси предмет, миңа калса, аның хакында күп нәрсә сөйли. Әлеге трубкага караган саен хаксызга рәнҗетелгән, гомеренең ахырына кадәр рухи бу җәрәхәтне ямап бетерә алмаган шагыйрь алдында баш иясе килә.

Истәлекләрдән күргәнчә, Х. Туфан Казанга һ. Такташ иҗатына гашыйк булганга килә. "Такташның шигырь кыңгыравы көмеш кыңгырау гына түгел, алтын кыңгырау булып тоелды. Эшләрне... ташлап, Такташлы Казанга килдем..."—ди ул.

Казанда иҗади эшчәнлеген башлаганчыга кадәр Х. Туфан "Милли шура" җитәкчелеге астында эшләүче татар яшьләре оешмасының җитәкчесе була. Әлеге түгәрәк әгъзаләре татарларның мәдәни автономиясе кайсы сыйныфтан чыгуына карамастан, башка милләткә кабалага төшмәс өчен, татарларның үзара берләшергә кирәклеге турындагы идеяләрне алга сөрәләр. Һәм бу эшне большевиклар партиясе хакимлегеннән башка, мөстәкыйль алып барылырга тиеш дип саныйлар. Г. Исхакый һәм башка әдипләрнең әсәрләрен сәхнәдә куеп, концертлар, милли җыр, көйләребез аша татар мәдәни автономиясен пропагандалыйлар. 1922 елда әлеге түгәрәк таркалгач, яшьләр Читадагы большевик татарлар җитәкләгән мөселман клубына кушылалар.

1940 елда кулга алгач, нигездә "Ант" поэмасына таянып һәм бу милли эшчәнлеген дә исенә төшереп, Х. Туфанны совет хөкүмәтенә каршы эш йөртүдә гаеплиләр. Шагыйрьнең шигъри хыялы сурәтләнгән вакыйгалар аның үзе өчен фаҗигагә әверелер дип кем уйлаган?!

"Ант" поэмасының эчтәлеген дөрес бәяләү өчен 3 тапкыр тикшерү комиссиясе төзелә. Беренчесендә—А. Шамов (Таттосиздатның матур әдәбият бүлеге редакторы), өченчесендә—Шәйхи Маннур, Гази Кашшаф (Таттосиздатның матур әдәбият бүлеге җитәкчесе) катнаша. Соңгы комиссиянең нәтиҗәләре шагыйрь язмышы өчен хәлиткеч роль уйный: Х. Туфан гаепле дип табыла.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда да татар әдәбиятында исемнәрен авыз тутырып әйтерлек, ихтирам белән телгә алырлык язучыларыбыз күренә башлады. М. Әмир, И. Гази, А. Шамовлар белән янәшә Ф. Хөсни, Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Н. Фәттах, М. Хәсәнов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Х. Сарьян, Ә. Баянов һ. б. кебек татар прозасын төрле темалар, оригиналь әсәрләр белән баеткан күренекле каләм осталарын атый алабыз. Әдәбиятта аларның һәркайсысының кабатланмас үз йөзе бар. Әйтик, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Бәшировларны үзенчәлекле

шәхси стильләренә карап, ихтирам белән аерып йөртсәләр, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Н. Фәттах, М. Мәһдиев кебекләре исә, чынбарлыктагы актуаль проблемаларны сәнгатьчә оста тасвирлап, укучы күңелен тетрәндерерлек итеп сурәтләүләре белән хәтердә калалар.

Торгынлык елларында иҗат иткән язучылар "әдәби әсәрләрнең бары идея ягыннан гына" бәяләнүен хәтерлиләрдер. Шул чорның идея ягыннан йомшак әсәрләре рәтенә А. Гыйләҗевның "Өч аршин җир", Ә. Еникиның "Рәшә" повестьлары кертелә һәм "идея ачыклыгы" җитмәүдә гаепләнә. Әмма нәкъ менә шушы язучылар Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан традицияләрен дәвам иттеләр, төгәлрәк әйткәндә, кеше күңелен сурәтләүдә психологик осталык күрсәттеләр. Димәк, алар кеше күңелен сафландыра торган хакыйкатьне эзләүдән туктамадылар. Шул ук вакытта тоталитар көчкә турыдан-туры каршы да чыга алмадылар. Заманасы шундый иде.

Совет хөкүмәте алып барган астыртын милли сәясәтнең нәтиҗәләре татар дөньясында үзен озак көттермәде. Татарстанда яшәүче халыкның бары 7 процентка якынына гына үз ана телендә белем алу насыйп булды. Татар язучыларының алдынгы карашлылары бу хәлләргә битараф кала алмады, әлбәттә. Мәсәлән, Н. Исәнбәтнең "Культур Шәңгәрәй", Ә. Еникинең "Әйтелмәгән васыять", Ш. Хөсәеновның "Әни килде", А. Гыйләҗевнең "Җомга көн кич белән" һ. б. әсәрләрдә маңкортлыкның төп сыйфатлары—милләтнең үз телен, гореф-гадәтләрен югалта баруы, иманснзлык, динсезлек мәсьәләләре ачык чагылды.

Шул ук Ә. Еники, завод-фабрика төтенен тасвирлауга, "кара алтын" суыручыларга дан җырлауга караганда, кеше күңеленең тирәнлеген ачып бирүне өстенрәк күрде.

Үз вакытында И. Гази да халык язмышы өчен кайгыртучы, "большевик тунлы", ләкин "милләтче йөрәкле" каһарманнар иҗат итми кала алмады.

Шулар белән бергә өстән төшерелгән күрсәтмәләрне үтәргә буйсындырылган, башкача уйлануны башына да китермәгән, татар халкының милләт буларак бетүгә дучар ителүен аңлый алу дәрәҗәсеннән ерак торган зыялыларыбыз гына да күпме иде?! Бу уңайдан халыкның күңел көзгесе булган әдәбиятыбызга карата Н. Фәттах әйткән сүзләрне искә төшерәсе килә: "Минем аңлавымча, бүгенге татар прозасының 80-90 проценты уртакул әсәрләрдән тора" (Гаделлек нигез булсын". "Казан утлары", 1989, 11 сан).

Октябрь инкыйлабыннан соң туган яңа җәмгыятькә аңа дан җырлаучы яңа әдәбият та кирәк иде. Мондый әдәбият "тудырылды" да. 30 еллардан башлап аңа коммунистлар партиясе билгеләгән "социалистик реализм" юл күрсәтеп килде. Нәтиҗәдә, яшәешнең асылын чагылдырырга тиешле, хакыйкать кануннарына таянып иҗат ителгән әсәрләре белән укучының күңелен сафландырырга (икейөзлелек, куштанлыктан арындырырга) тиешле әдәбиятыбыз нинди хәлгә төште?! Ул Үзәк Комитетның "карарларын кыйбла итеп", большевикларның ялган-мәкергә корылган идеологик күрсәтмәләренә нигезләнеп язылган, тормыш-чынбарлыктан ерак торган әсәрләр белән тулды. Алай гына да түгел, кайсы чор кешесе алып укыса да үзенә әхлакый-гүзәл сыйфатлар кабул итәрлек тәрбияви тәэсирен югалтты. Аларның кыйммәте бары тик билгеле бер чор өчен генә сизелерлек булды.

Безнеңчә, милли ядкяр саналырлык әсәрләр бары тик үз милләтеңне борчыган әһәмиятле, актуаль мәсьәләләрне, проблемаларны күздә тотып язганда гына туа ала. Башка телгә тәрҗемә иткәндә дә алар бөтен тулылыгы белән чит милләт вәкиленә җиткерелә алмый.

Бүген татар халкын борчуга салган тема—милли үсеш, яңарыш һәм дә мөстәкыйльлекнең ахыргача җиткерелүе мәсьәләсе. Әйе, халыкның үткәне, андагы бәхәсле якларны яктырткан бик күп әсәрләр иҗат ителде. Әмма милләтнең бүгенге торышына ачык, дөрес бәя биргән, киләчәген көрәшчелек итәргә алынган, милләтенең иминлеге өчен көрәшергә әзер, батыр йөрәкле, пәйгамбәрдәй язучыларыбыз табылырмы?!

**Алсу КӘРИМОВА,**
А. М. Горький музееның фәнни хезмәткәре.

*Шамил Усмановның туууына 100 ел*

# ЯЗУЧЫ—КАҺАРМАН

Шамил Усманов—киң катлау укучыларга яхшы таныш татар язучысы. Аның күп санлы повестьлары, хикәяләре, пьесалары рус, әзәрбайҗан, үзбәк, казакъ телләрендә дә дөнья күрде. Бу әсәрләрнең төп эчтәлеге—халык фаҗигасенә әверелгән революция, гражданнар сугышы вакыйгаларының канлы күренешләре. Чынбарлыкны автор акка һәм кызылга буяп кына түгел, үзе күреп белгәнчә, башка төсләрдә дә гәүдәләндерергә тырыша.

Профессиональ язучы булып формалашуында Ш. Усмановның хәрби һәм сәяси эшчәнлеге аеруча әһәмиятле урын тота. Ул яза башлаганда ук үзенең бу хезмәтен сәяси эшчәнлегенең бер тармагы итеп карый, әсәрләренә дә билгеле бер сәяси юнәлеш бирә. Гражданнар сугышы елларында тупланган бай шәхси хәрби тәҗрибә аның әсәрләренең сюжетына нигез сала.

Шамил (тугач бирелгән исеме—Габдулла) Хәйрулла улы Усманов 1898 елның 26 декабрендә Саратов губернасы Кузнецк өязе Пәндәлгә авылында (хәзерге Пенза өлкәсе Кузнецк районы) укытучылар гаиләсендә туа. Оренбургтагы Хөсәения мәдрәсәсенең урта сыйныфын, аннары һөнәр училищесын тәмамлаганнан соң Ш. Усманов 1914 елда Актүбә шәһәрендәге тегермәндә слесарь булып эшли башлый. 1917 елның 4 февралендә хәрби хезмәткә алынып, Акчуриннарның Сембер губернасы Зөя башы (Гурьевка) авылындагы оборона өчен эшләүче туку фабрикасына эшкә җибәрелә.

Ташып торган энергияле, аралашучан унсигез яшьлек егет тиз арада фабрика эшчеләре арасында үз кеше булып китә. Патша бәреп төшерелгәч барлыкка килгән хөррият дулкыннары аны өскә күтәрә. Бер-бер артлы булып торган митингларда төрле партияләр вәкилләренең сугыш, җир, икмәк кебек бөтен кешене дә тирән кызыксындырган мәсьәләләр буенча чыгышларын, аларның бер-берсе белән бәхәсләрен йотлыгып тыңлый Шамил, үзенә кайсы партия таләпләре якынрак икәнлеген абайларга тырыша. Көн кадагына суга торган лозунглар белән чыккан большевикларны ул үзенә фикердәш итеп таный, 1917 елның 10 мартында алар партиясенә языла.

Дәвам итеп килгән бөтендөнья империалистик сугышы бертуктаусыз яңа солдатлар таләп итеп тора. Ул солдатларның шактый өлешен Казан хәрби округындагы запас полклар әзерли. 1917 елның июнендә Шамил Усманов шундый полкларның берсенә—Сызраньда урнашкан 119 нче пехота запас полкына—җибәрелә. Биредә ул үзенең белеме, тормыш тәҗрибәсе, сәяси өлгергәнлеге, татар һәм рус телләрендә яхшы сөйләшүе, ораторлык сәләте булуы белән башкалардан аерылып тора. Болар өстенә—ул әле большевиклар партиясе әгъзасы да. Шундый сыйфатларга ия булган Шамилне полк солдатлары Сызрань солдатлар советына сайлыйлар. Совет депутатлары аны башкарма комитетка, ә башкарма комитет әгъзалары аны рәислеккә тәкъдим итәләр. Моннан тыш Шамил—большевиклар партиясенең Сызрань өяз комитеты әгъзасы, хәрби комендатураның шәһәр идарәсе башлыгы, Казан округындагы иң зур гарнизоннардан исәпләнгән Сызрань гарнизоны революцион штабының әгъзасы һәм сәркәтибе.

Сызрань большевиклары, шулар исәбеннән Ш. Усманов та, гарнизондагы 45 меңгә якын офицер һәм солдатны Советлар хакимияте өчен көрәшергә күндерәләр. Шәһәрдә аларга каршы торырлык башка көч табылмый. Нәтиҗәдә, 28 октябрьдә (яңа стиль белән 10 ноябрьдә) Сызраньда һәм шул көннәрдә өяз волостьларында хакимият тыныч юл белән Советлар кулына күчә.

Ноябрь аенда Казанда хәрби округ солдат советлары һәм хәрби комитетлары делегатларының II съезды була. 14 ноябрьдә съезд делегатларының киңәшмәсендә округ белән идарә итү өчен вакытлы коллегия оештырыла. Сызрань вәкиле Ш. Усманов

бу коллегиягә сайланып, округ җитәкчеләренең берсенә әверелә, округ буенча бирелгән приказларга үзенең имзасын куя.

Көн тәртибендәге башка мәсьәләләрне карап тикшергәннән соң делегатлар 25 ноябрьдә округ хәрби комитетын һәм вакытлы коллегия урынына даими эшләүче коллегия—округ белән идарә итү өчен биш кешедән торган комиссарлар советын сайлыйлар. Ш. Усманов округ хәрби комитеты әгъзасы итеп сайлана. Съезд беткәч Усмановны Петроградка командировкага җибәрәләр. Ул анда хәрби эшләр буенча халык комиссары В.А. Антонов-Овсеенкога съезд турында доклад ясый.

1918 елның февралендә, дутовчылар һәм калединчылар хәрәкәтенең көчәюе сәбәпле, Казан округы хәрби комитеты әгъзалары хәрби көч оештыру өчен урыннарга таралалар. Ш. Усманов, Сызраньга кайтып, ирекледәрдән бер отряд оештыра һәм шул отряд башында Оренбургка юнәлә. Биредә Усманов отряды Кәриб Хәйруллин җитәкчелегендә оешып яткан икенче бер отряд белән берләшеп, Оренбург мөселман батальоны барлыкка килә. Батальонның командиры итеп К. Хәйруллин, комиссары итеп Ш. Усманов билгеләнә.

Оренбургтан көнбатыштарак Дутов казакларының хәрәкәте көчәеп, алар бертуктаусыз Оренбургка баручы тимер юл эшелоннарына, станцияләргә һөҗүм итеп торалар, шәһәрне үз кулларына төшерергә омтылалар. Хәйруллин-Усманов батальонына Переволоцкий станциясенә китәргә, станциядән көнбатыштагы һәм көнчыгыштагы тимер юл участокларын сакларга, поездлар йөрешен тәэмин итәргә әмер бирелә. Күрсәтелгән урынга барып урнашкач, батальон сугышчылары дутовчыларның һөҗүмнәрен бер-бер артлы кире кайтарып торалар.

Үзенә йөкләнгән бурычны үтәгәч батальон Оренбургка кайтарыла. Дутовчылар исә, Оренбургны алу максаты белән шәһәрдән көнбатыштарак зур көчләр туплап, һөҗүмгә күчәләр. Шәһәрдә дутовчыларга каршы торырлык көчләр булмаганлыктан, аны калдырып чыгу котылгысызга әверелә. Ләкин шәһәрдәге учреждениеләрне оешкан төстә эвакуацияләү өчен беркадәр вакыт кирәк. Шул вакыт эчендә дутовчыларны шәһәргә кертмичә тоткарлап тору бурычы Хәйруллин-Усманов батальонына йөкләнә. Батальон Сакмар елгасы аркылы салынган күпердән чыгып, аны дутовчылардан сакларга тиеш була. Батальон сугышчылары дутовчыларның көчле утына һәм һөҗүмнәренә карамыйча аларны күпергә уздырмыйлар. Шәһәрдә эвакуация эшләре тәмамлангач кына күперне шартлатып, әзер торган поездга утырып Актүбә шәһәренә юнәләләр. Биредә Оренбург мөселман батальоны төрле милләт вәкилләреннән, шулар исәбеннән хәрби әсирләрдән дә торган отрядлар белән берләшеп, III Интернационал исемендәге легион барлыкка килә. Бу легионда җиде укчылар ротасы, артиллерия взводы, атлы күзәтчеләр, пулеметчылар, элемтәчеләр, хуҗалык командалары була. Роталар милли принциптан чыгып төзелә. I нче, 2 нче һәм 3 нче роталар венгрлардан, 4 нче—немецлардан, 5 нче һәм 6 нчы—татарлардан, 7 нче рота башкортлардан, үзбәкләрдән, казакълардан, чехлардан, румыннардан, серблардан, поляклардан тора. Легион сугышчыларының гомуми саны 1200 гә җитә. Легион командиры поляк Белевич, комиссары Ш. Усманов һәр ротада хәрби сәяси эшне кызылармиячеләрнең ана телендә оештыралар, аларның тырышлыкларын бер юнәлешкә—куелган хәрби бурычны үтәүгә юнәлдерәләр.

1918 елның август-ноябрь айларында легион Тургай далаларында ак казаклар белән сугыша, Яйсан станциясен саклый, Актүбә группасы составында Оренбургны Дутов казакъларыннан азат итүдә катнаша.

Ш. Усманов Оренбург мөселман батальонының һәм III Интернационал исемендәге легионның сугышчан юлын соңрак үзенең "Легион юлы" дилогиясендә тасвирлый.

Комиссар Усманов легион сугышчыларының кыска вакыт эчендә хәрби осталыклары артуын, сәяси аңнарының үсүен күрә. Мондый уңай күренешләр бигрәк тә рус телен начар белгән, хәрби тәҗрибәләре булмаган татарларда, башкортларда, үзбәкләрдә, казакъларда күзгә ташлана. Бу куанычлы хәлнең сәбәпләренең берсен легион комиссары роталарда хәрби-өйрәтү, сәяси-агарту эшләренең кызылармиячеләрнең ана телендә алып барылуында күрә. Чынлап та, ана теле—рус булмаган кызылармиячеләрнең сугыш сәләтен күтәрүче мөһим бер чара икән. Бу Усманов өчен беренче ачыш була. Шушы хакыйкатьне тирән аңлап, Усманов үзе өчен икенче ачыш ясый. Әгәр дә бер телдә, яки тугандаш телдә сөйләшүче кызылармиячеләрне аерым роталарга гына түгел, батальоннарга, полкларга, бригадаларга тупласаң, бу хәрби бүлекләрдә хәрби эшкә өйрәтү, сәяси-агарту эшләрендә ана телен куллануга зур мөмкинлекләр

ачыла. Шул юл белән гаскәрләрнең хәрби сәләтен тиз вакыт эчендә һәм югары сыйфатлы итеп күтәрергә була. Шамил Усмановка бу ачышлар шул кадәр көчле йогынты ясый ки, ул үзенең алдагы хәрби тормышын Кызыл Армиянең милли гаскәрләре арасында эшләүгә багышлый.

Армиядә милли гаскәрләр оештыру идеясе Ш. Усмановка кадәр дә күп кенә кешеләрнең фикерен били. Февраль революциясеннән соң барлыкка килгән милли хәрби оешмаларның, шулар исәбеннән мөселман хәрби комитетларының, Бөтенруссия мөселман хәрби шурасының да беренче максатлары иске армиядә милли гаскәрләр оештыру була. Кызыл Армиядә милли гаскәрләр оештыру мәсьәләсен беренче буларак Үзәк мөселман комиссариаты һәм аның җитәкчесе Мулланур Вахитов күтәреп чыга. 1918 елның февраль, март айларында шушы тәкъдимнәр белән ул милли эшләр буенча халык комиссариатына һәм хәрби эшләр буенча халык комиссариатына мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, бу ике комиссариат та Кызыл Армиядә милли гаскәри бүлекләр оештыру турында үзләренең карарларын чыгаралар. Шулар нигезендә 1918 елда Мәскәүдә I нче татар-башкорт батальоны, Казанда I нче мөселман социалистик полкы, I нче совет запас мөселман пехота полкы, I нче мөселман коммунистлары батальоны, Әстерханда К.Туйбактин исемендәге мөселман полкы, Пермьдә 21 нче мөселман укчы полкы, Саратов губернасында I нче мөселман Совет полкы, Самарада татар батальоны төзелә.

Кызыл Армиядә татар милли гаскәрләре оештыру белән җитәкчелек итәр өчен Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариаты каршында М.Вахитов җитәкчелегендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе төзелә. Мулланур Вахитов Казанга килгәч ак чехлар кулына әсирлеккә төшеп атылганнан соң, аның урынына рәислеккә М. Солтангалиев билгеләнә, ә Хәрби коллегия үзе хәрби эшләр буенча халык комиссариаты карамагына бирелә. Хәзер Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчелегендә зуррак милли гаскәри бүлекләр оештырырга да мөмкинлекләр ачыла. 1919 елның январь азагында Баш командующий Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә Казанда, Самарада, гомумән Идел буе шәһәрләрендә мөселман полклары оештырырга рөхсәт итә.

Шулай итеп, Ш. Усманов үз тәҗрибәсендә милли гаскәри бүлекләрнең әһәмиятен аңлаган вакытта, мондый бүлекләр төзү мәсьәләсе кызыл Армия җитәкчелеге тарафыннан принципта хәл ителгән була. Ләкин принципта хәл итү белән гамәли хәл итү арасында зур аерма барлыгын Усманов тиз төшенә. Оренбург мөселман батальонында хезмәт итәргә теләгән татар кызылармиячеләренең күп булуын истә тотып, Усманов батальонны полкка әйләндерү фикерен күтәреп чыга. Бу фикерне батальон сугышчылары да, легион җитәкчелеге дә хуплый, әмма I нче армия революцион хәрби советы тиешле командирлар юклыгы сылтавы белән кире кага. Усманов, моның белән килешмичә, Уфага килгән Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе М. Солтангалиев белән очрашып сөйләшер өчен 1919 ел февраленең чатнама суыгында атка утырып Оренбургтан чыгып китә. Очрашкач, ике эшлекленең бер фикердә булуы тиз ачыклана. Солтангалиев Усмановка Мәскәүгә барып, Бөтенруссия баш штабыннан мөселман полкы төзергә наряд алырга тәкъдим итә, хәрби эшләр буенча халык комиссары Л.Д.Троцкий исеменә мөселман бригадасы төзү кирәклеге турында хат язып тоттыра. Усманов Уфадан Мәскәүгә киткәч, Солтангалиев 28 февральдә В. И.Ленин, И.В.Сталин, Л.Д.Троцкий, хәрби эшләр буенча халык комиссары урынбасары Э.М.Склянский, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе урынбасары Н.Г.Вахитов, Үзәк мөселман комиссариаты рәисе урынбасары А.М.Енбаев исемнәренә суккан телеграммасында үзе тарафыннан Оренбургта татар-башкортлардан мөселман дивизиясе, йә бригадасы төзү буенча доклад ясар өчен Мәскәүгә Ш.Усманов җибәрелүе турында яза.

Уфадан Мәскәүгә килүче поездда Ш.Усманов бик авыр шартларда 8 тәүлек бара. Мәскәүдә И.В.Сталин, Бөтенроссия баш штабы комиссары И.Дзевялтовский белән сөйләшә, алардан конкрет булмаган, икеле-микеле генә җаваплар ала. Л.Д.Троцкийга мөрәҗәгать итә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе исеменә язган хатында Усманов Казанда мөселман бригадасы төзергә тәкъдим итә. "Әгәр дә бу мәсьәлә унай хәл ителсә,—дип яза ул,—мин берничә мөселман халкы телен белүче буларак бригада төзү эшенең бөтен җаваплылыгын үз өстемә алырга, бу эшкә кичекмәстән тотынырга һәм Кызыл Армия сафларында соңгы мөмкинлегемә чаклы калырга әзер".

Нәтиҗәдә, Республика революцион хәрби советы 1919 елның 10 март утырышында Идел буе хәрби округында мөселман бригадасы төзү турында карар кабул итә. Округ комиссариатының 24 мартта биргән приказы нигезендә бригаданың идарәсен, I

нче полкын, элемтә ротасын төзү өчен Казан, 2 нче полкы өчен Самара, 3 нче полкы өчен Алатырь шәһәрләре билгеләнә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе тәкъдиме буенча бригаданың сәяси комиссары итеп Ш.Усманов билгеләнә.

Мәскәүдән Казанга килгән Усманов бригада штабына тиешле белгечләр табу буенча зур эшләр җәелдереп җибәрә. Бригада командиры вазифалары вакытлыча Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең хәрби бүлеге мөдире М.Г.Крыймовка йөкләнә. 27 мартта Усманов Мәскәүгә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә бригаданың төзелә башлануы турында телеграмма җибәрә.

Ш. Усманов бригадага "Аерым Идел буе татар бригадасы" дигән исем бирүне тәкъдим итеп Идел буе хәрби округы комиссариатына мөрәҗәгать итә. Тиздән "татар" сүзеннән соң "укчы" сүзен өстәп Республика революцион хәрби советы приказы чыгарыла.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы булган "Кызыл Армия" газетасының 6 апрельдә чыккан 35 нче санында Ш.Усманов һәм М.Крыймов имзалары белән "Хөррият сөйгән татар егетләре, кызыл байрак астына!" исеме белән татар бригадасы штабында эшләрлек төрле белгечләр чакыручы белдерү басыла. Шунда ук "Карл Маркс урамы, 56 нчы Молотков йорты" дип штабның адресы да күрсәтелгән. Газетаның шул санында "Татар бригадасы" исемле редакция мәкаләсендә бригаданың төзелә башлавы, аның Казанда төзелүче I нче полкына Мулланур Вахитов исеме бирелүе турында языла.

19 апрельдә Мәскәүдән Казанга күчкән Үзәк мөселман хәрби коллегиясе һәм РКП/б/ ҮК каршындагы Көнчыгыш халыкларының коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы утырышында Ш.Усманов бригада төзүнең торышы турында доклад ясый. Утырышта катнашучылар, докладчы белән килешеп, Оренбург мөселман батальонын Алатырьда төзелүче 3 нче полкка кушу, бригада төзү эшен чираттан тыш төзүгә күчерү, бригада каршында аерым кавалерия дивизионы һәм аерым артиллерия батареясе төзү турындагы тәкъдимнәр белән Л.Д.Троцкийга мөрәҗәгать итәргә, дип карар чыгаралар.

Тиздән бригада командиры итеп Й.И.Ибраһимов, штаб башлыгы итеп И.И.Тальковский билгеләнәләр. Зур хәрби тәҗрибәле бу кешеләр бригаданы төзеп бетереп, аны хәрби хәзерлеккә китерүдә, аннары киләчәктә бригаданың сугышчан хәрәкәтләренә җитәкчелек итүдә аеруча әһәмиятле эш башкаралар.

Колчак ягында сугышучы ак казакларның кызыллар кулында булган Оренбургка һөҗүмнәре көчәю уңаеннан татар бригадасының I нче полкы 13 майда ашыгыч рәвештә сугышка, Оренбург төбәгенә җибәрелә. Полкны сугыш кырына бригада комиссары Ш.Усманов озата бара.

1919 елның июленә татар бригадасы тулы составы белән Самарада туплана. Биредә бригада полкларында Ш.Усманов җитәкчелегендә киң сәяси-агарту эшләре җәелдерелә. Көнчыгыш фронты гаскәрләренең Көньяк группасы сәяси бүлегенең 4 июльдә чыккан 39 нчы бюллетенендә бригада турында болай язылган:

"Татарларны үз телләрендә тәрбияләү аларның сугышчан сәләтен күтәрүдә яхшы нәтиҗә бирә. Бригадада сәяси эш югары дәрәҗәгә куелган. Агитаторлар, оештыручылар, 18 кешелек драматик труппа бар. Кәеф революцион".

Август башында бригада сугыш кырына чыгып китә. (Бригаданың сугышчан юлы белән кызыксынучыга М.Рафиковның "От Волги до Тянь-Шаня" (Казан, 1976) исемле китабын тәкъдим итәм.—И.Г.)

1919 елның сентябрендәге сугышларның берсендә Ш.Усманов көчле контузия ала, сәламәтлеге нык какшый. Шул уңайдан, бераз дәваланып өчен ял алып, ул Казанга кайта.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Усмановны сәламәтлеге начарлану сәбәпле бригада комиссары вазифасыннан азат итеп, аны үзенең сәяси бүлекчәсе мөдире итеп билгели. Усмановның хәрби коллегиядә эшли башлау вакыты бу оешманың хәрби-оештыру функцияләре кимәтелү бәрабәренә аның сәяси-агарту функцияләренең көчәйтелүе вакытына туры килә. Шул сәбәптән бу юнәлешкә җитәкчелек итүче сәяси бүлекчә зур штатлы сәяси бүлеккә әверелә, аның составында гомуми, культура-агарту, оештыру, агитация-информация, нәшрият бүлекчәләре барлыкка килә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе үзе дә тулысынча Республиканың революцион хәрби советының сәяси идарәсе карамагына бирелә.

Татар һәм башка төрки кызылармиячеләр арасында сәяси тәрбия эшләренең ана телендә куелуының нинди әһәмияткә ия булганын тирән аңлаган Ш.Усманов сәяси бүлек җитәкчесе буларак сәяси, культура-агарту хезмәткәрләре әзерләүне беренче чираттагы

бурыч итеп саный. Ул эшли башлаган вакытта сәяси бүлек каршында 1919 елның маеннан бирле эшләп килгән кыска сроклы агитатор курслары барлыгы өч чыгарылышта 159 сәяси хезмәткәр әзерләп чыгарганнар. Курсларга бирелгән акча беткән. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе киңәйтелгән сәяси курсларның вакытлы штатының проектын әзерләп Республиканың революцион хәрби советына җибәргән булган. 26 сентябрьдә ул штат расланып, курслар даими эшләүче хәрби-сәяси агитаторлар курслары дип атала башлый, курсантлар саны да һәр агымда 300 кеше карала.

Ш.Усманов бу курсларда эшләргә яхшы укытучылар җәлеп итүгә зур әһәмият бирә. Аның чакыруы буенча курсларда вакытында күренекле педагоглардан исәпләнгән Вакыйф Зыя, Абдрахман Вәлитов, Насыйх Мөхетдинов, Хатыйп Мөхетдинов, Фатих Сәйфи, Әминә Мөхетдиновалар эшли башлыйлар.

1920 елның февраленә, ягъни курсларның ачылу вакытында, 240 кеше укырга кабул ителә, шуларның 232 се—кызылармияче, 5-се—команда составыннан.

Курсантлар арасында укый-яза белмәүчеләр дә шактый булганлыктан, андыйлар өчен әзерлек группасы оештырылып, аларны укырга-язарга өйрәтәләр, татар һәм рус телләрен укыталар, сәяси грамотадан, математикадан, географиядән, тарихтан дәресләр бирәләр.

Төп группада татар әдәбияты, сәяси грамота, математика, татар теле, география, тарих, рус теле укытыла. Ике группада да факультатив рәвештә Россия тарихы, көнчыгыш мәдәнияте, диннәр тарихы турында лекцияләр укыла.

9 майда 76 сәяси хезмәткәр әзерләп чыгарыла. Калган курсантлар, хәзерлекләре тиеш дәрәҗәгә җитмәгәнлектән, укуларын дәвам итәр өчен курсларда калдырылалар.

Сәяси бүлек эшчәнлегенең Ш.Усманов күп көч куйган икенче юнәлеше—нәшрият эшләре. Кызылармиячеләр арасында гына түгел, җирле халык арасында да популярлык казанган көндәлек "Кызыл Армия" газетасына яңа авторлар, журналистлар табуга, аның эчтәлеген баетуга, материалны кызыклы итеп бирүгә Усманов күп көч сарыф итә. Бу газета белән бер рәттән 1920 елның 25 февраленнән сәяси бүлек рус телендә атнага бер мәртәбә "Красная Армия" исемендә икенче газета да чыгара башлый. Газеталардан тыш сәяси бүлек күләмнәре зур булмаган брошюралар бастырып тарата. Алар күбрәк сәяси хезмәткәрләр тарафыннан кызылармиячеләр арасында эшләгәндә файдаланылалар.

Сәяси бүлек нәшриятында бишәр мең тираж белән Ш.Усмановның "Канлы көннәрдә" (1919), "Беренче адым" (1920) пьесалар да басылып чыга һәм алар популяр сәхнә әсәрләре булып танылалар.

Ш. Усманов үзенең нәшрият өлкәсендәге эшчәнлегендә Г.Ибраһимов, И.Казаков, Ш.Әхмәдиев, Ф.Бурнаш, С.Атнагулов кебек эшлекләргә таяна.

Ш.Усманов урыннарда чыгып килгән татар газеталарын да күзәтеп бара, ул газеталарга карата күрсәтелгән гаделсезлекне бетерергә тырыша. Менә шушы уңайдан Усмановны характерлый торган бер мисал. 1920 елның январь башында Ш.Усмановка Малмыждан бер хат килә. Бирелә өяз партия оешмасының татар-башкорт секциясе тарафыннан чыгарылып килә торган "Ярлылар тавышы" газетасының чыгудан тукталуы һәм аның сәбәбе буларак татарча белмәүче хәрби цензорның бу газетаны басканчы русчага тәрҗемә итеп аңа китерүне таләп итүе турында языла. Бу кычкырып торган ахмак гаделсезлек турында Ш.Усманов туп-туры Ленин исеменә телеграмма җибәрә. Ул үз чиратында бу эшне хәл итүне Троцкийга тапшыра. Ә Троцкий исә ул цензорны цензорлык хокукын алып, эшеннән куарга күрсәтмә бирә. Нәтиҗәдә "Ярлылар тавышы" газетасын бастыру җайга салына.

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең Ш.Усманов җитәкчелегендәге сәяси бүлеге Республика (РСФСР) запас армиясенең Казанда урнашкан сәяси бүлеге белән тыгыз элемтәдә эшли. Запас полкларда укый-яза белмәгән кызылармиячеләрне укытуга Казан мәктәпләре укытучылары тартыла.

Запас армиядәге татар солдатларына культура хезмәте күрсәтү өчен артистлар, музыкантлар чакырыла. Бу эшне оештыруда М.Мутин, К.Тинчурин, К.Шамил кебек күренекле сәнгать осталары катнаша.

Ш.Усманов үзен талантлы сәяси эшлекле итеп танытты. Аның сәяси активлыгы бигрәк тә Татарстан республикасын игълан итүгә хәзерлек алып барган көннәрдә күренде.

Татарстан республикасы турында декрет чыгып, аның вакытлы власть органы буларак Революцион комитет төзелгәч, Ш.Усманов Ревком секретаре итеп билгеләнә. Бу органның төп максаты Татарстан Советларының Учредительный съездын хәзерләү

булганлыктан, Усманов та бу мәсьәләгә зур игътибар бирә. "Учредительный съезд мөнәсәбәте белән" мәкаләсендә дә, Татарстан территориясендәге татар коммунистларының 26-29 июльдә булып узган 1 нче өлкә конференциясендә ясаган агымдагы хәл турындагы докладында да, съездда татар халкы вәкилләренең 50 % тан да ким булмавы зарурлыгын ассызыклап күрсәтә, съезд чакыру көне итеп партиянең губерна комитеты бюросы билгеләгән 25 август көнен уңышсыз таба, бу фикерне дәлилләү өчен ул көннең иң кызу кыр эше вакыты икәнлеге, татар крестьяннары арасында бернинди дә хәзерлек эшләре алып барылмавы, Бәләбәй, Бөре өязләреннән Татарстанга керү-кермәү турында хәбәр булмавы күрсәтелә, губкомның бу факторларны искә алмавы тәнкыйтьләнә һәм съезд чакыру датасын кичектерергә тәкъдим итә. Конференциядә күпчелек чыгыш ясаучылар да шул фикерне куәтлиләр, съездны кичектерү кирәклеге турында карар кабул итәләр.

Губком җитәкчеләренә Ш.Усмановның, аның фикердәшләренең республика төзү буенча актив эшчәнлекләре ошамый. Губком бюросы 2 августтагы утырышында татар коммунистларының өлкә конференциясендә Татарстан Советларының Учредительный съездын чакыру көне турында әйтелгән фикерләр белән килешергә мәҗбүр булып, съездны бер айга кичектерү турында карар чыгара. Ләкин, шулай булуга да карамастан, съезд чакыру көнен кичектерү мәсьәләсен конференциядә күтәреп чыкканга кадәр губком бюросына куймаганнары өчен дип И.К.Фирдәвескә, И.М.Казаковка һәм Ш.Х.Усмановка партия шелтәсе белдерелә, аларны, алар кебек актив башка эшлеклеләрне булачак республиканың дәүләт органнарыннан читләштерү чараларына да керешелә. Шул максаттан И.К.Фирдәвес Көньяк фронтта, Ш.Х.Усманов Төркстан фронтында эшләр өчен мобилизацияләнәләр.

Ш.Усманов Төркстан фронты Революцион-хәрби советында, аннары Бохара хәрби комиссариатында эшләп, Казанга 1922 елның мартында гына кайта. Биредә ул 16 нчы мөселман пехота команда курслары начальнигының сәяси эшләр буенча ярдәмчесе, шул ук елның сентябреннән—курсларның комиссары, 1924 елның гыйнвареннан 6 нчы берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбе комиссары булып эшли.

1925 елның 1 гыйнвареннан Ш.Усманов—Мәскәүдә, хәрби уку йортлары идарәсенең сәяси секретариатында өлкән инспектор. Шул ук елның сентябрендә М.В.Фрунзе исемендәге хәрби академиянең бер еллык курсларына укырга кереп, аны тәмамлагач, Ташкентка, Шәрык курслары начальнигының сәяси эшләр буенча ярдәмчесе итеп билгеләнә.

Ш.Усмановның 1919 елда һәм егерменче елларда төрле газеталарда, бигрәк тә "Кызыл Армия" газетасында, кайбер сирәк китапларда басылган мәкаләләре, чыгышлары бар. Аларның барысы да диярлек эчтәлекләре белән милли дәүләтчелек, милли гаскәрләр мәсьәләсенә һәм гомумән милли мәсьәләгә багышланганнар. Бу хезмәтләрдән бигрәк тә татар халкының дәүләтчелеге, аның вәкилләрен хакимият органнарына күбрәк тарту турында кайгырту, әмма, республика төзелгәч, аның эченә татар халкының бары чиреге генә керүе, автономиянең тар кысаларында "чуваш бияләе хәтле" генә территориядә калуы өчен яну-көю күренә. Татар халкы тарихына кереп калган күп кенә шәхесләргә карата объектив караш булдыру өчен дә шактый материал бар бу мәкаләләрдә. Җитәкче урыннарда республикага, татар халкы мәнфәгатенә каршы эшләре белән генә мәгълүм булган кешеләрнең утыруы, ул кешеләрнең республика өчен янып-көеп йөрүчеләрне читкә этәрүләре борчыйй авторны.

Татарстан республикасы, татар халкының фәнни, объектив тарихы языла гына әле. Ул тарихта ялкын йөрәкле, каһарман шәхес Ш.Усманов та үзенең лаеклы урынын алачак.

**Илдус ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
тарих фәннәре кандидаты.

*Тарих*

# ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР

## 13. Төрекләр

Төрекләр дигәннән, башта шуны әйтеп үтәсе килә: ике иҗекле итеп "төрек" дип әйтү һәм аны "төрек" дип язу фәкать безнең татарларда гына, калган һәммә төрки халыкларда һәм тарих, тел, этнография хезмәтләрендә бу этноним бер иҗекле итеп "түрк", "турк", "төрк" формаларында әйтелә һәм языла. Бу этнонимның этимологиясе (килеп чыгышы) турында галимнәр тарафыннан әлегәчә фәнни нигездә төгәл бер фикергә киленгәне юк.

Элеккеге СССРда яшәүче төрекләр үзләрен "түрк" дип атыйлар, чөнки алар чыгышлары белән чыннан да төрекләр, аларның туган туфрагы элекке Госманлы Төркия империясендә булган. Төркиянең төньяк-көнбатышында алар яшәгән җирләр Иран—Грузия (Гөрҗестан), Төркия—Грузия арасында барган сугышлар нәтиҗәсендә (XYI—XYII) Грузиянең көньяк өлешендәге Месхетия дип аталган төбәгенә кушып алына. Бу төрекләрне Анадолу (госманлы) төрекләр белән аеру, бутамас өчендер, Грузиядәге төрекләрне инде яшәгән төбәкләре исемен кушып, "месхет төрекләре" дип тә атап йөртә һәм яза да башлыйлар.

1989 елгы мәгълүматлар буенча аларның саны 207512 дип күрсәтелгән, хәзер БДБда 350 мең төрек бар диләр. Әмма бу саннарның икесе дә дөреслекне чагылдыра дип әйтеп булмый, чөнки аларның байтагының паспортларын да, үзләреннән сорамыйча, кайсы республикада яшәсә, шул республика милләте күрсәтелгән, грузин, әрмән яки әзербайҗан дип язылган була. Бу төрекләр элекке СССРдагы төрки халыклар арасында иң бәхетсезе, иң күп җәфа чиккәне, йортсыз-илсез калганы, гидайга әйләнгәне дисәк хата булмас. Алар гасырлар буенча үзләре яшәгән җирдә гөрҗиләр (грузиннар), әрмәннәрнең туктаусыз золымы, кысрыклавы астында үтә авыр тормыш кичереп киләләр. Советлар чорында да аларга тынгылык бирелми, туктаусыз җәберләү, эзәрлекләүләр астында яшиләр: Сталин, милләтләр эше буенча халык комиссары булгач (1924), үзенең Грузиясен аз санлы башка "чүп-чар" милләт халыкларыннан "тазартмакчы" була. Һәм явыз эшен яклаучысыз, җәберләнгән шушы төрекләрдән башлый. Аның күрсәтмәсе белән 1924 елдан башлап алар СССРда яшәүче милләтләр исемлегеннән сызып ташлана һәм "төрк" дигән этноним кулланыштан чыгарыла. 1930 елларда бу төрекләрнең исем-фамилиясен, милләт исемен көчләп үзгәртү башлана һәм, ниһаять, аларны бөтенләй ассимиляцияләү, милләт буларак юк итү өчен туган җирләреннән Грузиянең төньяк төбәкләренә, Әзербайҗан, Әрмәнстан республикаларына депортацияләп куалар (1932). 12 ел шул җирләрдә сөргендә газап чиккәннән соң, инде алар төркилекләрен югалттылар диптер, туган җирләренә, Месхет төбәгенә кайтырга рөхсәт ителә. Әмма сөргендә җирле халык белән аралашып төпләнгәннәре кайтмый кала, ә кайтканнарына исә Грузия хөкүмәте ультиматум куя: биредә яшәргә теләсәгез—гөрҗи милләтенә күчәсез, күчмәсәгез—дүрт ягыгыз кыйбла. Көчләп грузинлаштыру башлана.

Билгеле булганча, 1944 елда Сталинның яшерен боерыгы буенча илдәге 22, Кавказдагы 18 "вак" милләт (шулардан 14е төрки-мөселман халыклары) ашыгыч рәвештә үз ил-йортларыннан сөрелә, шул елның 14 ноябрь төнендә мал вагоннарына төяп Грузиянең Месхет төбәгенең биш районында—236 авылында яшәгән 160 мең төрек СССРның төрле якларына, шулардан 100 меңнән артыгragы Үзбәкстанның Фәргановә өлкәсенә сөрелә. Анда урнашып-төпләнеп 45 ел тыныч кына гомер кичергәндә, 1989

---

Ахыры. Башы журналның 11 санында

елның җәендә милләтчелек тәтене белән исергәч, мылтык, пычак белән коралланган үзбәкләр төрек кышлакларына төн уртасында утлы кисәүләр тотып ташланалар, меңләгән төрекләрне суялар, аталар, көчлиләр, йортларына ут төртәләр, яндыралар. Бу фаҗигадән исән калганнарны ашыгыч рәвештә йөк самолетларына төяп, инде өченче мәртәбә, төрле якларга, Россиянең 24 өлкәсенә, ташландык авылларга олактыралар. Андагы шартларга чыдый алмыйча, төрекләр үз ватаннарына якынрак җирләргә—Краснодар, Ставрополь крайларына, ә күпчелеге кан кардәш Әзербайҗан җирләренә качып кайталар. Грузия аларны үз җирләренә кертми, Грузиянең ул чактагы Президенты Гамсахурдия катгый рәвештә: "Төрек килмешәкләренә бездә урын юк, кайта калсалар кан коелачак",—дип белдерү ясый. Шулай итеп, бу бичара төрекләр төрле якларга сибелә, җирсез-йортсыз, ватансыз хәлендә әле дә гидайлар тормышын кичерә. Шулай да аларга өмет чаткысы күренде шикелле: төрекләрнең 150 гаиләсен Төркия үзенең Ыгдыр шәһәрендә урнаштырды. Грузиянең хәзерге Президенты Э. Шеварднадзе карары буенча, 5 мең төрек гаиләсенә үз ватаннарына—Месхет-Хавит төбәгенә кайтып урнашу хокукы бирелде.

Бу төрекләрнең теле төрки телләрнең алтай төркеменә карашлы угыз тармагына керә. Әмма милләтләр чорнашында озак вакытлар яшәү нәтиҗәсендә, аларда төрки тел лексикасы югала бара, аларның телендә башка гаиләдәге эберий-кавказ (грузин) теленең йогынтысы зур.

Бу төрекләрнең үз алфавиты (язуы) да, үз әдәби теле дә юк. Месхетлы төрекләрнең күпчелеге Ислам (сөнни) динендә, бер өлеше грузин-православие диненә чукындырылган.

## 14. Тувалылар

Аларның бик борынгы исемнәре сойон (русларда "саян") һәм урәнхай (русларда "уренгой") булган. Хәзерге үз атамалары тыва (күплектә тывалылар). Тывалылар Үзәк Азия белән Себер тоташкан җирләрдә, Саян, Шапшал, Тибәтау, Танна таулары чолганышындагы, географиядә "Тува чокырлыгы" ("Тувинская котловина") дип аталган җирдә яшиләр. Аларның бу җирләрдә безнең эрага кадәр III гасырларда ук яшәүләре турында мәгълүматлар бар. Яңа эра башында бу җирләргә һуннар, алардан соңрак төрки кабиләләр килеп керә һәм алар сяньби, җуҗан дип аталган ике зур кабиләгә бүленеп, союздаш булып яшиләр һәм соңыннан бу кабиләләрдән "тыва" (тува) халкы формалашып китә. YI гасыр урталарында бу җирләр Төрек каганаты буйсынуында кала һәм бу каганатны уйгурлар тар-мар иткәч (745 елда) тувалылар җиңүче уйгурлар һәм алар белән килгән кыргызлар кул астына эләгә, тувалыларның бу төрки халыклар арасында ассимиляцияләшү процессы тагын да тизләшә. Шулай итеп, тувалыларның этногенезында төрки телле кабиләләр һәм алар тарафыннан ассимиляцияләнгән төрле телдәге аборигеннар катнашкан.

1207 елда Тува җирләрен Чыңгызхан гаскәрләре басып ала һәм тувалылар YI гасырга кадәр монголларның кытайлар токымыннан булган Юань династиясе хакимлегендә Алтынханнар дәүләтендә яшиләр.

XYII гасырда тувалылар яшәгән җирләрнең күп өлешен җуңгарлар яулый, аларны исә 1757 елда манҗурлар тар-мар иткәч, бу халык 1912 елга кадәр шулар изүе астында кала. 1914 елда җирле феодаллар теләге буенча тува "Урянхайский край" исеме белән Россия составына алына.

Гражданнар сугышы беткәч, Колчак куылгач бу җирләрдә Совет власте игълан ителә һәм 1921 елның 14 августында Бөтентува оештыру хуралы (корылтае) карары белән Танну-Тыва Халык Республикасы игълан ителә, мәркәзе итеп Хем-Белдыр шәһәре билгеләнә. 1926 елда ул Тува Халык Республикасы дип, ә мәркәзе Кызыл исемендә үзгәртелә.

1944 елның 17 августында Тува Халык Республикасының Кече хурал сессиясе СССР Югары Советына республиканы СССРга кушуны сорап мөрәҗәгать итә һәм РСФСР Югары Советының карары нигезендә (13. 10. 44) ул автономияле өлкә статусы белән Россия Федерациясенә кушыла. 1961 елның 10 октябрендә бу өлкәгә Тува АССР статусы бирелә.

1989 елгы мәгълүматлар буенча РСФСРда яшәүче тувалыларның гомуми саны

206629 кеше дип исәпләнә. Болардан тыш 50 меңгә якын тувалы Монголия Халык Республикасында яши.

Тувалыларның төп кәсебе терлекчелек (сарык, болан, дөя асрау). Терлекчеләр "аратлар" дип атала һәм киездән ясалган йортларда ("кдесег"ләрдә) яшиләр. Диннәре элек мәҗүси (шаманизм) булган, ул әле дә кайбер урыннарда тотыла, ләкин XYII гасырдан башлап тувалыларның күпчелеге ламанизмга (буддизмның бер тармагына) күчкәннәр.

Тува теле төрки телләрнең уйгур төркеменә карашлы уйгур-тукуй тармагына керә. Лексик фондының нигезе төрки сүзләрдән гыйбарәт. Шулай да ул бик чуар: XII гасырдан башлап тувалылар телендә монгол теленнән алынмалар күбәя башлый, бер үк вакытта шул ук монгол теле аркылы кытай, һинд, иран телләреннән дә байтак сүзләр керә, ә XYII гасырдан башлап Урта һәм Көнбатыш Себердә руслар экспансиясе нәтиҗәсендә һәм бигрәк тә советлар чорында, тува теленең лексик составы рус теле алынмалары хисабына "байый" (мәсәлән, икмәк сүзе "хлип", сан сүзе "число", метибче—"школачы" булып китә).

Диалектологик яктан тува теле әлегәчә җитәрлек өйрәнелмәгән. Бүгенге торышына карап анда географик төбәкләргә бүленгән дүрт диалект теркәлгән, үзәк зона (Улуг һәма үзәнендә, Чаадана елгасы бассейнында яшәүчеләр) диалекты; бу диалект тува әдәби теленең нигезе итеп алынган. Көнчыгыш (Һемчин елгасы бассейнында яшәүчеләр) диалекты. Төньяк-көнчыгыш (таджин—Бий елгасы бассейнында яшәүчеләр) диалекты. Дүртенчесе—Көньяк-көнчыгыш (Олы Танну тау сырты, Әрзин елгасы агымында яшәүчеләр) диалекты. Бу соңгысында монгол лексикасы зур урын алган.

## 15. Гагаузлар

**1989** елдагы халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча СССРда яшәүче гагаузларның гомуми саны 197768 кеше хисаплана, шуларның күпчелеге (155 меңе) хәзерге Молдованың көньяк районнарында, аерым бер төбәктә яши, калганнары Украинаның Одесса өлкәсендә (25 мең чамасы), Болгариядә (15 мең чамасы). 1944 елның маенда кырым татарларын депортацияләгәндә, Кырымда яшәгән 20 меңгә якын гагаузлар да төрле якларга сөреләә һәм алар бу статистикага керми калганнардыр дип уйларга нигез бар.

Аларның этногенезы турында галимнәр арасында ике төрле фикер йөри. Кайберәүләре алар Болгария берничә гасырлар Төркия (Госман) империясе кул астында яшәгән чорда (XIY—XIX гасырлар) тел ягыннан төркиләштерелгән, әмма дин ягыннан үзләренең христиан динен саклап калган болгарлар дисә, күпчелек галимнәр аларны урта гасырларда Болгариягә күчеп килеп, славян (православие) динен һәм мәдәниятен кабул иткән төркиләрнең "үз" дип аталган төркеменең госман төрекләренең изүэзәрлекләүләренә түзә алмыйча Россиянең Кара диңгез буйларына, Румыниянең Бессарабия (хәзерге Молдова) җирләренә качып килеп урнашучылар дип хисаплый.

Столыпин аграр реформасы вакытында (1908—1911) аз җирле крестьян хуҗалыкларын бетерү барганда, гагаузларның бер өлеше Бессарабия һәм Украинадан төрки кардәшләр яшәгән Урта Азиягә, Казакъстанга күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Алар бу җирләрдә бүген дә аерым авыллар, кышлаклар булып көн күрәләр. Шулай төрле тарафларга, җирләргә таралу нәтиҗәсендә гагаузлар рухи, мәдәни һәм өлешчә тел ягыннан да үзләре яшәгән җирләрдәге төп халыкларга якынаялар, өлешчә ассимиляцияләнәләр. Менә шушы тарихи сәбәпләр аркасында, таркалып яшәгән гагаузларның нинди дә булса аерым дәүләт төзелеше булмый кала. Тик соңгы елларда, СССР таркалгач, Молдовадагы гагаузларның мөстәкыйльлек өчен милли хәрәкәте башлана. Ул көчәя бара һәм алар 1993 елда Молдова федерациясе эчендә Гагауз автономияле өлкәсен оештыруга ирешәләр, үз территорияләре булган милләт сыйфатында яши башлыйлар.

Гагауз теле төрки телләрнең көньяк-көнбатыш угыз төркеменә керә. Лексик һәм фонетик яктан төрек, бигрәк тә кырым-татар теленә бик якын, кайбер тюркологлар ( Т. Ковальский, Г. Дерфер) гагаузлар телен госманлы төрек (анадолу) теленең бер

диалекты дип тә хисаплыйлар. Совет тюркологлары (Н. Дмитриев) гагауз телен мөстәкыйль төрки тел дип хисаплыйлар.

Шулай да, бер генә саф төрки тел булмаган шикелле, саф гагауз теле дә юк, аның лексикасында, фонетикасында, грамматик төзелешендә славян (болгар, рус, украин, молдован, румын) телләренең йогынтысы нык сизелә.

1957 елга кадәр гагаузларның язуы булмый, шул елны гына алар рус (кириллица) нигезендә үз алфавитларын төзиләр. Гагауз телендә ике диалект бар: үзәк (чадырлын-комрат) диалекты. Ул әдәби телнең нигезе итеп алынган. Һәм географик яктан киң таралган көньяк (вулканешти) диалекты. Алар арасында аерма әллә ни зур түгел, кайбер сузык авазларның фонетик аермасында гына, мәсәлән, үзәк диалектта дерә-елга, дәрья, гежә—төн, бән-мин, ә көньяк диалектында шул ук сүзләр дере, гeжe, бен.

## 16. Карачайлар

Үз атамалары—карачайлы. Элек алар үзләрен "аланнар" дип атаганнар. Күрше халыклар аларны әле дә шулай "аланнар" дип атап йөртә. Болай атауның нигезе дә бар: IX—XII гасырларда, монгол яуларына кадәр, карачайлар (күрше балкар, осетиннар да) Хазар каганатыннан аерылып чыгып, бу җирләрдә (Төньяк Кавказда) барлыкка килгән иран телле Алания (Алан) дәүләтендә яшәгәннәр. Карачай этнонимын кайбер этимологлар ике компонетка бүлеп "кара" һәм "чай" (чәй) сүзләреннән ясалган диләр. Имеш, Кавказда, Урта Азиядә дә чәй ике төрле була: кара һәм күк (яшел) чәй. Имеш, бу халык кара чәй генә эчә икән. Минем фикеремчә, бу этнонимдагы "чай"ның эчә торган чәйгә бернинди дә бәйләнеше юк. Төрки телләрдә "чай", шулай ук "жай", "тай", "зәй", "сай" вариантлары барысы да "су", "елга", "дәрья" сүзен белдерә. Димәк ки, карачай—Кара елга (Кубань) елгасы буенда яшәүче кеше димәктер.

Этногенез ягыннан карачайлар монголлардан соң бу якларга килгән төрки телле халыкларның (болгар, хазар, кыпчакларның) үзара бер-берләре белән аралашу, укмашу нәтиҗәсендә формалашкан халык дип хисаплана. Карачайларның төп өлеше хәзерге Карачай- Чиркәс автономияле өлкәсендә яши. Бу өлкә 1922 елда оештырыла, ә 1926 елда Карачай һәм Чиркәс милли округ статуслары алып, аерылышалар. Бу "вак-төяк" халыкларның икесе дә "барлык милләтләрнең дусты" явыз Сталинның боерыгы белән депортациягә эләгәләр һәм 1943 елның октябрендә үз йортларыннан куылып, Себергә, Казакъстанга, Үзбәкстанга сөреләләр. Ә Карачай-Черкәс автономияле өлкәсе бетерелә. 1957 елда алар (һәм башка 22 "вак" милләт) реабилитацияләнгәннән соң, үз җирләренә кайталар һәм шул ук елда берләштерелгән Карачай-Черкәс автономияле өлкәсе яңадан кайтарыла. Реабилитациядән соң карачайларның (һәм башка депортацияләнгән милләтләрнең дә) бер өлеше сөрген җирләреннән кайтмый кала, шул сәбәпле бүген аларның төгәл санын ачыклау читен. 1989 елгы хисапка алу буенча, элекке СССРда яшәүче карачайларның гомуми саны 156140 кеше хисаплана.

Алар электән үк терлекчелек белән көн күргәннәр, беренче урында сарык асрау булган. Тормышны, хуҗалыкны алып баруда, бигрәк тә сезонлы ашыгыч эшләрдә (печән әзерләү, сарык йоны алуда) бер-берләренә күмәкләшеп булышу—хәчәр (өмә) ысулы киң кулланылган һәм бу йола бүген дә киң кулланышта. Гадәттә карачайларның яшәгән авыллары зур һәм авылның һәр урамы нәсел-нәсәбә, туган-кардәш гаиләләрнең йортларыннан гыйбарәт. Өйләрнең нигезе таштан, яшәү өлеше агачтан, түбәсе саман балчыктан һәм гадәттә анда чәчәкләр яки үлән үсә. Төп ризыклары сарык ите һәм сарык сөте продуктлары: эремчек, каймак, сөт. Көндәлек туклануларында әйрәнгә май өстәп төче камырлы көлчә турап әзерләнгән аш. Диннәре—Ислам диненең сөнни тармагы.

Телләре карачай-балкар теле дип атала һәм төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә. Бу тел бик борынгылардан санала. Хумара шәһәрчегендә табылган борынгы төрки телдәге рун язуындагы таш такталар һәм күп кенә сүзләрнең төрки язма ядкяре "Кодекус куманикус"ныкына якын килүе шуны исбатлый. Бу телнең төп нигезе төрки булса да, гарәп, фарсы һәм кавказ-иберий теленнән кергән алынмалар шактый урын тота.

## 17. Балкарлар

Үз атамалары берничә: таулу, маллкарлы, балкарлы, балгар. Бу халыкның күпчелеге Кабарда-Балкар автономияле республикасында яши. Бераз өлеше Кыргызстанда, Казакъстанда аерым авыллар булып көн күрә.

1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматларына караганда, аларның элекке СССРдагы гомуми саны 85126 кеше.

Балкарларның этногенезы хәзергәчә төгәл ачыкланмаган. Кайбер галимнәр, алар Идел-Кама Болгар дәүләтен монголлар басып алгач, Төньяк Кавказга качып киткән булгарилар дип фараз кылса, башкалары бу халык элек-электән үк Төньяк Кавказда яшәгән җирле кабиләләрнең монгол яуларыннан соң килгән ирантелле һәм төркителле халыкларның (алан, болгар, хазар, кыпчакның) аралашуыннан укмашкан, формалашкан, үзләренә төрки тел кабул иткәннәр, дип хисаплыйлар.

Алар Идегәй нигез салган Нугай урдасы таркалу чорында (XYI йөз башы) Кавказның көньяктагы тарлавыкларына күчеп китәләр, ләкин русларның Кавказны яулап алу сугышлары вакытында (1817—1864) яңадан элекке җирләренә, Кавказның төньяк тигезлекләренә кайталар, терлекчелек, игенчелек белән шөгыльләнә башлыйлар.

Революциядән соң, 1922 елда Кавказ арты федерациясе оештырыла. Балкарларны кабардалар белән бергә кушып, шул федерациягә кертәләр, бу федерация бетерелгәч, кабардалар белән алар РСФСР составына аерым өлкә булып кушылалар. Соңыннан бу өлкә автономияле республика статусын ала. Анда яшәүче балкарлар гомумхалыкның фәкать 9 процентын гына тәшкил итәләр. Бу республика кушма исем—Кабарда-Балкар исемен ала (1936).

1944 елда башка "вак милләт" халыклары белән бергә, балкарлар да Сталин депортациясенә эләгәләр, Себергә, Казакъстанга, Урта Азиягә сөреләләр. 1957 елда алар да реабилитацияләнәләр һәм үз җирләренә кайталар; хәзер Кабарда-Балкар республикасындагы халыкларның 25 процент чамасын тәшкил итәләр.

Антропологик яктан алар европеид төркеменә керәләр, тышкы кыяфәтләре, руслар әйтмешли, "кавказский тип"—кара чәч, кара күзләр, кинчә йөз, йөнтәс тән. Диннәре—Исламның сөннилер юнәлеше.

Телләре карачай-балкар теле дип атала һәм төрки телләрнең кыпчак төркеменә карый. Карачай-балкар теле бик борынгылардан санала һәм XIX йөз төрки язма ядкяре "Кодекус куманикус" теленә бик охшый. Бу тел, кайбер төрки телләрдән аермалы буларак, безнең татар әдәби телендәге шикелле Җ, Ң, калын Гъ, Къ авазларының кулланылуы белән характерлы (жер, жылы, кең, мамыкъ, болгану). Бу халык төрле телдәге милләтләр чолганышында яшәве сәбәпле, иран-кавказ-иберий телләрендә сөйләшүче осетин, кабарда, черкәс, чечен, абхаз, сван халыкларының лексикасы карачай-балкар теленә сизелерлек йогынты ясаган. Бу тел ике төп диалектка бүленгән: 1. карачай-баксан-чегем диалекты; аңа "ж" ләп һәм "ч"ләп сөйләшү хас: җер-жир, чәч; 2. маллкар-холомобызыңгы диалекты; монысына "ц"ләп, "з"ләп сөйләшү характерлы: цац—чәч, зер—жир, кицу—кичү, цыфых—чыпчык.

## 18. Хакаслар

Бу төрки халык Красноярск краеның көньягындагы Хакас автономияле өлкәсендә яши. Бу өлкә Енисей елгасы белән Алатау, Саян таулары арасындагы киң, сөзәк тарлавыкта урнашкан. Хәзерге хакасларның электән тәгаен бер генә үз атамалары булмаган, яшәгән урын, төбәкләренә карап үзләрен төрлечә хаас, сагай, пелтер, кызыллы, койбыл татарлары дип атап йөрткәннәр. Революциягә кадәрге рус рәсми әдәбиятында да алар төрлечә аталып килә: "енисей татарлары", "абакан татарлары", "минусински татарлары", ә кытайлар аларны "ха-ги-ас" дип атаганнар һәм бу атама җирле әйтелештә бераз үзгәртелеп "хакас" формасын алган һәм 1930 елда Кросноярск краенда аларның үз милли өлкәсе оештырылгач, бу өлкәгә Хакасия исеме бирелә, "хакас" анда яшәүче төп халыкның этнонимы булып китә.

1989 елдагы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча хакасларның саны 80328 кеше хисаплана. Бу халык сан ягыннан зур булмаса да, аның тарихы бик тирән, аларның

кабиләләре бу җирләрдә безнең эрага кадәр XII гасырда ук яшәгәннәре мәгълүм. Башта алар һуннар, соңыннан кытайларның төрле династияләре кул астында яши, соңгыларын төрек каганаты тар-мар иткәч (YI), бу җирләргә төрки телле төньяк уйгур, кыргыз, алтай кабиләләре килеп урнаша һәм аборигеннар (җирле кабиләләр) белән аралашып китеп, үзләренең телен индерәләр. Соңгы дәверләрдә исә бу конгломерат кабиләләр Чыңгыз хан (XIII), Монгол-ойрат (XY), Алтын хан (XYI) дәүләтләре кул астында яшиләр, төрки тел нигезендә оешып формалашалар. XYII гасыр урталарында бу тарлавыкка руслар да килеп җитә һәм аны Россия җирләре дип игълан итәләр. Руслар бу тарлавыктагы халыкларны аерым җир-олысларга ("землица"ларга) бүлгәләп, Енисей губернаторы тарафыннан билгеләнгән воеводалар хакимлегенә буйсындыралар.

Электән хакасларның төп кәсебе — терлекчелек, аучылык; һөнәрләре — тимер һәм төсле металлардан көнкүреш әйберләре эшләү булган. Хәзер исә Хакасия промышленносте алга киткән, танылган өлкә (күмер, тимер рудасы, төсле металл, мәрмәр, урман материаллары, җиңел промышленность). Руслар килгәч бу җирдәге барлык этник төркемнәр чукындырыла башлый, ләкин соңыннан аларның байтак өлеше иске диннәренә — шаманизмга кире кайталар һәм бу культ хакаслар арасында хәзер дә шактый киң таралган.

Хакас теле төрки телләрнең уйгур-угыз төркеменә керә һәм шушы төркемдәге камасин, шор, сары-уйгур, алтай теленең төньяк диалекты белән бергә аерым хакас төркемчәсен тәшкил итә. Үз язулары рус алфавиты нигезендә 1926 елда гына барлыкка килә, газеталары, дәреслекләре чыга башлый. 1929 елда башка төрки халыклар белән бергә алар да латин шрифтына күчәләр һәм тагын 1939 елда шул ук халыклар белән беррәттән кириллицага кайтырга мәҗбүр булалар. Хәзер хакас теле шартлы рәвештә ике диалектка — сагай һәм качын диалектларына бүленгән. Бу соңгысы хакас әдәби теленең нигезе итеп кабул кылынган. Шуның нәтиҗәсендә бу ике диалект арасында аерма югалып бара. Лексик яктан хакас теленең тамырында кайбер фонетик үзенчәлекләре белән гомумтөрки сүзләр ята, мәсәлән: кизи — кеше, пас — баш, азах — аяк, агыс — авыз. Шулай да хакас телендә монгол-манҗур, кытай һәм соңгы вакытта бигрәк тә рус теленең йогынтысы бик нык күренә. Мәсәлән: килуч — ключ, ачкыч, ыстол — стол, пылат — платок һ. б.

## 19. Нугайлар

Алтын Урданың Төньяк Кавказдан, Каспий, Аралдан башлап Дунайга кадәр сузылган өлешенең хакиме Чыңгыз хан улы Җучинең онычы гаскәрбашы (үнменбашы, русчасы — темник) Нугай бәк була. Аның хакимлеге астында яшәгән төрки халыклар үзләрен нугай кешеләре, нугайлылар, нугайлар дип атап йөртәләр. Башка халыклар да аларны шулай дип атый (ногайцы, ногаи).

1391 елда Алтын Урда ханы Туктамыш гаскәрләре Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә, бу сугышта Туктамышның элекке әмире, соңыннан аның дошманы Идегәй дә Тимер ягында үз гаскәре белән катнаша (Туктамыш — Идегәй арасындагы көрәш мәшһүр "Идегәй" дастанында бәян ителгән). Бу җиңүдән соң Идегәй үз туган йортына, Мангытка — Идел белән Җаек арасындагы төбәгенә кайта һәм тарихчыларыбызның әйтүенә караганда (А. Халиков, М. Сәфәргалиев), анда, Алтын Урдадан аерылып, аерым дәүләт төзи; ул Нугай Урдасы дип атала (чөнки бу төбәк элекке Нугай җирләрендә булган һәм бу җирдәге төркиләр үзләрен нугайлылар дип атап йөрткәннәр). Бу атама соңыннан этноним булып киткән. "Нугай" сүзе Алтын Урда таркалып, берничә ханлыкларга (Әстерхан, Казан, Кырым һ. б.) бүленгәч тә халык телендә кулланышта йөри: Әстерхан нугайлары, кырым нугайлары (Кырымның төньягындагы татарлар). Үзбәкләр татарларны бүген дә "нугай килмешәкләре" дип атыйлар.

Нугай Урдасы соңыннан үзе дә башында морзалар торган берничә олысларга бүленеп китә. (Шундый нугай морзаларыннан берсе Йосыф морзаның кызы Сөембикә Казан ханы Җангалинең, аннан соң Сафагәрәй ханның хатыны була.)

"Нугай" атамасы башка төрки ханлыкларда (Казан, Касыйм, Себер, Әстерхан, Төньяк Кырым) соңыннан "татар" этнонимы белән алыштырылса да, Төньяк Кавказ, Каспий буе төркиләрендә ул хәзергәчә сакланып калган.

Нугайларның хәзер үз административ-территориаль бүленешләре юк, алар төрле төбәкләрдә: Ставрополь краенда, Дагъстан, Чечен, Ингуш республикаларында, Карачай-

Чиркәс автономияле өлкәсендә сибелеп яшиләр. Аларның соңгы тарихы үзләре яшәгән төбәкләрдәге халыклар язмышына бәйле. Мәсәлән, Кавказның (Дагъстаннан башка) өлкәләрендә яшәгән "вак-төяк" халыклар белән бергә, "халыклар дусты" Сталинның приказы белән 1944 елда нугайлар да үз җирләреннән депортацияләнә—төрле якларга сөрелә. Күбесе юлда һәм сөрген урыннарында ачлыктан, җәфалыктан һәлак була. 1957 елда алар да реабилитацияләнә һәм исән калганнары үз йортларына кайталар.

Халыкларның санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча (1989) элекке СССР территориясендә яшәүче нугайларның гомуми саны 75181 дип күрсәтә. Диннәре—Ислам диненең сөннилөр юнәлешенә инану.

Нугай теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә, ләкин лексик-фонетик яктан үзләре яшәгән урыннардагы халыклар телләренә бәйле. Аларның телләреннән алынмалар күп, хәтта алар теленә кучү дә бар. Әйтик, Әстерхан нугайларының әдәби теле—безнең татар теле, Дагъстанның Хәсәу-Йорт, Баба-Йорт районнарында яшәүчеләрнең әдәби теле—кумыкныкы. Гомумән алганда, нугай теле кыпчак төркеменә кергән башка телләрдән лексик, грамматик яктан әллә ни аерылмый, шулай да фонетик яктан төрек һәм үзбәк, каракалпак телләренә якын: акыкат—хакыйкать, умер—гомер, таала—тәгалә, саат—сәгать.

Нугай сөйләш теле өч диалектка бүленә: узнугай (Ставрополь нугайлары), каранугай (Дагъстан нугайлары), акнугай (карачай нугайлары). Алар бер-берсеннән кайбер фонетик үзенчәлекләр белән генә аерыла: 1. жорт, бысак, бизим, мага (йорт, пычак, безнең, миңа), 2. жорт, пысак, бизин, магар, 3. йорт, пичак, бизниң, мәга.

## 20. Алтайлылар

Алтайлылар Россия Федерациясенең Алтай краена кергән Таулы Алтай автономияле округында яшиләр. Алар элек Кытайда Жунгар-Ойрот дип аталган борынгы ханлыкта яшәгәннәр, бу ханлыкны кытайлар басып алгач (1756-58), андагы аз санлы төрки телле халыклар (дербет, бәит, торгыт, захчин һ. б.) Алтайның тарлавыкларына күчеп килгәннәр. Үзләрен элек яшәгән ханлык исеме белән "ойротлылар", "ойротлар" дип атыйлар. Себердән Колчак гаскәрләре куылгач, 1922 елда Алтай крае составында Ойрот автономияле милли округы оештырыла. 1948 елда аның исеме үзгәртелә—ул Таулы-Алтай автономияле округы дип атала башлый (Горно-Алтайский автономный округ). Шуннан соң элекке ойротлар да алтайлылар дип атала башлый һәм бу исем этноним булып кала.

Россия империясенең Себердәге экспансиясе чорында бу төбәк Россиягә кушып алына (1757) һәм җирле халыкларны рәхимсез изү башлана, шаманлык, будда динендәге ойротларның күп өлеше чукындырыла (шулай да шаманизм кайбер урыннарда хәзер дә яши).

Этнографик яктан алтайлылар ике төркемгә—төньяк һәм көньяк алтайлыларга бүленгән. Төньяктагыларының күпчелеген төрки (уйгур, кыргыз) телле ойротлар тәшкил итә, аларны тарихи хезмәтләрдә руслар "кара тутлы татарлар" (черневые татары) дип тә атаганнар. Көньяктагылары (монгол, остяк, төрки, кет) телләрдәге этник төркемнәрдән гыйбарәт, алар үзләрен төрлечә атап йөртәләр: "алтай-кижи" (алтай кешесе), "тубалар", "кумандылар". Боларын элек руслар рәсми документларда ак калмыклар (белые калмыки) дип атаган. Көнкүрешләре—терлекчелек (панта-мөгезле болан, сарык, мамык йонлы кәҗә асрау), аучылык (тиен, ас, чәшке, кеш мехларын әзерләү), мөгезле эре хайваннарны көтүләп асрау.

Алтай теле төрки телләрнең кыргыз-кыпчак төркеменә карый. Ул бу телдә байтак борынгы төрки лексик берәмлекләрнең сакланып калуы белән характерлы. Мәсәлән: буга, бога—үгез. Безнең Алабуга шәһәре топонимы да шушы "буга"дан килә, "ала үгез димәктер" (Г. Саттаров); кое-кузук (безнең телдә бу борынгы төрки "кузук"тагы "з" авазы "е"гә үзгәргән, соңгы "к" югалган. Алтай теле төньяк (куманда) һәм көньяк (челкан) төркемнәренә бүленгән. Алар бер-берсеннән кайбер авазларның алмашып килүе белән аерыла. Мәсәлән, төньяк төркемдә ул—алмаш, ура—чокыр, мурө—бүре, пүрүк—бүрек булса, көньяк төркемдә бу сүзләр ол, оро, бөрү, бөрүк диелә. Әдәби телнең нигезе итеп көньяк төркемдәге диалектлар алынган һәм бу әдәби тел лексик-фонетик яктан кыргыз теленә якын тора.

Алтайлыларның гомуми саны 1989 елгы хисапка алу буенча 70777 кеше хисаплана.

Шулардан 85 проценты үз телләрендә сөйләшә, 15 проценты үзләрен рус телендә иркен сөйләшүче дип саный.

## 21. Шорлар

Үз атамалары—шор. XYII—XYIII гасырлардагы тарихи документларда алар төрлечә аталганнар: "мрас татарлары" (Мрас елгасы исеменнән), "кондом татарлары", (Кондом елгасы исеменнән), "Кузнецк татарлары", ягъни барысы да "татарлар" дип аталган. Этимологлар фикеренчә (М. Фасмер, А. Преображенский, Н. Шанский) "шор" этнонимы да елга исеменнән (гидронимнан), бу халыкның күпчелеге яшәгән Том елгасының тармагы Шордан алынган. Шорлар Кемерово өлкәсенең әлеге елгалар, Абакан, Алатау, Таштагул тарлавыкларында, Таулы Шория (Горная Шория) дип аталган төбәктә яшиләр. Сан ягыннан алар күп түгел, 1989 елгы халык санын исәпкә алу буенча фәкать 17 мең кеше хисаплана һәм элекке СССРдагы 26 төрки халыклар арасында 22 нче урында торалар. Этногенезлары буенча алар озак вакытлар угор, самодий, төрки этник төркемнәрнең (алтайлылар, хакасларның) аралашып яшәве нәтиҗәсендә формалашкан дип хисаплана. Шуңа күрә, тел ягыннан гына түгел, гореф-гадәт, мәдәният, көнкүрешләре белән дә алар күрше алтайлыларга, хакасларга бик якын.

XX гасыр башына кадәр бу халык ыруглык төземе тәртибендә яши. Көнкүреш-тормыш кичерүләре—терлекчелек, аучылык (болан, ат, сарык асрау) һәм тимерчелек һөнәре. Алар борынгы заманнардан ук рудадан тимер эретеп, төрле көнкүреш әйберләре, хуҗалык әсбаплары ясау осталары булганнар. Шуңа күрә руслар аларны "кузнецкие татары" дип тә атап йөрткәннәр. Шорларның бүгенгәчә Кемерово өлкәсе составында үзләренең милли административ бүленеш алганнары юк.

Шорлар теле төрки телләрнең уйгур-угыз төркемендәге хакас төркемчәсенә керә. Электән үзләренең язуы булмаган, 1928 елда гына латин графикасы нигезендә үз язулары булдырыла (билгеле инде, 1940 елда алар да рус графикасына "күчәләр"). Лексик яктан шор теле әлегәчә җитәрлек өйрәнелмәгән, әмма бу телнең нигезе гомумтөрки икәнлегенә шөбһә юк. Мәсәлән: күн—көн, кояш, ай, кижи—кеше, чакшы—яхшы, суг-су, елга, таг—тау, пир—бер, ике—йиге. Шулай да шор телендә монгол, рус, алтай, хакас телләреннән кергән алынмалар шактый урын били (лексик фондның 60 процентын тәшкил итә).

Шор теле тюркологиядәге классификация буенча ике төп диалектка бүленә: мрас, һәм кондом диалектлары. Алар бер-берсеннән башлыча фонетик яктан аерылалар: мрас диалектында борынгы төрки телендәге күп кенә сүзләрдә "з" авазы әлегәчә сакланып калган. Мәсәлән: азу—аю, кузурук—койрык, козан—куян, казын—каен, азак—аяк һ. б. Кондом диалектында исә "з" авазы "е", "йе" белән алыштырылган. Әлеге сүзләр бу диалектта "аек", "койрук", "коян", "каян" дип әйтелә. Сүз уңаеннан шуны да өстик, борынгы "кузурук" сүзе рус теленә "козырек" булып күчкән. Элек төркиләр мехлы җәнлек "кузурыгын" (койрыгын) баш киеменең алдына (маңгай өстенә) тегеп куя торган булганнар, ә кайбер халыкларда, мәсәлән, башкортларда, бу "кузурук" (койрык) бүрекнең арт ягына, жилкәне каплау өчен тегелгән була.

Шорларның диннәре электән шаманизм булган, бу якларны руслар экспансиялэгәч (XYII—XYIII) аларны христиан диненә (православиегә) күчереп, чукындыралар, әмма урыны-урыны белән шаманизм (төрле ритуаллар белән сикерү, бию, дерелдәү, барабан сугу һ. б. изге рухлар белән элемтәгә керү, сөйләшү) әле дә сакланып килә.

## 22. Долганнар

Бу төрки халык турында күпләрегезнең ишеткәне дә юктыр, мөгаен. Алар бик аз санлы халык, 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча аларның саны нибары җиде мең чамасы (26 төрки халык арасында 23 урында). Долганнар төрки халыклар арасында Россиянең иң төньягында, табигатьнең иң салкын почмагында—тундрада, Таймыр ярымутравында, Красноярск краена караган Таймыр Долган-Ненец автономияле округында руслар, сахалар (якутлар), ненецлар арасында яшиләр. Көнкүрешләре үзләре белән янәшә яшәгән халыкларныкы белән бер: болан асрау, аучылык

(тиен, ас, чәшке аулау). Бу тиреле җанварларны алар читлектәрдә дә асрыйлар, балыкчылык белән шөгыльләнәләр. Тораклары элек агач колга терәкләрдән конус формасында кагылган корама өстенә тиреләр ябылган, "чума" дип аталган" йорт" (юрта) иде. Хәзер бүрәнәдән салынган өйләргә күченү төгәлләнеп бара.

Этногенез ягыннан долганнарның тарихы әллә ни ерактан килми. Бу җирләргә (Енисей тамагына, Таймыр ярымутравына) XYI йөз башында Лена, Олекма елгалары буенда яшәгән эвенк, ненец, саха халыклары күченеп килә һәм биредә электән үк яшәп килгән долган кешеләре килмешәк төрки сахаларнын (якутларның) телен кабул итәләр. XYII—XYIII гасыр ахырында руслар бу җирләргә дә килеп җитәләр, аны Россиягә кушып алалар, бу кыргый крайны Енисей губернасына кертеп, Турухан крае дип атап (Турухан елгасы исеменнән), сәяси җинаятьчеләр өчен сөрген урыны итеп билгелиләр. Биредә 1905—1907 елларда Сталин, Свердлов, Спандарян кебек тарихта эз калдырган шәхесләр сөргендә була.

Долганнарның дине элек шаманизм була, руслар килгәч, аларны православие диненә "күчерәләр".

Долганнарның аерым бер теле юк, төрки телләрнең уйгур төркеменә кергән якут (саха) теленең бер диалекты дип санала.

## 23. Караимнар

Үз атамалары—карай (күплектә—карайлар). Бу этнонимнын (атаманың) нигезендә борынгы яһүд (иврит) телендәге карай сүзе ята. Ул "яттан укучы", "яттан белүче" дигән сүзне белдерә; биш китаптан гыйбарәт Тәуратның "Тора" дип аталганын яттан әйтә-укый ала торган дини әһелләрне шулай атаганнар. Бу атама яһүдләрдән гарәпләргә күчеп, ислам дине аркылы төрки-фарсы телләренә дә кергән, диләр. Ислам динендәге халыклар да Коръәнне яттан белеп укучыларны (Коръән-хафизларны) кари (кара) дип атыйлар. (Безнең Абдулла Кариев псевдонимы, Әзербайҗан композиторы Кара Караев, үзбәк биючесе Бернара Кариева фамилияләре шул исемнән, күрәсең). Ягъни "караим" әнә шул "Тора" китабында язылганнарга гына ышанучы иудаизм динендәге бер сектага оешкан төрки телдәге этник төркем буладыр.

Этногенез яктан алар YIII—IX гасырда Хазар каганатына кергән яһүд динендәге төрки телдәге кабиләләр булган, бу каганат җимерелгәч, Кырымда тупләнгәннәр. Кырым ханлыгы дәверендә (XY—XYIII) караимнар бу ханлыкта шактый зур урын тоталар (мәсәлән, акча кою алар кулында була), әмма XY йөз башларыннан аларны төрле якларга көчләп куа-тарата башлыйлар. Литва кенәзе Витовтның Кырымга каршы походыннан соң (1397), караимнарның шактый өлеше Литваның Тракай өлкәсенә, Украинаның Галич, Луцк өлкәләренә күчерелә, бер өлеше Польша җирләренә китә. Россия империясе Кырымны "кушып алгач" (1783), караимнарны Рәсәйнең төрле өлкәләренә күчерү дәвам итә. Шулай итеп, нәтиҗәдә аларның аз өлеше генә үз ватаннары—Кырымда кала, үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклый ала, ә башка төбәкләргә күчерелгән, куылганнары шундагы җирле халык, милләтләр арасында тел, мәдәният, гореф-гадәтләре ягыннан кушылып, этник милли төркем (халык) буларак югалышка дучар булалар.

Кырымда яшәгән караимнар да кырым татарлары һәм башка "вак" милләтләр белән бергә Сталинның 1944 елгы 11 май фәрманы белән туган йортларыннан Үзбәкстанга сөреләләр. Оккупация чорында да (1941—1944) яһүд диненә булганнары өчен аларны аяусыз кыралар, сөргендә исә тагын да мәрхәмәтсезрәк геноцидка эләгәләр. Нәтиҗәдә оккупациягә чаклы Кырымда аларның саны 10 мең чамасы хисапланса, 1989 елгы халык санын алу буенча караимнарның гомуми саны 2600 кешегә кала. Реабилитациядән соң (1967) аларның бер өлеше (30 проценты) Үзбәкстанда кала, башкалары Кырымга кайта, Краснодар шәһәренә күчеп килә. Шулай итеп, тарихның ачы язмышы белән бу халык та, мөсхет төрекләре шикелле, төрле якка сибелеп, таралып бетә.

Караимнарның теле төрки телләренең кыпчак төркеменә керә. Үзләренең рәсми әдәби теле дә, язулары да (алфавитлары да) юк, кайсы халык арасында яшәсәләр, шулар графикасын (латин, кириллица, яһүд) кулланалар, 19 проценты гына үз телләрен туган тел дип саныйлар.

Географик яктан яшәү төбәкләренә карап, тюркологлар караим телен өч төп

диалектка бүленәр: кырым, галич, тракай. Бу диалектларның нигезендә төрки тел ята, мәсәлән: киши—кеше, кол—кул. Диалектлар бер-берсеннән нигездә фонетик яктан аерыла, мәсәлән: үбү-үпү-өпү, юрү-йирү-йүрү. Лексик яктан да аерма бар: тәрәзә—тереже, пензаре, дерезе; сыер—сыгыр-инәк. Караимнар телендә, башка төрки телләр лексик фондындагы шикелле, гарәп, фарсы телләреннән кергән алынмалар да байтак: акыл, азиз, җымаат (җәмәгать), файда, гормәт(хөрмәт), өмюр (гомер), рәсем (гадәт), тараф, бәхет, дуст, душман, жомарт, гюнаһ, пак, шагар (шәһәр) һ. б. Бу исә аларның төрле якларга таралганчы мөселман мәдәнияте белән дә бәйләнештә булганнарын белдерә.

Сүз уңаеннан шуны да өстәргә була: Илья Ильф һәм Евгений Петровның "12 урындык", "Алтын бозау" классик әсәрләрендәге баш герой Остап Бендерның прототибы караим егет Илья Леви-Майтон булган диләр.

## 24. Кырымчаклар

Атаманың үзе үк бу халыкның тарихы, язмышы Кырымга бәйле икәнлеген күрсәтеп тора. Алар, чыннан да, борын-борыннан Кырым ярымутравында яшәп килгәннәр. Әмма аның бөтен җирендә түгел, ә зур шәһәрләрендә, аерым алганда Симферополь, Севастополь, Керчь, Судаг, Феодосиядә вак һөнәрчелек, кәсепчелек, сәүдә белән көн күргәннәр. Аларның теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә карый һәм фонетик, лексик яктан кырым татарларыныкыннан аерылмый диярлек; ә менә диннәре башка—иудаизмга (яһүдләр диненә) карый, шуңа күрә дә аларны җирле һәм тирә-яктагы халыклар "кырымтатар еврейлары" яки "талмудчы татарлар" дип атыйлар. Менә шулай яһүдләргә дини яктан бәйләнештә булганнары өчен немецлар оккупациясе вакытында (1941—1944) алар фашистлар тарафыннан мәрхәмәтсез геноцидка дучар ителәләр—аларны берәмләп түгел, төркемләп аталар, дарга асалар, аерым корылган лагерь-геттоларда җәзалап, үлемгә дучар итәләр. Оккупациягә чаклы аларның саны ун меңгә якын була. Сталин приказы белән 1944 елның 18 май төнендә алар да кырым татарлары белән бергә депортацияләнәләр, әмма хәзергә кадәр аларның күпмесе Кырымда исән калганы мәгълүм түгел. Шунысы гына мәгълүм, депортацияләнгәндә юлда аларның байтагы газапланып үлә, сөрген җирләренә (Үзбәкстанга) илтеп "урнаштырылгач" та күпләре төрле чирләрдән, ачлыктан кырыла. Шул сәбәпләрдән, 1989 елда халык санын алу мәгълүматларына караганда, СССР территориясендә яшәүче кырымчакларның саны 1448 кешегә генә кала! Кырымчакларның этногенезы, аларның Кырымга килеп чыгуы ерактан килә. Танылган тарихчы-этнограф М. Губогло һәм Ю. Симченко фикеренчә, яһүдләр Кырым ярымутравына YII йөздә Византиядән, андагы христианнарның дини кысрыклауларыннан качып килеп урнашалар һәм үзләренең берничә синагогларын (гыйбадәтханәләрен) салалар. XY гасырда Кырымдагы яһүдләрнең саны аларны Литвадан, Киевтан сөрүләре сәбәпле арта. Алар Кырымда ныклап төпләнәләр, Кырым ханнарына матди яктан булышлык күрсәтәләр. 1595—1728 еллар арасында Кырым ханнарының аларга сәүдә һәм көнкүрештә салымнарга ташламалар, Карасубазар шәһәре тирәсендә түләүсез җирләр бирү турында ярлыклары сакланган. Бу льготалар аларга кырым татарлары арасында ассимиляцияләнү шарты белән бирелгән, ягъни алар бу льготалар бәрабәренә кырымтатар төрки телен, көнкүреш, гореф-гадәтләрен кабул итәргә тиеш булалар. Бу шартлар кабул ителеп, гамәлгә керә бара: кырымчаклар кырым татар теленә күчәләр, күп гадәтләрен, көнкүреш формаларын (татарча өй-җиһаз, киенү, музыка-көй, бию һ. б.) милли атрибутларын кабул итеп төрекләшәләр, әмма диннәрен һәм аңа бәйле дини ритуалларын, йолаларын саклап калалар. Хәзер аларга үзләренең динен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калу мөмкинлеге гамәлдә юкка чыккач, күпләре Израильгә һәм башка чит илләргә күчеп китәргә мәҗбүр булалар һәм алар милли төрки халык буларак бетеп баралар.

## 25. Тофаларлар

Төрки телләр классификациясе буенча бу халык "тофалар" дип атала, ә хәзерге үз атамалары "тубалар", ягъни "тубалылар". Моннан да элегрәк атамалары—карагаслар. Элеккеге СССРда яшәгән төрки халыклар арасында тофалар иң аз

санлы, алар 731 генә кеше. Алар әлеге классификациягә карап, төрки телләрнең көнбатыш тармагына карашлы уйгур төркеменең уйгур-тукей төркемчәсенә кертелгән. Бу аз санлы, инде бетеп бара торган төркиләр Иркутск өлкәсенең Түбән Үдә районында яши. Этногенезы һәм формалашу чоры тува халкына бәйле һәм тарихи яктан аермасыз диярлек. Алар башта тувалы тажиннарның бер өлеше, тармагы булып хисаплана. Моннан өч гасыр элек тува халкы этник яктан икегә бүленеп китә: XYII йөзнең икенче яртысында тофалар тувалылардан аерылып, Саян тауларының көнчыгышына—Үдә, Бирүсә, Гутар, Ия һәм Обьның башка кушылдыклары буйларына күченеп китәләр.

Электән тофаларларның теле, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, ырымнары тувалыларныкы белән тыгыз бәйләнештә булса, алардан аерылганнан соң бу яктан аларда үзләренә генә хас байтак үзгәрешләр барлыкка килә. Бу аермаларның килеп чыгуына, әлбәттә инде, аларның бер-берсеннән аерылышып, аралашмый изоляциядә яшәүләре сәбәп була. Чөнки тува-тажиннар моннан соң Җүгәр ханлыгы, Кытай империясе астында һәм тәэсирендә калалар, ә тофаларлар исә Русия империясе составына кертеләләр һәм руслар йогынтысында яшиләр. Алар Русия воеводаларына һәм рус казнасына кеш (соболь) мехы белән ясак түләп яшәргә мәҗбүр ителәләр. Төп көнкүреш кәсепләре—урман җәнлекләре авы була, моннан тыш болан мөгезеннән, сөяктән, каты агачтан, каен тузыннан, болан тиресеннән төрле көнкүреш әйберләре (савыт-саба, торба, уенчыклар һәм башкалар) эшләү буенча танылган осталар булып дан тоталар, үзләренең хуҗалык, көнкүрешләрендә калай чәйнек белән чуен-казаннан башка барлык кирәк-ярак әйберләр үз куллары белән ясалган була. Мәсәлән, өс киеме иләнгән болан тиресеннән яки бастырылган йоннан, аяк киеме шул ук кеш яки ас мехыннан, болан сеңереннән үрелгән җеп белән тегелгән була. XYIII йөз ахырынача алар зур булмаган (3-4) чумлы төркемнәргә бүленеп-күченеп йөриләр (чум—агач колгалар өстенә болан тиресе ябылган күчерелмәле йорт). XIX йөз башыннан тофаларлар барысы да утраклы тормышка күчә.

Тофаларлар борынгыда мәҗүси булалар, соңыннан шаманлыкка күчәләр һәм хәзергәчә шулай яшиләр, алай да борынгы мәҗүсидән килгән төрле ритуалларын (өйләндерү, зиярәтләү-күмү һәм башкалар), кайбер башка гореф-гадәтләрен әлегәчә саклап киләләр.

## ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ

Шушының белән элекке СССРда яшәүче 25 төрки халык, милләтләр турында кыскача тарихи-этнографик мәгълүматлар бирү тәмамлана. (Үзебезнең татарлар турында инде моңа кадәр бик күп санда фәнни һәм популяр басмалар чыгарылганын һәм әле дә чыга барганын исәпкә алып, аерым бүлешмә бирелмәде.)

Белешмәләр белән танышкан кешеләр шуңа игътибар иткәндер:

1. Төрки халыкларның яшәү урыннары бик тә киң: алар Ерак Көнчыгыштан алып, Көнбатыш Себер, Идел-Кама бассейны, Урта һәм Үзәк Азия, Кавказ, Кырым, Балтыйк буе, Карпат итәкләрендә, ягъни төрле төбәкләрдә яшиләр, икенче сүз белән әйткәндә, төрки халык, төрки милләт булмаган җир юк. 1989 елгы халык санын исәпкә алу мәгълү-матларына карaганда, аларның СССРдагы саны 49,5 миллион хисаплана. Ә бөтен дөньяда алар күпме? Бу турыда төгәл сан юктыр. Кайбер галимнәрнең хисаплавы буенча—200 миллион чамасы диелә һәм алар җир шарының барлык кыйтгаларында, илләрендә яшиләр.

2. Белешмәләр шуны да күрсәтә: гәрчә төрки халыкларның телләрендә тамыр бер булса да, аларның әдәби һәм сөйләм телләрендә фонетик, лексик, грамматик яктан аермалар шактый. Мәсәлән, без төрки халык хисапланган якутлар (саха) яки чуашлар белән иркен аңлаша алмыйбыз. Моның өстенә һәрбер төрки халык теле үзе бернича диалектка бүленгән.

3. Төрки халыклар арасында дин берлеге дә юк. Дөрес, аларның күпчелеге Ислам динендә (аның да ике—сөнни һәм шигый тармагында,) ә калганнары төрле диннәрдә: будда, ламаизм, шаманизм, иудаизм, христиан диннәрендә һәм аларның да төрле секта, агымнарында.

**Рәис САФАРОВ**

*Кайтаваз*

# ХӘНИФӘМЕ, МӘСТҮРӘМЕ?

Һәр санын хөрмәт белән укып барган "Казан утлары" журналының 1998 елгы 3 санында Лирон Хәмидуллинның "Иске чаршауларны алып ташлыйк" исемле, классик язучыбыз Г. Ибраһимовның иҗат мирасына, тормышына багышланган мәкаләсен укыдым һәм андагы кайбер фикерләр мине кулыма каләм алырга мәҗбүр итте. "Гөлсем Мөхәммәдованың "Олы юл" әсәрендә "коммунист биографиясенә" тап төшерердәй тагын бер кечерәк эпизод бар әле,—ди автор.—Ул да булса, Г. Ибраһимовның беренче өйләнүенә бәйле "Үкенечле төн" сәхифәләре".

"... Г. Ибраһимов, советча рәсми никах беләндерме, юкмы, шул чорның бик актив бер большевиклар фиркасы әгъзасына өйләнә".

Әйтәсе килгән сүзем, язасы килгән фикерем әнә шул "бик актив большевиклар фиркасы әгъзасы"—Галимҗан Ибраһимовның беренче хатыны Мәстүрә апа Фәйзуллина ("Олы юл" әсәрендә ул Хәнифә исеме белән бирелә...) хакында.

Кандидатлык диссертациям егерменче елларда Татарстанда һәм Идел буе республикаларында барган хатын-кызлар хәрәкәтен өйрәнүгә багышланган булганлыктан, шул чорның бөтен авырлыкларын үз күкрәкләре белән ерып барып, яшь республикабызны төзүдә һәм аякка бастыруда катнашкан фидакарь җаннар белән очрашырга туры килде. Җитмешенче елларда, Аллага шөкер, аларның кайберләре исән иде әле.

Авыр туфрагы җиңел булсын, күп вакыйгаларның шаһиты, егерменче елларда татар хатын-кызларының мактаулы җитәкчесе Зөһрә апа Баимбетова миңа шул чорның тирән каршылыкларын аңларга, күзалларга булышты. Мәстүрә апа турында да җылы сүзләрне иң беренче Зөһрә ападан ишеттем. Аның үзе хакында исә минем мәкаләләрем матбугатта басылып чыкты.

Бу ханым үзе дә, ире Гыйлемдар Баимбетов та—Галимҗан Ибраһимовны да, Мәстүрә Фәйзуллинаны да бик якыннан белгән шәхесләр. Гыйлемдар белән Галимҗанның тормыш юллары бергә үрелеп бара диярлек. Икесе дә кордашлар, икесе дә Башкортстаннан. Әле Октябрь революциясенә кадәр үк башланган танышлык эсэрлар партиясендә дәвам итеп, Совет властеның беренче елларында төзелгән җитәкче оешмаларда да аларны гел янәшә куя. Гражданнар сугышы да аларны бергә очраштыра: Гыйлемдар—Көнчыгыш фронтның 5-армиясендә сәяси комиссар, "Кызыл Яу" гәзитәсенең баш мөхәррире, ә Галимҗан—шул армия сугышчылары ярдәмендә Колчак тылына үтеп разведка мәгълүмалары җыя.

Соңрак хатыннары Зөһрә белән Мәстүрә дә 1919 елны Казанга киләләр. Икесе дә хатын-кызларның һәм балаларның гомерләрен саклауда тырыш хезмәттә. Икесе дә бик чибәр, белемле, бик тә уңган ханымнар була. Шул елларда чыккан үзәк һәм җирле матбугатта аларның эшләрен мактап язган бик күп мәкаләләр укыдым.

Мәстүрә Фәйзуллина Казанга, инде әйткәнемчә, 1919 елның көзендә килә. Колчак армиясенә ияреп, иленнән аерылып китеп барган Пермь сәүдәгәре Гыйльман бай гаиләсе белән танышып, аның берданбер сылу кызы Мәстүрәнең вәгъдәсен нәкъ менә шул разведчик булып йөргәндә алган икән Галимҗан. Аның "Совет властеннан качкан эмигрантлар белән очрашуы" хакында үзенең истәлекләрендә М. Шаһиәхмәтов та күрсәтеп үтә. (Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. —Казан. Татарстан китап нәшрияты.—1966 ел, 149 бит.)

Әти-әнисен Кытайга озатып, алардан инде мәңгегә аерылган яшь кыз үзенең вәгъдәсе буенча Казанга килә. Алар өйләнешәләр, матур гына гаилә тормышы башлана. Мәстүрә башта Халык мәгарифе комиссариатының аналарны һәм балаларны саклау бүлегенә җитәкчелек итә. Соңрак бу бүлек Сәламәтлек саклау комиссариатына күчерелгәч тә, ул аның җитәкчесе булып кала.

1920 елда Татарстан хөкүмәте оешкач Мәстүрә ханым республиканың иң югары

органы—Татарстан Үзәк башкарма комитеты (ТатЦИК) коллегиясенә сайлана. Татарстан өлкә партия оешмасы хатын-кызлар бүлеге коллегиясенең дә ул актив әгъзасы була.

Егерменче елларның авырлыгын әйтеп, язып торасы да юк. Шул чорларда яшь Татарстан республикасы өстенә төшкән михнәтләр, татар милләтеннән булган җитәкчеләргә эш шартларының чиктән тыш авыр булуы хакында инде байтак язылды.

Мәстүрә кайда гына эшләмәсен, йөзгә кызыллык китерми. Балалар өчен ясле-бакчалар төзү, балалар һәм хатын-кызлар сәламәтлеген яхшырту максатыннан консультация пунктларын булдыру, Кызыл Армия сугышчылары гаиләләренә ярдәм оештыру, бала табу йортларын күзәтү астына алып, эш шартларын яхшырту өчен даими кайгырткан татарча бюллетеньнәр чыгаруны оештыру—болар барысы да ул җитәкләгән бүлек эше. Әле шулар өстенә күпме утырышларда, күпме җыелышларда катнашып чыгышлар ясаган, докладлар укыган ул!

1920 елның ахырында алар икесе бергә партиягә керәләр. Мәстүрәнең билет саны 0979340, билетында фамилиясе Ибраһимова. Димәк, Галимҗан өйләнгәндә үк "бик актив большевиклар фиркасы әгъзасына" түгел, бәлки ак эмигрант кызына өйләнгән булып чыга түгелме?

1920 елны алар бала көтәләр. Мәстүрә инде әти-әниләре белән хат алыша башлый, аларга да ана булачагы хакында яза.

Шунысы да мәгълүм: большевиклар фиркасына кергәч, Галимҗан Мәстүрәдән әти-әнисе белән аралашмавын таләп итә. Ләкин: "Мин анамның хәләл күкрәк сөтеннән ник баш тартыйм"—дигән җавапны ишетә. Ата-анасыннан баш тартмавы өчен Мәстүрәгә соңрак та күп бәлаләр күрергә насыйп була, тик алар хакында соңрак.

Зөһрә Баимбетованың сөйләве буенча, Кытайдан Галимҗаннарга бер вагон тулы әйбер килә. Анда йорт җиһазлары, савыт-саба, икесенә дә яхшы кием-салым, ә туачак балага үсеп буйга җиткәнче кирәкле нәрсәләр була. Шушы бүләкләр аларның аерылышуына сәбәп тә була, күрәсең. Чөнки Ибраһимов бүләкләрне алуга ук бүгениртәгә бала табарга торган Мәстүрәне ташлап чыгып китә. Чыгып киткәндә ул Мәстүрәгә: "Синең контр атаң-анаң өчен җавап биреп торасым килми",—ди. Гаилә җимерелә.

Аңа кадәр алар Башкортстанга, Галимҗанның әнисе Хәсәнә апа янына кунакка кайтырга сүз куешкан булалар. Чөнки Хәсәнә апа улының бик тә чибәр мөселман кызына өйләнгәнен ишетеп бик куана. Түземсезлек белән аларның кунакка кайтуларын көтә. Килене дә беренче баласын каенанасы янында табарга тели. Шуңа күрә дә, гаиләсе җимерелүгә карамастан, Мәстүрә Солтанморатка үзе генә булса да кайта. Гаиләсен ялгап җибәрү өмете белән баласын тапкач та каенанасы янында яшәп карый. Тик бер кискән икмәк кире ябышмаган күрәсең. Кызганычка каршы, баласы да озак яшәмәгән, ул Казанга ялгызы гына кайткан.

Ә икенче хатыны Гөлсем апаның Мәстүрәгә карата ни дәрәҗәдә объектив булганын әйтүе кыен. Әмма, әйтеп үтелгән "Олы юл" әсәрендә ул нигәдер бу ханымның Галимҗанның законлы, никахлы хатыны икәнен дә, ә үзенең Ибраһимовка кияүгә чыгып аерылган хатын булганын да күрсәтергә "онытып" җибәрә. Документаль әсәр язган авторга мондый хәтерсезлек бер дә килешми төсле.

Әйе, 1923 елда Галимҗан Гөлсем Мөхәммәдовага өйләнә, ә Мәстүрә атаклы җырчы, үзешчән композитор Газиз Әлмөхәммәтовка кияүгә чыга. (Баимбетовлар гаиләсе бу вакытта Казаннан киткән була. Шушы гаиләнең иң якын дусларыннан берсе мәшһүр артист, виртуоз мандолиначы Исмәгыйль Иалов истәлекләренә нигезләнеп язам.) "Алар искиткеч матур яшәделәр,—дип сөйләде Исмәгыйль абый Илалов Мәстүрәләр турында,—1924 елны кыз балалары туды, аңа Рауза дип исем куштылар. Гаиләдәге җылылыкка, дуслыкка сокланмаган кеше юк иде. Тик баштарак материаль яклары бераз кысан булды. Бала булгач Газизнең акчаны күбрәк табасы килә, әмма ул иҗат кешесе—опера язу хыялыннан да айный алмый иде. Газизнең хәлен аңлаган изге җан Мәстүрә шул чакта да фидакарьлек эшләде. Ирен опера язарга күндереп, 40 көнлек баласын яслегә урнаштырып, үзе эшкә чыкты".

Озакламый Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши, Юрий Виноградовларның уртак җимеше "Эшче", "Сания" опералары языла һәм сәхнәдә куелып, уңыш казана. Тормыш та җайланган кебек була, тик күңелләре генә тыныч булмый.

Менә 1929 ел—Сталинның "бөек борылыш елы" дип аталган, иң элек зыялыларны җинаять җаваплылыгына тартып эзәрлекләгән вакыт җитә. Партия

әгъзаларын тикшереп, "чистартулар" башлана. Татарстан партия оешмасының иң күренекле җитәкчеләре, гражданнар сугышында Совет властен яклап катнашкан Кашшаф Мохтаров, Гасыйм Мансуров, Рәүф Сабиров, Мигъдәт Борындыков, Мәхмүт Бүдәйлиләр партиядән чыгарыла. Ә Мәстүрә—алар кул астында, алар җитәкләгән оешмаларда эшләгән кеше. Ул һаман да хатын-кызларның тормыш-көнкүрешен яхшырту комиссиясенең коллегия әгъзасы, җаваплы сәркәтибе. Җитмәсә, Мигъдәт Борындыков кулга алынгач та үзенең гаепсезлеге хакында партия өлкә комитетына хат язып, аны тапшыруны Мәстүрәдән үтенгән. Мәстүрә, "халык дошманы" белән бәйләнешкә кергәне өчен үзенә ни булачагын белсә дә, тиешле урынга ул хатны тапшырган. Шул ук 1929 елны анын үзен дә башта партиядән, соңрак эштән дә чыгаралар. Партиядән чыгарылу сәбәбе: "контрреволюцион ата-аналары белән араны өзмәгән һәм өзәргә дә теләмәгән өчен", дип язылган. Шунысы кызык, "чистарту" комиссиясе каршында да Мәстүрә иманына тугры кала, ата-анасыннан баш тартмый.

Шулай итеп, Мәстүрә белән Газизгә Казанда яшәргә мөмкинлек калмый. Алар Уфага күчеп китәләр. Тик анда да кара язмыш каршылый. Эшкә урнашып, җаннары сөйгән эшләренә бирелеп яши генә башлыйлар—1937 елда Газиз, 1938 елда Мәстүрә кулга алына. Газизне шунда ук аталар, баласы бәхетеннән Мәстүрә исән кала.

Төрмәдә ул монашкалар янында утыра. Ачы хәсрәтен бераз җиңеләйтү өчен ул ни кушсалар шуны эшли, монашкалардан искиткеч матур чигү үрнәкләре өйрәнә. Инде онытыла язган бу борынгы чигүләрдән гаҗәеп матур әйберләр ясый. Төрмәдәге надзирательләр ул чигешләрне Мәскәүдән килгән тикшерүчеләргә күрсәтәләр һәм аларның чигү иясен күрәселәре килә. Арадан берсе элекке елларда Үзәктәге хатын-кызлар хәрәкәтендә катнашкан, Мәстүрәнең дә эшләрен белеп, уңай бәя биргән кеше икән. Ул Мәстүрәне таный. Шул шәфкатьле җан ярдәме белән Мәстүрә (8 айдан соң булса кирәк) төрмәдән котыла. Тик эшләргә эше, торырга фатиры, тотарга акчасы булмый.

Кызларының авыр хәлгә төшүен ишетеп чит җирләрдән ата-анасы кайтырга чыгалар. Ни фаҗига, аларны да чикне үтеп чыгуга кулга алалар һәм шунда ук юкка да чыгаралар.

Шундый авыр көннәрдә рәхмәт фәрештәсе булып Исмәгыйль абый Илалов ярдәмгә килә аңа: кызын табуда булыша, акчалар биреп тора. Билгеле, бу ярдәме өчен үз тормышына нинди куркыныч янавын белгән Исмәгыйль абый. Ана шул хакта әйткәч: "Мин башкача булдыра алмадым. Газиз дә, Мәстүрә дә минем иң якын дусларым иде. Бу хакта беренче тапкыр сиңа әйтәм. Мәстүрә хакында язарга кирәк. Ул онытылырга тиеш түгел. Күпме кешегә ярдәм итеп яшәде, ул изге җаннардан иде",—диде.

Элек үз кул астында эшләгән бер ханым Мәстүрәне балалар яслесенә җыештыручы итеп урнаштыра алган, ишек төбендә генә булса да яшәр урын да биргән. Еллар рәтләнә төшкәч, аларның да тормышы бераз җайланган. Мәстүрә шул яследә мөдир булып эшләп, аны үрнәк балалар бакчасына әйләндергән, оныкларын тәрбияләшкән.

1978 елны Мәстүрә апа вафат була. Мин аның кызы Рауза апага хат яздым. Әнисе хакында язуын үтенгән идем. Анын "Тормышының соңгы көннәренә кадәр кешеләргә искиткеч ярдәмле булды, актык сыныгы белән бүлеште", дигән хатын алдым. Рәхмәт.

Мәстүрә ханым хакында "Афзал абый Шамов бик әйбәт белә",—дигәнне ишеткәч, аңа да шалтыратып очрашырга рөхсәт сораган идем. Әмма соңга калган булып чыктым. Афзал абый авырый иде. Мине кабул итә алмавын аңлаткан хатын-кыз (кызы иде булса кирәк, рәхмәт аңа) минем йомышымны тапшырган булган. Афзал абый: "Мәстүрә изге җаннардан иде, шулай язсыннар, шулай истә калсын",—дигән. Мәстүрә апаның намуслы хезмәте турында күп укыганга, олы җанлылыгы, кешелеклелеге турында күпләрдән ишетеп белгәнгә—шул хакта язасым, милләтебезнең зыялы бу хатын-кызы хакында укучыларга мәгълүмат җиткерәсем килде.

**Тәминә БИКТИМЕРОВА,**
тарих фәннәре кандидаты

*Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә 60 ел*

# МИЛЛИ УЧАК ЯКТЫСЫ

Татар кешесе дөньяның кайсы төбәкләрендә генә яшәмәсен, үзенең бердәнбер газиз Ватаны Татарстанга, борынгы Казан һәм Болгарга, мәгърур Идел ярларына ашкына. Аның халкы, тарихы, гореф-гадәте, үткәне-киләчәге шушында.

Татар халкының рухи мәдәниятен, күңел байлыгын, күркәм иҗадиятын Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле бөтен дөнья халыкларына барлык бизәкләре белән илтеп ирештерә.

Аларга затлылык һәм горурлык, нәфислек һәм тирәнлек хас. Борын-борын заманнардан килгән җырлар һәм дастаннар, биюләр һәм кыйссалар аларны иҗат иткән затларның—исемсез һәм исемнәре билгеле бөек талантларның җан җылысын безнең күңелләргә күчерә, безне барлык чорлар белән берьюлы яшәтә, бәсгәйтә.

Бу байлыкның тамчысын да җуймыйча исән саклау, яшәтү, киләчәк буыннарга исән-имин килеш тапшыру—



*Ансамбльнең җитәкчеләре. Сулдан уңга: баш балетмейстер Р. Гарипова, оркестр җитәкчесе Р. Мостафин, сәнгать җитәкчесе Л. Кустабаева, баш хормейстер В. Гәрәева.*

Ансамбль татар хәятында иң беренче тапкыр 1938 елда аваз салды һәм 60 ел буена ул җыр-биюләр, музыка аша дөнья халкы алдында татар халкын гәүдәләндереп яши.

Ансамбльнең затлы сәнгатен Бөекбритания, Япония, Тунис, Италия, Франция, Алмания, Төркия, Финляндия, Кытай, Югославия, Нигерия, Польша һәм башка бик күп ил тамашачылары ихластан алкышлады.

Татарның җыр-биюләренә ни өчен бар халыклар да мөкиббән китә соң? безнең коллективның төп максаты әнә шунда. Кабатланмас, бөек культураны тирәнтен белгәндә, жаның белән тойганда гына бу максатка ирешеп була.

Халыкка үзенә-үзен күрсәтеп, татарның үзен татарлыгы белән горурланырдай хисләр уятуда ансамбльнең әһәмияте бәяләп бетергесез.

Халыкара мәгълумат алмашу академиясенең Бөтендөнья форумы делегатларының берсе ансамбльнең чыгышын караганнан соң болай диде: "Сезнең концертларыгызны карагач—



Татарстаннан читтәгеләргә татар булып калуы мең тапкыр җиңелрәк"...

Әлмәттән бер нефтьченең ачынып әйткәнен онытасым юк: "Балачакта сезнең концертларны караган булсам, туган телемне югалтмаган булыр идем".



Ә үз телләрен, милли рухын җуя барган бүгенге буын өчен шушы тәрбия никадәр кирәк! Менә шуңа күрә дә ансамбль инде 15 ел дәвамында "Безнең мирас" дигән программа белән җөмһүриятебез мәктәпләрендә махсус чыгышлар ясый. Инде классикага әверелгән тама-



шалар: "Аулагөй", "Сабантуй", "Туй", "Каз өмәсе", "Корбан бәйрәме", "Рамазан", "Шәрекъ клубы", "Төрки дөнья", "Сәйдәшем", "Әрни әле, әрни ул яра", "Ачкыч", "Казан кунаклары", "Җаныем—жанашым" яңа буын тамашачыларын милли учагыбыз яктысына җыя, таралышмаска, югалтышмаска өнди.

**Лима КУСТАБАЕВА,**

Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.



*Безнең календарь*

## Шәһит Әхмәдиевнең тууына 110 ел

Күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы журналист һәм язучы Шәһит Әхмәдиев туган халкының бәйсезлеге, хезмәт ияләренең бәхетле киләчәге өчен көрәш юлында күп көч куйган шәхесләрнең берсе. Ш. Бабич атаклы "Китабеннас фи хаккыл—хавас", ягъни "Күренекле кешеләр хакында китап" дигән әсәренең "Яңартылганнар" дигән өлешендә аңа мондый эпиграмма багышлый:

**Хөрriяттә син, Шәһит, ай-яй күп кырдың бугай,**
**Ярлыны ярдан алырга бик тырыштырдың бугай.**

Шәһит Әхмәдиевнең тормыш юлы бик авыр һәм шактый катлаулы була. Ул 1988 елның 29 декабрендә элеккеге Чистай өязенең Татар Ялтаны авылында дөньяга килә. Ул кечкенәдән белемгә омтылучан, зирәк бала була, башлангыч белемне туган авылында ала. Әмма күп тә үтми, аның әти-әнисе үлеп китә һәм Шәһит туган-тумача кулында ятим бала булып кала. Берәр приютка элэгеп яки малайлыкка ялланып булмасмы дип, 1901 елның җәендә ул авылыннан чыгып китә. Оренбургка килеп, "Хөсәения" мәдрәсәсенә керә. Ул баерак шәкертләргә самавыр куеп, кер юып көн күрә. Бераз үсә төшкәч, башка шәкертләр җәйге каникулга таралган айларда тимер юл төзелешендә һәм башка урыннарда эшләп, өс-башын бөтәйтергә, кышка бераз акча эшләргә тырыша.

1905—1907 еллардагы революция давыллары торгынлык һәм схоластика хөкем сөргән иске мәдрәсәләрне дә уята. Алдынгы шәкертләр иске тәртипләргә каршы көрәшкә күтәреләләр: коры дин белеме генә өйрәтә торган программа, искелеккә нигезләнгән мулла-мәзин һәм хәлфәләр генә әзерләп чыгара торган мәдрәсәләрне ташлап чыгалар яки укыту программаларын үзгәртүне, дөньяви белем бирүне таләп итәләр.

Бу елларда инде яшь егет булып үсеп җиткән Ш. Әхмәдиев Оренбургта да, соңрак Уфага килгәч, "Галия" мәдрәсәсендә дә шәкертләр хәрәкәтенең башлап йөрүчеләреннән була һәм шуның өчен ике мәдрәсәдән дә куып чыгарыла. Аның бергә укыган сабакташы һәм якын дусты Галимҗан Ибраһимов үзенең "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" дигән хикәясендә әнә шул вакыйгаларны сурәтли.

Кара реакция еллары килеп, илдә эзәрлекләүләр башлангач, Ш. Әхмәдиев Себергә китә. Иртеш буендагы авылларда балалар укыта һәм үзе дә "укый", ягъни үзлегеннән белемен күтәрү өстендә эшли—рус, француз һәм гарәп телләрен өйрәнә.

Ләкин аны барыбер Казан үзенә тарта. Ул, бераз акча җыйгач, 1910 елның җәендә Казанга кайта һәм, университетка керү максаты белән, үзлегеннән әзерләнә башлый. Шушы чорда ул Оренбург һәм Уфа мәдрәсәләрендә бергә укыган сабакташы Галимҗан Ибраһимов белән очраша; алар Суконный урамындагы бер гаиләдә бергә фатирда яшәп алалар. Соңыннан Ялтадан Ш. Әхмәдиевкә җибәргән хатларының берсендә ул еллар турында Г. Ибраһимов болай дип искә ала: "Син минем гомерне беләсең; күпме ачлык, ялангачлык; күпме начар, юеш, сасы квартираларда калтырап кыш чыгулар; күпме көн-төн тырышып укулар, язулар; менә шулар һәммәсе җыелып килеп мине аяктан ектылар, туган..."

Ш. Әхмәдиев тиздән типографиягә хәреф җыючы, корректор булып эшкә керә, аннары газета-журналларда төрле информацияләр, спектакльләргә, әдәби әсәрләргә рецензияләр бастыра, публицистик мәкаләләр яза, тәрҗемәче булып эшли. Шушы елларда беренче очерклары, нәсер һәм хикәяләре басыла башлый. Әдәбиятка беренче адымнарын атлаганда аңа иҗади ярдәм күрсәтүче һәм әсәрләренә юл ачучы кеше Г. Ибраһимов була. Шул чорның башка демократик фикерле язучылары кебек, Ш.Әхмәдиев тә "Суга баткан килен" (1912), "Мөгаллим" (1913), "Татар кызына" (1914), "Сагыш" (1914) кебек әсәрләрендә азатлык-хөрлек идеяләрен яклап чыга, тормыштагы гаделсезлеккә, дини фанатизмга, кыргый-гореф гадәтләргә каршы чыга, чын дуслыкка, рухи тигезлеккә нигезләнгән саф мәхәббәткә, халыкның аң-белем дәрәҗәсен үстерү юлында армый-талмый тырышкан хезмәт кешеләренә мәдхия җырлый.

Ш. Әхмәдиевнең барлык әсәрләре, нигездә, 1912—1917 елларда язылган. Шуннан

соң ул бөтен көчен революцион көрәшкә, дәүләт һәм җәмәгать эшләренә багышлый һәм шул ук вакытта газета журналларда публицистик мәкаләләр һәм истәлек язмалары бастыруын дәвам итә.

Ш. Әхмәдиев Октябрь революциясен шатланып каршылый. Бу көннәрдә ул Мулланур Вахитов белән якыннан таныша, аның белән бергә Үзәк Мөселман социалистлар комитетында зур оештыру эшләре алып бара, Казан сәүдә хезмәткәрләре һәм конторщиклары профсоюз оешмасына җитәкчелек итә, соңга таба "Аваз" исемле газета чыгара башлый. Газетаның оештыручысы да, редакторы да Ш. Әхмәдиев була. Эчтәлеге белән вак буржуаз газета булуына карамастан, "Азат" үзенең битләрендә вакытлы хөкүмәткә, империалистик сугышка каршы юнәлдерелгән мәкаләләр бастыра, властьны Советларга бирүне таләп итә, татар хезмәт ияләрен революцион рухта тәрбияләүдә большевикларга зур ярдәм күрсәтә.

Ш. Әхмәдиевнең журналистика өлкәсендәге эшчәнлегенә аерым тукталмый үтү мөмкин түгел. Ул—татар совет вакытлы матбугатына нигез салучыларның, аны үстерү юлында армый-талмый эшләгән энтуазистларның берсе. Аның бөтен дәүләт һәм җәмәгать эшчәнлеге, бөтен әдәби иҗаты вакытлы матбугат белән аерылгысыз бәйле. 1913 елда "Ак" журналында чыккан бер мәкаләсендә ул балалар әдәбияты өлкәсендә яшәп килгән җитди кимчелекләргә туктала, күпчелек әсәрләрнең коры үгет-нәсихәт, акыл сатудан гыйбарәт икәнлеген күрсәтеп үтә; балага тормышны танып белергә ярдәм итә торган әсәрләр кирәк, ди. "Бездә сәнагъ нәфисә бармы?" исемле күләмле мәкаләсендә (1914) ул композиторларыбыз, скульпторларыбыз, рәссамнарыбыз булмавыннан, сәнгатьнең башка тармаклары акрын үсүгә борчылып яза, татар драма театрын оештыручы Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, театр сәнгатенең беренче карлыгачлары Мортазин, Болгарская, Тинчурин, Сәмитова һәм башка артистларның иҗади уңышларына шатлана, аларга файдалы киңәшләр бирә. Шул ук вакытта ул үзе дә театр эшчәнлегендә актив катнаша. А.Н.Островскийның "Төшемле урын" әсәрен татарчага тәрҗемә итә. Ф. Әмирханның һәм С.Рәмиевнең "Сәйяр", "Нур" труппалары тарафыннан куелган сәхнә әсәрләренә тирән эчтәлекле рецензияләр яза.

Ул—"Мәгариф" журналын оештыручылардан һәм аның беренче редакторларыннан. Журнал битләрендә аның республикада халык мәгарифен дәрес оештыруга, уку-укыту эшләрен юлга салуга юнәлдерелгән мәкаләләре бер-бер артлы чыгып тора.

1918 елда Ш. Әхмәдиев Казан губерна башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлана. Башта ул Казан шәһәр мәгариф бүлегенең мөселман секциясе мөдире, соңыннан губерна мәгариф халык комиссары булып эшли. 1918 елның январенда ул РСФСР Халык Комиссарлары Советы каршында төзелгән Эчке Россия мөселманнары комиссариатының үзәк коллегиясе әгъзасы һәм Бөтенроссия мөселманнарының мәгариф халык комиссары урынбасары итеп билгеләнә. 1918 елның сентябрендә РСФСР Милләтләр Халык комиссариаты Ш. Әхмәдиевне Идел буе, Урал һәм Себер өлкәләрендә контрреволюциягә каршы көрәшү һәм мөселман пролетар матбугатын оештыру буенча Гадәттән тыш комиссия вәкиле итеп җибәрә.

1919—1921 елларда Ш. Әхмәдиев Урта Азиядә халык мәгарифен торгызуда төрле җитәкче эшләрдә эшли: башта Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитетының "Кызыл Шәрекъ" исемле агитпоездында политбюро әгъзасы һәм халык мәгарифе инструкторы буларак, соңыннан Төркестан республикасының мәгариф комиссары һәм мәгариф эшчеләре профсоюзы рәисе сыйфатында, җирле халык арасында уку-укытуны җайга салу буенча зур эш башкара, культура-агарту учреждениеләренең эшен яхшырту, газета чыгару кебек мөһим чараларга җитәкчелек итә. Үзбәк, казакъ, кыргыз, төрекмән халыкларының орфографиясен камилләштерү өлкәсендә дә аның хезмәте бар: 1921 елның январенда бу мәсьәлә буенча аның җитәкчелегендә мәдәният работникларының Бөтентөркестан съезды үткәрелә.

1921 елда Урта Идел өлкәсендә каты ачлык башланып, аңа каршы көрәш бөтен ил күләмендәге мөһим бер эшкә әверелгәч, партия Үзәк комитетыннан сорап, Ш. Әхмәдиев туган-үскән ягына—Татарстанга кайта һәм янадан Мәгариф халык комиссары булып эшли башлый. Ул сугыш елларында тәрбиячесез калган, ачлыктан интеккән ятимнәр өчен балалар йортлары, һөнәр мәктәпләре, производство мастерскойлары ачу, республикада мәгариф эшләрен юлга салу буенча зур оештыру эшләре алып бара. Бу елларда ул партиянең Татарстан өлкә комитеты әгъзасы һәм СССР Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлана.

Ш. Әхмәдиев озак дәвам иткән каты авырудан соң 1930 елның 12 августында 42 яшендә вафат була һәм Казанның М. Горький исемендәге ял паркындагы Туганнар зиратында күмелә.

## Мансур Крыймовның тууына 100 ел

М.Крыймов имзасы белән язган, егерменче-утызынчы елларның актив шагыйре, яңа чор җырчысы булып танылган әдип тумышы белән—Апас районы Чүри-Бураш авылыннан. Ятим үсә, авылның Кәрим мәзин гаиләсендә тәрбияләнә (Крыймов фамилиясе дә шуннан килеп чыккан). Бик яшьли хезмәт-михнәтнең төмен белә: 1915 елдан Кавказда, Грозный нефть промыселларында, Әстерхан байлары хуҗалыгында бил бөгә, балыкчы була һ.б. 1917 елдан—патша армиясендә, аннан кызыл гаскәрдә солдат... Гражданнар сугышыннан соң Мәскәү янындагы Люберцы шәһәрендә заводта эшли. 1923 елдан Мәскәүдә "Кызыл шәрекъ" типографиясендә хәреф җыючы, аннан корректор була. Мәскәүдә яшәүче үзе кебек үк яшь язучылар белән аралаша, шигырьләр яза башлый; ә инде 1925 елда Мәскәү, Казан нәшриятларында берьюлы өч китабы басылып чыга ("Комсомол җырлары", "Чүкеч җырлары", "Кызыл "Бәдәвам"). Аннары—башка шигырь китаплары, хикәяләр... Уннан артык китап чыгара ул һәм алдынгы, социализмны җырлаучы эшче-коммунист шагыйрь булып, киң танылу ала: иске формаларда яңа эчтәлек салынып, агитация, публицистика өстенлек итә. Эшчеләр темасына да яза ул ("Җырларымны бирдем күмергә" (1931) җыентыгы.); "Кызыл лачыннар", "Фатыйма", "Провокатор", "Партизаннар" кебек поэмаларын бастыра. Бүгенге күзлектән караганда иң кызыклысы, гыйбрәтлесе шул, бәлки: 1930-1932 елларда Мәскәү, Казан нәшриятларында аның дүрттомлыгы—"М.Крыймов әсәрләре" басыла. Яңа чор, система үзенең тугры җырчысын әнә шулай бәһалый... һәм 1938 елда гомеренә дә шул ук тоталитар режим чик куя...

1961 елда М.Крыймовның, Р.Башкуров кереш сүзе белән, сайланма характердагы "Шигырьләр. Поэмалар" җыентыгы дөнья күрде.

## Хәй Вахитның тууына 70 ел

Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов) 1918 елның 2 декабрендә Биектау районы Мәмдәл авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1934 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казан театр техникумына укырга керә. Техникум ябылу сәбәпле укуын дәвам иттерә алмый, Чистай районына укытучы булып китә. 1937—1940 елларда Казан музыка училищесында белем ала, аннан соң Республика җыр-бию ансамблендә җырчы булып эшли, 1941 елда исә армиягә алына. Башта Совет Армиясенең җыр-бию ансамблендә җырчы, соңыннан разведчик булып I Белоруссия фронты гаскәрләре составында Польшага кадәр юл уза.

1945 елда армиядән кайта һәм Казан дәүләт консерваториясенең теория-тарих факультетына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый һәм гомеренең соңгы көненә кадәр фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Хәй Вахитның "Соры кортлар" исемле пьесасы һәм "Дулкыннар" дигән шигырьләр җыентыгы 1938-1939 елларда дөнья күрә. "Канлы куллар" дип аталган пьесасы исә 1939 елда Минзәлә колхоз-совхоз театры тарафыннан сәхнәгә куела. Бер үк вакытта Хәй Вахит балалар өчен шигырьләр дә иҗат итә.

Хәй Вахитны язучы итеп таныткан жанр—драматургия. Аның "Беренче мәхәббәт" (1960), "Рәхим итегез!" (1961), "Кайда соң син?" (1963), "Карлыгач канат кага" (1965), "Соңгы хат" (1966), "Күк капусы ачылса" (1967) һ.б. пьесалары шул чор драматургиясенең, театр сәнгатенең олы бер казанышы буларак бәяләнде.

1960 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган "Беренче мәхәббәт" драмасы өчен Хәй Вахит Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Х. Вахит опера либреттолары һәм музыкаль комедияләр авторы буларак та билгеле. Аның "Самат", "Дим буенда", "Җиһангир", "Наемщик" (Т. Гыйззәт драматик поэмасы буенча) дигән опера либреттолары һәм "Мәхәббәт җыры", "Кияүләр" (1975) исемле музыкаль комедияләре дә бар. 1956 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

Ул—1978 елның 7 июлендә вафат булды.

*Jьlmajьp-kəlep kenə*

## Əxtəm Fətxi

### Taqtaş onьqlarь

(Məƣərif veteranь xatirələre bujьnca parodiə)

Belmim, əllə kypkə, əllə bik ozaqqa,
Axьrь, məŋge onьta almamьn,
Tambof urmannarь şawьn uzьp,
Məktəp balalarь şaulawьn.
Alar məŋge minem qolagьmda,
Şaulap, jərəgemne jarьrlar,
Şьr tilelər, qalmьj minem arttan,
Qaja barsam, ozatьp barьrlar.
Ber çirdə juq mondьj tərtipsezlər,
Ber çirdə juq mondьj şajannar,
Ber çirdə juq, sabaq uqьmьjca,
Klasstan-klassqa kycə alƣannar...

Şajtan balalarь, təmam azdь,
Məktəpkə də xəzer jərmilər.
Jərsələr də, buş baş belən inde,
Dəresləren rətləp belmilər.
... Tatar tele dəresenə kermi,
Sukin sьnnar, zalnьŋ başьnda,
Dənjalarьn onьtьp, tup tibələr
Taqtaş portretь qarşьnda.
Acьmnan teşləremne qьsьp,
Jəgerəm Taqtaş rəseme qarşьna,
Min qapqacь sьman kilep basam:
Tup timəsen şaƣir başьna!

Malaj alda jəri, min—qarşьnda,
Yzem jərim, yzem saƣalьjm.
Əgər tupnь tibə-nitə qalsa,
Totьp jaŋaqlarƣa camalьjm.
Malaj dərestən də tibep qujdь,
Kyrməmeşkə başta sabьştьm.
Taƣьn tipkən ide, tyzalmadьm,
Jaqasьna barьp jabьştьm...
Okop taşlap kitkən dezertirnь
Totьp alьp kilgən şikelle,
Dəresennən qacqan sukin sьnnь
Arestovajt itep kiterdem.
"Mokamaj"nь jatlamasaŋ—berle,
Qolaƣьŋa el!"—dim. "Elmim!"—di.
"Alajsa xet baş syzen əjt!"—dimen.

Malaj busьna da: "Belmim!"—di.

Malaj әjtә: "Taqtaş usal bulƣan,
Gәnah-fәlәn, diep tormaƣan,
Zәꞑgәr tәndә kyrşe qarcьƣьnьꞑ
Aq әtәcen kerep urlaƣan.
Şul eşlәre өcen awъl xalqь
"Razbojnik" dip isem birgәnnәr,
Awъldaƣь barlьq usallьqnь
Annan ƣьna kyrep jәrgәnnәr."
... Әhә, menә kem ikәn ul jawъz malaj,
Taqtaş babasьn xur ityce!
Menә kem ikәn ul, tuplar tibep,
Portretьn xarap ityce!

Ә qьzlarьm minem, çan kisәgem,
Pesilәrdәj tәyfiq iәse!
Uqularь, tәrtiplәrenә dә
Hic tә kilmi nacar, diәse!
Ә qьzlarьm... qьzьl pocmaqta,
Bajraq kisep, kylmәk tegәlәr.
Citlәrenә asьlmalar asьp,
Uqa belәn citen bөgәlәr...
Bul'var zurnallardan өlge alьp,
Burƶujlaşqan syzlәr tezәlәr:
"Yktәbrneꞑ birgәn bylәklәren
Saqlarƣa, dip kirәk tapmьjbьz,
Lenin julьn taşlap, aldap satar
Bazar tarafьna atlьjbьz!"

Uqucьlar—әle uqucьlar,
Uqьtucьlar tьnƣь birmilәr:
Uqьtasь caqta, bajraq totьp,
Mitinglar jasap jәrilәr.
Uqьtucьlar taƣьn baş kytәrde,
Fatir, dilәr, barter sorьjlar.
Nuƶa, brat, tәmam aptьradьm,
Tuda-suda ujlap tordьm da,
Qazna buş, dip, taşka baş ordьm da,
Sponsorlar ezlәp jynәldem.

Ә sponsor әjtә: "Bik kirәkle
Keşe kebek aşьƣa-aşьƣa,
Galoşlarьꞑ salmьj, aqca sorap,
Ni dip kerdeꞑ ataꞑ başьna?!."

Mәktәp eşe, brat, çiꞑel tygel,
Ata-analar qurqьp tormьjlar,
Kyzeꞑne dә jomьp өlgermiseꞑ,
Xәzer ber nәrsәꞑne urlьjlar.
Ata-anasь ber xәl, aşxanәdә
Peşekcelәr tьnƣь birmilәr,
Jonlь borьnnarь, qajmaq aşьj,
Ac balalar — mine tirgilәr.

Belmim, әllә kypkә, әllә bik ozaqqa,

Axrь, məꞑge onьta almamьn,
Məktəptəge saƣətlərem uzƣac,
Qolaq pərdələrem şaulawьn.
Alar məꞑge minem qolaƣьmda,
Şaulap jərəgemne jarьrlar.
Pensiəgə cьƣьp qotьlƣancь,
Alar mine ozatьp barьrlar...

## It janьndaƣь etlər

Aşxanəgə it qajta.
Alabaj saqlap jata.
Mədir qarawьlcь qartqa,
Kisətep, syz quzƣata:
—Itne ettən saƣala,
Kilə qalsa, quala,—
Dip keləttə itneꞑ şəben
Sajlaƣac, kəjləp ala:
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

Aljapqьcьn elə-elə,
It cabucь ir kilə.
It capqac, qarawьlcьƣa
Əjtə qatƣьjlьq belən:
—Kyr etne, jəri ɵrep,
Itne cəldertmə berүk,—
Di də itce, çьrlap kitə,
Zur uq kisəkne tərep:
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

Peşekce it peşerə,
Sumkasьna təşerə.
Andьj it ac Alabajnьꞑ
Kermi xətta təşenə.
Peşekce bu zur təjenen
Alьp kitə ɵjenə.
Təjenenə səjenə-səjenə,
Çьrlьj qajtqan kəjenə:
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

Aş ɵləşyce xatьn
Itneꞑ ɵləşmi barsьn.
Etneꞑ isnənyen kytep,
Jəş xanьm ala jarsьp:
—Kyr inde, şuşь etne,
Haman saƣalьj itne.
Kɵnozьn isnəp jərsə də,
Şul etkə haman çitmi.
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

Qarawьlcьƣa it oşьj,
Qart jomşaq qalça aşьj,
Kimergən səjəgen etkə,
Kyzen—xanьmƣa taşlьj:
—Dərman kyp, dilər, ittə,
Monь təşenə et tə,—
Di-di qart haman şajarta,
Syzne şul cama jərtə:
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

Aşxanədə ac xalьq,
Utьra xəlsez qalьp.
Mədir səjli, it bulmaunь
Aꞑlatmaqtan syz alьp:
—Xalьq itsez tilmerə,
Et it aşap simerə.
... Ə Alabaj, ьrlьj-ьrlьj,
Qorь səjək kimerə:
—It jatsьn, it janьnda et jatsьn,
Ul et nicek tik jatsьn?!

# 1998 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

1998 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 5

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Баттал Ф. Сатирик хикәяләр. № 6
Галиев М. Догалы еллар. *Эссе.* № 1, 2
Галиев Ф. Әтнә—күңелем бишеге. *Истәлекләр.* № 10, 11
Гали Ә. Лаеш шулпасы. *Хикәя.* № 11
Галиуллин Т. Гомер тәлгәшләре. *Эссе.* № 7
Гомәр Г. Шаһмиран. *Повесть.* № 12
Гыйләҗев А. Тәмәкене ташладык, рәхәт яши башладык. *Киноповесть.* № 10
Гыймадиев А. Балалар өчен хикәяләр. № 10
Диндаров И. Йолдыз жиле. *Хикәя.* № 10
Зыя С. Ике дөнья арасы. *Хикәя.* № 4
Зәйдулла Р. Кечкенә кешеләр. *Хикәяләр.* № 8
Иксанова И. Ике хикәя. № 3
Ихсанова Л. Кемгә сөйлим серләремне? *Автобиографик повесть.* № 8
Камалов Б. Хатирәләр яңарган көн. *Повесть.* № 9
Мирхәйдәров Р. Игълан буенча танышу. *Повесть.* № 4
Нәбиуллин Т. Качкын. *Повесть.* № 9
Поварисов С. Күкнең җиденче катында. *Роман.* № 5,6,7
Салах Ә. Балыкчы малайлар. *Хикәяләр.* № 11
Төрек хикәяләре № 10
Фәизов Р. Ике әни. *Повесть.* № 1
Хуҗин М. Тар тыкрык сукмагы. *Хикәя.* № 5
Хәлим А. Авылдаш. *Хикәя.* № 7
Хәсәнов Н. Инрәү. *Повесть.* № 2
Шаһимәрдән М. Татлы агу. *Роман.* № 11, 12
Әмирхан М. Гөлнәзирә. *Повесть.* № 3

## ШИГЪРИЯТ

Анак. Ш. Үткәннәр авазы. *Шигырьләр.* № 9
Афзал Г. Мин картайган саен усалланам. *Шигырьләр.* № 1
Баян Ә. Салават күпере астында. *Шигырьләр.* № 12
Булатова К. Айлы кырда калган ялгыз ат. *Шигырьләр.* № 6
Вәлиев Мөдәррис. Нигез. *Шигырьләр.* № 8
Галиев Ш. Вакыт ага безнең аркылы. *Шигырьләр.* № 9
Гали Муса. Көне килгәч. *Шигырьләр.* № 10
Гамбәр Н. Мәңгелектән кайтып килешли. *Шигырьләр.* № 4
Гаташ Р. Бармы көчем—яшь моңны юатырлык. *Шигырьләр.* № 2
Гатауллин Рәшит. Күзләр көзгә охшап килми икән. *Шигырьләр.* № 7
Гыйззәтуллина Ф. Тамгалы таллар. *Шигырьләр.* № 12
Гәрәева С. Симфония. *Шигырьләр.* № 11
Емельянов Я. Әләк. *Шигырьләр.* № 11
Зәйдулла Р. Шигъри тәфсирләр. № 11
Зөлфәт. Аулак сукмак. *Шигырьләр.* № 7
Илгөләм. Хыялым булып кал. *Шигырьләр.* № 3
Каюмов М. Сал. *Шигырьләр.* № 4
Миңнуллин Р. Китеп барам көләч җәйдән. *Шигырьләр.* № 5
Морат Г. Без кичәргә тиеш Иделне. *Шигырьләр.* № 6
Мәдияров Н. Яна учак. *Шигырьләр.* № 3
Мөдәррисова Х. Горур ялгызлык. *Шигырьләр.* № 8
Мөслимова Ф. Әмма очу—нинди хозур! *Шигырьләр.* № 3
Низамиев Р. Җилләр сыман, су агышы сыман. *Шигырьләр.* № 11
Нәжми Н. Сиксән тулганда. *Шигырьләр.* № 2
Рәхим Г. Аулак *Шигырьләр* № 8
Рәшит Ә. Сөйлә җиргә милләт хакыйкатен. *Шигырьләр.* № 8
Сафина Н. Әйтегез яшен... айның?! *Шигырьләр.* № 7
Сөләйман. Мәңгелек көй. № 5
Тарханова Ф. Нәүмиз күңелем кабат канатлана. № 11
Фәйзуллин Р. Әй, бу яшәү! *Шигырьләр.* № 1
Фәйзуллин Р. Шәфәкъ аша таң ата. *Шигырьләр.* № 12
Харис Р. Яңа шигырьләр. № 4

Хисамов Н. И кыз бала!.. *Шигырьләр.* № 3
Хәлим А. Исхакый каурые. *Шигырьләр.* № 10
Шабаев М. Балачагым башкаласы. *Шигырьләр.* № 7
Шагыйрьжан Л. Янар, янаркошым! *Шигырьләр.* № 9
Шиһап Р. Мәҗбүри гөнаһлар. *Шигырьләр.* № 4
Шәрифуллина Э. Таллар жаны. *Шигырьләр.* № 10
Юзеев И. Мәңгелекнең кайсы ноктасында? *Шигырьләр.* № 3
Яруллин Ф. Якты ай янында. *Шигырьләр.* № 2
Яхин Ф. Сагыну көне. *Шигырьләр.* № 6
Әминева Н. Мәңгелек теләгән жаным. *Шигырьләр.* № 9
Әхмәдиев Н. Чакматаш. *Шигырьләр.* № 5
Әхмәтжан Роберт. Үр төшкәндә. *Шигырьләр.* № 10
Җамал Р. Аңым белән жаным. Шигырьләр. № 6

## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Галәү М. Яшәсен ипи белән суган. № 12
Мөхәммәдев Ш. Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай. № 6

## ДРАМАТУРГИЯ

Миннуллин Т. Сөяркә. *Ике пәрдәле драматик хикәя.* № 6
Садриев Ф. Яшьләй сөйгән ярлар. № 11

## ӘДӘБИ МИРАС

Баттал Таймас Г. Мин бер яктылык эзләгән идем. № 4,5
Еники Ә. Ченәкәй—кем ул? № 4
Гайнетдин М. Мулла шагыйрь. № 2
Иманколый М. Газәлләр. № 2
Ченәкәй Т. Иҗатыннан үрнәкләр. № 4
Шәмси С. "Җенелгәннәр арасында мин дә бар идем". № 4

## ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин Ш. Күңел күзе белән. № 4
Борһанов Ә. Кем гаепле? Нәрсә эшләргә. № 6
Бәйрәмова Ф. Тәгәри китте йомгагым... *(Хаҗ көндәлеге).* № 9,10
Галиев Ә. Бер һөйкәлнең тарихы. № 12
Гамбәр Н. "Әйдә, халыкка хезмәткә!.." *(Нәҗип Нәкъкаш белән әңгәмә).* № 9
Дунай Ф. Заманына күрә заны. № 1
Зарипов М. Иван Губкинның тантанасы һәм фаҗигасе. № 3
Зарипов М. "Кара май"ның калжасы. № 5
Латыйфи Ф. Чистаенда чистарындык, Туапседа туплandык. № 12
Минһаж Р. Татарның татардан башка дусты юк. № 4
Шәфыйков Я. Әмирлекләрдә очрашулар. № 7
Әйди Т. Себер үзебезнеке. № 7
Әкбәров Н. Шәфкатьсезлек. № 9

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Тимергалин А. Кая таба һәм... кая тикле? № 9

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ахунов Г. Шагыйрь ачкан дөнья *(Шәүкәт Галиевкә 70 яшь).* № 11
Биктимерова Т. Хәнифәме, Мәстүрәме? № 12
Бәшир Ф. Юлын белгән—арымас *( Нурихан Фәттахка 70 яшь).* № 10
Галимуллин Ф. Кече кирмәннең олы Ринаты. № 12
Ганиева Ф. Шагыйрь гомере—аккошлар юлы *(Роберт Миңнуллинга 50 яшь тулу уңаеннан).* № 8
Гаташ Р. Салисәбез турында. № 11
Гыйззәтуллин И. Язучы—каһарман *(Ш. Усмановның 100 еллыгына).* № 12
Камалов Б. Хәзинәгә өстик әле. № 7
Маннапов Ш. Гали батыр онытыгы. № 11
Мостафин Р. Ш. Усманов турында өч риваять. № 1
Рәшитов Ә. Күңелгә вәхи ингәндә. № 4
Сибат Р. Гаташ—мәхәббәт жырчысы. *Эссе.* № 3
Фәйзуллин Р. Кайту. № 8
Хафизов С. Әдәбиятта базар заманы. № 8
Хәлим А. Кем анда? № 4
Шабаев М. Түземнәр генә бәхеткә лаек. № 2
Шәрәфиев Р. Үзең шатлана белмәсәң. № 1
Шәрәфиев Р. Шигъри сүзнең җегәре. № 4
Юныс М. Акъәбинең кабере янында. № 9
Әхмәдиева Л. Нигезен какшаттылар. № 4
Әшрәфжанов Х. Тамырыбыз тарихта. № 2

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Госманов М. Яңа юнәлеш. № 10
Зарипов Х. Сабан туйларында—халкыбыз асылы. № 8
Камалов Б. Мажаралы повестьлар. №4
Нәҗипова Ә. Олы әдип "Кичү"е. № 5
Сафина Н. Жиргә төшә сөю йолдызлары. № 1
Фәйзуллин Р. Розалина—гөлсукмак. № 4
Хәмидуллина Р. Кыргыйлыкка каршы. № 6

Әхмәдуллин А. Әдәби вакыйгага бу. № 10

## Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ БУЛДЫРЫЛУГА 40 ЕЛ

Казанышларыбыз елъязмасы. №10

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Гайнетдин М. "Хаким вә хөр гакыл бар дип". № 9
Исламов Р. Алтын Урда әдәбияты. №7, 9, 10

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Кәримова А. М. Горький музее һәм татар әдәбияты. № 12
Мәхмүтов Х. Орхон ядкярләре. № 4
Нигъмәтуллин Э. Тоткынлыкта. № 7
Хөснетдинова Р. Андыйлар табигатьтә сирәк очрый. № 4
Хәмидуллин Л. Иске чаршауларны алып ташлыйк. № 3

## ХӘТЕР

Абдуллин Я. Шиһабетдин Мәрҗани. № 1
Бәшири З. Ардаклым. *Шигырьләр.* № 6
Галиуллин Т. Кабатланмас шәхес. № 1
Гамбәр Н. Авырту булып калды *(Фәннур Сафинның тууына 50 ел).* № 6
Ибраһимова Ф. Галимҗан Ибраһимовның фатирлары. № 1
Мостафин Р. Фаҗигале язмыш *(Мин Шабай турында яңа мәгълүматлар).* № 7
Нуруллина Р. Иман сафлыгы. № 4
Рәмиев З. Тукайлар замандашы *(күренекле әдип Зариф Бәширинең тууына 110 ел тулу уңаеннан).* № 6
Сафин М. Дустымны юксынам. № 1
Хәкимов Ә. "Тукай". № 4
Шабаев М. Туган җирнең баласы иде... № 9
Әхтәмов Ш. Бәян Гыйззәт хатлары. № 7

## ФӘН

Мостафин Ш. Гомерлек дуслык. *(Нур Гыйззәтуллинга 70 яшь).* № 6
Профессор булу җиңелме? *(Профессор Ф. Сафиуллина белән әңгәмә).* № 6
Сафаров Р. Төрки халыклар. № 11, 12
Фәхретдинов Р. Татар тарихы битләреннән. № 6
Хәбибуллин М. Һуннар—болгарлар, кыпчаклар һәм татар халкы. №8
Хәйретдинов Р. Бормалы юллар *(Академик Рәфикъ Нәфиговка 70 яшь).* № 6

## СӘНГАТЬ

Госманов М. Театрыбызның әһәмияте хакында. № 6
Кустабаева Л. Милли учак яктысы *(Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең 60 еллыгы уңаеннан).* № 12
Татар театр ярата *(Шәүкәт Биктимеровка 70 яшь тулу уңаеннан).* № 10
Тимбикова К. Чәчәк аткан гөл. № 2
Фәттахов Р. Умырзая кебек... *(Мәшһүр җырчы Рәшит Ваһаповның тууына 90 ел).* № 5
Хуҗахмәт Ф. Гөлсем бәхетенең серләре. № 6
Шәйдуллина Н. "Театрда гомер үткәне сизелми..." № 1
Шәһри Болгарга мәдхия. № 3

## ЮБИЛЕЙЛАР

### ЯКОВ ЕМЕЛЬЯНОВНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Шагыйрь, поп һәм якташ. № 11

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Исхакый Г. Ике хикәя. № 2
Ибраһимова Ф. Әдипнең тормыш мизгелләре. № 2

### ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гыйззәтуллин Н. Үз заманының улы. № 3

### АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Абдулла Алиш турында Х. Гыйльметдинов, Ә. Бикчәнтәева, Г. Латыйп истәлекләре. № 10

### ХАТИП ГОСМАННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Ягъфәров Р. Хатип ага ядкаре. № 5

### ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Миңлебаев К. Гүзәл мирас калдырган әдип. № 2

### ШАМИЛ БИКЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Маннап Ш. Килә икән хатлар... үткәннән. № 1

### БУЛАТ СӨЛӘЙМАННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Хәмид Р. Каһарманнар затыннан иде ул. № 5
Сөләйман Б. Аучы өенә кире кайтмады. *Шигырьләр.* № 5

### МӨХӘММӘТ САДРИГА 85 ЯШЬ

Гаташ Р. Бәхет турында җыр. № 5
Садри М. *Шигырьләр.* № 5

### АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКА 70 ЯШЬ

Ахунов Г. Язучы һәм заман. № 1

### РӘИС ДАУТОВКА 70 ЯШЬ

Гамбәр Н. Эш турында "Эшчән керпе" белән сөйләшү. № 3

МИРФАТЫЙХ ЗӘКИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Әхмәдуллин А. Остазыбыз дустыбыз. № 8

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВАГА 70 ЯШЬ

Гаташ Р. Моннар бәйрәме. № 1
Зәйнашева Г. Мәхәббәт турында уйланулар. *Шигырьләр.* № 1

РАБИТ БАТУЛЛАГА 60 ЯШЬ

Морат Г. Савылсын бәгырь. № 3
Батулла. Каләм яза, кәгазь түзә. № 3

РАВИЛ БИКБАЙГА 60 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Тукайлар, Бабичлар юлыннан. № 12
Бикбай Р. Җыр башы. Шигырьләр. № 12

РИФКАТЬ ЗАКИРОВКА 60 ЯШЬ

Гаташ Р. Авыл улы, шахтер, шагыйрь. № 6
Закиров Р. Кичке моң. Шигырьләр. № 6

ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРОВКА 60 ЯШЬ

Юзеев И. Шигырьдә—рәссам, рәсемдә—шагыйрь. № 2

МАНСУР ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Гамбәр Н. Аккош күлендә утлар. № 1

"ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН" ГАЗЕТАСЫНА 80 ЕЛ

Шәмсетдинов Г. Көнъязмадан туа елъязмалар. № 3

"МӘГАРИФ" ЖУРНАЛЫНА 80 ЕЛ

Шәрифуллин Ф. Мөгаллимнәр мөгаллиме. № 11

КОТЛЫЙБЫЗ!

Саимә Ибраһимовага 70 яшь. № 3
Булат Солтанбәковка 70 яшь. № 11
Диас Вәлиевкә 60 яшь. № 7
Шаһинур Мостафинга 50 яшь. № 1

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Шәһит Әхмәдиевнең тууына 110 ел. № 12
Мансур Крыймовның тууына 100 ел. № 12
Фәтхи Бурнашның тууына 100 ел. № 1
Мөнир Мазуновның тууына 80 ел. № 4
Сәет Кальметовның тууына 80 ел. № 4
Хәй Вахитның тууына 80 ел. № 12

СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Абдуллина Р. Телне каләм саклый. № 7

ӘЙ, ГОМЕР АГЫШЛАРЫ...

Дуслык илчесе, туганлык җырчысы. № 2
Мәңгеләшкән мизгелләр. *Фоторепортаж.* № 8

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Вәлиуллина Р., Гобәйдуллина А., Зиннәтуллин Н., Мәүликаева Ф., Яушев Д. *Шигырьләр.* № 5
Гариф Н. Парчалар. № 5

УКУЧЫ СҮЗЕ

№ 2, 3, 4, 6, 7, 10, 11

ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Ә. Мөхәммәди. Төрки—татар елнамәсе. №12
Сирматов И. Тарих башы—ерак гасырларда. № 2

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Саттаров М. Чыдам Вилдан. *Шигырьләр.* № 6
Тавлин Г. Кушаматлы—югалмас. № 7
Фәтхи Ә. *Шигырьләр.* № 12

ИМЕШ-МИМЕШ ТҮГЕЛ

Камалов Б. Уйга килгән алга килә. № 4
Маннапов Ш. Әдипләр тормышыннан. № 1
Маннапов Ш. Оча торган тәлинкәләр. № 4
Нәҗми Н. Сугыштан соңлап кайткач. № 2
Нәҗмиев Т. Ашка таракан төшү. № 4
Сафаров Р. "Файдалы җанвар". № 2

Галиев Ш. Хикмәтле сүзләр. № 1; № 4

Латин имласында уку күнекмәләре №1-8

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан №1—12

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### М. ШӘЙМИЕВ— ШӘРӘФЛЕ ПРОФЕССОР

11 ноябрьдә Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтында (МГИМО) Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев МГИМОның шәрәфле профессоры дипломына лаек булды.

### ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ— КАНАДАДА

18—23 октябрь көннәрендә Татарстан Республикасы Премьер -министры Р. Миннеханов җитәкчелегендәге рәсми делегация Канадада булды. Монреаль, Оттава, Квебексетида үткән эшлекле очрашулар барышында дару препаратларын бергәләп җитештерү, модульле торак йортлар төзү һәм Казанның “АНСАТ” вертолетларын Канада компаниясе двигательләре белән җиһазлау буенча да өч проект рәсмиләштерелде.

Квебекнең җирле хакимиятчеләре Монреаль янындагы калкулыкларның берсен “Казан тавы” дип атадылар һәм бу хакта делегация башлыгына рәсми таныклык тапшырдылар.

### ПАКИСТАНГА СӘЯХӘТ

“Табигать кануннары буенча яшәү рәвеше” җәмгыятенең Бөтендөнья башкарма комитеты (үзәге—Голландиядә, президенты—Беван Моррис) чакыруы буенча “Казан утлары” журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин Тынычлык Ассамблеясе конференциясе эшендә катнашты. 8—12 ноябрь көннәрендә Пешавар шәһәрендә үткән бу конференциягә дистәләгән мөселман илләреннән вәкилләр чакырылган иде. Р. Фәйзуллин Исламабад һәм Карачи шәһәрләренә дә сәяхәт кылды.

### КАЗАНЫБЫЗ—ИҢ ТӨЗЕК ШӘҺӘР

Җөмһүриятебез башкаласы “Россия Федерациясендәге иң төзек шәһәр” исеменә үткәрелгән Бөтенроссия конкурсында җинеп чыкты. Шул уңайдан, Казан каласына РФ төзелеш, архитектура һәм торак сәясәте буенча дәүләт комитетының, җирле промышленность, коммуналь-көнкүреш предприятиеләре эшчеләре үзәк комитетының махсус призы тапшырылды. Башкала мэры К. Исхаковка исә “Россия Федерациясе торак-коммуналь хуҗалыгының мактаулы хезмәткәре” дигән исем бирелде.

### “АГЫЙДЕЛ” МӨХӘРРИРЕ— РЕДАКЦИЯБЕЗ КУНАГЫ

22 октябрьдә “Казан утлары” журналы редакциясендә тугандаш Башкортстанның күренекле шагыйре, “Агыйдел” журналының баш мөхәррире Сафуан Әлибаев белән очрашу булды. Үзара тәҗрибә уртаклашу рәвешендә үткән кызыклы әңгәмә барышында һәр ике тугандаш әдәбиятлар өчен файдалы фикерләр һәм тәкъдимнәр әйтелде.

### ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ КӨННӘРЕ

23-25 октябрь көннәрендә Кукмара районында һәм Киров өлкәсенең Нократ Аланы районында әдәбият-сәнгать көннәре булып узды. Ул күренекле балалар язучысы Ләбибә Ихсанованың—75, Татарстанның халык рәссамы Мәхмүт Усмановның 80 яшьлек юбилейлары уңаеннан оештырылган иде. Очрашуларда, юбилярлар белән бергә, Кукмара якташлык җәмгыяте президенты—профессор Ф. Галимуллин, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, каләм әһелләреннән М. Насыйбуллин, Ш. Мәксудова, В. Ихсанова, Р. Сибат, Г. Гыйльманов, Г. Морат, Р. Рахман, Ш. Хәлимова, Ш. Мостафин, М. Әһлиуллин, В. Галимов, композитор В. Усманов, җырчы И. Биктаһиров һ. б. катнашты.

### ҮЗ ШАГЫЙРЕН ОЛЫЛЫЙ ХАЛЫК

Татарстан Язучылар берлеге, Апас районы хакимияте һәм киң җәмәгатьчелек Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевның 70 яшьлек юбилеен зурлап билгеләп үтте. Әдипнең туган ягында—Апас районының Олы Бакырчы авылында уздырылган тантанада язучылардан Г. Ахунов, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Л. Сабирова, М. Гәрәев, Ф. Яхин, Г. Садә, рәссамнардан Э. Зарипов, Ф. Зыязов, җырчылардан Ф. Вәлиәхмәтов, И. Сафин һ. б. катнашты. Апаслылар Ш. Галиевка туган нигезендә—анын исемен йөрткән урамда яңа йорт та торгызып куйганнар. Бер үк вакытта бу бина

шагыйрьнең иҗат йорты-музее ролен дә үтәячәк. Хәзер бирелә танылган рәссам. Э. Зариповның шагыйрьгә һәм аның якташларына багышланган кырыктан артык рәсем-портреты урын алды.

* * *

23 ноябрьдә Ш. Галиевны башкалабызда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында хөрмәтләделәр.

### ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ САФЫНА

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 4 ноябрьдә үткән чираттагы утырышында авторларны берлеккә кабул итү коллегиясенең (рәисе—Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев) соңгы вакытта башкарган эшчәнлеге турындагы информация дә тыңланды. Коллегия тәгъдим иткән Локман Бадыйкшан, Хәлим Җәләй, Александр Архипов кандидатуралары утырышта хупланып, һәр өч авторга да Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы таныклыклары тапшырылды.

* * *

Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов җитәкләгән "Проза, драматургия һәм публицистика остаханәсе"нең чираттагы утырышында яшь галим-публицист, философия фәннәре докторы Айдар Юзиев һәм "Мирас" журналының баш мөхәррире урынбасары, прозаик Фирдәвес Зариф иҗат иткән әсәрләрне тикшерү булды. Соңыннан һәр ике автор да бертавыштан Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителделәр.

### ОЧРАШУЛАР

"Казан утлары"н алдыручы укучыларыбыз чакыруы буенча, журналыбызның бүлек мөхәррире—шагыйрь Рәдиф Гаташ һәм даими авторыбыз—өлкән әдип Әхсән Баян башкалабыздагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкертләре белән очраштылар. Кунаклар тыңлаучыларны "Казан утлары" журналында киләсе елда урын алачак кайбер әсәрләр белән таныштырдылар, аларга үзләренең иҗади эшләре турында сөйләделәр, шигырьләрен укыдылар.

* * *

Ноябрь башында журналыбызның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин Казан театр училищесы студентлары белән очрашып, аларны журнал эшчәнлеге белән таныштырды, яңа шигырьләрен сөйләде.

### ЮБИЛЕЙГА—ЯҢА КИТАП

Татарстан Республикасы Дәүләт архив хезмәтенең 80 еллык юбилеена багышлап, Татарстан китап нәшрияты "Мирсәет Солтангалиев. Сайланма хезмәтләр" китабын бастырып чыгарды. Китапның төзүчеләре—академик И. Таһиров житәкчелегендәге редакция шурасы—тарих фәннәре кандидаты М. Гыйззәтуллин һәм архивчы-тикшерүче Д. Шәрәфетдинов.

### ДОКТОРЛЫК ДИССЕРТАЦИЯЛӘРЕ ЯКЛАНДЫ

Соңгы вакытта республикабызда филология фәннәре докторлары саны тагын да арта төште. Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре—кульязмалар һәм текстология бүлегенең төркем җитәкчесе Марсель Әхмәтҗанов "Яңа археографик табышлар һәм аларны татар әдәбияты тарихын өйрәнүдә файдалану", "Мирас" журналының баш мөхәррире, Миннәхмәт Сәхапов "Г. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты", Казан дәүләт педагогика университетының рус әдәбияты кафедрасы доценты Альбина Саяпова "Дәрдмәнд һәм XX гасыр башы татар әдәбиятында символлар проблемасы", Казан дәүләт университетының татар журналистикасы кафедрасы доценты Васил Гарифуллин "Татар газеты текстының лингвостилистик системасы" дигән темаларга докторлык диссертацияләрен якладылар.

### КЕШЕ КИТӘ—ҖЫРЫ КАЛА

13 ноябрьдә, җомга көнне М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының төп җырчысы—Россия Федерациясенең атказанган, Татарстан Республикасының халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Хәйдәр Бигичев** кинәт вафат булды. Әле 50 яшен дә тутырырга өлгермәгән талантлы җырчы белән саубуллашу өчен 16 ноябрьдә опера-балет театры бинасына халык ташкыны агылды. Мәрхүм белән хушлашырга Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-Министры Р. Миннеханов, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, әдәбият-сәнгать әһелләре, күпсанлы дуслары, якыннары килде.

Мәшһүр җырчы башкалабызның Яңа бистә зиратында җирләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ТӨРКИ-ТАТАР ЕЛНАМӘСЕ

Әле Ислам кергәнче, мәҗүсилек заманнарында ук барлыкка килгән елнамә—12 цикллык календарьда һәр 12 ел нинди дә булса җәнлек, хайван, йә булмаса кош исеме белән атап йөртелә. Елларнын тәртибе мондый: 1—тычкан, 2—сыер, 3—барс, 4—куян, 5—аждаһа, 6—елан, 7—елкы, 8—куй, 9—маймыл, 10—тавык, 11—эт, 12—дунгыз.

Ел башы, ягъни Яна ел 21 мартта, төн белән көн тигезләшкән вакытта башланган. Ел 12 айдан торган һәм алар саннар белән йөртелгән. Биш 12 еллык исә 60 ел, хәзергечә әйтсәк, бер гасыр тәшкил иткән (милади белән исәпләгәндә без хәзер 34 гасырда яшибез).

Ел исеменә карап халык арасында анын сынамышы да таралган: барс елы—байлык, тычкан елы—баллык, сыер елы—туклык, куй елы—кытлык, куян елы—йотлык h.б.

XI йөз төрки галиме Мәхмүт Кашгари болай дип язган: *"Төркиләр бу елларнын һәр кайсында бер хикмәт бар дип уйлыйлар. Мәсәлән, аларча сыер елы керсә, сугыш күп була, чөнки сыер сөзешергә ярата торган хайван. Тавык елында азык-төлек күбәя, ләкин тынычсызлык арта, чөнки тавыкнын ризыгы ашлык бөртеге булып, шуны табып ашау өчен ул әйберләрне туздырып йөри... Дунгыз елы керсә, салкын, кар һәм фетнә күп була. Шул рәвешле һәр елга бер юрау кылалар"*.

Мәхмүт Кашгари, галим кеше буларак, безнен чор кешесе кебек үк ел атамаларына һәм аларнын юрамаларына беркадәр өстәнрәк караса да, әле XIV йөздә дә татар патшалары рәсми документларда һиҗрә белән бер рәттән төрки ел атамасын да күрсәткәннәр. Мәсәлән, Кыпчак дәүләте (17 йөздән Алтын Урда) солтаны Туктамыш ханнын Литва кенәзенә язылган хаты "795 ел һиҗрә белән, тавык елында язылды" дип тәмамланган.

Тышлыкта урнаштырылган календарь 1900—2007 елларны эченә ала. Элеккерәк, йә булмаса борынгырак чорларда булган нинди дә булса вакыйганын төрки-татар календаренын кайсы елга туры килүен ачыклау кыен түгел. Ул фәндә эшләнгән. Без файдалана торган ел исәбенен башы төрки-татар календаренын 10 нчы елына туры килә, ягъни миладинын беренче елы тавык елына туры килә. Шуна күрә шартлы рәвештә тавык елын миладинын беренче елы белән тәнгәл китереп 1 нче ел дип алалар:

1 (10)—тавык, 2 (11)—эт, 3 (12)—дунгыз, 4 (I)—тычкан h.б.

Миладинын нинди елын булса да 12 гә бүлгәннән сон барлыкка килгән бөтен сан—үткән чорнын тулы (12 еллык) циклларын, ә калдык исә төрки-татар календаренын әлеге шартлы санын күрсәтә. Мисал өчен, Казаннын басып алыну елы 1552. Аны 12 гә бүлгәннән сон мондый саннар чыга: 1552 : 12 = 129; калдыгы 4. Димәк, Казаннын алынуы шартлы 4 нче, ягъни тычкан елына туры килә икән.

Төрки-татар календаре үзенен төгәллеге белән аерылып торган. Һәр язгы олуг көннән икенчесенә кадәр чиратлашып килгән 30 һәм 31 көнлек 12 ай, 365 көнлек ел тәшкил иткән һәм ул бернинди буталчыклык та тудырмаган. Яна ел исә календарь буенча "яшь көн", ягъни яшь, яна язгы кояш белән башланып киткән.

Борынгы төрки-татар календаре теге яки бу халыктан алынмады микән дип фаразлау бик борынгы чорларга алып кереп китәр һәм анын әле кемнен кемнән алганлыгын ачыкларга кирәк булыр иде. Һәрхәлдә, моннан 12 мен еллар чамасы элек таш гасырда Беринг бугазы аша Америкага күчеп башка кабиләләр белән аралашып беткән бик борынгы төрки кабиләләр телендә "яшь кин", ягъни яшь, яна кояш атамасы булуы (ул майа календарендә сакланган), аларнын шул ук олуг көннән башланган календарь белән файдаланганлыклары турында фаразларга мөмкинлек бирә.

12 еллык төрки-татар календаре беренче карашка ай яки кояш белән бәйләнмәгән кебек тоелса да, ул нигездә галәмдәге йолдызлыклар системасы белән турыдан-туры бәйләнгән. Кояш үзенен 1 ел эчендәге әйләнешендә 12 зодиак (грекча "җәнлек") йолдызлыкларыннан (кыз, арыслан, кысла h.б.) үтә.

**Әзһәр МӨХӘММӘДИ,**
профессор

## "МӘГАРИФ" НӘШРИЯТЫ 1999 ЕЛДА




Татарстан Республикасы Милли нәшрияты "Мәгариф"—нигезе гасыр башында ук салынган шул исемдәге нәшриятның рухи дәвамчысы, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару үзәге. Аның яңадан торгызылып эшли башлавына да 7 ел булды.


Бүген "Мәгариф"—татар дөньясына мәгърифәт индерүче төп нәшрият. Ул елына йөзләгән исемдә ике миллионлап китап чыгара.

"Мәгариф" нәшрияты актив рәвештә татар теле һәм әдәбиятыннан өр-яңа дәреслекләр һәм уку әсбаплары эшләүнең дәүләт программасын тормышка ашыра. Аларның бер өлеше—рус телендә сөйләшүче балалар өчен чыгарыла.

Нәшриятның колачын һәм изге ниятләрен 1999 елда гамәлгә ашачак тематик планда да күрергә мөмкин. Иҗат перспективалары ифрат зур, киң. Ул—укучылар өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре, укыту-методик һәм педагогик әдәбият, ул—сүзлекләр, белешмәләр һәм матур әдәбият үрнәкләре. Нәшрият киләсе елда төрле профильдәге 100 дән артык китап бастырырга җыена. Шуларның егермеләбе матур әдәбият китабы. Дәрестән тыш уку өчен өстәмә әдәбият—классик мирас һәм бүгенге әдәбият үрнәкләре—"Мәгариф китапханәсе" дигән махсус сериядә чыгачак. Алар арасында Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, исән язучыларыбыздан И. Юзеев, Н. Фәттах, Т. Миңнуллин, Ш. Галиев, Р. Харис, Т. Галиуллин, Ф. Латыйфи, М. Хәбибуллин, Р. Мөхәммәдиев, М. Фәйзуллина, Р. Хафизова, Э. Шәрифуллина һ. б. ларның әсәрләре бар.

"Мәгариф" нәшриятының адресы:
Казан, Бауман ур., 19.
☎: 32-49-97; 32-11-90.

Индекс 73210




Әдәбият белгече Фоат Галимуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)